ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2010



# «КАЗАН УТЛАРЫ»
## 2010 елда тәкъдим итә

**ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ:**

**Мәдинә Маликова.** Нурзифа. *Роман;* **Рәмзия Габделхакова.** Тау артында кояш бар. *Роман;* **Марат Кәбиров.** Бердәнбер һәм кабатланмас. *Роман;* **Альберт Хәсәнов.** Данәгөл. *Роман;* **Әсгать Салах.** Үрләргә менгән чаклар. *Повесть;* **Айгөл Әхмәтгалиева.** Бәллүр богау. *Повесть.* һ.б.

**ШИГЪРИЯТ:**

**Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мирза, Лена Шагыйрьҗан, Клара Булатова, Илдус Гыйләҗев, Флера Гыйззәтуллина, Салисә Гәрәева, Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Луиза Янсуар, Ленар Шәех** һ.б. яңа шигырьләре, поэмалары.

**ПУБЛИЦИСТИКА:**

*Бөек Җиңүнең 65 еллыгы (фронтовик язучыларның хатлары, истәлекләре, әсәрләрдән өзекләр);* ТАССР төзелүгә 90, Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация игълан ителүгә 20 ел тулуга багышланган мәкаләләр, Россиядә халык исәбен алу уңаеннан аналитик язмалар.

**ФӘН ҺӘМ СӘНГАТЬ:**

**Җәүдәт Фәйзи**. Халык җырлары тарихыннан; **Адлер Тимергалин.** Тукай сүзлеге турында; **Әхтәм Зарипов.** Татар киносы: бүгенгесе һәм киләчәге; **Нурмөхәммәт Хисамов.** «Кыйссаи Йосыф» һ.б.

**ХӘТЕР:**

**Миркасыйм Госманов.** Күренекле шәхесләр турында истәлекләр;
**Мирсәй Әмир** Көндәлекләр.
**Җамал Вәлиди** мирасыннан.

*2010 елда шулай ук күренекле әдәбият-сәнгать әһелләренең юбилейлары уңаеннан мәкаләләр, «Әдәбиятлар дуслыгы—халыклар дуслыгы», «Тормыш язган хикәяләр», «Авылларыбыз тарихы», «Татар энциклопедиясе битләреннән» сәхифәләре дәвам итәчәк; әдәбиятыбыз елъязмасы булган «Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан», «Казан утлары» архивыннан» рубрикалары, юмор-сатира әсәрләре дөнья күрәчәк. «Ак җилкән» сәхифәсендә исә яшүсмерләрне мавыктыргыч повесть-хикәяләр, шигырьләр, кызыклы язмалар көтә.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2010

**1**
**(1047)**

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**
***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***Редакциянең хезмәт коллективы***

**НАШИРЕ:**
***«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
Факс—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

Рәфикъ ЮНЫС. «Бу—төкәнмәс көрәш!». .... 6

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Газинур МОРАТ. Яңа елда—ак карлар. .... 5
Фәнис ЯРУЛЛИН. Чиксезлекләрнең мин чигендә. *Шигырьләр*. .... 15
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Җәяүле сәйран. *Роман*. .... 20
Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Фикердәшләр, бергә берләшик тә... *Шигырьләр*. .... 53
Рашат НИЗАМИ. Сәйдәшнең соңгы елы. *Кыйсса*. .... 57
Рифә РАХМАН. Әзер калыпларга сыймас хис бу... *Шигырьләр*. .... 97
Рәзинә МӨХИЯР. Уян, халкым!.. *Шигырьләр*. .... 100
Камил КӘРИМОВ. Күрше авыл кызы. *Бәян*. .... 108

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Барлас КАМАЛОВ. Гомер кичендә. *Хикәя*. .... 103

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Миңзифа ТАҖЕТДИНОВА. Корьәннең Такташка тәэсире. .... 127

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Рафаэль МОСТАФИН. Туфанның кайтуы. .... 134
Рәшит ФАЗЛЫЕВ. Шаян талант. .... 137

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. .... 140
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. .... 143

**ЮБИЛЕЙЛАР**

«Татарстан яшьләре»нә 90 ел. .... 146
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Күңеленә дөнья сыйган. .... 166
Әсгать Салахка 75 яшь. .... 168

**СӘНГАТЬ**

Бату МУЛЮКОВ. Халыкның моңлы улы. .... 149

**ЮМОР–САТИРА**

Газинур МОРАТ. Ике икең биш була. .... 151
Безнең календарь. .... 169

**АК ҖИЛКӘН**

Илдус ХУЖИН. Яңа робинзоннар. *Хикәят*. .... 170
Алмаз ХӘМЗИН. Безнең дуслар мәктәптә! .... 180
Алсу НУРГАТИНА. Шигырьләр. .... 182

Тукайның мемориаль үзәген булдырыйк! .... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .... 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово редактора»: Р. ЮНУС «Это—борьба без конца и края!»
«Проза и поэзия»: роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Пешие прогулки» (прод.), ретро-описание Р. НИЗАМИ «Последний год Сайдаша», повесть К. КАРИМОВА «Девушка из соседнего села»; стихи Г. МУРАТ, Ф. ЯРУЛЛИНА, И. ГИЛЯЗОВА, Р. РАХМАН, Р. МУХИЯР.
«Из сокровищницы татарских рассказов»: Б. КАМАЛОВ. «На закате жизни».
«Литературная критика»: М. ТАЗЕТДИНОВА. «Влияние Корана на Такташ».
«Книжное обозрение»: Р. МУСТАФИН. «Возвращение Туфана»,
Р. ФАЗЛЫЕВ. «Талант озорной».
«История»: А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (прод).
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод).
«Искусство»: статья Б. МУЛЮКОВА о композиторе Дж. Файзи.
«Юмор-сатира»: Г. МУРАТ. «Дважды два будет пять».
«Белый парус»: И. ХУЗИН. «Новые робинзоны».
«Юбилеи»: 90 лет газете «Татарстан яшьләре»; статья Г. БАЙРАМОВОЙ к юбилею поэтессы Н. Измайловой.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Зимний пейзаж. Писатель-публицист Ильшат ВАЛИУЛЛА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Editorial»: R. YUNUS «This is a struggle without end!»
«Prose and poetry: novel by R. MIR-KHAYDAROV «Hiking» (continuation), retro-description by R. NIZAMI «Saidash's last year», story by K. KARIMOV «Girl from neighboring village»; poetry by G. MURAT, F. YARULLIN, I. GILAZOV, R. RAHMAN, R. MUHIYAR.
«From treasury of Tatar stories»: B. KAMALOV. «At the end of life.» «Literary criticism»: M. TAZETDINOVA. «Influence of Koran at Taktash».
«Book review»: R. MUSTAFIN. «Tufan's return»
R. FAZLYEV. «Talent mischievous».
«History»: A. KHALIKOV. «500 Russian surnames of Bulgar-Tatar origin» (continuation).
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
«Art»: article by B. MULUKOV about composer J. Faizi.
«Humor-satire»: G. MURAT. «Two and two is five.
«White Sail»: I. HUZIN. «New Robinsons».
«Jubilee»: 90th anniversary of newspaper «Tatarstan yashlyare»;
article by G. BAYRAMOVA to the anniversary of poetess N. Izmailova.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Winter landscape. Writer and publicist Ilshat VALIULLA.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 28.12.2009, график буенча 28.12.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–1981. Тираж 2959.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.

Газинур
Морат

# ЯҢА ЕЛДА—АК КАРЛАР

*Акча-акча карлар ява...*
Халык җырыннан

**Яңа еллар безгә**
**Акча-акча**
**Карлар яуган чакта киләдер.**
**Гомеркәйләр сыза барган саен,**
**Яшәү хакы арта нигәдер.**

**Гомеркәйләр сыза барган саен,**
**Гел үзгәрә тора бәяләр...**
**Ә хәрәмне зәм-зәм иткән заман**
**Хәләл хакын кайчан бәяләр?**

**Ә хәләлне хәмер иткән дәвер**
**Кайчан айнып килер тәүбәгә?..**
**Тәүбәсезләр түргә үрләгәндә**
**Гел кыйшая барыр түбәләр.**

**Тәүбәсезләр, төнге йөремсәк күк,**
**Ил башыннан йөрер, түбәдән...**
**Илдә яшәүләрнең хакын халык**
**Һәрчак яше белән түләгән.**

**Бәяң очсыз булса, табыла ул**
**Хак өстәүнең кырык хәйләсе.**
**Арта хакы гомер итүләрнең,**
**Төшә барса кеше бәясе.**

**Гомеркәйләр сыза барган саен,**
**Бәя үзгәрә гел нигәдер...**
**Яңа еллар безгә**
**Акча-акча**
**Карлар яуган чакта киләдер.**

# «БУ—ТӨКӘНМӘС КӨРӘШ!»

XXI гасыр башы 50—60нчы еллардан караганда әкияти бер заман булып тоела иде. Күп кенә фантастлар үзләренең әсәрләрендә ошбу елларны тасвирладылар. Коммунизм дигәнен дә инде 1980 елда ук төзеп бетерәсе идек ләбаса... Хәзер менә «кешелекнең якты хыялы» булган җәмгыятьнең 30 еллыгын каршылаячак идек бит без.

Берәр алдан күрүче, бу «әкияти» чорда заводлар эшсез калыр, капиталь ремонттан соң батарейларыгыздан су агып интектерәчәк, квартирга түләргә акча житкерә алмассыз, балаларыгызны институтка ришвәт түләп кенә кертерсез дисә, ышанучы табылыр иде микән?

Менә бу яңа елның беренче санындагы кереш мәкаләбездә ни турында язылырга тиеш иде? Авторларыбыз һәм укучыларыбыз ярдәмендә журналны тагын да яхшырту хакында, әлбәттә. Матбугатыбыз хакында. Әйе, бу турыда да сүз булыр. Ләкин әүвәл башка мәсьәләләргә кагылып алыйк. Чөнки татар вакытлы матбугатының хәле шактый мөшкел. Тиражлар кимегәннән-кими бара. «Казан утлары»ның киләсе елның беренче яртыеллыктагы тиражы 2009 елның шул чордагысыннан артыграк. Бу—асылда үзебезнең тырышлык нәтиҗәсе. Һәм әлеге сан 1990 елгыдан нык калыша. Вакытлы матбугатыбызның авыр хәле исә иң әүвәл милләтебезнең хәленә бәйле.

Бер ел элек мин журналда (2008, № 12) «Карабыбыз батып барганда» дигән мәкалә бастырган идем. Күңелне биләгән авыр гамь бу бер ел эчендә аз гына да кимемәде. Киресенчә, татар карабы һәлакәткә якыная гына төште.

Безнең өчен хәзер иң хәтәре—халкыбызның телсезләндерелүе. Хәтта Татарстанда да үги телгә әйләндерелгән татар теле дәүләт, җәмгыять эшләреннән генә түгел, инде фәннән, мәгърифәттән, хәтта ки тормыш-көнкүрештән дә зур тизлек белән кысрыклап чыгарыла. Кем тарафыннанмы? Иң әүвәл сүздә һәм Конституциядә халыкларның тигезлеген таныган, чынлыкта исә моның гел киресен гамәлгә ашырып яткан Рәсәй хакимнәре тарафыннан. Әмма моны, аклап булмаса да, күпмедер дәрәҗәдә аңлап була әле: алар, ничек кенә матур сайрамасыннар, асылда үзләрен ил-җирләрне яулап алу, халыкларны изү-сыту рухы белән сугарылган империя варислары итеп тоялардыр. Ә менә Татарстан хакимнәрен аклап та, аңлап та булмый. Автономия кысаларыннан баш тартып, суверен Татарстан статусын игълан итеп, аны референдумда бөтен Татарстан халкыннан раслатып, шуны Конституциябездә беркетеп, яуланганның төп өлешен Рәсәй белән уртак Шартнамәдә имзалый алган килеш тә шәлперәеп-мескенләнеп янә автономия аранына кереп бетә язуыбыз, яулап алынганнан соң тарих безгә нибары ике генә тапкыр биргән форсатның инде икенчесен дә ычкындыруыбызны ничекләр аңлап булсын ди, йә. Чигенүләр була аладыр ул, әйе, ләкин ахырына кадәр үк диярлек мөстәкыйльлегенне, шуна өстәп тагын мәгарифеңне, ягъни телеңне үк биреп чигенү кадәресе? Юкса телне һәм шактый дәрәҗәдә сәнгатьне дә саклау һәм үстерү, Хрущев коммунизм төзи башлаганга кадәр, автономия кысасында да мөмкин булган иде.

Ельцин хакимияттән киткәннән соң вәзгыять үзгәрде, кысу нык көчәйде бит, дияр кайберәүләр. Ләкин чигенү инде Ельцин вакытында ук, ни гаҗәп, безгә зур мөмкинлекләр биргән Шартнамәгә кул куелу белән диярлек башланган иде. «Ныгытып кысу»га килсәк, Идел—Урал Штаты (тарих биргән беренче форсат) төзелә алмыйча калган 1918 елдагы вәзгыять белән чагыштырырлыкмы соң аны?

Сөрген дә, төрмә дә, стенага терәп ату да янамый лабаса... Безнең чоргарак килик: 1957—60 елларда Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булган урыс Семен Игнатьев коммунистчыл заманда да, эштән алынырга мөмкин икәнен белгән килеш тә татар халкына игелекләр кылып өлгергән әнә. Бу—мәктәпләрдә татар теленең статусын күтәрү, Г. Тукай премиясе булдыру һ.б. *(Солтанбәков Б. Татарлар һәм Игнатьев.—К. Утлары, 2008, № 12).* Казан мунчасында бер урыс кешесе минем белән теттереп татарча сөйләште. Игнатьев чорының тере ядкәре булып чыкты ул. Хәзерге житәкчеләребез исә, шактый гына мөстәкыйльлек кулга кергән килеш тә, татар халкын халыкара хокукны һәм Татарстан Конституциясен генә түгел, Россия Федерациясенең үз Конституциясен бозып җәберләүгә дә юл куялар.

Монда мәсьәлә, бәлкем, курку-курыкмауга гына да кайтып калмыйдыр. Туксанынчы еллар башында, бигрәк тә референдум чорында президент М. Шәймиев тә, Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин да ин хәтәр мәлләрдә дә үзләрен кыю-тәвәккәл тотканнар иде. Чигенүләр Рәсәйдә капитализм төзи башлау һәм ашыгыч рәвештә миллионерлар-миллиардерлар ясау—«буржуйлар» сыйныфын хасил итүгә бәйле микән әллә? Олуг хакимнәр дә фәрештәләр түгел, адәм балалары гына икәнлекне күреп-тоеп торабыз лабаса.

Хәер, М. Рәхимов та һич фәрештә түгел. Башкортстанда татарларны кысу, башкорт санын татар исәбенә арттыру исә—начардан да начар, әшәке бер эштер. Әмма референдум да үткәрмәгән, Шартнамә дә төземәгән, мөстәкыйльлекне безгә караганда күп өлеш азрак алган республикада башкорт халкын саклап калу һәм үстерү беркайчан да истән чыкмый торган төп максатларның берсе икәнлеге дә чәчрәп күренеп тора бит.

Бездә исә милли төсмердән уттан курыккан кебек куркалар. «Милли чырае булмаган («без национальной окраски») республика» дип горурланып сөйлиләр. Ләкин хәтта автономияле республикалар да нәкъ менә шул милли төсмерне, республикага исем биргән халыкның милләт буларак ачылуын («чәчәк атуын») күздә тотып төзелгән ләбаса (стратегик максат бүтән булса да). Хәзер бу бер мәзәктә солдат балта пешергән кебек килеп чыга түгелме соң? Милли республика булуга таянып, өлкә-крайлардагыга караганда кабарынкырак идарә штаты, президент посты булдырыла да, майлы куе ботка пешеп житкәч, балта алып ташлана.

Дөньядагы барча татарларга милли егәр өстәп торырга, милләтне үстерергә-көчәйтергә тиешле *Татар*стан татарлар өчен каберстанга әйләнә бармасмы?.. Әйдәгез, «Казан утлары»нда ук басылган (2007, № 5) бер исталектән өзек укып китик әле. Элек Кытайда яшәгән Зифа Табиева болай дип язган: «Менә без, Голжадагы татарлар, чит илдә яшәсәк тә, шулай тату, халкыбызны, туган телебезне яратып, бердәмлек аны белән тырышып-тырмашып яшәгән, һаман алга омтылган идек... Казанга кайтырга кирәк, үз жиребездә үзебез булып яшик дип Казанга кайттык. Тик монда үз телендә сөйләшкән, үз тарихы белән якыннан кызыксынган, халкының киләчәген төптән уйлап кайгырган татар яшьләрен эзләп табарга кирәк икән. Әллә татар булып калыр өчен чит илләрдә яшәргә кирәк микән ул?»

Татар язмышына тәэсир итәрлек министрлыклар, комитетлар, шәһәр һәм район мәгариф бүлекләре һәм башка шундый мөһим урыннарда түрә булып кемнәр утыра? Татар кешесеме, әллә татар фамилиясе генәме? Берсеннән-берсе авыр вәзгыятьләр кичереп торганда берәрсенең «Җәмәгать, болай ярамый, бетәбез бит!» дип чаң сукканы булдымы? Кемдер, бәлкем, теләгәндер дә, ләкин татар республикасында татарны яклап сүз әйтү түрә өчен шактый хәтәр эш ул. Ә менә күрмәмешкә салышып тыныч кына эшли бирү—мөмкин. Хәтта әле астыртын-мыштым гына яки ачыктан-ачык диярлек татар тормышын урыс рельсларына күчерә бару, әйтик, татар мәктәпләрен һәм балалар бакчаларын аз-азлап яки кинәт тә урыслаштыру кебек эш-гамәлләр дә бик мөмкин. Татарстанда чиновниклар хәтта татар милләтен бетерүгә өлеш кертеп тә жинел-рәхәт гомер кичерә, карьера ясый алалар кебек. Һәрхәлдә, моның өчен хөкемгә тартылган, эшеннән алынган яисә шелтә-кисәтү генә булса да бирелгән бер генә чиновникны да белмим мин. Һәркайсыбыз күреп-белеп торганын мисалга китерим әле. Татарстанның дәүләт телләре турындагы законны бозган өчен тиеш булганча җавапка тарта башласалар, мондый эшләрнең

иге-чиге булмас иде. Бәлкем, зур-зур түрәләрдән башларга кирәк булыр иде әле. Әмма гап-гадие генә дә эшләнми бит. Әгәр дә күп чыгымнар тотып алыштырылган урам исеме такталарындагы хаталар айлар-еллар буе исән-имин чәчрәп тора ала икән, кемнәрдер бу эшкә чик куярга һәм гаеплеләрне җавапка тартырга тиештер бит инде. Әйтик, «*Жину* проспекты» өчен. Урамның бер өлешендә нәкъ шулай язылган! Реклама текстында испанча, итальянча яки идишта язылася сыңар сүз генә булса да, теләсә-каян сүзлекләрен эзләп табып, бер хатасыз язарлар иде. Монда исә Татарстан башкаласында ике дәүләт теленең берсендә дүрт хәрефле сүздә өч хата җибәрелгән! Ләкин моның өчен берәү дә кызармый-оялмый, күрәсең. (Тикшерә алмыйм, шуна күрә хаклыгын гарантияләмим, әмма мина Казан мэриясендә эшләүчеләр бүтән төрлерәк хаталар киткәндә оялалар дип әйттеләр. Мәсәлән, кигән күлмәгең мең доллардан арзанрак булганда.) Язучыга һәм эшне кабул итүчегә җәза бирелмичә, такталарны шулар исәбенә алыштырган хәлдә генә дә Казанда бүтән бер хата да җибәрелмәс иде дип уйлыйм мин. (Ә менә шәһәр транспортында яна тукталышларны ике телдә әйттерә башлаган өчен—рәхмәт).

Татар телен азмы-күпме белү ике дәүләт телле милли республикада һәрбер җитәкчегә фарыз булса, татар мәгарифенә, татар мәдәниятенә, татар матбугатына, тулаем татар халкы язмышына тәэсир итә алырлык җитәкче постларга билгеләнүче затлар, белгечлекләре буенча әзерлекле булудан тыш, татар телен шәп белергә, моннан тыш әле татар тарихын һәм халкыбызнын хәзерге хәлен дә белергә, милләт гамен үз итеп яшәргә тиешләр. Ләкин мондый таләп аларга бөтенләй куелмый булса кирәк. Гомумән, җитәкче постларга билгеләгәндә гел бүтән, без белмәгән мантыйк та кулланылмый микән? Берәүне, мәсәлән, бер редакциягә «яп-яраксыз» дип таптылар да, икенче редакциягә «яраттылар» әнә!

Газет-журналларны үзгәртү омтылышы көчле. Гаять четерекле нәрсә, сак булырга, традицияләрне өзмәскә кирәк. Югыйсә чуртан тотам дип чөкернәдән дә коры калуың бар—бу тираж җәһәтеннән, басманы «татарсызландырып», милләтне бетерүгә дә өлеш кертүең бар... Аннан, без хәзер талантлы, булдыклы татар журналистларының һәркайсын белергә һәм сакларга тиешбез. Журналистикага гына кагылмый бу, әлбәттә. Шундый бер чорга кердек ки, тиз арада гадәттән тыш чаралар күрмәгәндә, көчле милли кадрлар җитмәү үзен гел сиздереп торачак, шул сәбәпле мәдәниятнең бөтен тармакларында да артка китеш, чигенү башланачак. Бу әле—татар телен укытуга бәйле үзгәрешләрне искә алмаган килеш тә. Җитәкчеләрдән берәүләр, моны аңлап житкермичә, Сталин заманындагыча, алыштыра алмаслыклар юк ул дигән принцип буенча эш итсә, икенчеләренә милләт һәлакәт алдында торганда да шома-җилбәзәк язмалар тулы, ягъни караб батып барганны сиздермәскә тырышып халыкны уенчак музыка белән мавыктырган оркестр сыман газет-журналларны хуп күрсә, өченче берләренә исә татар матбугаты бөтенләй дә кирәкми, ул никадәр тизрәк тончыкса, шулкадәр шәбрәк бугай.

Кызганыч ки, бернинди басым ясалмаган килеш тә «тешсез» булып чыгып килгән татар басмалары шактый бездә. Һәм гомумән, Татарстанда матбугат иреге чикләнүгә иң әүвәл үз-үзләренә туктаусыз бармак изәп торган журналистлар һәм бигрәк тә баш мөхәррирләр гаепле түгел микән дигән шигем бар. Баш мөхәррирләр гаделлек хакына тәвәккәлгә барудан, эштән алынудан куркып дер калтырап торганда матбугат ирекле була алмый ул!

Татарстан президентының күп еллар элек әйткән, без матбугат ирегең кысу юлыннан бармабыз дигән сүзе бар. Һәм монарчы аны бозганы юк иде шикелле. Тискәре фактларны белеп тә житкермәскә мөмкинмен, ләкин унай фактларны китерә алам. «Ватаным Татарстан»да (Татарстан Дәүләт Советы һәм Министрлар Кабинеты газетасы!) 2004 елда Зөлфәт Хәкимнең «Ватансызлар вата Ватанымны» дигән «тешледән дә тешле» мәкаләсе басылып чыкты. Шуннан соң күпләр баш мөхәррир Минназыйм Сәфәров белән исәнләшергә дә куркып йөргәннәр. Әмма ул, шөкер, бер генә шелтә сүзе дә ишетмичә, үз урынында утыра бирә... «Казан утлары»нда да үткен-үткен мәкаләләр басылып тора. «Звезда Поволжья» газетасының ун ел буе исән-имин чыгып килүе дә шуны ук раслый дип беләм. Укучыдан гафу

үтенеп, үземнән дә бер мисал китерим әле. 2001 елны М. Шәймиев янә Татарстан президенты булып сайлангач басылды бу язмам. «Ватаным Татарстан»да М. Шәймиев турында фикеремне язып бирүне сораганнар иде. Мондый чакта гадәттә ин-ин җылы сүзләр генә әйтелә. Мин башта «Татарстан референдумы» дигән тарихи-публицистик хезмәтемне әзерләгәндә президентның «Идел»нен баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәй белән мине ничек шәп кабул итүе турында сөйләдем. Әңгәмә башында, ничектер хәйләкәр генә җаен табып, президент үзе мина өч сорау бирде. Беренче сорау мондый иде: «Мин ул чакта *(1992 ел)* Югары Совет председателе идемме әле?» «Юк, Сез президент булып 1991 елны сайландыгыз», дидем мин. Һәр өч сорауга дөрес җавап биргәч кенә президент минем белән ачылып бетеп, ихластан сөйләшә башлады... Бик шәп әңгәмәдәш иде ул. Кәгазьгә карамыйча бер сан да, бер генә төпле фикер дә әйтә алмаган кайбер олут түрәләр ише түгел. Язмамда шушы әңгәмә барышында туган тәэсирләремне бәян иткәч, президент турында гомуми унай фикеремне әйткәч, болай дип яздым: «Мин М. Шәймиевнен бөтен сәясәте, эш-гамәлләре белән дә килешеп бетә алмыйм. Милли университет мәсьәләсендә житди дәгъвам да бар. Әле телгә алынган китабымда *(«Татарстан референдумы»)* Президентка тәнкыйть сүзләре дә әйтелде. Ана тәнкыйть «Идел» журналында да басыла килә. Ләкин монын үзебез өчен шаукым-фәләнен беркайчан да сизмәдек тагын» (10 апрель саны). Редакциягә ультиматум куйдым: йә тулы килеш чыгарасыз, йә бөтенләй чыгармыйсыз!» Минем язма өстә ниндидер инстанция аша үтте, әлбәттә, ләкин кыскартылмыйча чыкты. Һәм бернинди зыян-зәүрәтен дә сизмәдем.

90нчы елларда Мәскәү журналистлары тәвәккәллек, кыюлык җәһәтеннән һәркайсыбызга үрнәк иде. Араларында А. Политковская, Д. Холодов кебек фидаи жаннар да бар иде. Ләкин бу чор үтте. Бер газета («Новая газета») һәм бер радиодан («Эхо Москвы») кала гаммәви мәгълүмат чараларынын барысы да диярлек хакимият астына кереп бетте бугай инде.

Бишме, алтымы ел элек Казанга Россия Телевидение академиясе президенты, матбугат ирегеn саклау комиссиясе рәисе Владимир Познер килде. Ул журналистлар белән дә очрашты. «Бу ирек нигә Мәскәүнен үзендә юк сон?» дигән сорау язып җибәрсәм дә, җавап алмадым. Алты еллап Америкада эшләп кайткан, демократиянен тәмен тәмам татып өлгергән бу телевидение йолдызынын үзенә дә авызын артык зур ачарга ирек бирмиләр иде шикелле. Ул 2001 елдан башлап беренче каналда алып барган «Времена» дигән иҗтимагый-сәяси ток-шоунын бердәнбер кыю урыны ин азакта әйтелгәләгән «Бүтән заманнар килер!» дигән сүзләр кебек тоела иде мина. Бераздан әлеге гыйбарәне дә ишетми башладык. 2008 елда исә бу бик тә олылап үткәрелә торган тапшыру туктатылып, күпмедер вакыттан аны «Познер» дигән, төн уртасында бара торган күп тыйнаграгы алыштырды.

Мәскәү журналистлары «Рус халкына куркыныч яный!», «Телебез бетә!» дип ара-тирә чан сугып куйгалыйлар. Без исә хәлебез мен өлеш авыррак булган, чын-чынлап һәлакәт алдында торган килеш тә моны һаман үзәк тема итә алмыйбыз әле. Төрле жанрларда, заманча әйтсәк, төрле форматта язарга кирәк. Иң әүвәл дәүләт житәкчеләребезгә тынгы бирмәскә, аларга гел ачы хакыйкатьне әйтеп, тормыш чынбарлыгын күрсәтеп торырга кирәк. Укымыйча яки укымаганга салышып калып булмаслык итеп! Курыкмыйк. Шундый хәлдә дә куркып тору, ипле-тәти журналист яки язучы булу яшәүме, үлемме дигәндә халкына үлем вариантын сайлау була бит ул. Аннан, без нигә куркырга тиеш ди әле? Явыз Иваннар, Сталиннарны Алла урынына күргән халыкка һич үтеп керә алмаса да, башка илләрдә бу ике икен дүрт кебек гап-гади бер хакыйкать инде: халык дәүләт өчен яшәми, дәүләт һәм анын бөтен түрәләре-түрәчекләре халыкка хезмәт итәргә тиеш. Татарстан житәкчеләре 1992 елны референдумда үзенә бөтенләй бүтән төрле язмыш сайлаган халык алдында җавап та тотарга тиеш әле. Аларның исә, бер генә тапкыр да, шул сәбәпле болай килеп чыкты бу дип анлатырга тырышып караганнары да булмады хәтта.

Татарстан Конституциясенен, татар халкы һәм Татарстан язмышына тәэсир итә алырлык законнарыбызнын үтәлеше җәһәтеннән министрлыклар һәм дәүләт комитетлары, район һәм шәһәр мәгариф бүлекләре, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, Казан «Горпечате» кебек оешмаларнын эшчәнлеген тикшереп чыгу зарур дип беләм...

Татар китабын һәлакәт чигенә житкерә язган сәбәпләрнең берсе—китап сатуның төзек системасы җимерелеп, китап кибетләренең хосусыйлаштырылуы. Монда кайбер дәрәҗәле кешеләрнең шәхси мәнфәгатьләре дә катышлы түгел микән дигән шигем бар... «Мәгариф» нәшриятының язмышы да хафаландыра...

Халкыбызга аның хәзерге аянычлы хәлен һәм аннан чыгу юлларын аңлаткан, аңга һәм хискә тәэсир итә торган, бәгырьгә үтеп керерлек язмалар әледән-әле басылып торырга тиештер ул.

Орган-фәлән булмаган, беркем алдында отчет тотмаган килеш тә әлеге төп, үзәк мәсьәләдән качыбрак көн күргән басмалар да бар. Аш—ашка, урыны башка дигәндәй, газет-журналларның төрлесе чыга бирсен. Ләкин «Акчарлак»ны «Кара чарлак»ка, «Уртак түшәк»не «Пычрак түшәк»кә әйләндерергә мөмкин чик үтелмәсен иде. Һәм алар тел бетсә үзләренең дә артып каласыларын истән чыгармасыннар иде. Мондый басмаларның тиражы ишәя хәзер. Әмма бу һич кенә дә шәплекне күрсәтми әле. Халык әнә сихәтле чәй дә, аракы да эчә (урыста «чай не водка, много не выпьешь» дигән сүз дә бар). Тираж—халыкка йогынты дигән сүз. Халыкның шактые хәзер бер, күп дигәндә ике басмага язылгачтын, бу йогынтының бер өлеше башка газет-журналлардан тартып алына, димәк. Бер басманы да гаепләргә теләмим, һәр кеше үзе нәтиҗә чыгарсын. Мин моның өчен ике пункттан торган бәһаләгеч кенә тәкъдим итәм. 1. Әгәр дә бу басма чыкмый башласа, татар халкы ни югалтыр? 2. Әгәр дә берәү үсмерчактан алып газет-журналлардан бары шунысын гына укыса, ул нинди кешегә әйләнер?

Журналда басылган роман турында бер газета аның «Казан утлары»нда басылганын әйтми генә язып чыгарасы иде. Әйтсәң, журналга реклама буласы икән! Юк, җәмәгать, безгә хәзер посып-бикләнеп яшәү турында түгел, киресенчә, мөмкин кадәр ярдәм итешеп, бергә-бергә исән калу һәм халкыбызны исән калдыру турында уйларга кирәк!.. Тагын әле бер-береннән әйберсен укып бару да җитми. Шәп әсәре яки мәкаләсе турында кешегә җылы сүз әйтү дигәне исә ана кесәннән акча чыгарып бирүдән дә авыррак бугай әле!.. Һәм... көчле, булдыклы, тәвәккәл баш мөхәррирләребезне, журналистларыбызны саклыйсы иде бит. Аларның нәкъ менә шундыйларыннан (шәп милли кадрлар кимегәннән-кими барган бер мәлдә!) котылырга теләүчеләр булуы ихтимал.

Газет-журналларыбыз яшь буынны тәрбияләүгә үтә зур әһәмият бирергә, моны татар әхлагына, шулай ук, бәлки, совет чорының да иң шәп традицияләренә таянып, махсус план төзеп, системалы рәвештә алып барырга тиештер. Юкса бүтән төрле планнар төзелә, балаларыбыз һәм яшьләребезне бүтән «кыйбла»ларга юнәлтү максат ителә кебек. Мондый шик миндә 5—6 еллар элек маршруты Ямашев урамы аша үткән трамвайга утыргач туды. Өр-яңа бу вагонның түшәме трамвай йөртүче кабинасына 3—4 метр кала 15ләп сантиметрга биегәеп китә. Шул урында хасил булган тар турыпочмаклыктан безгә менә мондый сүзләр дәшеп тора: «Не уступай хорошее место». Язу шәп дизайн белән, пыяла эченә кертеп, заводта эшләнгән. Өлкән яшьтәгеләргә, инвалидларга, балалы хатыннарга урын бирергә тиешлеген сендереп үскән завод җитәкчеләре үзләре генә мондый эшкә тәвәккәлли алырлар идеме икән? Юк! Мондый фәрманны Мәскәүдән дә теләсә кем бирә алмый әле. Бу бары дәүләт идеологлары белән килештерелгән гамәл генә була ала. Максат—эгоизм, индивидуализм кебек сыйфатларны сендергән яңа тип, капиталистчыл яшь буын тәрбияләү. (Шөкер, Казан транспортчылары моңа күнмәгәннәр. Кабина ишегендә кемнәргә урын бирелергә тиешлеген санап чыккан язу бар иде.) Шунда үземне тетрәндергән икенче бер хәл исемә төште. Телевизор карап утырам. Анда ничектер (мина гына «ничектер» инде, бар да алдан уйланылган, әлбәттә) луата (ирләрнең ирләр белән якынлык кылуы) турында сүз чыкты. Үзәк каналда иң популяр тапшыруларның берсен алып баручы иптәш шул чакны ике сүз әйтте. Ике генә, ләкин—телевизор караган яшьләр, үсмерләрне шушы кабәхәт юлга бастыру максат ителгәндә иң көчле сүзләр иде бу. «Это модно!» диде ул. Мин бу адәмне шуннан соң телевидениегә аяк бастырмаслар дип уйлаган идем. Әле һаман эшли! Югары даирәләрдә таянып кешеләр бар, димәк!

Безгә хәзер балаларыбызны ничек тә булса заманның наркомания кебек пычрак чирләреннән, әхлаксызлыктан аралап калырга кирәк. Ныклы каршы тору

көче, жирәнү хисе—иммунитет тәрбияләргә кирәк. Моны татар әхлагына, ислам кануннарына таянып эшләп була. Татар мәктәпләре дә үзенә күрә бер иминлек утраулары кебек. «Иде» дип өстәргә тиеш булабызмы инде хәзер?

Әти, әни, әби, бабай булу—үтә җаваплы һәм үтә авыр вазифалар ул. Бигрәк тә менә мондый, татар өчен гаять четерекле заманда. Авырлыгы тоела, карвалол, валидоллар эчеләдер ансы. Ләкин белемсез-мәгълүматсыз килеш, баланның нинди дөньяда яшәгәнен, аны кайсы юлга кертеп җибәрергә теләгәннәрен, шуннан китеп барса ниләр буласын белмәгән-чамаламаган килеш без балаларыбызга игелек кылучылар түгел, аларны каһәрле язмышка дучар итүчеләр була алабыз бит. 90нчы елларда күпме бала, нигә мине татарчага өйрәтмәдегез дип, әти-әниләренә дәгъва белдерде әнә. Чыннан да, баланы ул яралу белән барлыкка килгән хакыннан—әти-әниләре, әби-бабаларыча сөйләшеп, укып-язып, җырлап-биеп яшәү хокукыннан мәхрүм итү бала алдында һәм Ходай Тәгалә алдында (халык-кавемнәр тикмәгә генә барлыкка килмәгән ләбаса) җинаять кылу түгелме соң? Баланы әти-әниләренә бүген отышлы булып күренгән чит юлга кертеп җибәрү аның борынгылыкка, күп бәла-казалардан саклый алачак куәткә тоташкан нәсел тамырларын имгәтү була бит ул! (Татар теле арта алса, чит илләрдә артыр иде, анда яшәүче милләттәшләребез кадерләп буыннан-буынга тапшырмаслар иде аны). Аннан, өлкәннәрнең үзләренә ни булып кайтыр соң бу? Заманның пычрак һәм хәтәр чирләрен урап үтә алган хәлдә дә, чит телдә сөйләшеп, ят җырлар җырлап, ят гадәтләрне (һәм гадәтсезлекләрне) сеңдереп үскән бала өчен әти-әнисе, әби-бабасы кадерле, газиз булырлармы? Картаймыш көннәрендә үз өйләрендә үк артык җан булып калмаслармы алар? Нигытып, тиреннәнрәк уйлансаң, бу уйлар сине һичшиксез суверенитет-мөстәкыйльлек, милли хәрәкәт кебек мәсьәләләргә китереп чыгарыр. Әгәр дә син ил эчендә ни дә булса эшләргә сәләтсез, ягъни агым уңаена гына йөзә алучы икән, өй эчендә булса да эшлә. Баланны чит-ятлар баласы түгел, нәсел-нәсәбенә ялганган үз балаң итеп үстер.

Унбиш еллап элек, Татарстан Язучылар берлегенең идарәсен сайлаганда, кемдер аның балалары татарча сөйләшми дигәч, халык бер агайга каршы тавыш биргән иде. Хәзер балалары татарча белми торган язучылар, галимнәр, журналистлар, сәнгать әһелләренең исемлеген төзесәң, «картинкә» нинди булыр иде икән? Сәхнәдә оныгы Нариман белән бергәләп җырлаган Рафаил Сәхәбидән үрнәк алыйк, җәмәгать!

Бик аз өлешен санамаганда, шушы гаять хәтәр мәлдә дә, карабыбыз батып барганда да зыялыларыбызның тавыш-тыны бик ишетелми. Гади халыкны гафу итеп була әле, алар күп нәрсәне аңлап җиткермәскә мөмкин, әмма бөтен нәрсәне дә белгән һәм шактые татар теле, татар фәне, татар сәнгате исәбеннән туенган кешеләрнең битарафлыгын ничекләр аңламак кирәк? Сораганда, төрле сәбәпләр әйтелә ансы. Ләкин әтисе яки әнисе авыр хәлдә булганда да кайтмаган, берничек тә ярдәм итмәгән бәндәләр дә акланырга сылтау табалар бит ул... (Бер мөхтәрәм авторыбыз, 37нче еллар, шул чактагы әләк-сатулар турында сүз кузгатылгач, янә шундый заман килсә, сатучылар күбрәк тә булыр әле дип шаккатырган иде... Бәлки, шаккатасы юктыр да?) Без мондыйларны берни дә эшләтә алмыйбыз, ләкин алар үзләренең кемлекләрен белеп яшәсеннәр.

Мәкальгә тиң җыр сүзләрен үзгәртеп, «Халыклардан халык һич ким түгел, тик бәхеткәйләре тиң түгел» рәвешендә елаучы-сыктаучыларны гаепли алмыйм мин, ләкин... Шәхесләр кирәк, түрәләр яки байлар кубызына биемичә, халык һәм хаклык хакына тәгаен, чын эш эшләүчеләр кирәк. 1992 елны безнең референдумны буарга дип Мәскәүдән прокурорлар бригадасы килеп төшкәч, карьера-фәләннәрен уйламыйча арага стена булып баскан Татарстан прокуроры урынбасары Марсель Мусин, Казан прокуроры мәрхүм Сәйфихан Нәфиев кебекләр. Үзе җитәкчелек иткән Казан Компрессорлар заводын беренче булып Татарстан карамагына күчергән һәм мондый предприятиеләр саны 2 процентган 92 процентка җитүнең төп сәбәпчеләреннән булган Әхмәт Галиев, бәгыреннән чыгарып диярлек «Сәләт» лагерын тудырган һәм озак еллар буена аны исән-имин яшәтә алган Җәүдәт Сөләймановлар да халкыбызның олы ихтирамына лаек.

Казан ханлыгы яулап алынгач, татар халкын халык буларак иң әүвәл ислам дине һәм муллаларыбыз саклап калган. Хәзрәтләребез рухи идеологлар да, еш кына

үлемнен күзенә карап, чукындыруга каршы торуны оештыручылар да, мәгариф системасын коручылар һәм мөгаллимнәр дә булганнар. Хәзер Татарстанда 1300ләп мәчет һәм биш меңләп мулла бар икән. Бик тә олы көч ләбаса бу! Тик... кайда ул көч, нигә сизмибез соң без аны?

Үтә четерекле мәсьәлә бу, әмма аны күтәрер вакыт житкәндер инде. Әйтергә хакым бар дип уйлаганнарны гына әйтәм, ялгышсам, төзәтсеннәр. Үз вазифаларын ихластан һәм жиренә житкереп үтәгән, халкыбыз гамен үз гаме иткән асыл хәзрәтләребез, бәлкем, күптер ул. Ләкин башкалары да бар бугай бит. Илаһи якны да кайгырту һәм фани яктан да үтә өлгер булу, иномаркаларда жилдерү бергә сыеша ала микән ул? Минем бу исәррәк башка кайчакны, их, хәзрәтләребезгә аттестация үткәрсән, әүвәл керемнәре, мал-мөлкәтләре турында декларация тутыртсаң иде дигән дуамал бер уй килә. Тагын да дуамалрагы да килгәли әле. Дога укыганда алларына ялган детекторы куеп, ачыкларга иде дим: ихластан укыйлармы, әллә «сәдака» атлы финанс операциясе үткәрәләрме икән? Аннан, бусы, бәлкем, дөрес тә түгелдер, әмма киенүләре дә ошап житми. Генераллар күк басып тора хәзрәтләребез! Орден-медальләре генә юк. Кайберләренең йөзенә дә генерал тәкәбберлеге чыга әле. Арада шамакайга ошаганнары да бар. Православие руханилары да шулай купшы киенә (католик руханиларның киеме күп тыйнаграк), ләкин алар динендә поплар—Аллаһы Тәгалә белән адәм балалары арасындагы олуг затлар, арадашчылар санала. Ислам динендә арадашчылар юк лабаса.

Мин Нурихан Фәттахның журналыбызда чыккан истәлекләрендәге мулла абзыйны һич оныта алмыйм. Әдип менә нинди сүзләр белән тасвирлый бу авыл мулласын: «Ягымлы, әдәпле һәм тыйнак кеше». «Йөзе һәрвакыт йомшак, ягымлы нур бөркеп торган күзләре. Тавышы шулай ук йомшак, ягымлы». «Ягымлы, тәрбияле, киң күңелле, аңлы, белемле». *(Беренче шигырь күк балачак... 2008, № 11. 106—108 б.)* Жанга менә шулай йөзләреннән нур бөркелеп торган хәзрәтләр тансык шул. Киеме, машинасы түгел, күңеле шәпләр тансык.

Күп кенә муллаларыбызның, гыйлем кеше булуларын күрсәтергә теләпме, урыс сүзләре кыстырып сөйләве бик тә ачуны китерә. Чукындыручылар теле катыштырылгач, гыйбадәткә көфер сүз килеп кергән кебек була. Яртылаш яки тулаем урысча вәгазь сөйләүләре исә тәмам шаккатыра. Айдар Хәлимнең «Имамнарга вәгазьне бары урыс телендә генә укырга кушылган» дигән сүзенә *(Пожалуйте нам айсберг.—Зв. Поволжья, 2009, № 42)* ышанып бетә алмыйм. Ләкин бу хәл миңа Нажар Нәжминең 1968 елны (№ 4) «Казан утлары»нда басылган мәшһүр «Татар теле» дигән шигыренең кайбер юлларын искә төшерде:

*Ассалар да, киссәләр дә*
*Үлмәдең син, калдың тере.*
*Чукындырган чагында да*
*Чукынмадың, татар теле.*

Баскынчы поплар эшләп житкермәгәнне үз муллаларыбыз эшләп ятамени инде хәзер?

Гарәбстанда укып кайткан яшь хәзрәтләрнең авылга бармаулары (сәдака аз!), Казанда өлешеп ятулары да гажәпләндерә. Христиан миссионерлары чит-ят халыклар арасында да, шәрә утрауларда да эшләгәннәр әнә... Муллалыкка укырга ин белемле, иң сәләтле, саф күңелле яшьләрне жибәрәсе иде бит. Киләчәктә алар алтын бәһасе торырлар иде!

Безгә хәзер бик тә, бик тә үтә популяр шәп жырлар кирәк. Кайда безнен композиторларыбыз?..

Республика милли чырайсыз калмас ул. Тормыш үзгәрмәсә, ягъни, үзгәртә алмасак, Казан күгеннән берөзлексез урыс чырае карап торачак. Татар каласы булып туган һәм баштагы 547 елында саф татар каласы булып яшәгән *Татар*стан башкаласының меңьеллыгын шул телдә бәйрәм иткән төндәге кебек.

Юк, бу милләттән булган республикадашларыбыз турында бер генә начар сүз дә әйтәсем килми минем. Дүрт ярым гасыр элек баштан кичкән хәлләр өчен хәзерге урысларга ачу саклап йөрү—ахмак һәм яман бер эштер. Безгә татулыкның кадерен белергә кирәк. Алар тегенди, алар мондый дип гаеп эзләү гадәтебез бар. Кайбер нәрсәләрне,

әйе, алардан йоктырганбыз. Мәсәлән, эчкечелекне. Ләкин башта ничә гасыр буена йоктырмаганбыз бит әле, әхлагыбыз-иманыбыз какшагач кына бирешкәнбез. Инде урысларнын үзләрен дә уздырып лыкынабыз! Бер танышымнын классташы Савинодагы янгыр канавында батып үлгән әнә. Күп булса ике көрәк тирәнлеге суда!

Урыслар аз-азлап үз тормышларын көйли башлады бугай алар. Дингә дә кайтып баралар шикелле. Ун еллап бер мунчада юынган кеше буларак, күрәм: тәре тагып йөрүчеләре дә артканнан-арта бара. Кырыктан узганнары арасында такмаганнары берән-сәрән генә диярлек хәзер.

Милли мәсьәләдә урыслар безне аңлап житкерми, әйе. «Кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә» дигәнне халыкларга карата да әйтеп була. Балтыйк буе илләрендәге милләттәшләре тел-мәгариф мәсьәләсендә бераз гына кысылуга, «өлкән агай» ихластан рәнжеп, нәкъ без сөйләгән сүзләрне сөйли башлады әнә!

Тату яшибез, әйе, ләкин бер-беребезгә ихтирамлы сабыр мөнәсәбәт, ягъни толерантлык дигән нәрсә бездә, аеруча түрәләребездә, кайчакта «толярантлык-колярантлык»ка—«өлкән» милләт алдындагы, канга тирән сеңгән мескенлекнең заманча чагылышына әйләнә дә кала...

Кыскасы, гаепне башкалар өстенә шудырып төшермәскә, үзебезгә ныгытып торып эшләргә, көрәшергә кирәк.

Көрәш дигәннән, милли хәрәкәтебез таркатылды, аерым көрәшче затларыбыз хокук саклау органнары тарафыннан туктаусыз куркытыла, «эш» арты «эш» ачылып кына тора. Шул рәвешле бераз булса да милли рухка ия барча татар кешеләрен өнсез калдырырга, «стерильләштерергә» уйлыйлар булса кирәк. Ләкин татарның эчке, потенциаль егәре барыбер зур. 90нчы еллар «киләчәк фондына» ниләр салып калдырганын бер күрербез әле. Заманалар да гел болай гына бармас ул. Тимер-бетон нигездә торган кебек тоелган коммунистчыл режим ничек тиз жимерелеп төште әнә!

2010 елда Татарстан АССР төзелүгә—90 ел (27 майда), Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация игълан ителүгә 20 ел (30 августта) тула. Уйланыр, үткәннән киләчәккә күз ташлар, планнар билгеләр өчен бик әйбәт форсат бу. Октябрьдә исә гаять авыр сынау көтә: Рәсәйдә халык исәбен алу үткәреләчәк. Монда *без күпме* дигән сорауга гына түгел: *без нинди халык* дигәненә дә шактый дәрәжәдә жавап алыначак. Бу тарихи вакыйгалар барысы да журналыбызда шәп чагылыш табар.

Уйга салган нәрсәләр күп инде ул. Публицист каләме әйтеп житкерә алмаганны, бәлкем, шигъри каләмем әйтеп бирер?

## ЧИГЕНӘБЕЗ, ӘММА...

**Жыңеләбез, әйе, чигенәбез.**
**Чигенәбез.**
**Инде сафлардан**
**Шыбыр-шыбыр коела ыбыр-чыбыр.**
**Качасыңмы син дә, каһарман?**

**«Көч—булмаган, кылыч сынык,—дисең.—**
**Каберташтай баскан илбасар».**
**Чирүебез[1], әйе, чирле безнең—**
**Тәпәләнгән дүрт ярым гасыр.**

**Меңнәр безне әзер өзгәләргә,**
**Яклап колбасалы коллыкны.**
**Йә, елыйкмы утырып?**
**Тынычланып,**
**Таш астында жәсәд[2] булыйкмы?**

---
[1] Чирү – гаскәр.

[2] Жәсәд – мәет.

Ялгышларны күзгә төртсәләр дә,
Алкышлар юк. Кем алкышласын?
Алкыш—эшләнгән эш.
Бары кулны,
Бары телне богау кысмасын...

Тирең сөрт тә—эшлә. Тагын эшлә.
Эшлә һәм—көт. Эшлә һәм—чыда.
Халык күрми икән, балык күрер:
Юкка чыкмый эзсез тамчы да.

«Халык бит юк»,—дисең.
Әйе, аны
Берәмтекләп әле җыясы;
Мәңгетуңнан, казып сөңге белән,
Чыгарасы татар кояшын.

«Арттагылар нигә тарау?»—дисең.
Син, алдагы, кара үзеңә.
Түгел, түгел көрәш кызулыгы—
Хәмер кызыллыгы йөзеңдә.

Аермыйкчы эзләп гел аерма—
Канат каеручы җитәрлек.
Җилем кирәк бүген, җилем кирәк—
Җиде җилне давыл итәрлек.

Җиңү өчен кирәк бергә җыгу
(Җиңелүләр, шөкер, өйрәтте!)—
Ташны тишкән тамчы түземлеген,
Елан аклын, яшен гайрәтен...

«Көрәш!», «Милләт!» дидек шигырьдә без.
Биек иде безнең каланча!
Инде сайлыйк: ни килешер безгә?
Кол чикмәне, әллә... япанча?..

Җиңеләбез, ләкин—җиңдермичә,
Тез чүктермичә җанны, вөҗданны.
Бер исән кул калса, байрак итеп
Шул күтәрер уртак иманны.

Бу төкәнмәс көрәш—җиңүгәчә.
Көчсезлекләр көчкә тоташа.
Саф арты саф, дулкын арты дулкын—
Бабайлардан оныкларгача...

Җиңеләбез. Сафлар түгләп ага,
Ләкин бетмәс барыбер түгелеп.
Әйе, мин дә бүген—җиңелүче.
Шөкер, хыянәтче түгелмен.

**Рәфикъ ЮНЫС,**
*«Казан утлары» журналының*
*баш мөхәррир урынбасары.*
*2009 ел, 25 декабрь.*



Фәнис
Яруллин

# ЧИКСЕЗЛЕКЛӘРНЕҢ МИН ЧИГЕНДӘ

## Милләтемнең йөз аклыгы

**Ходай миңа озын гомер биргән**
**Һәм эшне дә биргән гомерлек.**
**Төннәремне көннәр белән үрәм,**
**Юкса булмый һич тә өлгереп.**

**Сүзләр белән сүзне тоташтырам,**
**Фикер белән кушам фикерне.**
**Шыксыз күңелләргә чәчәк сибәм,**
**Чәчәкләрем минем мең төрле.**

**Гамьсезләргә гамьнәр биреп китәм,**
**Уйлар табыша бит хаклыкны.**
**Хаклыгыңны күрсәтергә мөмкин**
**Тик уятып кына халыкны.**

**Хакыйкатьне бездән яшерер өчен**
**Бәйләп карадылар күзләрне.**
**Тик булмады. Күзне бәйләүчеләр**
**Сукырайды бары үзләре.**

**Телебезне кат-кат киссәләр дә**
**Үсеп чыга торды телебез:**
**Тамырыбыз бик тә тирән киткән,**
**Корый торган агач түгел без.**

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938) — *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист; күпсанлы китаплар («Тозлы җил», «Серле дөнья», «Пьесалар» һ. б.), шул исәптән 5 һәм 3 томлык «Сайланма әсәрләр» (2004 һәм 2007—08 еллар) авторы. Казанда яши.*

Шагыйрьләре, җырчылары барда
Теле бетәмени халыкның?
Җыры, моңы, данлы үткән юлы—
Сакчылары бит ул халыкның.

Ходай миңа озын гомер биргән,
Бер сакчысы иткән хаклыкның.
Җырың-моңың аша күрсәт, дигән
Милләтеңнең йөзе аклыгын.

***

Кулда каләм. Алда кәгазь.
Ак хыяллар күңелдә.
Хыял атының яллары
Сибелә йолдыз җилендә.

Кешни атым. Аның тавышы
Китә ерак-еракка.
Уйсызларны уйландыра,
Гамьсезләрне уята.

Чаба атым бер йолдыздан
Бер йолдызга сикереп.
Тоягыннан очкан утлар
Кала күккә сибелеп.

Чиксезлекләрнең чигендә
Бераз сулыш ала да—
Күкләрнең зәңгәрлегендә
Эреп тагын югала.

Яшем арта барган саен
Җаным тарта биеккә:
Күкне җиргә бәйләп йөрим
Шигырем белән бер җепкә.

## Бара кеше

*Яшь гомерне үтә диләр,*
*Үткәнен күрсәң иде.*
*Үткән чакта тотып алып*
*Кирәген бирсәң иде.*

Халык җыры.

Үтсен, әйдә, үтсен яшь гомерләр,
Елга елга түгел акмаса.
Бер халәттә торып калыр идек
Тормыш дулкыннары какмаса.

Йөрәкләрне ярып кермәс иде
Югалтулар, ачы сагышлар.
Булмас иде бик күп үкенечләр,
Булмас иде бик күп ялгышлар.

Без шатлана белмәс идек хәтта—
Кайгы-хәсрәтләрне күрмәсәк.
Сагынырга нәрсә калыр иде—
Яшьлекне без
Хәтер төпләренә күммәсәк?

Бөтенесе кирәк кешеләргә
Үсәр өчен ныклы Ир булып.
Сыналабыз чорлар давылында
Төшмәс өчен сынып-сыгылып.

Ә яшьлек ул сагыныр өчен генә,
Яшәр өчен акыл, көч кирәк.
Үз биеклегенә менә кеше
Савап, гөнаһларын өстерәп...

## Көтеп алам

Һәр яңа көн сабый бала кебек,
Елый, көлә—әйтми сәбәбен.
Тынычланды дигәч, дулап ала
Яки куя үзенең таләбен.

Йөгерәсең шуны үтәр өчен,
Кичәге уй бүген ярамый.
Сабый холкы бик тиз үзгәрүчән,
Яңа уен сорый, яңа сый.

Уйланасың, башың эшләтәсең
Үтәр өчен сабый таләбен.
Үтәмәсәң иртәгегә кала
Бүген эшләячәк гамәлең.

Иртәгесен нинди сабый туар,
Нинди булыр холкы-фигыле?!
Шундый уйлар, шул борчулар белән
Көтеп алам туар һәр көнне.

## Тәүбә итәргә дә вакыт калмый

Буталышып беткән күңелләрдә
Буяуларның агы-карасы.
Якынайды, артык якынайды
Гөнаһ белән савап арасы.

Бара кеше язмыш сызган юлдан,
Ләкин белми—дөрес барамы?
Көтмәгәндә упкыннарга төшә,
Урап үтә биек тауларны.

Йә салкыннар куырып ала аны,
Яки өтә кайнар кояшы.
Кешеләрне сынар өчен шулай
Корылгандыр, ахры, дөньясы.

Кайнар чүлдә сусап барган чакта
Күренеп китсә нәни бер чишмә,—
Үз юлыннан борыла да кеше
Сөенә-сөенә ятып су эчә.

Эчеп кенә калмый, чишенеп ташлап
Рәхәтләнеп анда коена.
Бу минутта аңа салкын чишмә
Җәннәт кебек булып тоела.

Шунда аның аңы ачылып китә,
Аһ, каһәре—ул бит ураза!
Барыр иде, түзгән булыр иде,
Чүлдә әгәр чишмә булмаса.

Тәүбә итеп тагын юлга чыга
Һәм еракта күрә бер алтын:
Йөгерә ул шунда бар көченә
Карамыйча алдын һәм артын.

Уйламый һич иблис эше диеп
Салкын чишмә, алтын тәңкәне.
Алда тагын нәрсә табылыр икән?—
Шунда аның хәзер бар гаме.

Кыйммәт нәрсә юлда гына ятмый,
Кеше анда, монда сугыла.
Әнә шулай, сизелмичә генә
Язмыш сызган юлың җуела.

Гөнаһ турындагы уйларың да
Хәтер төпләренә күмелә.
Тәүбә итәргә дә вакыт калмый,
Гомер кылы шартлап өзелә...

## Күңелемдә ята күп роман

Күңелемдә күпме вакыйгалар!—
Ничә романнарга җитәрлек.
Кулда каләм, алда кәгазь ята,
Язар идем, җитми җегәрлек.

Яшь гашыйклар сере яна эчтә,
Бу серләрне ничек сакларга?
Сер капчыгын чишеп җибәрүгә
Исемнәре беленер ятларга.

Мәхәббәтнең булмый нindиләре?—
Гөнаһлысы, сафы—керсезе.
Яп-яшь җаннар яна мәхәббәттә
Кем парлашып, кемдер берүзе.

Килә кызлар серен ачар өчен,
Бер бушанып калыр өчен дә.
Юатучы түгел, сүзсез генә
Тыңлаучы да кирәк кешегә.

Гашыйкларның сүзен тыңлаганда
Алар белән бергә мин янам.
Күңелемә ничек сыйдырырга?
Һәр мәхәббәт үзе бер роман.

* * *

Ташлап китте чибәрлек,
Ташлап китте егәрлек.
Иң-иң тугры дустым булып
Калды бары юләрлек.
Шул юләрлек һаман мине
Кызларга гашыйк итә.
Чибәр кызлар күрсәм һаман
Йөрәкләр ярсып китә.

Арбам бар да—атым юк,
Сөяр өчен хакым юк.
Төкерәмен барсына да—
Юләрләргә закон юк.

## Урлап китәрмен әле

Алай итәрмен әле,
Болай итәрмен әле;
Төнлә юрганыңа төреп,
Урлап китәрмен әле.

Очарбыз караңгы төндә
Мәхәббәт атавына.
Төшәрбез кайнар диңгезнең
Иң тирән катламына.

Төн белән көннәр кушылыр,
Тукталып калыр Вакыт.
Кайнар диңгезнең төбеннән
Чәчәкләр чыгар калкып.

Калырбыз шаулы диңгездә
Йөгерек дулкын булып:
Яшәрбез тынгы белмәүче
Ирекле межкын булып.

* * *

Чиновникның ишеге калын була,
Ул ишекне тора эт саклап.
Кабинетта—«утырыш»: карт чиновник
Сөяркәсен утыра кочаклап.

* * *

Ничек яшимендер, гәүдәм хәзер
Тора бары бер уч сөяктән.
Күптән бетәр идем, илаһи көч
Агылмаса әгәр йөрәктән.

* * *

Кайчак дәрт тотып кала,
Кайчак эш тотып кала;
Алырга килгән Газраил
Төкереген йотып кала.

* * *

Күпләр әйтә: роман яз син, диләр,
Вакыйгалар синдә җитәрлек...
Начармыни роман вакыйгасын
Бер шигырем барса күтәреп?!

* * *

Җәйләр үтте, көзләр җитте,
Инде кышка керәмен.
Кар өстендә үсәр, ахры,
Минем соңгы гөлләрем...

*2009*

Рауль Мирхәйдәров

# ҖӘЯҮЛЕ СӘЙРАН

РОМАН

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### Прокурор

#### 1

«Лас-Вегас»та бер ел эшләү дәверендә прокурор бу кала хакында инде бөтенесен дә белә иде. Көн саен чәйханәгә йөрүе дә хәбәрдарлыгын арттырды. Кайчагында кемнәрдер махсус рәвештә аның алдында кычкырып сөйләшәләр, шулай итеп, үзләренчә мәгълүмат җиткерәләр. Кеше аркылы әйтүчеләр дә бар. Боларның һәммәсе дә нинди максат белән эшләнә? Моңа җавап бирүе кыен. Зур кеше, сөргендә-типкедә булса да, барыбер зур кеше булып кала бирә. Әгәр ул теләсәме, ул теләсә... Хәер, Көнчыгыш халкының һәр вакыйгага үз карашы,—кайбер кыланмышларын, сүзләрен аңлау, төбенә төшү өчен монда озаклап яшәргә кирәк. Юк, прокурор элеккеге зур кеше ролен уйнарга теләмәде, шуңа андый очракларда аларга кушылып китмәде. Һәр җирдә, шул исәптән чәйханәдә дә үзен тиешле дәрәҗәдә тотуы, анда булганнар чираттагы яңалыкны иләп, шау килгәндә тыныч калуы, элеккеге прокурор яшерен хакимияткә ия, дигән ышанычны тагын да ныгытты.

Берәр ай элек чәйханәдә утырганда, ниндидер пенсионер сер итеп кенә аңа шәһәргә кәртчеләр ияләшүе турында хәбәр итте, араларында хәтта башка республикадан һәм Мәскәүдән килүчеләр дә бар икән. «Югары лига осталары катнашында кучмә уен»,—дип шаяртты сүзгә тапкыр карт. Бертуганының улы кунакханәдә электрик булып эшли икән һәм кәртчеләр өчен өстәл өстенә якты ут көйләп биргән. Аларның откан һәм оттырган акчаларының суммасын әйткәндә, карт хәтта тотлыга башлады. Әмма Азларханов бу гаҗәеп хәбәрне тыныч кына тыңлады. Яңалык түгел: өлкә прокуроры булганда, аеруча зур урлау-талаулар, үтерешләр белән очрашырга туры килде, төбенә төшеп тикшерә башлагач, аларның асылында кәрт уены, зур суммада оттырышлар ятканы күренде.

Ике атна элек кичен һава сулап йөргәндә, ул кунакханә янында кулларының җитезлеге аркасында Факир дип йөртелгән Сурен Мирзоян-Сурик һәм Аргентиналы кушаматлы данлыклы кәртче Аркадий Городецкийларны

---

*Дәвамы. Башы узган елның 12 санында.*

күреп калды. Бу йомыкый гына шәһәргә кәрт уенынннан башка Факир белән Аргентиналының тагын нинди эшләре төшсен? Мәгәр прокурор бер нәрсәдә шикләнмәде: әгәр тикшерә башлыйсың икән, бу бәндәләр әллә нәрсәләр уйлап чыгаралар, тел-теш тидерерлек итмиләр. Теге пенсионер Факирның бер төн эчендә аны тотлыгырга мәҗбүр иткән суммадан йөз тапкырга артыкны откан белсәме, бичара карт шунда ук сөйләү сәләтен югалтачак. Бөтенләйгә. Дөрес, теге төннән соң райпотребсоюз рәисе белән бик эре бер хуҗалыкчы үз-үзләренә кул салгач, барысы да өскә калкып чыкты; казна акчаларын оттырган тагы алты кешене төрмәгә озаттылар. Менә шул вакытта прокурор Факир белән танышты да инде. Оттырган акчаның бер тиенен дә кире кайтарып булмады: Мирзоян бер чемодан акча отканын яшермәде, тик өч көннән икенче берәүгә тулысы белән оттыруын, ул кешене гомерендә беренче күрүен әйтте һәм бәхетле уенчының төс-кыяфәтен тасвирлап бирде.

Димәк, хәзер кәртчеләрнең күзе «Лас-Вегас»ка төшкән?

Ә нишләп төшмәскә? Кунакханә, ресторанныарга ике күрше өлкәнең «дөнья тоткалары» күз буярга, акча туздырырга килә—аларны уенга тарту әллә ни кыенлык тудырмый. Дөрес, шәп итеп чистартырга мөмкин булган мондый «акча капчыклары»н уенга әзерләү өчен кайчакларда айлар-еллар үтә, ә кәрт өстәле артына утырткач инде—бер төн эчендә «шалт»! Шик юк: ресторанныарның өчесе дә кунакханәгә килеп урнашкан кәртчеләр өчен клиентлар табып бирүче ролен үти.

Әмма чәйханәдә ишеткән аяктан егарлык хәбәрләр дә, галәти булмаган шәһәрнең яшерен тормышы да аның күңел кылларына чиртә алмады. Юк, ишеткән-күргәннәренә битараф түгел, анарда әле иң мөһиме—сизгерлек югалмаган, хәтта өметсезлеккә бирелгән чакларында да ул: бу минем эшем түгел, монысы мина кагылмый дип әйтә алмады. Ике инфарктан соң күпме гомере калгандыр? Ул шул вакытны сузарга теләп яшәде, соңгысыннан могҗиза белән генә исән калды бит.

Аннары хәзерге хәлендә ни кыла ала соң ул? Язарга? Кемгә? Бәлага таргач кына белде: югарыга адресланган хатларның санаулысы гына өлкә йә республика чиген үтә ала икән. Кануннарны читләтеп уза торган нинди-дер яшерен кул гаделсезлек турында ачынып хәбәр салган конвертларның юлларын кисә. Ә киртәләрне үтә алганнары исә «Тикшерегез!» дигән тамга белән өстеннән шикаять ителүчегә әйләнеп кайта. Һәм тикшерәләр—хат авторының тормышын балачагыннан башлап хәзерге көнгә кадәр инә күзеннән үткәзәләр, гаеп-кыек табылмаганда туган-тумачасының җиде буынына җитәләр һәм, эзләнә торгач, теләкләренә ирешәләр. Әйберләрне сатып алуга караганда күбрәк табуга корылган хәзерге заманда шикаять авторларының азчылыгы гына үзләре зарланган кешеләрдән «чистарак» булып чыга. Ә яман аты чыккан кешенең шикаятен анонимка урынына да күрмиләр, шунда ук ябып куялар.

Азлархановның шунысын да ишеткәне бар: ул прокурор булып билгеләнгәнче, ресторанда хезмәт итүчеләргә кагылган зарларны кабул итеп тә тормаганнар—алданучыларның үзләрен кисәткәннәр: акча туздырып ресторанныарда йөрмә, янәсе. Кайбер үзсүзлеләренә читләтеп кенә аңлатканнар: яхшы, ресторанга шулай еш йөрүегезнең сәбәбен ачыкларга тырышырбыз, эш урыныгызга хат җибәрербез, уңайлы вакытка хатыныгызны повестка белән чакыртып алырбыз, дип авызын томалап куйганнар. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, прокурор түбәнрәк урындагы башкаручыларның тырышлыгы белән генә кар йомарламы кебек үсә барган җинаятьчелектән арынып булмавын яхшы белә иде. Ярар, ул Факир белән Аргентиналыны шәһәрдән кудырту өчен тырышыр, көчен кызганмас ди, тик калган конкурентлары шатланачак

кына. Моннан алты ел элек Мирзоян ана:

—Мин нинди җинятьче булыйм, иптәш прокурор? Урлаганмы мин, талаганмы? Эшчене, колхозчыны йә берәр интеллигентны отып, икенче хезмәт хакына кадәр гаиләсен акчасыз калдырганмы?—дигән иде.—Хөрмәтле кешеләрне таладың, дисез. Шәһәр, район комитетындагылар сезнең өчен мөхтәрәм, ә минем өчен алар караклар, әле ниндиләре! Каян килә аларга йөз меңнәр? Минем кебекләр булмаса, аларның чын йөзләрен берегез дә белә алмас идегез, нәфес капчыкларын акча белән тутыруларын дәвам итәрләр иде. Күрәсезме, каракларны фаш итеп, җәмгыятькә файда гына китерәм мин. Моның өчен утыртырга түгел, рәхмәт әйтергә кирәк. Кая ул, көтәрсең сездән...

Узган гомерен барлаганда, прокурор күп нәрсәгә өлгереп җитмәгәнен аңлады. Вакыт-вакыт ул үзенең элекке эшен ишегалды себерүче хезмәте белән чагыштырды. Мәсәлән, буран дулаганда, ул кар көри, кешеләргә капкага кадәр юл ача, билен турайтып аз гына сулу алам дисә, күрә: чистарткан сукмагы артыннан ук кар белән тула барган. Азларханов та республикада кануннарны бик оста гына урап узарга өйрәнгәннәрен сизеп, белеп торды һәм, прокурор буларак, үз бурычын җиренә җиткереп үтәде: эш ачты, материалларын судка тапшырды—ә нәтиҗә юк. Партия һәм совет органнары да, халык контроле, партконтроль—бар да судка басым ясый: мона кагылырга ярамый, монысы туган, тегесе кода, монысы депутат, тегесе Герой, карыйсың—прокурор куйган таләпләрдән берни калмаган. Урыны төрмәдә булган берәү ерып чыкты шулай, аннары икенчесе, ә өченчесе—артында тылы нык булганы—прокуратурага исе дә китмәде: хакимияттәгеләр өчен кануннар язылмаган, янәсе.

Прокурор яшьрәк, энергиясе ташып торган чагында: менә монда кыса төшәм, бу урында җыям, тагын бер талпынам—аннары уңайга китәр,—дип уйлый иде. Хәзер исә гадел хөкемгә карата электәге ышанычы сагышлы елмаю гына уятты.

Тормышта өметләре челпәрәмә килгән вакытлары да булды аның.

Күп еллар элек Тын океанда эсминец бортында үз-үзенә гомерен гадел хөкемгә багышларга сүз бирде, янәсе, тирә-юньдә кимсетелгән адәм заты булмасын, бар да канун тарафыннан яклау тапсын. Алга таба да аның фикере үзгәрмәде, Акмулла далаларында йөзләгән исемсез каберләр янында басып торганда да шул антын кабатлады. Хәзер инде аңлады: аның буынына—эзсез-нисез ГУЛАГларда черегәннәрнең балаларына хөкем органнарының эшчәнлегендә дөреслек торгызу мөмкин булмады.

Ул—шактый зур урын биләгән юридик фәннәр кандидаты, киңәшмәләрдә ясаган докладлары белән коллегаларын гына түгел, Югары суд әгъзаларын һәм Республика прокуратурасын аптырашта калдыргалаган кеше. Аспирантурада укыганда ук башлаган докторлык диссертациясенә берничә мәртәбә тотынып караса да, көндәлек эш-мәшәкатьләр аркасында анысы тәмамланмый кала бирә, аның ул заман өчен кыю саналган уй-фикерләре бәхәскә җирлек тудырдылар.

Юриспруденция медицина түгел. Медицинада гына ул кешелек тормышын хәвеф-хәтәрдән саклап калу өчен вакцинаны башта табиб үзендә сынап караган очраклар булган. Инде язмышына шулай язылган икән, юрист буларак, үзе белән килеп туган бу хәлне шәхсән уйлап, нәтиҗә ясарга тиеш. Булып узган хәлләр аның хокук саклау органнарына карата элеккеге карашын тагын бер кат раслады—үзгәрешләр кирәклеге мәсьәләсе өлгерде. Һәм хәзер шул органнарның эшчәнлеген фәнни тикшерүне тәмамлау аның тормышында иң мөһим эшкә әйләнде. Шуңа күрә ул санаулы гына калган вакытын сакларга, юк-барга бүленмәскә карар кылды. Табиблар йөрәгенең өченче инфарктны күтәрә алмаячагын ачыктан-ачык әйттеләр.

Ул һәр елны өлкәдәге подотчетный хокук органнарының эшен тикшерде— моны кинәттән, кисәтеп тормый-нитми генә башкарды. Тикшерү берничә этапта үткәрелгән очраклар булды, шунлыктан күрше район житәкчеләре аның сәфәре турында алдан белеп тордылар. Тик ел ахырына—алты тапкыр тикшерәме ул, жиде тапкырмы—районнар санынча алып барылган унбиш калын амбар кенәгәсендә жентекләп язылган язмалар барлыкка килде. Шуларга бер күз салу өчен, житәкчеләр әллә ниләр бирергә әзерләр иде. Биш еллап узгач, прокурор кенәгәләрне кулга төшерергә йөрүләрен сизенде: йә аның машинасына зыян салдылар, йә ул туктаган кунакханә номерларының астын-өскә китерделәр.

Өлкәнең төзәтү-хезмәт колонияләрендәге хәлләрнең торышына да вакытын бүлде, ул аларда хезмәтнең ничек оештырылуы, аның тәрбиягә ни дәрәжәдә тәэсир итүе, йогынты ясавы турында белеште. Аның фикеренчә, монда кичекмәстән матди-техник базаны ныгыту, хөкем ителгәннәрнең хезмәт белән кызыксынучанлыгын арттыру буенча ашыгыч чаралар күрелергә тиеш иде.

Кайбер башка юристлар кебек, ул да тикшерү аппаратын прокуратурадан аерып чыгарырга, судта халык утырышчылары санын ишәйтергә, аларның хокукларын киңәйтә төшәргә тәкъдим итте. Суд процессында адвокатның ролен арттырырга, кулга алынучыларга гаепләү белдерелгән мизгелдән аның ярдәменнән файдалану мөмкинлеге тудырырга дигән фикердә торды. Әмма аның чыгышларындагы андый идеяләр коллегаларына һәм югарыдагыларга ошап бетмәде.

Республикада бөтен илгә хас булган мәшәкатьләрдән башка үзләренә генә караганнары, әйләнеп узарга мөмкин булмаганнары да житәрлек иде. Инкыйлаб катлауларны бетерде, әмма тегe яки бу ырунықы дигән нәрсә сакланып калды, житмәсә, йогышлы чир кебек елдан-ел үсә генә бара. Әгәр тегe яки бу тармакны тикшерә башлыйсың икән, берсендә, мәсәлән, барысы да югары белемле бер ыру кешеләре йә бер үк жирлектән чыкканнар, сәүдәдә—икенче, сәламәтлек саклауда—өченче ырунықылар, кая карама, акчалы тармакларның барысында да шул хәл. Шушы ук чир югарыга да үтеп керде. Бервакыт Азлархановка дусты—күрше өлкә прокуроры: «Безнең өлкә комитеты бюросы әгъзаларының сигезе бер ырудан чыкканнар, бишесе—якын туганнар. Кая гына язсам да, бар да элеккечә кала бирә, чөнки бу ыруның вәкилләре югарыда, республикада да утыралар»,—дип сөйләп торган иде.

Консерв заводында эшләгән юристконсультантның төп вазифасы хәзер көнгә берәр сәгатен ала микән? Ә калган вакытында ул яза, машинкала баса, күчермәләр ала, запрос ясый һәм кирәкле китапларга заказ бирә. Менә бу укыган, белемле кешенең башкарган эше инде. Тормыштагы күп нәрсәләрне хезмәт урынындагы кешеләр түгел, ә бу эш өчен жаны авыртканнар башкара. Ә прокурорның жаны әрни...

Әле беркемгә мәгълүм булмаган бу хезмәтен—докторлык диссертациясен— ашыктыручы, артыннан куучы булмады, аны тәмамлаганга карап берниндi якты киләчәк, язмышында үзгәрешләр булырын күрмәде, дан-шөһрәтләр дә өмет итмәде, әмма ул аның күнеленә тынычлык алып килде, көннән-көн ышанычын арттырды. Үзен ул таулардагы тарлавыклар аша берүзе күпер салучыга, йә булмаса жимешләрен авыз итә алмасын белә торып та буш урында бакча үстерүче сәер кешегә охшатты. Андыйларга дан кирәк түгел, алар өчен иң мөһиме—үзләреннән соң бакча, күпер, кичү юлы, сахра-чүлдә кое казып калдыру. Аның да һәр язган юлы канун яки карар булып китә алмаса да, кайбер әһәмиятле нәтижәләр ясаганда этәргеч булып хезмәт итәр.

Кан басымы күтәрелгәндә, йөрәгә кыскан йә сагыш баскан көннәрдә аеруча ашыкты-кабаланды: өлгерә алмыйм... өлгерсәм ярар иде...Әгәр ул-

бу була калса, хезмәт урынындагы өстәл тартмасында һәм өендә адресы күрсәтелгән хатлар ята...

Башкарылган хезмәтенең басылган һәм укылган өлеше сейфта саклана, һәр папкага җибәрелергә тиешле хатлар да салып куелган. Аның белән бергә Мәскәүдә аспирантура тәмамлаганнарның күбесе югары урыннарда утыралар, һәм прокурор бу язулар аларның ышанычлы кулларына эләгер дип өметләнә.

Соңгы араларда аның башына бу гадәти булмаган шәһәрдә яшәлгән елына гомуми нәтиҗә ясау уе кереп урнашты. Әгәр бер егерме яшьне алып ташлап булса, Азлarханов ике дә уйламый мондагыларның эшләрен законсыз дип табар иде. Әмма инде илленең чигенә житкәндә, ул кадәр кискен-катгый булып булмый икән. Бервакыт үзе дә сизмәстән: «Бу шәһәрдә уңайлыклар, ай-яй, күп»,—дип ычкындырганда, законлымы ул йә законга каршымы—анысын уйлап тормаган иде. Чынлап та, өендә әз генә ремонт эшләре чыктымы—рәхим ит: осталар җыела торган чәйханә чатны борылгач та. Хатыныңның туган көненә чәчәк кирәкме? Базардагы чәчәк сатучыларга адресыңны калдыр—тиешле сәгатьтә өегездә кыңгырау шылтырар. Машинаңны буярга, бәрелгән-сугылган җирләрен шомартып җибәрергәме—шәһәрдән чыгу юлында Варданян көтеп тора. Әйбәт башкарамы? Ничек кенә әле—алтын куллы, йомры башлы, артыгын алмый.

Нәрсә, сездә туймы, туган көнме, башыгыз каткан—гомерегездә биш пардан артык кунак кабул иткәнегез булмадымы? Баш ватып торасы юк, төш вакытында машина тукталышында Мәхмүт аганы эзләп табыгыз. Йөз кешегә исәпләнгән пылау, өч йөз таяк кәбап, ике йөз кайнар сумса, йөзләгән яңа пешкән бөккән—бар да әзер. Коммуналь йортта яшисезме, борылырга да урын юкмы? Борчылмагыз: ишегалдыгызга түбә ясап, өстәл куеп бирерләр.

Гомумтуклану торышының ни хәлдә икәнен яхшы белгәнгә, прокурор завод ашханәсенә баруга караганда тукталыш янындагы чәйханәгә йөрүне кулайрак күрде. Әле ярый, бу шәһәрдә кешеләрнең көн күрүен тормыш үзе шулай җайга салган. Нәтиҗәсе күренеп тора: шәхси эшчәнлек дәүләткә комачаулык итми, киресенчә, рудник ябылганнан соң бетүгә барасы урынга, күр—кала ничек чәчәк аткан!

Дөрес, мондый эшчәнлекнең барысын да яхшылар рәтенә кертеп булмый. Күпләр кәсепләренең законлы булмаганын аңлый. Кичләрен рестораннарга күз салыгыз: шыплап тулган—аяктан егылганчы бәйрәм итәләр. Менә син рөхсәт бир, законлаштыр, баштарак булышып җибәр—вакытлы күренеш булмавын халык күрсен, ышансын. Аннары үзе үк нәтиҗә ясар: «Лидо»га болай ешлауның кирәге бармы? Еллар узган саен ул шуны аңлады: тыюдан да җиңеле юк икән.

Үзенең докторлык хезмәте турында, билгеле, ул берәүгә дә әйтмәде, ярдәм дә көтмәде, аннары аңа кем ярдәм итә алсын ди? Бары тик аны кызыксынучан күзләрдән сакларгамы теләде, берәрсе белә-нитә калса—әһә, кануннар чыгаручы табылган, имеш, дип, көлкегә калуың бар. Консерв заводы юристконсультантының тузган кабинетында кануннар язып була дип кем ышансын? Законнар бит алар югарыда, зиннәтле кабинетларда чыгарыла дип уйлыйлар. Әгәр ул шул көнне беренче тапкыр «Лидо»га кичке ашка кергәч, элеккеге коллегасы белән очрашып, бер өстәл артына туры килгән булса, хәзерге вакытта башкарган төп хезмәте турында авызын ачып сүз әйтмәс иде, мөгаен. Ничек тә бу сөйләшүдән качарга тырышыр иде. Әмма республикада танылган прокурорның ничек түбәнгә тәгәрәве турындагы әңгәмәдән барыбер котыла алмас иде.

Әйе, шәхси тормышы, язмышы турындагы гәптән качып булмас иде.

## 2

Прокурорның үткәннәргә әйләнеп кайту теләге юк, әмма бүген, нигәдер, биш ел элек булган шәһәрара иртәнге шылтырау кабат ишетелгән кебек тоелды. Лахутига, өенә шылтыраттылар. Дулкынланган ирләр тавышы, аны исеме белән атап:

—Бәла, иптәш прокурор, зур бәла. Бик тиз кайтып житегез, Лариса Павловнаны үтерделәр,—дип хәбәр итте.

Ул: «Ничек инде үтерделәр?! Кайда?!»—дип тә сорарга өлгермәде, телефон трубкасын әллә куйдылар, әллә төшереп жибәрделәр. Ул бизгәк тоткандай калтыранып жыена башлауга, өзми-куймый телефон шылтырарга тотынды.

Машина чакыртканнан соң, Азлархановбары бер генә кешегә шылтыратты: аларның өлкә милициясендә тумыштан ук тикшерүче сәләте бирелгән капитан Чураев атлы төпле, акыллы егет бар иде. Чураевның хатыны иренең бер сәгатьләп элек вертолетта фажига булган урынга очуын әйтте. Димәк, милиция аякка бастырылган. Күңеленең бер почмагында, бәлки ялгышканнардыр, Лариса исәндер, дигән өзелер-өзелмәс өмет чаткысы бар иде әле, әмма икенче, өченче шылтыраулардан соң ышанычы бетте—мондый очракларда судмедэкспертлар ялгышмыйлар.

Өч сәгатьтән ул анда—өлкәнең иң ерак районында иде инде. Жирле археологлар уналтынчы гасырның шактый зур ятмаларын ачканнар, арада яхшы сакланган керамик өй кирәк-яраклары да табылган, шуңа белгеч буларак Ларисаны чакырганнар иде.

Көтмәгәндә ташландык ишегалдында аның гәүдәсенә тап булган малайның хәбәреннән соң, Ларисаны район больницасының моргына китергәннәр. Район житәкчелеге прокурорны шунда көтеп тора иде. Азлархановморгка ялгызы гына керде, аның бик озак тоткарлануына борчылган капитан Чураев ишекне сак кына ача төшеп, эчкә күз ташлады. Прокурор дөньядан киткән кыяфәттә хатынының баш очында басып тора. Ул әле дә булган хәлләргә ышанып житми, ахры. Ларисаның сул чигәсендә оешкан кан һәм йөзендә катып калган курку галәмәте, медиклар әйтмәсә дә, үлемнең кинәт килгәнен күрсәтеп тора. Прокурор эченнән генә хатынына: «Шул адәм актыкларын тапмыйча, моннан китмим»,—дип ант итте һәм үзен көтеп торган төркем янына чыкты.

—Инде егерме еллап безнең районда үтереш булганы юк иде,—дип акланды бистә хужасы борчулы тавыш белән.

Чыннан да, бистәдә житди сәнәгать предприятиеләре булмаганга, читтән килүчеләр юк диярлек, шуңа ул тыныч урыннардан саналган. Әмма бүген аның башында статистика кайгысымыни? Прокурорга тәкъдим ителгән милиция бүлмәсендә икәү генә калгач, капитан Чураев:

—Кичкә эзләренә чыгармын дип уйлыйм,—диде һәм ана «Полароид» белән төшерелгән төсле фотографияне сузды.

Чәйханә верандасындагы айванда дүрт карт утыра. Һәрберсенең алдында—чәйнек белән чәй һәм касә. Рәсемнәрдә ясалган кебек матур картлар, ә күзләрендә—гажәпләнү. Лариса «Полароид»тан әзер фотоларны алып, өләшеп чыккан икән—шуңа таң калып утырулары булган. Хатыны кайда гына булмасын: чәйханәдәме, базардамы, кунактамы—«Полароид»ы ана кешеләр белән аралашуда беренче ярдәмчесе булды.

—Мин картларның һәрберсе белән аерым-аерым сөйләштем, алар сезнең кайгыгызны уртаклашалар: «Бик сөйкемле ханым иде»,—диләр.—Безнең якларны яхшы белә иде. Яныбызга килеп утырды да, чәй йота-йота, балчыктан уенчыклар ясаучы йөзьяшәр Кәримжан ага турында сорашты. Ул яшь чагында Горчаково станциясендәге урыс остаханәләрендә эшләмәде микән дип кызыксынды, диләр. Картлар аны тумышы белән Маргиланнан

дип уйлаганнар. Менә бар белгәннәре шулар. Берәр сәгатьләп утыргач, ул, картлардан юлны белешеп, Кәримҗан агаларга китеп барган.

—Ә монда ничек килеп эләккән?—дип сорады прокурор, рәсемнән күзен ала алмыйча.

—Аларның кичә крайны өйрәнү музее машинасында Таҗикстаннан—казу эшләреннән кайтып килешләре булган. Юлда бер хатынны утырткканнар. Сүз ара сүз чыгып, ул хатын шушы районда Кәримҗан исемле карт яшәве, аның балчыктан кызыклы уенчыклар ясавы, шуннан килгән акчага көн итүе турында сөйләгән. Лариса Павловнаның бик тә картны күрәсе килгән. Коллегаларының өйләренә ашыкканын белгәнгә, машинадан төшеп калган. Район прокуратурасына кереп, ничек булса да озатуларын үтенермен, дигән. Кәримҗан агаларга барып житә алмаган, әмма ул үле килеш табылган ихата картларның өйләренә бару юлында.—Чураев авыр итеп сулыш алды.—Сәбәбе ачык дип уйлыйм. Янында сумкасы булган, ә анда—музей өчен берәр нәрсә алып булмасмы дип бухгалтериядән алынган өч йөз сиксән сум акча. Документларын карадым. Тик кемнендер күзе гадәти булмаган фотоаппаратка төшкән, ахры, кулыннан тартып алмакчы иткән. Лариса Павловна каршылык күрсәткәч, үтерүчеләр куркуларыннан яки ачулары чыгып, чигәсенә авыр, тупас әйбер белән суккannar.

Прокурор бу хәлне үз күз белән күреп, хатынының ачыргаланып ярдәм сорап кычкырганын ишеткәндәй, җилкәсен куырып куйды.

—Аның тагын бер фотоаппараты—«Кодак» булырга тиеш, анысы тагын да кыйбатрак.—Азлarханов югалып калды.—Ул икесен дә һәрвакыт үзе белән ала иде.

Чураев башын чайкады.

—Мин монысын белми идем. Икенче фотоаппарат турында сүз кузгатучы булмады. «Кодак» аның янында да, акчалары салынган сумкасында да күренмәде. Бу эшне үзгәртә бит әле. Лариса Павловна машинадан тукталышта төшеп кала, бу вакытта анда кеше күп була. Аппаратурага теше үткән, өстәвенә кулы кычытып торган кеше ябык кына ханым кулында шундый кыйммәтле табышны күргәч, артыннан куа китәргә мөмкин. Әмма «Кодак»ның бәясен белгән кеше, мөгаен, җирлеләрдән түгелдер. «Поларoид»ка килгәндә, аның гадәти булмавы мондагыларның да игътибарын тарткандыр, ә бу, минемчә, эзләүне бу тирәдән башларга кирәклекне күрсәтә. Әгәр тукталыштан ук аның артыннан ияргән кеше дип уйлыйбыз икән, ул хәзерге вакытта Мәскәүдәме, Ростовтамы, гомумән, илебезнең теләсә кайсы почмагында иркенләп күңел ачып йөрергә мөмкин...—Чураев тотлыгып калды.—Әмирхан ага, ант итәм: ул адәм актыгын җир тишегеннән булса да табачакмын, андый җинаятьчеләрне кичерергә ярамый...—диде дә, күзләре яшьләнеп, бүлмәдән атылып чыкты.

Прокурор бүлмәдә бер сәгать утырды, ике...—телефон дәшмәде. Ул калтыранган кулындагы фотографиядән күзен ала алмады, уналты сәгать элек кенә Лариса белән гәпләшеп утырган мөлаем йөзле картларга карады, нибары уналты... Һәм бу уе аны куркытып җибәрде, күз алдыннан алда көтеп торган ялгызлык, бушлык үтте, гомеренең соңгы көннәренә кадәр шушы уналты сәгатькә башта сәгатьләр, аннары көннәр, айлар, еллар өстәләсен уйлап иманеп китте... Кинәт кенә шул картлар янына барасы,—берниндi максатсыз, сорау алыр өчен түгел, анысын капитан Чураев инәсеннән җебенә кадәр җентекләгән инде—болай, күрәсе килде.

Ул коридорга күз салды, ишек төбендә кизү милиционер басып тора, күрәсен, урындагы җитәкчеләр шулай хәл иткәндер—ни булмас, янәсе. Прокурор милиционерга фотографияне сузып хуҗасына кайтаруларын үтенде һәм ярты сәгатьтән теге картларны чәйханәгә чакыруларын сорады.

Ун минут та узмагандыр, машина әйләнеп тә кайтты; картлар иртәдән бирле чәйханәдә утыралар һәм прокурор белән очрашырга әзер икән. Тик аксакалларны шактый нык куркытканнар, ахры, сөйләшү барып чыкмады. Һәрхәлдә, өркетүче Чураев түгел, Азлархანов монысын төгәл әйтә ала. Картлар куркуларын яшерергә тырышалар—менә анысы шикләндерде. Прокурор Ларисаның икенче фотоаппараты да үз янында булуын тәгаен ачыклады, картлар аны бик төгәл итеп сурәтләп бирделәр. Димәк, аның хатынына тукталыштагы кеше ияргән диган шик дөрескә чыгарга мөмкин.

Прокурор машинага утырырга торганда, аның янына очып диярлек милиция мотоциклы килеп туктады. Сержант урындыгыннан төшеп тә тормыйча ярып салды:

—Эләктерделәр, иптәш прокурор. Тоттылар...

Прокурор кабинага керүгә, машина кузгалып та китте.

Милиция бинасы тулы халык. Тар коридорда Әмирхан Даутович күренүгә, төркем, ике як стенага елышып, ана юл ачты. Тирә-юньдәгеләргә күз дә салмыйча, ул туп-туры ишек төбендә басып торган полковникка таба атлады. Полковник, кулы белән ишарәләп, аны кабинетына чакырды, аннары, башкалардан алда өлгерим дигәндәй, ашыга-ашыга тезеп китте:

—Гаебен таныды, адәм актыгы, таныды, бөтен кәгазьләргә дә кул куйды.

Бүлмә уртасына куелган урындыкта урта яшьләрдәге, кыяфәте сукбайга охшаган шапшаграк бер ир-ат утыра иде. Коридор һәм кабинет тулы шау-шу, этеш-төртешкә битараф бу адәмнең карашында язмышына буйсынуы чагыла. Прокурор аның ягына күз ташлап алды да җыелганнарга:

—Аның белән ялгызымны гына калдырыгыз,—диде.

Халык төркеме теләр-теләмәс кенә кабинетны бушатты.

Ярты сәгатьләп узгач, Азларханов милиция башлыгын кабинетка дәште. Бу вакыт эчендә ишек төбеннән китмәгән полковникның, бусаганы атлаганда, каушаганы йөзенә чыкты.

—Иргашев, тынлагыз әле, минем кайчан да булса җинаятьне теләсә нинди юл белән ачарга дигәнем булдымы? Бәлки элек эшләгән урыныгызда шулай булгандыр, әмма сез районга килгәннән бирле шактый сулар акты. Инде өйрәнергә вакыт. Бу очракта, шәхсән үземә кагылса да, сезне хуплый алмыйм. Бу бәхетсез җан сезнең басым астында танырга мәҗбүр булган. Сез нинди алымнар белән эш итәсез, ә? Җинаять кодексына күз салгалагыз, югыйсә безнең юллар аерылырга мөмкин.—Полковникны уттан алып суга салган озын паузадан соң дәвам итте:—Ә бу кешене мәҗбүри дәвалауга озатыгыз һәм киләчәктә чираттагы җинаятьне «ябу» өчен аның фамилиясен запаста тотмагыз. Карагыз аны, минем хәтерем әйбәт, сынап карарга тәкъдим итмим.

Прокурор күз унында торткан маддә полковникка яхшы таныш: нәкъ менә хезмәт урыныннан явызларча файдаланганы өчен аны өлкәнең милиция башлыгы урындыгыннан «очырдылар», башта шәһәр хезмәте посты җитәкчесе булды, аннары шәһәрдәге бер районныкына, алга таба авыл җирлегенә үк тәгәрәттеләр. Тик монарчы берәүнең дә прокурор шикелле хезмәт урынына лаеклы булмавын йөзенә бәреп әйткәне юк иде әле.

Полковник артыннан ишек ябылуга, аңа ияргән түрәләре дә чыгу юлына атладылар, бераздан машина ишекләренең шапылдаганы ишетелде, һәм бина каршындагы мәйдан күз ачып йомганчы бушап калды.

Прокурор рәшәткә тотылган тәрәзә аша тоткынның куркынып, як-ягына карана-карана, ишегалды буйлап үтүен карап торды, тегесе әле һаман да үзенең котылуына ышанмый, менә-менә артыннан килеп янә

тотарлар да калтыранган кулларына кабат богау салырлар дип көтә иде, күрәсең. Элек шулай булгалаган, аңа чит эшләр өчен җавап тотарга туры килгән. Капка янына килеп җитүгә, куып килмиләрме дигәндәй, соңгы кат артына борылып күз салды да йөгерергә үк тотынды. Хәер, авыру кешенең кызганыч теркелдәвен йөгерү дип атап булыр иде микән? »Һәрбер кешедә, хәтта кешелеклелек сыйфатларын югалтырга бер адым калганнарда да үз-үзен саклау инстинкты бар»,—дип уйлады прокурор һәм йөрәген беренче мәртәбә нидер чәнчеп алды.

### 3

Кич житте, бина бушап калды, хәтта көне буе ишек төбен саклаган старшина да каядыр китеп югалды. Бары тик кизү бүлмәсеннән генә шылтыраулар ишетелгәләде, әмма прокурор каршында торган телефон тавыш-тынсыз иде. Район бүлеге буенча кизү әледән-әле чәй китерде— тик үзе башлап сүз әйтергә кыймады, прокурор да берни сорашмады. Терсәкләрен язу карасыннан чуарланып беткән өстәлгә терәп, куллары белән башын тотып, шактый озак утырды. Читтән караган кешегә, мөгаен, йокымсыраган кебек тоелыр иде. Тик алай түгел шул: ул коридорның теге башындагы телефонның һәр шылтыравына, милиция яныннан үтеп киткән һәрбер машина тавышына сискәнеп, башын күтәрә: иртәдән бирле капитаннан хәбәр көтә.

Кичке эңгер-меңгер әкренләп куерды. Ишегалдында шланг тоткан бакчачы күренде. Ул, ниһаять, машиналардан бушап калган мәйданны, көннәр буе тузан йоткан чәчәкләрне, хәтта шушы иске баракның беренче хуҗалары утырткан имәннәрнең аскы ботакларын да көчле су ташкыны белән юдырырга кереште. Тик Әмирхан Даутович кына боларны күрмәде.

Озак та үтмәде, прокурор утырган бүлмәнең киереп ачылган тәрәзәләреннән саф һава ургылып керде. Әлегә кадәр сәламәтлегеннән зарланганы булмады Азлархановның, эссене дә, салкынны да бердәй кичерде. Әмма бүген һава җитмәде, тыны кысылды; дымлы җир исе, саф һава аны бик тиз үз хәләтенә кайтарды.

Роза түтәлләре янындагы фонарьларны кабыздылар, яңа юылган асфальт ут яктысында ялтырап ята, ә җыелып калган кечкенә сулыклар өстеннән сизелер-сизелмәс кенә җинелчә пар күтәрелә.

«Әллә яңгыр явып киттеме?»—дип гаҗәпләнде Азлархнов, тик бу уен бик тиз башыннан куды, көньякта җәйләрен яңгыр—сирәк кунак. Урындыгыннан күтәрелүгә, оеган аяклары сызларга кереште, аксаклап диярлек тәрәзә янына килде дә, изүен ачып, ашыга-ашыга, саф һава сулый башлады. «Урамга чыгарга кирәк, шылтыратсалар ишетелми калмас»,—дип уйлады һәм тынчу кабинеттан урамга атлады.

Юылган асфальт инде кипшерә төшкән, әмма сулыш алуы рәхәт, тәрәзә каршындагы бакчадан һәм аз гына эчтәрәк урнашкан чәчәк түтәлләреннән яшеллек, дымлы җир исе аңкый. Ул, үзе дә сизмәстән: «Нинди тылсым бар бу суда»,—дип сөйләнеп куйды. Төбенә кадәр ачып куелган ишек янына басып, ерактан машина уты күренмәсме, розаның чәнечкеле куаклары артыннан өлкәнең иң яхшы тикшерүчесе Чураевның җитез, җинел сыны килеп чыкмасмы дип, карашын караңгылыкка төбәде. Төнгелеккә калган кизү тәрәзәдән прокурорның чәчәклеккә таба атлавын күзәтте. Аңа бүген прокурорның кайгы килгәндә дә үзен ирләрчә тотуы, бигрәк тә милиция башлыгын акылга утыртуы, сукбайга мөнәсәбәте бик ошады. Милиционер әле бик яшь, университетның юридик факультетында читтән торып белем ала һәм юристларның күпчелеге кебек киләчәктә прокурор булырга өметләнә. Коллегаларыннан, университеттагы иптәшләреннән Азлархнов

турында күп ишеткәне бар анын, шуна күрә мөмкинлектән файдаланып, анардан күзен алмый һәр адымын күзәтте. Егет үзенең төне буе монда утыруына үкенде, бүген милициянең бөтен көче ведомстводан тыш сак хезмәткәрләре белән берлектә үтерүчене эзләүдә икәнен белә, менә шушы минутларда да, инде бик соң булуга карамастан, районда, өлкәдә генә түгел, бар җирдә эзләү баруына шикләнми.

Кизү торуны кабул итеп алганда, анын күзе журналдагы ике телефонограммага төште. Алар капитан Чураев тарафыннан Республиканың Эчке эшләр министрлыгы белән Бөтенсоюз җинаятьчеләрне эзләү бүлегенә җибәрелгәннәр. Беренчесе өлкә прокуроры килеп җиткәнче теркәлеп куелган:

«Үзләре белән «Полароид» фотоаппараты йөрткән шикле кешеләргә игътибар итүегезне сорыйм».

Һәм икенчесе:

«Шик төшкән Полароид»лы кешедә икенчесе—соңгы модель «Кодак» та булырга мөмкин».

«Кызганыч, бернинди хәбәр юк,—дип уйлады кизү.—Менә хәзер чыгарга да: «Борчылмагыз, иптәш прокурор, егетләр эзенә төшкәннәр, котәргә генә кирәк»,—дияргә иде. Булмый шул. Ул яңа чәй пешерде дә урындык алып прокурор янына юнәлде.

Прокурор чәйдән дә, урындыктан да баш тартмады, башын селкеп рәхмәтен белдерде дә койма буенча арлы-бирле йөрүен дәвам итте. Кизүнең кереп китәргә җыенганын күреп:

—Капитан Чураевтан хәбәр юкмы?—дип сорыйсы итте.

Милиционер авыр сулады:

—Хәзергә юк шул, иптәш прокурор...—Әйтергәме, юкмы дигәндәй, аз гына уйланып торганнан соң, түзмәде:—Бер сәгатьләп элек лейтенант Мусаев шалтыратты. Ул мондагы, аны капитан Чураевка ярдәм итәргә билгеләделәр. Бик үпкәләгән тавыш белән Чураевның аны юлэргә чыгаруы, машинасыз калдыруы турында хәбәр итте. Ә эш болай булган... Алар Мусаевларга төшке ашка кергәннәр. Чураев анардан гражданский киемнәр сорап алып, кышлак егетләренә охшатып киенгән. Төштән соң Мусаевның шәхси машинасына утырып юлга кузгалганнар, аларның нинди дә уртак планнары булган, ахры. Тик көтмәгәндә Чураев автостанция ягына борылырга кушкан. Егерме минутлап югалып торганнан соң, әйләнеп килгән дә, лейтенантка чәйханәгә кереп унайлы урынга урнашырга боерган. Аннары, шундый-шундый кеше күренсә, шунда ук тоткарла, дигән. Ә үзе тиз генә машина белән сезнең якка барып хәбәр итәм дә шунда ук кире әйләнеп киләм, дигән. Шулай итеп, Мусаевка постны ташламаска кушкан да китеп барган. Безнең лейтенант чәйханә ябылганчы җиде сәгатьләп утырган. Аннары гына капитанга анын үзе түгел, ә җирле номерлы «Жигули»ы гына кирәк булганына төшенгән. Менә мина билгеле булганнары шулар, иптәш прокурор. Ә Чураев монда күренмәде...

Прокурор аны тыңламый иде инде. Кием алыштыру, машина куу—болары нинди хикмәт икән? Тик бу бер дә Чураевка охшамаган иде, нәкъ менә анын тышкы буяуларга исе китми, ә эшенең нәтиҗәләре күпне күргән белгечләрне дә таң калдыра. Җирле кешенең ярдәменнән баш тарту? Монда бернинди дә бәйләнеш күренми. «Димәк, җирле кеше ана нигәдер комачаулаган,—дигән нәтиҗәгә килде прокурор.—Көтәргә! Көтәргә!»—дип, биек куаклар янында йөренүен дәвам итте.

Кинәт карангылык эченнән машина уты күренде, анын тавышына милиционер атылып чыкты. Дулкынланулары юкка булды: килүче—район прокуроры иде. Ул коллегасын кичке ашка чакырды, әмма Азлархановаңың белән ике-өч сүз алышты да тәкъдимен кире какты.

Төн хакимлекне үз кулына алды: күрше мәхәлләдә утлар сүнде, арлы-бирле чабышкан бистә этләре каядыр китеп югалды, магнитофон тавышы да тынды, бары тик ара-тирә сонга калган машиналар гына тынлыкны бозгалап ала. Сизелерлек салкынайтты, Әмирхан Даутович үзе вакытлыча урнашкан кабинетка керде. Тынып калган телефонга карап: «Инде иртәнгә кадәр хәбәр булмас»,—дип уйлады. Башын учларына салып утыра торгач, үзе дә сизмәстән, Лариса белән үткәргән бәхетле көннәренә әйләнеп кайтты. Шунадырмы, якынлашып килгән машина тавышын ишетми калды. Бары тик ишегалдына килеп кергән «Жигули»ның якты утлары тәрәзәләрне айкап алгач кына, тормозлар чыелдавы Азларханов колагына килеп керде. Ул да булмады, капитанның таныш тавышы ишетелде:

—Капкаларны бикләп куй, хәзер көтүләре белән туган-тумачалары килеп житәчәк. Һәм ярты сәгатьсез берәүгә дә ачасы булма. Ишеттеңме—берәүгә дә, хәтта полковник Иргашевка да!—дип боерды ул кизү лейтенантка.— Ачкыч Чураевта диярсең, әнә, булдыра алсалар койма аша үрмәләсеннәр.— Һәм тагын кемгәдер:

—Ә сез машинадан төшегез дә тиз генә уты янып торган кабинетка элдертегез. Сезне анда көтәләр,—диде.

Әле истәлекләреннән арынып, бүгенгегә кайтырга өлгермәгән прокурор янына Чураев этеп-төртеп диярлек ике егетне алып керде. Аның һәрбер хәрәкәтеннән ашыкканлыгы сизелеп тора иде.

—Карап тор, үзара сөйләшмәсеннәр!—Ишек төбенә килеп баскан кизүгә шулай диде дә прокурорны, ымлап, икенче бүлмәгә чакырды.

Әмирхан Даутович ут кабызды һәм каршында торган капитанның арып-талганын күреп, утырырга тәкъдим итте. Тик тегесе кулын гына селтәде дә ишекне ныгытып ябып куйды.

—Юк, иптәш прокурор, үзегез утырыгыз, сезнең алда авырлыклар башлана гына. Мин үземә кагылганын эшләдем һәм, зинһар, мине бүлдермичә игътибар белән тынлагыз, безнең вакытыбыз бик аз. Хәзер төн уртасы дип тормаслар—дистәләгән машина киләчәк, туган-тумача, дус-ишләр, эреле-ваклы түрәләр очып куначак, миңа сезнең белән генә калырга ирек бирмәячәкләр.

Ул көчләп диярлек прокурорны утыртты да аңа фотография сузды.

Аптырап калган прокурор:

—«Полароид?!»—дип кенә әйтә алды.

—Акрын!—дип кисәтте аны капитан.—Әйе, «Полароид».

Йомарланган фотографиядән кочаклашып торган ике егет елмая иде. Берсе—озын буйлы, таза, тәкәбберлеге йөзенә чыккан, ә икенчесе—тегесенең җилкәсенә дә житмәгәне—дистрофик, чыраенда куштанлык катып калган, әфәндесе боерсын гына—теләсә нинди әмерен үтәргә әзер. Күпме генә карап торсаң да, аларны дуслар, бер-берсенә бәйләнгәннәр дип уйга да кертеп булмый.

—Исегездә калдырдыгызмы?—дип сорады капитан.

Прокурор башын селкеде, фотосурәттә икенче бүлмәдә калган егетләр иде. Капитан фотографияне алды да, вак-вак кисәкләргә ерткалап, кесәсенә салып куйды.

—Бу фотография бездә юк дип саныйк. Мин берәүгә дә күрсәтмәскә дип сүз бирдем, югыйсә ул гаиләгә көн бетәчәк, хәер, үзегез дә аңларсыз әле. Иң мөһиме: үтерүчеләр безнең кулда. Хәзер яклаучылары ябырылганчы, кизү катнашында сорау алырга өлгерик. Миңа калса, җирле милиция аларга миннән алдарак чыккан, тик ниндидер каршылыкларга очраган, ахры. Бикхуҗаевларның, әнә теге тук чырайлысының өендә мин полковник Иргашев белән район прокуроры Исмәгыйлевларның тавышын ишеттем

шикелле, тик кистереп әйтә алмыйм. Инде соң булуга карамастан, рәсемдәге егетләрнең икенчесе дә шунда иде. Башта мин аларга бардым, үзеннән генә сорау алмакчы идем, тик өендә туры килмәде, әнисе бик горур гына : ике сәгать элек дусты—бик зур кешеләрнен улы Әнвәр килеп, мотоциклына утыртып кунакка алып китте, кара тәкә суйганнар икән,—дип аңлатты.

—Кемнәр алар—Бикхуҗаевлар?

—Сөен Бикхуҗаев—мамык игә торган миллионер-колхоз рәисе, Социалистик Хезмәт Герое, республика Югары Совет депутаты. Аның алты ир, ике кыз туганы бар, аларның барысын да аякка бастырды. Сез аның туганнарын яхшы беләсез, алар бар да өлкәдә югары урыннарда. Әле тагын шунысы бар: нәсел-ыруларының бу якларда сүзе үтә, данлыклы, бик күпләр Сөен Бикхуҗаевның финанс ярдәме белән күтәрелделәр.

—Сез дә, капитан, хаҗи нәселеннәнме?—дип сорады прокурор.

—Әллә охшаганмы? Мин кайчандыр бик шәп гаиләдән чыккан бер кызны яраткан идем. Тик әти-әниләре өйләнешергә ризалык бирмәделәр, абыйлары исә дус егетләре белән берничә тапкыр үләр хәлгә җиткәнче тукмадылар. Андый гаиләнең ир-егетләре гади генә кызларга өйләнергә мөмкин, ә кызларына үзенә тиң булмаганга чыгарга—рөхсәт юк. Шул вакытта мин язмышымда...—Чураев кинәт сүзен бүлде.—Безгә вакыт, киләләр.

Тынлыкны бүлеп, якынлашып килгән машина тавышлары ишетелде. Икесе дә машиналарның монда ашыгуларын чамалады.

Алар күрше бүлмәгә керделәр. Капитан сорау алу өчен кәгазьләрен әзерләргә дә өлгермәде, машиналарның балкып торган фаралары бинадагы бердәнбер якты тәрәзәгә төбәлде. Капканың бикле икәнен күргәч, шаулашырга, кычкырырга тотындылар, кайсыдыр өзлексез клаксонын кычкыртты, кемдер сүгенде, гомумән, ата улны, ана кызны белмәс хәлгә җиттеләр. Ул арада, шау-шуны басып, үз дәрәҗәсен белгән ачулы тавыш ишетелде:

—Прокурорның хатынын үтергәннәр дигәч тә, бу нинди башбаштаклык? Төн уртасында балаларыбызны алып чыгып китәргә ни хакыгыз бар?

—Таныш булыгыз, Сөен Бикхуҗаев үзе,—дип аңлатты капитан прокурорга.

Тавыш-гауга, чыр-чу мәхәлләне аякка бастырды: этләр өрергә тотынды, өйләрдә ут алдылар.Ул арада кайсыдыр чүкеч белән йозакны ватарга керешге. Боларның барысына полковник Иргашевның бас тавышы кушылды:

—Хәзер үк капканы ачыгыз! Капканы ачарга боерам!

Тик ишек төбендә торган кизү урыныннан кузгалмады, ул күрсәтмәләр бирүче егетне тыңлый иде.

—Юридик факультет студенты?—Прокурор гаҗәпләнде.

—Әйе,—кече Бикхуҗаев дерелдәгән иреннәре арасыннан сыгып чыгарды,—әтием прокурор булырсың диде.

Капитан иң мөһим сорауны бирергә өлгермәсләрен чамалап, прокурорны бүлдерергә теләде, әмма тегесе аны ишетер хәлдә түгел иде, урыныннан сикереп торып:

—Син—булачак юрист?—дип кычкырды. Аннары хәле киткәндәй урындыгына чүкте дә капитанга:—Дәвам итегез,—диде. Әмма Чураев төп соравына күчкәнче, Азлрханов урыныннан торып тәрәзә янына килде. Нәкъ каршыда Бикхуҗаевның туганнары, дуслары котырына иде. Тәрәзәдә прокурор күренүгә, алар элеккедән дә бигрәк шауларга тотындылар. Прокурор борылды да әкрен генә егетләргә таба атлады, ә тегеләре куркынып, утырган урыннарында кыбырсына башладылар.

Чураев, ниндидер күңелсезлек булырын чамалап, прокурор янына ашыкты. Тегесе кизәнергәме, әллә куркуыннан кычкырырга тотынган кече

Бикхуҗаевны түшеннән эләктереп алырга дипме кулын күтәргәндә, аның янәшәсенә килеп басты һәм прокурорны ялгыш адымнан саклап калырга әзерләнде. Әмма Әмирхан Даутович кулын күтәргән килеш, әкрен генә аңа таба ава башлады.

Капитан прокурорны тотып калды һәм кизүгә:

-Тизрәк, «Ашыгыч ярдәм» чакыртыгыз!—дип кычкырды.—Ташкент белән телефон аша махсус элемтә урнаштырыгыз!—дип өстәде.—Ә үзе прокурорны җайлап идәнгә яткырды да баш астына кемнеңдер чапанын кыстырды.

Якында гына урнашкан район больницасының «Ашыгыч ярдәм»е белән бергә ишегалдына теге өер дә үтеп керде, әмма кизү торган милиционер Чураев кушуы буенча бинага бары тик урындагы кешеләрне генә уткәрде, гаҗәпкә каршы, инде соң булуга карамастан, алары да шактый булып чыкты. Шулчак Ташкенттан шылтыраттылар.

—Бу капитан Чураев,—диде тикшерүче.—Утерүчеләрне кулга алдым, тулырак мәгълүмат сәгать-сәгать ярымнан Ташкентта очрашкач. Ә хәзер бик тиз санитар авиация белән элемтәгә керегез һәм районга самолет җибәрегез—ун минут элек прокурорга инфаркт булды.

—Нәрсәгә ул самолет, безнең район больницасына йә өлкәнекенә илтергә була.—Капитан трубканы куюга, полковник Иргашев ризасызлыгын белдерде. Хәзер ул үзен көндезгегә караганда кыюрак тота иде.

Чураев игътибар белән полковникка карады, алда аларны озакка сузылган көрәш көткәнен сизгәндәй, өздереп:

—Мин прокурорны сездә дә, өлкәдә дә калдырмыйм, үз кулларым белән Ташкенттагы табиблар кулына илтеп тапшырам,—дип җавап кайтарды.

## ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

### Бикхуҗаевлар

#### 1

Хатынын күмгән вакытта була алмавы өчен прокурор әле дә үзен гаепле саный, аны соңгы юлга дуслары, музейда бергә эшләгән хезмәттәшләре, прокуратурадагы иптәшләре озатты. Шулай да таякның юан башы капитан Чураевка туры килде: ул аның үзен санитар очкычта республиканың кардиологик үзәгенә, ә хатынын Лахути урамындагы ятим калган йортларына китерде. Үзе үк Әмирхан Даутович өчен күмү вакытын фотографиягә төшерде, эзләп табылган «Поляроид» һәм «Кодак», шулай итеп, соңгы мәртәбә хезмәт күрсәттеләр.

Прокурор хатынының каберенә килгәндә, елак көзнең тоташ вак яңгыр сибәләгән соңгы көннәре иде. Ташкент хастаханәсендә ике ай ярым үткәреп, туры аэропорттан килеше иде аның. Хастаханәдән кулына Ялтадагы кардиологик санаторийга юллама тоттырып, бик кырыс киңәшләр биреп озаттылар. Элеккечә өлкә прокуроры урынын биләсә дә, хәле эшкә чыгу турында авыз ачарлык түгел, әле дәваланасы да дәваланасы. Табиблар аны һәртөрле борчу-кичерешләрдән сакларга тырышсалар да, прокурорның, аңына килүгә, хәлләрнең кичек торганын беләсе килде, билгеле. Чураев фотографияләрне китергәч, анардан да шактый гына яңалыклар ишетте.

Полковник Иргашев Чураевны үзенең вәкаләтләрен арттырып җибәрүдә, тикшерүне тыелган юллар белән алып баруда гаепләгән һәм капитанны бу эштән читләштергәннәр.

Суд-хөкем өчен эш әллә ни кыенлыклар тудырырлык түгел иде. Балигъ булырына ике айлап калган җинаятьче үз гаебен таныды. Сәнгать белгече Тургановага талау максаты белән һөҗүмне үзе ниятләве һәм башкарып чыгуы турында сөйләп бирде. Юк, ул аны һич кенә дә үтерергә теләмәгән,

имеш, бар да көтмәгәндә килеп чыккан. Фотоаппаратны тартып алып йөгерә башлауга, зыян күрүче аның артыннан ташланган, ә тегесе мотоцикл шлемы белән селтәнгәндә ялгыш хатынның чигәсенә эләктергән. Аның иптәше Әнвәр Бикхуҗаев—«Ява» мотоциклының хуҗасы—җинаять кылырга барудан баш тартып, дустын да үгетләп караган, тик гаҗәеп фотоаппаратка ия булу теләге белән янган Ходайкулов ана пычак тергән, һәм Бикхуҗаевның Турганова артыннан кузгалмый хәле калмаган.

Хөкемдар гаепләнүчедән, ни өчен тоткарлаган вакытта Бикхуҗаевлар өендә булуы турында сорагач, ул үтерүчене эзләүләрен белүе, иптәшенен сатуыннан куркып, аның өенә баруы һәм тегесе әйтә-нитә калса, гомере белән түләячәген сиздерүе турында сөйләп бирде, дустына янаган пычакны күрсәтте. Суд үтерешнен алдан уйланмаган булуын, юридик факультет студенты Бикхуҗаевның да шаһит буларак биргән шундый күрсәтмәсен искә алып, гаепләнүченең әле балигъ булмавын, авыру әнисен бакканын исәпләп, аны ун елга хөкем итте. Тикшерү һәм суд эшләре бик аз вакытта хәл ителде. Дөреслек тантана кичерде: үтерүче табылды һәм тиешле елларын алды, җинаятьче тарафыннан аздан гына зыян күрмәгән студент Бикхуҗаев та университетта, инде өченче курста белем тупларга керештe, көтмәгәндә хөкем залында шаһит буларак алган тәҗрибәсе киләчәктә ана гамәлдә кирәк булачак әле.

Билгеле, читтән караганда дөреслек тантана итте, явызлык бик тиз арада җәзасын алды, дип уйларга җирлек бар. Мәхкәмә утырышы ачык булды, тик чын-чынлап төбенә төшә башласаң, аның ачык үткәрелүенен үз тарихы бар. Аны өч мәртәбә чигерделәр, һәм Лариса Павловнаның хезмәттәшләренә берничә мәртәбә рейс автобусларында шәһәргә кире әйләнеп кайтырга туры килде, юл шактый озын, эш сәгатьләрен һаман-һаман каллыра алмаганга, соңга таба аларның саны кимегәннән-кими барды. Ә аннары һич көтмәгәндә процессны элек хәбәр ителгәннән бер көн алда үткәреп тә куйдылар. Бар, канәгатьсезлек белдереп кара—аларның беркем бәйләнә алмаслык сәбәпләре әзер. Зал да туп-тулы, тик андагылар арасында Лариса Павловнаның язмышы һәм прокурорның кыен, авыр хәле өчен борчылган кешеләр бөтенләй юк диярлек. Әмма шаһит буларак катнашкан Әнвәр Бикхуҗаевның кардәш-ыру, туганнары бар да монда, өстәвенә, хөрмәтле кешеләрнең улын—ансызлыгы аркасында бәлага юлыккан студентны якларга, ак һәм кара «Волга»ларга төялеп, өлкә кешеләре дә килгәннәр. Залда бар да студент өчен җан атып, аның шаһитлыктан гаепләләр урындыгына күчеп утырмагае дип борчылучылар гына дисәк тә, ялгыш булыр иде. Юк, җирле халык кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен судтан башка да яхшы чамалый, тик аларны һәрнәрсәгә көче җитә торган Сөен Бикхуҗаевның бу вакыйганы ничек ерып чыгачагы кызыксындырды. Колхоз рәисе, салып алгач, бигрәк тә соңгы елларда, симез бармагы белән күкрәгендәге Герой Йолдызы белән депутат тамгасына төртеп, колхозчыларга: «Закон—менә мин ул!»—дип акырырга, шапырынырга ияләнде. Менә аның үз мөмкинлекләрен артыграк бәяләмиме икәнен ачыкларга җай чыкты. Дөресен әйткәндә, күпләр Бикхуҗаевларның кодрәтеннән шикләнмәде дә, тик араларында кайберләре барыбер ниндидер могҗизага ышаналар иде—ә бәлки? Судта бит сүз яклардай һичкеме булмаган караңгы бер кышлак хатыны турында түгел, ә өлкә прокуроры җәмәгате, чит илләрдә дә билгеле галимә хакында бара лабаса!

Гадәттәгечә килеп чыкты: халык почмакларда чышын-пышын килсә дә, депутатка ишетелә-нитә калмасын тагын дигәндәй, як-ягына каранудан узмады...

Судта капитан Чураев та бар иде. Билгеле, ана берәү дә суд утырышы буласын хәбәр итмәде, киресенчә, аны бу эштән читләштерделәр, хәтта бу

вакыйгадан ерактарак торырга киңәш иттеләр; дөрес, җинаятьчеләрне тиз арада эләктерүе өчен рәсми рәвештә рәхмәт белдереп, күнелен күтәрергә дә онытмадылар. Тик аның кебек тәҗрибәле тикшерүчене ансат кына юлдан яздырырмын димә: судта уйналачак тамашаны ул алдан ук чамалады.

Судка ул башкаларның игътибарын җәлеп итмәс өчен иркен плащ киеп, эченә япон магнитофонын кыстырып килде. Бик шома гына барачак суд утырышын яздырып алу өчен өч кассета муеннан ашкан иде.

Чураев үзен кызыксындырган кешедән күзен алмады. Бу адәмне ул фаҗига булган көнне очратты, шул төнне үк аның белән очрашкан да булыр иде, әмма прокурор белән бәла килеп чыкты.

Судтан соң Чураев шәһәргә тиз генә кайтып китмәде. Кичкә кадәр базарны, чәйханәләрне әйләнеп чыкты, бар җирдә сүз бүгенге суд турында гына иде. Күз бәйләнгәнче вакытын автостанция янындагы чәйханәдә үткәрде, кайчандыр ул монда шактый шүрләп калган лейтенант Мусаевны җибәргән иде. Лейтенантка үтерүченең куркыныч портретын сурәтләп бирде, әмма үзеннән уйлап чыгармады—узган елны бер фатирдан шундыйны каптырган иде. Аңа нәрсә эшләргә кала иде соң? Ул картлардан чәйханә тирәсендә кемнедер күргәннәрен белде, тик алар аның кем булуын әйтергә кыенсындылар, димәк, бу кеше җирлеләрдән түгел—монысы көн кебек ачык. Өлкәдән ана: район үзәгендә төрмәдән кайткан бер генә җинаятьче дә, бер генә рецидивист та даими теркәлмәгән, бары тик элегрәк растрата ясаучылар белән казна талаучылар гына яши, дип хәбәр иттеләр. Димәк, алар үткән җинаять белән бәйле җирле кешедән түгел, ә бәйләнмәвең хәерлерәк булган икенче бер адәмнән курыктылар. Чураев җинаятьчеләрне эзләгән көнне менә шушы шиккә тукталды һәм өлкәдә олысыннан кечесенә кадәр таныш лейтенант Мусаев үзенә ярдәмче була алмасына төшенде, хәтта киресенчә, аның катнашында,ай-һай, берәрсе авызын ачып сүз әйтер иде микән? Ул шунда ук мәет табылган ишегалдына кыйгач торган үр башындагы йортка игътибар итте, аның верандасыннан урам да, дувал артындагы ишегалды да аермачык күренә иде. Тик ул йортка соңрак, кичкырын гына килде. Вакыт бара, ә Чураев тотынырлык бер генә җеп очы да күрми, һәм ул барысын да өр-яңадан—Турганованы тапкан малайдан башларга булды. Аңарга, нишләптер, малай хатынның сумкасыннан икенче фотоаппаратны—«Кодак»ны алгандыр кебек тоелды.

Малай белән әңгәмәдән соң, аның фотоаппаратны күрмәве мәгълүм булды. Дөрес, капитан аның маңгаена терәп сорамады. Алар йортына икенче кат әйләнүен акларга теләгәндәй, Чураев малайдан үтерелгән хатынга ничек тап булуы турында тагын бер мәртәбә сөйләвен үтенде. Бәлки, анын тикшерүче буларак таланты менә шушындый зирәклеге аркасындадыр? Малай инде ничәнчедер мәртәбә кабатлады: кичке эңгердә урамда футбол уйнаганнар, туплары ишегалдына очкан, гадәттәгечә, зуррак малайлар аны туп артыннан җибәргәннәр...Чураев кирәк була-нитә калса дип, малайлар турында, кайсысы типкәннән соң тупның дувал өстеннән очып керүе турында җентекләп сорашты. Менә шунда малай башта тупнын каршы яктагы Сөннәт агаларның ишегалдына тәгәрәвен исенә төшерде, бу вакытта картның яшелчә бакчасында казынган чагы була. Гадәттә ул балаларга тупны койма аша үрелеп биргән, ә монысында нигәдер аягы белән юл аркылы йортның ишегалдына таба тибеп җибәргән дә: »Әнә, барыгыз, тәмам күз бәйләнгәнче Раушанның әбисе ихатасыннан эзләгез!»—дип өстәгән.Үле хатынга юлыккач, алар янына өлкәннәр йөгереп килгән һәм араларыннан берсе: »Милициягә хәбәр итәргә кирәк»,—дигән. Бу урамда телефон Сөннәт агаларда гына булган, карт үзе дә ишегалдында икән, тик ул телефоны төзек түгеллеген әйтеп, малайларга велосипедта барырга киңәш иткән.. Юк кына деталь шикелле, әмма шәрык кешесенә ул күп нәрсәләр

хакында сөйли: бу күнелсез хәбәрне, гәрчә ана катнашлары булмаса да, юристлар теле белән әйткәндә, йөз процент алибилары булуга карамастан, тиешле урынга житкерүдән саклаunion. Үз ишегалдыннан Сөннәт ага очраклы рәвештә булса да бу көнне буп-буш урамданиләр кылынганын күрми калырга тиеш түгел, ин соң чиктә тавышларны ишеткәндер, шуңа да балаларны ишегалдында яткан мәеткә юлыксыннар дип, туп артыннан кертеп жибәргәндер.Тик Сөннәт ага бу вакытта өендә булмаган,имеш, ә аз гына сонрак Чураев «Полароид» белән төшерелгән фотографиягә тап булып, прокурор хатынының кем кулыннан киткәнен белде. Суд барышында Чураев Сөннәт агадан күзләрен алмады—аның икенче шиге дә аклана иде шикелле. Менә шуңа энгер-менгер каплануга, капитан аларга юл тотты.

Сөннәт ага, капитан уйлаганча, куркаклардан булып чыкмады, ул төнге кунакны артык ыгы-зыгы купмый гына каршы алды, югыйсә, милиция таныклыгы күрсәтүгә, бигрәк тә авыл кешесе коелып төшүчән. Ул капитанны ачык верандага алып керде һәм абажурсыз лампочка яктырткан өстәл артына утыртты; аннан, чынлап та, урам һәм каршы йортның ишегалды уч төбендәгедәй күренә иде. Аннары үзенен хата жибәрүен аңлап:

—Мөгаен, сезгә монда тагын да унайлырак булыр,—дип, бакчадагы тәбәнәк айванга ымлады.

«Әлбәттә, миңа да, үзенә дә шулай жайлырак булыр»,—дип уйлап куйды Чураев,чөнки үр башында утырган йортның көчле яктыртылган верандасы әллә кайдан ялт итеп тора иде.

Сөннәт ага да өстәл өстендәге чәйнекне эләктереп, айванга килеп утырды һәм ачыктан-ачык сизелеп торган астыртынлык белән:

—Тыңлыйм сезне, закон кешесе,—диде.

Тик капитан аннан башканы көтмәгән, әле шушы вакытта бусагасын да атлатмас дип уйлаган иде, шуңа астыртынлыгын сизмәгәндәй, йомшак кына башлады:

—Сөннәт ага, мин сездән ни өчен балаларны мәет яткан ишегалдына кертеп жибәрүегез турында да, ни өчен милициягә хәбәр итәргә теләмәвегез турында да сорап тормыйм, әмма мин телефоныгыз эшләгәнен төгәл беләм, чөнки шалтыратып, хатыныгыз белән сөйләштем. Сезнең милиция белән эш йөртергә теләмәгәнегезне аңлыйм. Тик мине бер нәрсә аптырашта калдырды: каршы йорт ишегалдында үтерелгән хатын ятканын кайчан һәм ничек белдегез, йә булмаса күрдегез? Бәлки бу хәл малайлар футбол уйнар алдыннан берникадәр алда, ә бәлкем алар уйнаган вакытта булгандыр? Сезнең верандадан Раушан апаның ихатасы уч төбендәгедәй күренә—менә хәзер мин моңа тагын бер кат инандым. Хәзерге көнгә кадәр жавап табалмыйм: сез бу вакыйганың шаһите, шулай бит?

—Ни өчен нәкъ менә бүген күзегез ачылды?—дип сорады йорт хужасы. Тавышында бернинди каушау юк, бары мыскыл гына чагылып үтте, үзе шулай да төнге кунакка чәй агызды.

—Мин бүген суд дәвамында сезне күзәттем, залдагы хәлләр мине кызыксындырмады, чөнки утырыш барышы миңа көн кебек ачык, өстәвенә магнитофонга яздырып алдым.

—Һәм кайсы ягым белән сезнең игътибарны жәлеп иттем инде?

—Кайсыбер жавапларга сезнең реакциягез кызыклы тоелды. Менә, мәсәлән, монысы,—һәм капитан магнитофонын кабызды, анда судья шаһиткә сораулар бирә иде.

—Бар да ачык булганда, судта минем нинди мөнәсәбәт күрсәтүемнең ни мәгънәсе бар, үтерүче табылды һәм хөкем ителде түгелме соң?—Сөннәт ага әллә сорады, әллә нәтижә чыгардымы, әңгәмәне йомгаклап куйды, тик аның тавышында инде элеккеге эчкерлелек сизелмәде.

—Ярар, нинди мөнәсәбәттә булуыгыз, бәлки, әһәмиятле дә түгелдер, әмма сезнең хәбәрдар булуыгыз—анысы бик мөһим. Тик сезнең реакциягез мине шуңа ышандырды: бу талау максатыннан һөҗүмне Азат Ходайкулов оештырмаган, һәм хет саксызлык аркасында булсын, әмма прокурорның хатынын ул үтермәгән.

Сөннәт ага ачулы көлемсерәде:

—Әйе, әйтәсе дә юк, закон һәм тәртип сагында нинди зирәк, үткен кешеләр тора бездә! Сез нәрсә, бер мин генә икеләнеп калдым дип саныйсызмы әллә? Сез чыннан да Азат Сөен Бикхуҗаевның улына янаган, мәҗбүр иткән, хәтта пычак күтәргән дип уйлыйсызмы? Ул бит ана бик нык ачуы кабарганда да күзен күтәреп карый алмый, бала чагыннан ук лакее ич ул аның. Алар өчен аңлы кешеләр башларын эшләткәннәр: балигълык яшенә җитмәгән берәү булганда, нәрсәгә икәүләшеп җавап тотарга. Билгеле, Азатны бәладә ялгыз калдырмабыз дип вәгъдә иткәннәрдер, ә тегесе шуңа ышангандыр, бигрәк тә аның күз алдында барысы да уйланганча барганда. Димәк, бу вакыйга бераз онытыла төшкәч, ике-өч елдан аны йолып алачаклар. Аңлашыла лабаса, юкка гына дускаен коткарып калмаган—Бикхуҗаевлар үзләренә кирәккәндә саран түгелләр.

—Ә мина, Сөннәт ага, сезнең кебек иманлы, авылның хөрмәтле кешесенә дөреслек, чынбарлык, гаделлек кыйммәтрәктер кебек тоелган иде...

Сөннәт ага бу сүзләрдән башта каушап калгандай булды, аннары аягына күтәрелеп, әңгәмәнең тәмамлануына ишарә итте һәм капитанга карата нәфрәтен яшереп тормастан:

—Менә сезнең кебек, белемле, хакимияттәге кешеләр гаделлек өчен көрәштә ни өчен һәрвакыт үзләреннән алда безне, гади кешеләрне куялар икән? Бу—намуслы кеше эше түгел,—диде.—Әгәр бүген судта торып басып, сез уйлаганнарны яхшылап чыгарып салган булсам—мине дөрес аңларлар идеме икән? Минем бабам, әтием алар кул астында яшәделәр, һәм менә мин дә Сөен Бикхуҗаевка бил бөгәм. Бүген тагын шуны аңладым: балаларым да аның улы Әнвәр Бикхуҗаевтан уза алмаячаклар. Ә хәзергә мин аларны ничек туйдырыйм, алтау бит алар минем—бар да колхоз рәисеннән тора. Һәм мин Әнвәр Бикхуҗаевның юлына аркылы төшимме? Сез үзегезнең ни-нәрсә теләвегезне аңлыйсызмы соң? Ярар, мин көчсез, җебегән, куркак кешеме—теләсә ничек атагыз, анысы сезнең ихтыярда, тик ант әгәр, монда сезнең якка басарлык бер генә кешене дә таба алмассыз. Һәм безне—минеме, башка берәүнеме алай кырыс итеп гаепләргә ашыкмагыз, әлгәре югарыда, үзегез арасында тәртип урнаштырыгыз. Безгә икенче төрле, чын-чынлап халык суды күрсәтегез, үз нәүбәтебездә без дә тезләребезне турайтып, хак сүзебезне әйтербез. Ә хәзер китегез.

Капитан теләр-теләмәс кенә урыныннан күтәрелде дә, хушлашып та тормастан, чыгу юлына юнәлде. Аның артыннан биек дуварның авыр ишеге ябылырга да өлгермәде, ишегалдында ут сүнеп, югалып калган кунак дөм караңгыда калды. Аның күңеле төште. Кайчандыр ул халыкның күндәмлеге—зур байлык, дип саный иде. Ә хәзер, Сөннәт аганың ишегалдыннан чыгып барганда, ул аның зур бәла икәнен аңлады.

## 2

Теге кичтә «Лидо»да өстәл артында элеккеге коллегалары белән туры килгән булса, прокурорның аларга менә нәрсә турында сөйлисе килмәде. Тик әңгәмә барыбер һәрберсенә таныш булган Лариса Павловнаның үлеменә кагылмый калмас иде, мөгаен. Ә аннан соң: «Ничек ул монда—«Лас-Вегаска» килеп чыккан?»—дигән сорау да бирелми калмас иде. Тик кемгә-кемгә, ә аның коллегаларына шәһәрчекнең рәсми рәвештә кулланылмаган

икенче атамасы бик таныш. Һәм янәдән биш ел элек көз ахырынын карлы-янгырлы кичендәге вакыйгаларга, Ташкент хастаханәсеннән чыгып, инфаркт кичергән хәлдә, бата-чума дигәндәй ташландык зиратта йөрүләренә әйләнеп кайтырга туры килгән булыр иде...

Иртә таннан бертуктамый вак янгыр пыскый. Прокурор, машинасын юл кырыенда калдырып, зират тавына жәяү күтәрелде. Шофернын зонт турында искәртүен игътибарга алмады, чөнки бу Ларисанын рухын кимсетер кебек тоелды. Хәтта эшләпәсен дә машинада калдыруны кулай күрде— кабер янына килеп, баш киемен салып, янәдән киеп куюны да ятышсыз, мәгънәсез кыланыш дип санады.

Озакка сузылган көзге янгырлар тауны юып, шомартып бетергән, авыр сары балчык утырган, күтәрелү шактый мәшәкатьле булды. Кабернен баш ягына куелган фанер тактада фломастер белән «1940—1978» дип язылган саннардан кала барысын да янгыр юып төшергән. Ә бу саннар исә хатынына язмыш тарафыннан бирелгән гомер озынлыгын искәртә. Шунда ук ун якка кыйшайган тактада череп бара торган кара тасмалы ике калай венок эленеп тора, аларны, мөгаен, прокуратура һәм Ларисанын музейдагы коллегалары китергән булгандыр. «Шунын кадәрле аяныч, төссез. Кеше исән чакта анын кадерен белмибез, үлгәч тә...Мондый зиратлар—адәмнәр рухыннан көлү, аларны мыскыл итү!»—Башына килгән бу уйдан прокурор сагышланып калды һәм кинәт Эркин Чураевнын гробка заказ биргәндә ары-бире чабып эзләнүен, теләнүен күз алдына китергәндәй булды, барып чыкмагач, гробны ниндидер иске сарай яки койма тактасыннан жыйнаштырмаган булсалар ярый әле... Ларисаны сонгы юлга озату картинасы аермачык булып күзаллануга, бите буйлап ихтыярсыз яшь тамчылары тәгәрәде. Болар—хатынынын башка юк икәнлеген хәбәр иткән теге хәерсез иртәдән сон тамган беренче күз яшьләре иде...

Монын кадәрле фәкыйрьлек, шапшаклык, ташландык уртасында ниндидер сүзләр әйтү урынсыз тоелды, шулай итеп ул кабер янында тын гына басып торганнан сон, хатыны белән сүзсез генә саубуллашып, чыгар юлга атлады.Уйларына уралган прокурор янгырны да, үзенен нык юешләнүен дә сизәрлек хәлдә түгел иде.

Зират капкасына житәрәк, кинәт кенә аягы таяп китте дә, кулларын ипсез жәеп, юеш балчыкка килеп төште. Аягына күтәрелүе булды—тагын егылды. Икенчесендә тора алмады, йөрәге теге чактагы кебек бугазына менде һәм ул, үзе дә сизмәстән, һәлакәткә дучар ителүе белән килешкәндәй, жиңеләеп калды, анын башыннан: «Менә, бар да бетте! Сине саклый, яклый алмавым өчен мине кичерә күр, сөеклем...Жанынны кыючыны жәзага тартырга өлгермәдем. Калай веноклар, исемсез фанер такта өчен дә гафу ит...Жирдә үткәргән сонгы сәгатьләрендә янында була алмавым, кабереңә бер уч туфрак сала алмавым өчен, зинһар, кичерә күр...»—дигән уйлар яшен тизлегендә үтеп китте.

Бер генә мизгелгә күз алдыннан бу калкулыкта төпләнгән зәһәр жилле төннәрне, баш очында тынычлыкны бозып чыңлашкан күгәргән калай веноокларны үткәрде һәм көчсезлегеннән үртәлеп елап жибәрде. Аннан сонгысы төштә күргәндәй булды: ул, бар булган көченә «юк!» дип кычкырып, капкага таба шуыша башлады. Язмышыннан бер ай, бары тик бер ай гомер сорап ялварды, жирдә кадерле хатынынын исемсез кабере калуын теләмәде. Мөгаен, менә шушы исән калу теләге коткарып калгандыр да аны.

Вак иләктән коелган кебек бертуктаусыз янгыр пыскый, карангылык куерганнан-куера бара, аулак зират кырыендагы машиналар, олаулар ермачлаган пычрак юл буйлап кеше үрмәли—ана һичшиксез исән калу кирәк иде.

Жылы машина эчендә йокымсыраган шофер, кемдер тәрткәндәй, кинәт уянып китте—тау башындагы каберлек караңгыга чумган, тирә-юньдә ник бер ут шәүләсе күренсен, шомлы тынлыкта бары янгыр шыбырдавы гына ишетелә. Ул шунда ук прокурор белән нидер булганына төшенде. Күнегелгән гадәте буенча куртка кесәсендәге авыр пистолетын барлады да зират ягына йөгерде. Чыгу юлында жирдә яткан прокурорны шәйләп, тиз генә пульсын капшады, озак уйлап тормастан күтәреп алды да машинасына таба китте.

Кабаттан реанимация палатасы, аннары өлкә хастаханәсенең кардиология бүлеге, анда аны үпкә ялкынсынуыннан да дәваладылар—шулай итеп, тагын яшәү белән үлем арасындагы ике ай үтте. Берәр айдан янына хәл белергә килүчеләрне кертә башлагач, ул ОБХССның шәһәр бүлеге башлыгын күрергә теләвен әйтте. Егерме еллап бу урынны биләгән Гобсек кушаматлы хәлсез генә күренгән кешенең чиксез мөмкинлекләргә ия булганын яхшы белсә дә, үзенең эш дәверендә прокурорның анарга бер генә үтенеч белән дә мөрәжәгать иткәне булмады. Шүрләп калган бүлек башлыгы шул көнне үк килеп житте. Бәлки берәр анонимка килгәндер, дип шикләнгән башлык авыруның беренче сүзләреннән үк жиңел сулыш алды: прокурорның үтенече вак-төяк булып тоелды, шулай да ул һичкайчан сатылмас Азлархановка хезмәт күрсәтү мөмкинлегенә чыгуга бик шат иде.

Икенче көнне палатага карап торышка ук абыйлы-энеле икәне кычкырып торган ике яшь кеше килеп керде, болар шәһәрдә танылган мастерлар—Григоряннар иде. Алар үзләрен тиешле дәрәҗәдә тоттылар, авыруга тирән ихтирамнарын белдерделәр, прокурорның хәлен сизеп, аны бүлдермичә тыңладылар.

—Сезгә, мөгаен, ни өчен чакыруымны аңлатканнардыр?

Ир туганнар сүзсез генә башларын селкеделәр.

—Минем бернинди планым, тәкъдимем дә юк.Сезнең зәвыгыгызга, осталыгыгыз, талантыгызга ышанам. Ир-ат буларак сезгә бер нәрсәне генә әйтәм: мин аны бик яраттым...—Һәм ул аларга хатынының фотографиясен сузды.

—Без дә, ул да бер-беребезне яхшы белә идек, без бит скульпторлар, менә бит ничек килеп чыкты...—Бераз тын торгач, өлкәнрәге дәвам итте:—Без иртән барып килдек инде. Зират ташландык хәлдә булса да, кабер урыны без энем белән күз алдына китергән таш өчен отышлы сайланган...Сез борчылмагыз, безгә таяныгыз, менә диген итеп ясарбыз, фотографияне сезнең рөхсәт белән алабыз...—Туганнар торып бастылар.

—Бер генә минут,—прокурор аларга сабыр итәргә ишарәләде.—Хезмәтегез күпме торачак?

Туганнар бәяне әйттеләр, аз түгел, тик чынлыкта бу эш күпкә кыйммәтрәк тора иде. Прокурор хәлсез генә елмайды да алдан ук әзерләп куйган конвертны сузды.

—Менә рәхим итегез, исәп-хисапны башта ук ясап куйыйк...минем хәлемне күрәсез, бүген исән...Монда сез әйткәннән өч мәртәбә артык...

Тегеләре шунда ук ябыштырып куелган конвертны ачмакчы булдылар, тик ул аларны тагын туктатты:

—Кирәкми. Без бала-чага түгел. Һәр хезмәт, бигрәк тә андый эш, тиешенчә бәяләнергә тиеш. Ә минем үтенечем буенча сезне эзләп тапкан кешегә икенче, үзегез теләгән сумманы әйтә аласыз, мин каршы түгел...

Ир туганнар аны аңлап елмаештылар да шыпырт кына палатадан чыктылар.

Прокурор күзләрен йомды. Шулай да өлгерде...Әйбәт булды, өлгерде...

## 3

Прокурор Лахути урамындагы йортта август ахырында, Ларисаның үлеме турындагы иртән килеп ирешкән хәбәрдән соң биш ай узгач кына кабат күренде. Гыйнвар аеның уртасы үтеп бара, күкне томалап коелган вак кар бөртекләре урам юлларына ята да, аяк астында изрәп, бик тиз арада пычрак боламыкка әйләнә. Әмма бакчага тел-теш тидерерлек түгел, ул элеккечә матур. Зәңгәр чыршыга күзе төште, аның беренче мәртәбә Яна елда бизәлми калуына үзәге өзгәләнде.

Прокурор кышка капланмый калган йөзем куакларын күзеннән кичерде: анда-санда көздән җыелмый калган тәлгәшләр күренә, бигрәк тә «Тайфи» дигән сорт чыдам, нык булып чыкты, аның кызыл чуклары урыны-урыны белән кибеп, төсләрен җуйсалар да, югалган хуҗаларын көтәргә булганнар. Әлегә көчсез, зәгыйфь тәбәнәк агачлар беренче мәртәбә кышка әзерлексез керде, һәм хуҗалары, әгәр бакча исән чыга икән—бу бары тик язмыш бүләге, очраклылык кына булачак, дип уйлаганда, үзен дә куз унында тотты. Чирәмлекне әрсез чүп үләннәре басып алган, ә җанлы койма булып тезелгән куаклар кыркып тигезләнмәгән. Эшләү, булдыру өчен күпме хезмәт, көч сарыф ителә, ә булганны юкка чыгару өчен бик аз вакыт та җитә...

Ул сары яфраклар каплаган сукмактан бакча түренәрәк үтте, күңелендә бәхетле чакларындагы вакыйгаларның берәр мизгелен генә яңартырга тырышса да—барып чыкмады. «Тайфи»ның эре бер тәлгәшен өзеп алды да хәзер үзенә ят булып тоелган өенә керде.

Ике атнадан прокурор Кырымга очты. Рәттән китереп бәргән ике инфаркттан соң, ул санаторийда ныклап дәвалануга һәм тәҗрибәле табиблар күзәтүенә мохтаҗ иде.

Кырым ана файдага булды, монда күңеле күтәрелеп китте һәм инде ул үзен һәлакәткә дучар ителгән итеп сизмәде. Февраль урталарында Ялтага килде, монда кышның эзе дә юк—чәчәк бөреләре тулышып килә, тирә-юньдә, күңелне иләсләндереп, яз исе, диңгез исе аңкый. Таулардан, «Массандра» виноградлыкларыннан йөгерек җил шәһәргә йокыдан уянып тормышка омтылган туфрак исе ташый. Прокурорның кәефе күтәрелүгә, мөгаен, тирә-ягын әйләндереп алган әнә шул табигатьнең яшәешкә, үсешкә, чәчәк атуга җан тырмашуы да тәэсир итми калмагандыр. Ул ялгызы озаклап яр буйларын сәйран кылды, причалларга килеп сыенган корабльләрнең исемнәре белән кызыксынды, тик алар бар да күптән түгел генә төзелгәннәр, суга төшерүләренә биш-алты еллап кынадыр, ә аның кайчандыр яшьлегендә үзе хезмәт иткән корабльгә охшаш берәр кораб-ветеранны күрәсе килә иде. Гаҗәп: Тын океанда дүрт ел гомерен калдырып кайтса да, ни диңгез, ни кораблар анарда җирсү уята алмадылар, шул чаклардан хәтерендә бер генә нәрсә уелып калган—флотта ул үз-үзенә, һичшиксез, юрист булырга һәм гомерен гадел хөкемгә багышларга дип сүз бирде. Кайчандыр, моннан күп еллар элек, эсминец палубасында томанга уралган ярларны шәйләргә тырышып, алдагы томышының ничек, нинди юлдан китәрен уйлап, дулкынланып басып торганы исендә. Менә хәзер, чирек гасырдан соң, кояш җылыткан яр буенда горизонтка китеп югалган диңгез киңлегенә төбәлеп торганда, аны шул ук сорау бимазалады.

Карсыз кыска кыштан соң, янәдән кафелар җанланды, яр буйларына пластик өстәлләр чыгарып тезделәр. «Восток» дигәне прокурорның күңеленә аеруча хуш килде, һәм,төш узуга, ул шунда килә торган булды. Бу сәгатьләрдә кафеда кеше аз була, озак тоткарланмый анарга гадәттәгечә бер шешә минераль су белән авыр үпкә ялкынсынуыннан соң табиблар язган бер стакан кызыл кырым «Алушта»сын китереп тә житкерәләр. Ул, тирә-юнендәгеләрне шаккатырып, ашыкмый гына бер стакан виносын

минераль су белән катнаштырып уртлый-уртлый, җылы кояшта изрәп утыра. Сирәк-мирәк кенә күршесе белән сүз алышкалый, әмма ялгыз булуны артыграк күрә иде. Төп причалга каршы урнашкан кафеның ачык верандасында озаклап уйланып утырган прокурорда картлык чалымнары чагылып китә, электән күреп белгән танышлары да соңгы ярты елда аның кинәт кенә өлкәнәеп китүен күреп,мөгаен, аптырашта калырлар иде.

Тик аның диңгез кинлекләренә китеп адашкан күз карашында һич кенә дә Босфорга юнәлгән корабль силуэтлары чагылмый. Бәлки ул теге зират калкулыгында «йөридер», йә хатыны истәлегенә һәйкәл коючы Григоряннарны исенә аладыр. Юк, ул район суды турында да, «шаһит» Әнвәр Бикхуҗаев турында да онытмады, тик көрәшер өчен сәламәтлеге ныгып җитмәгәнгә, тырышып-тырмашып ул уйларны башыннан куалап маташты. Ике инфаркттан соң көч-хәл белән аякланган прокурор өченчесе китереп бәрүдән курыкмады, анарга нәкъ менә шул өченчесенә кадәрге араны мөмкин кадәр озайту максатында йөрәген ныгыту мөһим, Бикхуҗаевлар кланы белән алышу өчен күпме вакыт китәчәк, шунын кадәрле генә булса да яшәргә кирәк иде анарга. Теге вакытта, көзге яңгыр астында, зират калкулыгында язмыш аңа карата мәрхәмәтле булды, һәм ул аның тагын бер мәртәбә мөмкинлек бирәсенә ышана, Аллаһы Тәгаләгә шуннан башка гозере, үтенече юк .

Март аенда, инде дәвалау курслары бетәргә ун көннәр калып барганда, прокурор һич уйламаганда капитан Чураевтан хат алды. Нәрсә дип әйтергә, күнелсез һәм шомлы хат иде ул. Капитан хатында көтмәгәндә полковник Иргашевның дәрәҗәсен күтәрүләре, аның өлкә милициясен житәкләве һәм хәзер Чураевның турыдан-туры башлыгы булуы турында хәбәр иткән. Шул ук вакытта үтерү эшен тикшергән район прокуроры Исмәгыйлевне дә күтәргәннәр, анысы да шәһәр прокуратурасында шактый зур урынны биләгән икән. Капитан хәбәрләрен шәрехләмәсә дә, прокурор Бикхуҗаевлар кланының ярты ел элек биргән вәгъдәләрен бик мулдан үтәүләренә төшенде. Бары тик судья гына үз урынында калган, тоташ егерме ел биләгән бу урыны өчен ул болай да язмышына рәхмәтле, өлкәнәеп барган бу адәмне хезмәт карьерасы, билгеле, хәзер кызыксындырмый иде инде. Тик ул да буш калмагандыр, мөгаен, судьяның балалары, оныклары файдасына башка гамәлләр каралгандыр.

Әмма прокурорны икенче бер хәбәр чыгырыннан чыгарды, күрәсең, хат та шуның аркасында юллангандыр. Капитан менә ниләр яза: яна житәкчесе аны милициядән кысрыклап чыгару белән генә чикләнмичә, маддә буенча куачагын белдергән : тәҗрибәле Иргашев өчен моны эшләү—ике тиен бер акча, янәсе. Капитан прокурордан үзен башка өлкәгә яки Ташкентка күчерүдә ярдәм итүен сораган. Прокурор төшенде: полковник Иргашев капитан Чураевның судка билгеле булганнан күбрәкне белүен чамалап, тиз генә аңардан котылырга ашыккан. Инде капитан Чураев ачыктан-ачык ярдәм сораган икән, димәк, хәл, чыннан да, җитди төс алган. Ул шул ук көнне Ташкент белән сөйләшергә заказ бирде, һәм бер атнадан капитанны башкалага күчерү мәсьәләсе хәл ителде.

Капитан Чураевның ачынып язган хатын алу прокурорны уятып җибәргәндәй булды: ныгып җитмәгән йөрәге тагын бер сынауны күтәрә алырмы йә шартлап ярылырмы—анысын уйлап тормады, хәрәкәт итәргә вакыт җиткәнен аңлады...

Ялтадан үзенең Лахутидагы йортына әйләнеп кайтканда, март ахырлары иде. Юл буе ташландык хәлдә калдырылган йорты, бакчасы турында уйланды, агачлар кышны уздыра алдылармы икән дип борчылды, киткәндә нәрсәдер эшләргә ни сәламәтлеге, ни көче, ни теләге булмады шул. Урам

капкасын ачып керүгә, гаҗәпләнүеннән катып калды: бакча кышны исән-сау чыккан! Ларисасы берәмтекләп дигәндәй җыйган тәбәнәк куаклар яшелгә төренгән; ишегалдының ерак почмагындагы карт платан ышыгында, аны көткәндәй, ялгыз лалә кояшка үрелгән; фарсы сиреңенең соңгы таҗлары күзләрен йомарга әзерләнгән. Күптәннән ботаклары киселмәгән куаклар да исән-имин кышлаганнар, язгы яңгырлар белән туенып, виноградлыкны да уздырып буй җибәргәннәр—тере койма булып басканнар, күләгәләре инде сукмакларга сузылган. Яшеллеккә күмелгән бакчасын күреп, прокурор җиңел сулыш алды.

## 4

Ярты еллап югалып торганнан соң, Әмирхан Даутович, беркемне кисәтеп тормастан, прокуратурага килеп керде. Хәер, аның санаторийдан кайтканын күпләр ишеткән иде инде. Прокурорны бер нәрсә гаҗәпкә калдырды: аның мөһерләнеп куелырга тиешле эш кабинетында аны вакытлыча алыштырган адәм утыра иде. Урынбасарның элеккеге кабинеты да шунда ук—кабул итү бүлмәсе аша гына, монда кереп урнашыр бернинди сәбәп юк, югыйсә.

Әмирхан Даутович кабинетын ун еллап рәткә китерде, кайчакларда аннан тәүлекләр буе чыкмады, хәтта куныш калган чаклары да булды. Шул еллар эчендә шәхси әйберләре дә шактый тупланды, һәм менә хәзер таныш булмаган кемсәләрнең аның китапларын актаруы, душта сөлгеләрен файдалануы прокурорның күңелен кайтарды. Билгеле, ул берәүгә дә теллән ризасызлыгын белдермәде, әмма канәгать булмавы йөзенә чыккан иде. Эш сәгатьләре тәмамланганчы монда калырга теләгән урынбасарына ризалыгын бирмәде. Аптырашта калган урынбасары үз бүлмәсенә чыгуга, ул тәрәзәләрне киереп ачты да җыештыручы хатынны чакырып алды. Шактый сөйләшеп утыргач, аңардан бүлмәсен яхшылап җыештырып чыгаруын һәм җилләтүен үтенде, берочтан бар савыт-сабаны алмаштыруын сорады. Теге бәхетсез көндә ашыгу сәбәпле мөһерләргә өлгермәгән сейфын яхшылап күздән үткәргәч, үз вазифаларына керешәсен хәбәр итү өчен, өлкә комитетына юнәлде һәм ул көнне прокуратурада башка күренмәде.

Өлкә комитетына бару юлында ул сейф тирәсендә бөтерелде—сейфта аның һәрбер район өчен аерым тупланган амбар кенәгәләре бар иде. Аларның урынында булуларына ул икеләнмәде, әмма үзе булмаган айларда чәйнеге, пиаласы, стаканы, сөлгеләренә сузылган кулларның анда да җитешүеннән шикләнде. Прокурор шәһәрдә үзенең сейф шифрыннан җитдирәкләрне ачып бирердәй өч кешенең барлыгын тәгаен белә, әгәр инде урындагыларга мөрәҗәгать итәргә теләмәсәләр, андый эшкә осталар өлкәдә берничә җирдә урнашкан төзәтү-хезмәт лагеренда аз түгел—полковник Иргашевның теләсә кайсын китертергә бер ымы җитә.

Өлкә комитетында да, прокуратурада да хатынының вакытсыз вафат булуы уңаеннан кайгысын уртаклашучыларның байтагын прокурор теге август ахырында булган хәлләрдән соң беренче тапкыр күрә иде. Кайгысын ихластан уртаклаштылар: Лариса Павловнаны хөрмәт итәләр иде, яраткан кешесен югалтканнан соң, прокурорның хастаханәдән хастаханәгә күчерелүен, инфаркт арты ифаркт кичерүен беләләр һәм хәленә керделәр. Хәтта прокурорның тышкы кыяфәте үк нинди зур фаҗига кичерүен сиздереп тора: чәчләре чаларган, берничә елга картайган, авыртулардан чүгеп калган шикелле. Бу көннәрдә кем белән генә аралашмасын, берсе дә ни суд, ни Ларисаның үлеменә китергән сәбәпләр турында авыз ачып сүз әйтмәде, күрәсең, тиз арада үткәрелгән судтан барысы да канәгать калган: җинаятьче тотылган, гаебен таныган һәм тиешле җәзасын алган—тагын ни кирәк, янәсе.

Шул көннәрдә эшлекле кинәшмәләрнең берсендә Әмирхан Даутович полковник Иргашев һәм җинаять кылынган районның элекке прокуроры, хәзергесе вакытта шәһәр прокуратурасында эшләүче Исмәгыйлев белән очрашты. Алар икесе дә аның янына килеп хәлен белештеләр һәм үзләренең бурычларын үтәүләрен, тик фаҗиганең алар җирендә килеп чыгуына кайгыруларын белдерделәр. Прокурор тыенкы гына рәхмәт әйтте, әмма ни суд, ни тикшерү нәтиҗәсе турында сорашып тормаска булды. Тикшерү эше аның өстәлендә ята һәм ул хөкемгә тартылучының якында гына—кайчандыр полковник Иргашев эшләп киткән күрше өлкәнең төзәтү-хезмәт колониясендә икәнен белә.

Прокурор хатынының үлеме буенча җыелган документларны инде ничәнче тапкыр кулына алды. Билгеле, тота-каба ябышырлык сәбәп юк кебек, беренче карашка бар да тәртиптә, тик артыгын төпченгән кешене тикшерү эшенең һәм судның шома, җинел, ин гаҗәпләндергәне—бик тиз арада башкарылуы барыбер сагаерга мәҗбүр итә, ни генә дисән дә—сүз кеше үтерү турында бара бит. Прокурор шуны бик яхшы аңлады: әгәр ул төнне аның белән бәхетсезлек килеп чыкмаган булса, үтерүдә шик төшкән егет гаебен таныса да, иртән җентекле тикшерү үткәрелми калмас иде, аннары «кайнар» эздән һәр икесеннән дә үтерештән соңгы вакытларын минутлап язып бирүләрен сорарлар иде, һәм менә шул чакта кече Бикхуҗаев үзенә тәкъдим ителгән шаһитлык ролендә, ай-һай, озакка кала алган булыр иде микән? Гаепләнүченең әнисе биргән күрсәтмәләр дә бик ярап куйган булыр иде, ул бит капитан Чураевка улының кичкә кырын Бикхуҗаевларга барып, дустына янавы дөреслеккә туры килмәве, киресенчә, караңгы капкач, Әнвәр Бикхуҗаевның күз явын алырлык «Ява»сында улын махсус кунакка алырга килүе турында сөйләп биргән. Әйе, прокуратура капитан Чураевны эштән читләштермәгән һәм тикшерүне полковник Иргашев үзе алып бармаган булса, суд ничек килеп чыккан булыр иде—билгесез. Хәтта капитан Чураев «Полароид» белән төшерелгән сурәтне тапшырган кешене һәм ишегалдында булган хәлләрне үз коймасы аша күреп торган Сөннәт аганы шаһит буларак судка китертә алмаган очракта да, Әнвәр Бикхуҗаев судан коры чыга алган булыр иде микән?

Әгәр ул төндә аны инфаркт екмаса, зур йогынтылы кланга ярарга тырышкан акыллы башларга каршы төшеп, гаепләнүченең күрсәтмәсе генә җитмәгәнлеген, суд аның гаепле булуын расларга тиешлеген таләп иткән булыр иде. Тик болар барысы да—әгәр, әгәр дә... генә инде шул... Бикхуҗаевлар кланын да исәптән чыгарып булмый, инфаркттан терелеп аякка баскач, өлкә прокуроры эшне кабаттан кузгата калса дип, көтмәгәндә, уйламаганда килеп чыккан шушы вакыт аралыгын үз кирәкләренә файдаланмаган дип кем әйтә ала? Бу очракта төп авырлык шунда: ул нәрсәгә генә тотынмасын, һәрбер адымы каршы як өчен аны ялгышлыкта, берьяклылыкта, шәхси үч алуда, эш урынын явызларча файдалануда гаепләү мөмкинлеге бирәчәк, моның ахыры исә нәкъ капитан Чураевныкы кебек тәмамланачак—аны эшенә якын да китермәячәкләр.

Бердәнбер юлы калды һәм ул шулай эшләде дә: республика прокурорына, артык ваклыкларына тукталмыйча, хатынын үтерү эшен кабат торгызуларын үтенеп, шәхси хат юллады. Атна үтеп китте, икенчесе, өченчесе түгәрәкләнде, әмма республика прокуратурасыннан ни язмача җавап күренмәде, ни телефон шылтыратуы ишетелмәде. Аның каравы ниндидер агымдагы эшләр белән партия өлкә комитетына кергәч, администрация бүлегендә көтелмәгән сөйләшү булды. Ул инде эшен тәмамлап, чыгып бара иде, бүлек мөдире сизелерлек каушый төшеп, аның тагын берничә минутка тоткарлануын үтенде. Ул ерактан башлады:

—Әмирхан Даутович, сезне монда ничек хөрмәт итүләрен, бәяләүләрен үзегез дә сизәсездер. Республика буенча сүз йөрткәндә, безнең өлкәдә хокук тәртибе бер баскычка югары тора. Бу, билгеле, турыдан-туры сезнең хезмәтегез нәтиҗәсе. Без моны бик яхшы аңлыйбыз. Коллегаларыгыз арасында зур абруйга ия булуыгызны да беләбез. Шуңа күрә Лариса Павловнаның фаҗигале үлеменнән соң какшап киткән сәламәтлегегез өчен без барыбыз да бик борчылдык. Җәмәгатьчелектә бу кайгылы хәбәрнең нинди көчле яңгыраш алуын күз алдыгызга да китерә алмыйсыз,—минем кабинетымдагы телефон бер генә минутка да тынып тормады. Бар да үтерүчене тиз арада табуны һәм җәзага тартуны таләп иттеләр, безнең якларда хатыныгызны бик күпләр белә, аның уңышлары белән горурланалар иде бит. Шуңлыктан, без кулыбыздан килгәннең барысын да эшләдек диясем килә һәм халыкны тынычландырдык дип уйлыйм, югыйсә, шундый шау-шулы эштә хокук саклау органнарының акрын кыймылдавын, сузуын берсе дә аңламас, кичермәс иде. Шәһәрдә нинди генә имеш-мимешләр йөрмәде, мин кешеләргә дистәләгән тапкыр сезнең исән-сау икәнегезне, менә-менә эшкә чыгарыгызны аңлатырга мәҗбүр булдым. Безгә сез булмаган арада менә шундый киеренкелектә эшләргә туры килде.—Аннары, ничек башларга белми бераз туктап торганнан соң, әңгәмәне үзенә кирәкле юнәлешкә борды.—Менә хәзер сәламәтләнеп, кабаттан безнең сафларга әйләнеп кайтуыгызга куанып, җаныгыз аз гына булса да тынычлык тапты дип йөргәндә, сез янәдән хатыныгызны үтерү эшенә кире кайтырга уйлыйсыз икән. Билгеле, мине дөрес аңласагыз иде, сүз дә юк, моны таләп итәргә хакыгыз бар, тик бу сезнең сәламәтлегегезгә, эшегезгә тискәре йогынты ясамасмы соң? Янәдән калкып чыгачак җәмәгатьчелек фикере турында әйтеп торасы да юк, кабат кирәкмәгән гайбәтләр, сүзләр китәчәк. Сез нәрсәгә ирешерсез—анысы әле билгесез, әмма тавыш-гаугасы, дөресен әйтим, чамасыз күп булачак. Эшне кабат күтәрүне сораган үтенечегезне дөрес аңламаслар һәм якламаслар дип уйлыйм. Тик бу минем шәхсән үз фикерем генә һәм,зинһар, бу иптәшләрчә сөйләшүне үзегезнең шәхси тормышыгызга, аннан да бигрәк прокурор эшчәнлегенә тыгылу дип саный күрмәгез.

Прокурор бүлдермичә, сүзсез генә тыңлап торды,—ул шунда ук бүлек мөдиренең кемдер тарафыннан йөкләнгән бу җаваплылыкны бик авырыксынып башкаруын сизеп, аңлап алды. Бәлки ул чынлап та ихластан сөйләгәндер, аның фикер йөртүендә дә логика бар, тик ана прокурорның бу эш буенча белгәннәренең мыскалы да таныш түгел иде. Бәлки әле ул үзенчә, шаһит буларак катнашкан Әнвәр Бикхуҗаев та күпмедер күләмдә җәзага тартылырга тиештер, диебрәк тә фикер йөрткәндер. Тик һәр нәрсәне бизмәнгә салып үлчәргә гадәтләнгән кеше буларак, моның өчен генә яңадан җәмәгатьчелектә ыгы-зыгы куптару, суд барышы һәм нәтиҗәсендә ниндидер хаталар булуын тануны кирәк дип санамады. Прокурор бу сөйләшүнең үзен сынау максатында үткәрелүен, кисәтү икәнен аңлады. Тагын шунысын да чамалады: аның хаты өлкәдән ары китмәгән һәм юкка гына ул республика прокурорыннан хәбәр көткән булып чыга. Бүлек мөдиреннән хат турында да, бу сөйләшүнең башында кем торуы турында сорашып тормады. Сәламәтлеген кайгыртуы, Лариса Павловнаны искә алуы өчен рәхмәт әйтеп, җавап кайтаруны кирәксенеп тормыйча саубуллашты. Мөдир дә төшеп калганнардан түгел, тикмәгә генә аңарга бу четерекле сөйләшүне үткәрү ышанып тапшырылмагандыр, ул да прокурорның уеннан кире кайтмаслыгына төшенде.

Өлкә комитетында булганнан соң, прокурор башкалага кабат хат язуның мәгънәсез икәнен аңлады; берәр айдан анда бик зур киңәшмә буласы, менә шунда ул, уңай вакытны чамалап, республика прокурорыннан үзен кабул итүен үтенер. Бу очрашуга ул җентекләп хәзерләнергә тиеш, кем белә: бәлки

капитан Чураев белән бергә бару җаен табарлар.

Иң элек эшне Сөен Бикхуҗаевның өлкәдә зур урыннар биләгән якын туганнарын барлаудан башлады. Ирләренең фамилияләрен алган ике кыз туганын ул үзе ачыклады, әмма өлкә комитетындагы белгечләр исемлегендә ике ир туганы гына бар, шуңа ышанычлы дип санаган кешеләргә мөрәҗәгать итәргә туры килде, һәм бик тиз арада депутатның башка фамилияләр алган дүрт ир туганы да табылды. Шәрыкның нечкәлекләрен белеп бетермәүчеләр гаҗәпкә калырга мөмкин, ничек инде... әмма биредә бертуган абый-эне, апа-сеңелләр төрле фамилия йөртергә мөмкин,—әйтик, әтисенекен йә бабасыныкын ала. Еш кына шундый хәлгә тарасың, берәр түрәгә кайсы да булса бюрократтан йә ришвәтчедән зарланып торасың, ә ул исә аның кыз яки ир туганы булып чыга. Колхоз рәисенең ир һәм кыз туганнарыннан кала өч улы бар, ягъни «шаһит»ның бертуган абыйлары, һәм алар да өлкәдә, районда югары урыннар билиләр. Прокурор төзегән исемлек шактый озын булып чыкты—әлеге клан читтән ярдәмгә өметләнми дә теләсә нинди каршылыкны җиңә, теләсә кемне урынына утырта алырлык иде. Әле алардан башка тагын күпме якын һәм ерак туганнары, кланга бәйле булган тугрылыклы кешеләре...

Күнеленә республика прокуроры кабул итми калмас дигән ышанычны беркетеп, тынычланып калды һәм кабаланмый гына очрашуга әзерләнә башлады һәм шушы нияте күңелен күтәреп җибәрде.

Табигатьтә яз үзенең хакимлеген урнаштырган мәл. Прокурор озаклап бакчасында кайнашты. Елларның берсендә бакчачы чакыртып, куакларны кыркыдылар. Ишегалды зураеп, иркенәеп китте. Эштән кайткач, бакчаның, ишегалдының һәрбер почмагын җыештырды, чүпләрне түкте. Ташландык хәлгә житкән ихата атна эчендә элеккеге хәленә кайтты. Әмма бакчада, ятимләнеп калган өйдә эш-мәшәкать шунын кадәрле күп, шимбә-якшәмбеләр, озын язгы кичләр сизелми дә үтеп киттеләр. Кышкы суыкларны кичерә алмаган виноград сабакларын кисеп, яшь үсентеләр өчен тирәүләр куйганда, үзе теләмәсә дә, уе Ташкент, гаделлеккә ирешү мөмкинлеге бирәчәк очрашуга әйләнеп кайтты.

Бикхуҗаевлар үзенә карата ничегрәк тотасын чамалап, ул планының, шахмат уенындагы кебек, берничә вариантын уйлады. Алар аның абруен, дәрәҗәсен төшерү өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшләячәкләр—монысын ачык белә, чөнки бу ысул тормышта бик күп мәртәбәләр расланган юл инде. Ул үзен-үзе белгәннән бирле намусы кушканча яшәргә тырышты, шуңа күрә кайсы яклап караса да, үзендә «таплар» таба алмады. Бу җәһәттән клан һәм аңа киңәш бирүчеләргә шактый кыенга туры киләчәк.

Кинәт башына китереп органдай булды: «Хөкем ителүче, ярый әле, клан һәм полковник Иргашев кул астында түгел, ерактә утыра». Әгәр дә тоткын белән берәр хәл була калса, мәсәлән, бәхетсезлек очрагы—прокурорның планы барып чыкмаячак, ул чакта аның эш-гамәлләре шәхси үч алуга кайтып калачак. Һәм ул кәгазенә, кирәк була калса дип, очрашуда прокурордан тикшерү тәмамланганчы сакчыларның күзәтүен көчәйтүне үтенергә кирәклекне билгеләп куйды. Вакыйгалар астында калган намусы уянып, егет үз куллары белән муенына элмәк салырга мөмкин—Бикхуҗаевлардан монысын да көтәргә була.

## 5

Өлкә комитетының администрация бүлегендә булган сөйләшүдән соң ике атналап узды микән, иртән иртүк прокурор кабинетында телефон шылтырады. Чыбыкның теге очында өлкә комитетының беренче секретаре иде. Эшкә чыкканнан соң, ул «беренче» белән берничә тапкыр очрашты,

ә берсендә алар дүрт сәгатьләп утырдылар, авырып яткан вакытында хәлителәсе әһәмиятле эшләр бик күп жыйналган иде.

Алдагы көндә генә күрешкән булганга, шылтырату прокурорны гажәпләндерде. Шулай ук беренче секретарьның коры, тыенкы тавыш белән көннең беренче яртысында өлкә комитетына кереп чыгуын соравы да аптырашта калдырды. Сөйләшү ни-нәрсә турында барачак, нindирәк кәгазьләр кирәк булачак—бу турыда ләм-мим, бер сүз әйтмәде. Вакыты да шаккатырды: гадәттәге «хәзер үк» яисә «шул сәгатьтә» түгел, ә «көннең беренче яртысында». Прокурорга әңгәмәгә әзерләнү өчен мөмкинлек бирүеме, әллә киресенчә,күңелен тынычсызлап, борчылырга мәжбүр итүеме?

Озак еллар өлкә прокуроры булып эшләү аны күп нәрсәгә өйрәтте, бигрәк тә түземлелеккә, салкын канлылыкка; югыйсә, нервлары какшаулар сәбәпле монда артык тоткарлана алмас иде, һәм ул секретарьның үзе белән ягымлы яисә коры сөйләштеме икәнен тикшереп тормады, чөнки ул да эш кешесе, көн тудымы—көтелмәгән хәл, мажара, һәрвакыт елмаеп кына торып булмый. Тик күңеле белән сизде: сөйләшү шәхсән аңа кагылышлы иде.

Прокурор кабул итү бүлмәсенә төш житәрәк килеп керде. Сәркатип кызга аның киләсе турында алдан искәртеп куйганнар иде, күрәсең. Ул башы белән шәп күннән тышланган ишеккә ымлады: «Көтә, инде ике тапкыр сорады».

Прокурор кабинетка керүгә, өлкә комитеты секретаре урынынnan күтәрелеп, каршына атлады, кәефе күтәренке вакытларда ул үзен гел шулай тота иде. Шәрыкта элек-электән килгән гадәт бар—сорауны шунда ук, маңгайга терәп бирмиләр, башта сүз жаенда дигәндәй саулык-сәламәтлек, гаилә хәлләрен сораштыралар, аннары инде эшкә күчәләр. Әле кичә генә очрашкан булсалар да, секретарь прокурорның хәлен сорашты, ярдәм кирәкмиме икәнен белеште. Аннан соң сәркатипне чакырып, чәй кертүен үтенде. Тегесе исә кабинет хуҗасының үтенечен көтеп кенә торган диярсең, күз ачып йомганчы чәйнек һәм касәләр күтәреп кереп тә житте. Прокурор сүзнең озынга китәсен чамалады.

Секретарь өлгер сәркатипкә рәхмәт әйтеп, касәләргә чәй агызды, әмма утырып тормады, кулына касәсен алып тәрәзә янына килде. Кабинет тәрәзәләре ишегалдына—бик матур бакчага караган. Әле өлкә комитетында төш вакыты, хезмәткәрләр жәйге ашханә һәм чәйханәдә утыралар. Кайчандыр урыс генерал-наместнигы өчен төзелгән борынгы йортның өченче кат тәрәзәсеннән пешекчеләрнең нәрсәләр белән сыйлаулары ачык күренә. Хәер, пылау, кыздырылган кәбап, кайнар бөккән, Туладан килгән делегация бүләк иткән өч чиләк сыешлы самовардан чыккан ангрен күмере исләре ачык тәрәзәдән кабинетка да агылып керәләр. Берничә тапкыр бакчада бергәләп төшке ашта булсалар да, бүген бу үзенчәлекле исләр аларның игътибарын жәлеп итә алмады.

Беренче кемнедер күзәткән кебекме, әллә сөйләшүне башларга кыенсыныпмы, сүзсез генә тәрәзә каршында басып торды, прокурорның монарчы аны андый икеләнеп калган хәлдә күргәне булмады. Бераздан ул үзенең алагаем зур өстәле янына килде, аерылып, күренеп торган кәгазь битен алды да чәйнек торган өстәл артына утырды. Кунакка да урын күрсәтте һәм кулындагы хатын сузды. Аны чакыртып алуга, мөгаен, шушы хат сәбәпче булгандыр—һәрхәлдә, прокурор шулай аңлады.

Кулына алуга, фирма бланкысындагы гарәп, инглиз, рус телләрендә зур хәрефләр белән жыелган учреждение атамасы күзгә ташланды. Прокурор «Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнарының дини идарәсе«дигән язуга күз йөртеп чыкты да бер генә мизгелгә кабинет хуҗасы кәгазьләрне бутамады микән дип шикләнеп калды. Аптыраулы карашын күреп, Беренче аны жәлләп куйды һәм:

—Юк, юк, ялгышмадың, алга таба укы. Әллә үзенә генә кемнәр өстеннәндер аноним хатлар һәм шикаятьләр агыла дип белдеңме? Менә, синең өстән дә бар, ун ел эчендә беренче мәртәбә, һәм бик вакытсыз килде, әйтерсең, кемдер сине, шуның кадәрле авырлыкларны кичергәннән соң, тәмам аяктан егарга уйлый...

Хат ике адреска җибәрелгән: республика коммунистлар партиясенең ҮКна һәм копиясе—өлкә комитетының беренче секретарена. «Зурдан, бик зурдан кубып башлаганнар»,—дип уйлады прокурор. Дулкынлануын сиздермәскә тырышып, күзен хат юллары өстеннән йөртә башлады.

«Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнарының дини идарәсе сезгә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Менә ничә еллар инде Азлархanов Ә. Д.ның керамика коллекциясендә Сардоба авылының Балан мәчетеннән алынган бу як мөселманнары өчен аерата дини кыйммәткә ия әйберләр саклана. Тумышы белән шушы авыл кешесе, үз акчасына Балан мәчет салдырган сәүдәгәр Якуб хажи 1867 нче елда мөселманнар өчен изге урынга—Мәккәгә хаж кылырга барган. Әйләнеп кайткач озак тормаган, үләр алдыннан үзенең бар малмөлкәтен авыл мәчетенә васыять иткән. Шушы әйберләр арасында дингә ышанучылар өчен кыйммәтле саналган көмеш бизәкләр төшерелеп, эче көмеш эмаль белән капланган, ерак юлларда су сакларга уңайлы ике савыт та булган. Бу савытлар Бохара әмире сараеның чүлмәкчесе Талимәрдан оста кулы белән ясалган. Алар Якуб хажи белән бергә Мәккәгә кадәр озын юл үткәннәр һәм изгеләндерелгән саналганнар. Хаҗиның вафатыннан соң, бу савытлар мөселманнар өчен тагын да зуррак кыйммәткә ия булганнар.

Дөреслекне раслау өчен хатка өстәп, Балан мәчетендәге әйберләрнең төсле сурәтләрен дә җибәрәбез. Фотография 1978 нче елда Локарнода (Швейцариядә) чыгарылган сәнгать альбомыннан алынды, рәсем астында инглизчә имза куелган: Л.П.Тургановaның (өлкә комитеты прокуроры хатыны) шәхси җыелмасыннан керамика.

Сездән гаделлекне торгызуыгызны һәм мөкатдәс истәлекләрне Сардоба мөселманнарына кайтаруда ярдәм итүегезне сорыйбыз.

Хөрмәт белән...»—һәм аннары крайга бик таныш имза сырланган.

Һөҗүм оста, житез һәм нәкъ вакытында ясалган—ул мона шикаятьнең беренче юлларына күз ташлауга ук төшенде. Дингә карата мондый мыскыллы караш кемдә дә ачу, ризасызлык тудыра, әлбәттә. Мәчеттәге изге саналган әйберләргә кул сузган вәхшине дәһри кешеләр дә хупламаслар иде. Гаделлек өчен көрәшкә кемнәр чакырылган диген? Дини идарә, партиянең ҮК, өлкә комитеты...Әйе, Бикхуҗаевлар кланына каршы көрәштә көчсезлеген танырга мәҗбүр булды прокурор—шушы яктан китереп сугасыларын башына да китермәгән иде. Кемдер бик теләгән очракта, явыз җан булып чыгуын да хәзер икән—ә ул тормышыннан ниндидер «таплар» эзләп маташкан булды. Билгеле, ул кланның Дини идарәгә, бигрәк тә өлкә комитеты секретарена ачкыч ярата алуына ышанмады, алар бары прокурорга яхшы таныш алым кулланганнар: фактларны уңышлы итеп үзләренә файдалы рәвештә бозганнар—үткен, бик үткен кыланганнар. Әйе, әйтәсең юк, бик яхшы йөреш ясаганнар, җавабын ансат кына табарлык түгел, шуңа күрә ул аптырашта калган секретарьга авыз ачып сүз әйтә алмыйча, башын иеп, шактый утырды.

Озакка сузылган авыр тынлыкны кабинет хуҗасының тавышы өзде:

—Аңламыйм, кемгә, нигә кирәк булган боларның барысы да? Кемгәдер сине аяктан егу кирәкме? Урыныңмы? Тик хәзергә мин моны сизмәдем, әгәр шулай икән, белешермен. Монда бу савытлар мөһим түгел, минемчә. Тик менә нәрсә—һич төшенмим. Без администрация бүлеге мөдире белән болай хәл иттек...Син үзең дә аңлыйсың инде: хат ҮКта исәптә, алар бездән

җавап көтә, шулай булгач, тикшерү үткәрмичә булмас. Сезнең гаилә белән килеп чыккан хәл җәмәгатьчелек фикерендә киң яңгыраш тапты, син хастаханәдә ятканда монданиләр майтарылганын күз алдына да китерә алмыйсың. Тикшерү эшләрен һәм судны бик кыска арада үткәрүләре өчен без милиция полковнигы Иргашев белән андагы прокурор Исмәгыйлевка рәхмәтле, халыкны шул рәвешле генә тынычландыра алдык. Шуңа күрә өлгерлекләре өчен бүләкләргә дигән тәкъдим кергәч каршы килмәдем, хәзер икесе дә өлкәгә күченделәр. Балан мәчет белән килеп чыккан хәл буенча тикшерерүне дә аларга тапшырдым.

Бераз тынып торганнан соң, чәен йотып куйды да хат белән җибәрелгән төсле фотоны караштыргалап, сорау бирде:

—Бу савытлар кайда соң? Өеңдәме, әллә безнең край музеендамы?

—Өйдә,—диде ул төшенке генә.

—Менә анысы яхшы, бик яхшы. Югалганнардыр дип борчылган идем, югыйсә, тавыш-гауганы көт тә тор. Зинһар, шоферың тиз генә миңа китереп китсен аларны. Ә мин Балан мәчетенең имамын чакыртуларын сорармын да үз кулларым белән тапшырырмын. Иң мөһиме—Дини идарә белән партия ҮКна кыска һәм ачык җавап бирү мөмкинлеге туа: кадерле ядкарьләр мәчеткә кире кайтарылды, бәлки шуның белән котылырбыз.—Һәм, сөйләшүнең тәмамланганын искәртеп, урыныннан торды.

Прокурор аңлатып торуны кирәк тапмады. Әле аңлатасылары алда—телдән дә, язмача да,—клан, шулай итеп, һич көтмәгәндә тагын өстен чыкты. Полковник Иргашев һәм прокурор Исмәгыйлев җитәкчелегендәге комиссия бу вакыйганы өреп кабартырга тырышачак, кемгә-кемгә, әмма аларга прокурор белән бергә-бер күрәштә җиңелергә ярамый иде.

Яңалыктан башы түнгән Азлархановakрен генә аска төшеп машинасына кереп утырды, уйларына уралган хәлдә, шоферына Лахутига барырга кушты. Ул тагын бер кат Беренченең алдан күрә белүенә зур бәя бирде, әле эшнең нәрсәдә икәнлеге ачыкланмаган, әмма инде ул савытлар артында нидер яшеренгәнен, аларның югалуы прокурорның язмышына тискәре йогынты ясаячагын сизенеп алган. Кинәт йөрәген шом басты: чынлап та, Аллам сакласын, бу ләгънәт төшкән савытлар югалган булсалар, Ларисага нинди генә нахак бәлаләр ягып бетерерләр, хәтта Швейцариядән кире алып кайтмаган дип әйтүләре дә бар иде. Хатынының соңгы күргәзмәсендә иң төп экспонатлар булган бу савытлар антикварлар теленнән төшмәде. Менә хәзер, шуларны исенә төшергәч, прокурорның күңеленә шик төште: өенә кайтканнан бирле коллекция тупланган бүлмәгә башын тыкканы да булмады бит аның. Шулай да Лариса үзенең яраткан кадерле экспонатларын Швейцариядән алып кайтуы төгәл хәтерендә.

Унтугызынчы гасыр керамикасы тупланган бүлмәнең бусагасын атлап кергәндә, каушавы басылмаган иде әле. Якуб хаҗи савытлары үз урыннарында тора. Башына килгән беренче уе: «Фотографның хәйләсеннән башка да—ул фотога савытларны зур бүре тиресе һәм чакма ташлы корал фонында төшергән—бик матур күренәләр» булды. Секретарьның фотога карап соклануы исенә төште.

Киштәдән авыр савытларны алгач, өй хуҗасы ачы көлемсерәде: шикаять белән нишләргә икән дип баш ватасы урынга, матур күренәләрме йә секретарьда нинди тәэсир калдырдылар икән дип уйлап тор инде.Ул бит боларның башында кем торганын яхшы белә. Никадәр генә тынычланырга тырышмасын, Локарнода чыгарылган альбомның күз алдында торган бите турындагы уйларны башыннан куа алмады. Кинәт үзеннән-үзе акылга ятышлы сорау калкып чыкты: «Тукта, бу битне алар каян алганнар, ә Швейцариядә басылган альбом алар кулына каян килеп эләккән?» Альбом

бит махсус, күргәзмәгә дип, аз гына тираж белән чыгарылды, хәтта Лариса да көч-хәл белән өч данә юнәтә алды. Берсен кайта-кайтышка хатынының мавыгуына ихлас бирелгән туганнарына бүләк иттеләр, ә икесе өйләрендә калды. Андый сирәк басманы, ай-һай, алай ансат кына табып булыр микән? Савытларны калдырып торып, ул китапханә тупланган кабинетка керде. Сынлы сәнгать буенча китаплар, репродукцияләр аерым киштәгә тезелгән, тышы җәеп куелган альбом исә күзгә ташланып тора.

Прокурор альбомны алды да тиз-тиз генә битләрен актара башлады. Менә ул—Балан мәчете керамикасы төшерелгән бит, бөтен, ертылмаган һәм аны кире урынына куеп, икенче данәсен эзләргә керešте. Бар киштәләрне айкап чыкты, өстәл тартмаларында казынды... Һәм кинәт альбомны узган ел Швейцария турында сөйләр өчен үзе белән эшенә алганы кылт итеп исенә төште. Хезмәтенә чыккан көнне сейфтагы эш кәгазьләрен актарганда күзенә чалынуын хәтерләде.

Савытларны машинага урнаштырып өлкә комитетына юллаганнан соң, Әмирхан Даутович җәяүләп кенә прокуратурага юнәлде. Бәлки, яшәреп килгән шәһәр буйлап сәйраны аның уйларын эзгә салыр, алга таба нинди адым ясарга кирәклеген анларга ярдәм итәр, ашыгырга кирәк, ашыгырга. Әмма башына юньле-рәтле фикер килмәде, бары кабинеттагы альбом кабат хәтеренә төшкәч кенә, прокурор җанланып китте: әгәр рәсем шул альбомнан ертып алынган булса, күп нәрсә ачыкланыр. Шул уйлар адымнарын кызулатырга мәҗбүр итте.

Кабул итү бүлмәсендә көтеп торучы күренми, ашыгыч шылтыратулар юк, керә-керешкә ул сейфны ачты. Альбом авыр, еллар узу белән таушалган амбар кенәгәләре арасына кысылган, әмма аның ачык төстәге тышы әллә каян аерылып, күренеп тора. Прокурор альбомны алып, өстәл янына килде.

Уйлап-нитеп тормый ачып җибәрүгә, керамика төшерелгән бит туры килде, әмма төбе генә калган —кемдер бик пөхтә итеп кисеп алган иде. «Димәк, күнелем дөрес сизенгән.—Прокурор альбомны шап иттереп ябып куйды.—Шахматчылар теле белән әйткәндә, Бикхуҗаевларның әзерлекләре менә нинди булып чыкты. Ярый, мин хастаханәдә дәваланганда, болар тик ятмаганнар, шахмат осталарына хас йөреш уйлап тапканнар. Ә менә запаста андый йөрешләре тагын күпме икән, әллә инде ясап та өлгерделәр микән?»

Прокурор инде нишләргә дип баш ватты. Билгеле, ул нәрсәдер эшләп карар, әмма Бикхуҗаевлар ярты ел буе кул кушырып утырмаганнардыр, аның һәр омтылышын тулы коралланган хәлдә каршы алырга әзерләрдер. Ул сейфтан Балан мәчете урнашкан район мәгълүматлары тупланган китап алды. Сардоба районы турында биш-алты бит укыгач, артыгын кирәксенмичә, китапны урынына куйды. Шушы күзенә чалынган язмалар, фактлар буенча гына да кланның монда язылганнар белән танышып, Балан мәчетеннән юкка чыккан савытлар турында районнан үзләре теләгәнне алдан алып куйганнарына шиге калмады. Шулай итеп, комиссия секретарь алдына прокурорны пычракка батырган документны китереп салачак, аның эш-гамәлен Җинаять кодексына ук кертеп куймасалар ярый әле—Бикхуҗаевлардан барысын да көтәргә була.

Кабинетыннан чыкмыйча кичкә кадәр утырса да, башына төпле фикер килмәде.Уйлар җебенең кайсына гына тотынса да, очы бер урында төйнәлә—республика прокуроры белән очрашып, Лариса турында сөйләшү, чиксез мөмкинлеккә ия клан, Балан мәчетеннән югалган савытлар, сейфтагы альбомның кисеп алынган бите, күптәннән кемнәрнендер күзләрен кыздырган амбар кенәгәләре, көтмәгәндә генә югары үрмәләгән Иргашев, Исмәгыйлевлар, шулай ук хөкем ителгән Азат Ходайкуловны

каядыр ераккарак күчереп, сакны көчәйтергә кирәклеге—барысы-барысы турында да ачыктан-ачык сөйләп бирергә кирәк. Әгәр бу очрашуда капитан Чураев та катнашса, тагын да ышанычлырак булыр иде.

Әлбәттә, республика прокуроры белән сөйләшүгә зур өметләр багласа да, ул үзенең каршы яклар алдындагы көчсезлеген таный, нинди генә планнар корса да, аның һәр адымына җавап әзерләрлек вакыт отуларын белә.

Кичен Лахутида һич уйламаганда шәһәрара телефон шылтырады. Шылтыратучы—Ташкенттан, республика прокуроры булып чыкты. Нәкъ өлкә комитеты секретаре кебек ул да аның сәламәтлеге, яшәү-көнкүреше белән кызыксынды, төп сүзгә күчәргә ашыкмады.

—Билгеле, төн уртасында, җитмәсә өенә тикмәгә генә шылтыратмавыма төшенгәнсеңдер дип уйлыйм. Эштән шылтыратсам, мине аңламаслар иде, кайда утырганымны яхшы беләсең. Хәер, сина аңлатып торасы юк,—дип, ниһаять, тәвәккәлләп сүз башлады ул.—Мин инде сине ун еллап бары тик яхшы яктан гына беләм, шуңа күрә хәбәр итүне кирәк санадым. Монда соңгы өч атнада ташкын булып синең өстән аноним хатлар агыла. Баштагыларына әллә ни игътибар бирмәдем, килгән берен өстәл тартмасына сала бардым, ә менә соңгыларын тотып тора алмыйм, чөнки алары берьюлы ике җиргә—ҮКка һәм безгә адресланган. Сафсата, тик безнең җавап кайтармый хәлебез юк. Берсе Ялтадан синең белән бер санаторийда дәваланган берәүдән килде. Ул болай дип язган: имеш, син җитмеш биш меңгә XVIII—XIX гасырлар керамикасының бик кызыклы коллекциясен тәкъдим иткәнсең, имеш, бу җыелма күп мәртәбәләр чит илләрдә күрсәтелгән һәм сәнгатьнең Европага билгеле каталогларына кертелгән икән. Имеш, син клиентлар эзләү максаты белән көн саен бик кыйммәтле саналган «Восток» кафесына йөргәнсең һәм анда бик озаклап утыргансың. Миңа тагын болай дип тә әйтелгән, янәсе, официантлар сиңа клиент тапканнар, әмма син алтмыш меңгә ризалашмагансың, әлеге кеше анонимканы комсыз булуына, юл куймаганына ачуы килеп, үч итеп язуы турында белдергән.

Ә икенчесе сине яхшы белгән кеше тарафыннан бик җентекләп язылган. Анысында сезнең коллекция тагын да югарырак бәяләнгән. Менә бер өзек китерәм: «Прокурор тарафыннан тупланган коллекция иң аз дигәндә йөз—йөз егерме мең тирәсе тора...»

Әле тагын болай дип язганнар: «...өлкә комитеты прокурорының уртача тормыш алып баруы—ширма гына, аның бар максаты—сирәк очрый торган коллекция хисабына баеп калу». Ял вакытларында үз гомереңдә бер мәртәбә өлкә комитеты юлламаларыннан файдаланмавыңны да искәрткәннәр. Монысын менә болай аңлатканнар: янәсе, эш урыныңнан файдаланып, хатының белән коллекция өчен кирәкле әйберләрне эзләп, экспедицияләргә чыгып киткәнсез. Сезнең ярдәм белән,—дип язганнар,—Лариса Павловна музей альбомын махсус реклама, ә соңрак файдалырак табыш алу өчен Лахутидагы бакчагызда бастырып чыгарган. Чит илгә чыгарылган альбомнарда, бигрәк тә соңгыларында ул бары тик үз керамикасын гына күрсәтергә тырышкан, янәсе аны читкә чыгарып, күпме торганын чамаламакчы булган, дигәннәр. Лариса Павловнаның төп максаты—киләчәктә җыелмасын тулысынча чит илгә алып чыгу һәм җае табылгач, коллекциясен сатып, баеп шунда калу,—дип тә өстәгәннәр.

Гомумән, менә шундый тузга язмаган, кеше ышанмаслык нәрсәләр язып тутырганнар. Менә тагын берсе: имеш, сез хатыныгыз белән соңгы күргәзмәдән соң, Швейцариядә калмакчы булгансыз, тик нидер комачаулаганмы, әллә ул ил күңелегезгә ошап җитмәгәнме—кире уйлагансыз, җитмәсә, бер елдан Лариса Павловнаның Америкада Нью-Йоркның хәзерге заман сәнгать Үзәгендә күргәзмәсе дә буласы икән.

Кыскасы, машинкада тыгыз итеп басылган сигез бит...Үзең дә беләсең, судья һәм прокурорлар өстеннән язылган шикаятьләр һәм анонимкаларның эчтәлеге бер төрле—ришвәт, ә монда кайсы төргә кертергә, ничек якын килергә белми икеләнеп калганнар. Өстән безгә комиссия төзергә куштылар, анда сезнең җыелманы бәяләү өчен сәнгать экспертлары да бар, кыскасы, шушы көннәрдә көтегез. Сезнең өчен бик авыр көннәр башлана, чын күңелемнән бу мәгънәсез вакыйганы исән-имин ерып чыгуыгызны телим...

Сөйләшү көтмәгәндә тәмамланды. Прокурор хәтта җавап та кайтара алмый калды, хәер, нәрсә дип әйтсен инде ул? Беркайчан, беркемгә хатынының тупланмасы өчен җитмеш биш мең тәкъдим иткәнем булмады дипме? Ул бит аны шул бәядә тора дип күз алдына да китермәде. Әллә шундый исемсез язмаларны тикшерергә алынучылар үз аңындамы икән дип сорасынмы? Янарак кына яраткан тормыш юлдашын югалткан, рәттән китереп бәргән ике инфаркттан яна аякланып маташкан кешенең уе акчадамыни?

Бу төнне ул керфеккә керфек какмады. Юк, бу әчкерле анонимкадан курыкмады, сорауларга җаваплар да эзләмәде, менә-менә киләсе комиссия белән очрашуга да әзерләнмәде. Бу ике әңгәмәдән шуны аңлады: бу хәл аның тикшерү-күзәтүе чигеннән узган, ягъни тормышының ышанычсыз каегы арканыннан өзелеп давыллап торган ачык дингезгә чыгып киткән. Шушы йокысыз төндә үзенең намуслы кеше дигән абруена җитди куркыныч янавы турында да әллә ни борчылмады. Гражданнарның хокукларын саклаучы прокурор буларак, ул кануннарның камил түгеллеген белә: комиссия чокчынуына, вәкил итеп җибәрелгәннәр тикшерүенә эләгү өчен җиренә җиткерелеп язылган бер анонимка җитә. Хәтта иң саф күңелле кеше дә андый очракларда үз эшләп тапканына көн итүен раслар өчен кесәсен әйләндереп күрсәтергә, эчке киемнән калырга, йокы, ашау бүлмәләрен, базын тикшертергә, гомумән, бар нәрсәсен чыгарып селкергә тиеш.

Комиссия синең намуслы булуыңны исбат итсә дә бу исемсез хат язучының алган ләззәте өчен бик зур түләү түгелме? Шуннан соң ничек итеп бер-береңнең күзенә карамак кирәк? Бернәрсә дә булмаган кыяфәт чыгарыргамы?

Аның җанын тагын бер уй кимерде: зур вәкаләтләр бирелгән ике кеше—өлкә комитетының беренче секретаре да, республика прокуроры да аның язмышы хәл ителгәндә кешелекле булуларын күрсәттеләр, тик үзен бары тик яхшы яктан гына белсәләр дә, аларның алда ачыктан-ачык ярдәмнәренә өметләнә алмавын төшендерделәр : моның дәлиле—төнге яшерен шылтырату. Нишлисең, анысына да рәхмәт.

## 6

Ә алга таба вакыйгалар кискен төс алды. Полковник Иргашев белән прокурор Исмәгыйлев җитәкчелегендәге комиссия Сардоба районында эшен бер көндә тәмамлады һәм кичкә өлкә комитетына Балан мәчетеннән Якуб хаҗи савытларының югалуы турындагы материалларны китереп тә җиткерде. Ә документлар исә кызыклы иде... Ягъни прокурор Азлархановның Балан мәчетендә өч тапкыр булган, хәтта даталары да күрсәтелгән; бу Әмирхан Даутовичның Сардоба районын тикшергән өч көне белән тәңгәл килә иде. Өч тапкырында да ул, Азлarханов, янәсе, имамнан бу савытларны бүләк итүен сораган, әмма тегесе, имеш, һәрберсендә кире каккан. Бервакыт прокурорның хатыны да мәчеткә килгән, Талимәрдән останың керамикасына сокланып, кувшиннарны үз тупланмасына алырга теләгән, янәсе. Ул, имеш, имамга үз куллары белән язып, записка да калдырган. Блокнот битендә аның почеркы белән:

«Кувшиннарыгыз бик ошады, алар теләсә кайсы күргәзмә коллекциясен бизәп торырлар иде дип уйлыйм. Музей аларны акылга сыешлы бәядә сатып алырга әзер. Кызганыч, үзегезне туры китереп булмады, шушы атнада тагын сугылырмын.

Хөрмәт белән, Л.П.Турганова».

Мона охшаш язуларны ул керамикасы кызыксындырган хуҗаларын туры китерә алмаган өйләрдә еш калдыра иде.

Ә савытларны прокурор үз куллары белән түбәндәгечә алган, имеш. Мәчет имамы мөселманнарның изге әйберсен шәхси коллекциягә үз ирке белән бирмәсен аңлагач, ул, янәсе, район прокуратурасы хезмәткәре Шамирзаевка Балан мәчетен күзәтү астына алырга, әз генә житешсезлек күренүгә үзенә хәбәр итәргә кушкан. Һәм андый сәбәп озак көттермәгән. Мәчеткә ремонт ясаган вакытта күрше кышлактагы мәктәпкә каралган ике кубометр агач материаллары белән бер машина кирпеч монда китертелгән. Һәм Шамирзаев өлкә прокуроры кушуы буенча урланган материал сатып алган имамга җинаять эше ачкан.

Нәтиҗәсе мондый: карт, авыру кешене куркытып, коткы юлы белән прокурор, ниһаять, үзе теләгән савытларга ия булган. Имеш, кувшиннарны алырга ул үзе шәхсән, Шамирзаев озатуында килгән. Бу «алу» датасы шулай ук расланган: чыннан да, ул көнне прокурор Сардобага килеп, прокуратурада кыска гына киңәшмә үткәргән иде.

Өлкә комитетының администрация бүлегендә комиссия нәтиҗәләре белән танышканнан соң, прокурор мөдиргә бер генә сорау бирде: — Сардобадан Шамирзаевны чакыртып буламы?

Моңа каршы бүлек мөдире кулларын гына җәеп җибәрде: —Сезнең һәм безнең бәхетсезлеккә, Шамирзаев өченче ел бакыйлыкка күчте. Ә имам—узган ел.

Озак көттерми Ташкенттан да комиссия килеп төште, бу турыда республика прокуроры төнлә шылтыратып, коллегасына хәбәр салды. Алар бишәү иде: таныш булмаган ике сәнгать белгече-эксперт, республика прокуратурасы хезмәткәре—анысы әле яңа, республика күләмендә халык контроле исеменнән үзен бик дәрәҗәле тоткан түрә һәм тагын берсе ҮКның парткомиссиясеннән.

Өлкә комитетында да, прокуратурада да, прокурор шәхсән үзе дә андый ук җитди составтан торган комиссияне көтмәгәннәр иде.

Өлкә комитетындагылар канәгать: чөнки үз комиссияләренең шикаять буенча тикшерү нәтиҗәләре кулларында . Һәм килгәннәр, Тургpraованың шәхси җыелмасын күргәнче үк, полковник Иргашев комиссиясенең кәгазьләре белән танышып чыктылар. Эш урынында утырган прокурорга комиссиянең килеп җитүен хәбәр иттеләр һәм, тикшерүчеләрне каршы алу өчен, ярты сәгатьтән өендә булуын үтенделәр.

Прокурор машина чакыртып тормады, җәяүләп кенә өенә юнәлде.

Апрель башлары. Яз көннән-көн хакимлекне үз кулына ала бара. Йорты янында ул бер генә мизгелгә тукталып, башлары киселгән «тере койма»га сокланып торды, сыек яшеллек күзләрне иркәли. Капканы ачык калдырып, ишегалдына керде. Ялтадан кайткач, бакчачы яллап, тәртипкә китерелгән ишегалды ялт итеп тора. Прокурор үзе дә эштән кайтуга, төн уртасына кадәр бакчасында кайнашты: агартты, кисте, сирәкләде һәм менә бүген коеп киткән юмарт март яңгырларыннан соң, ишегалды, роза, сирень куаклары махсус тикшерүчеләрне каршы алырга әзерләп куйгандай булган. Ул ирексездән Ларисаның куллары тудырган могҗизага сокланды—монда барысы да аны хәтерләтә иде.

Уйларына күмелеп, комиссиянең килеп кергәнен дә сизми калды.

—Искиткеч!—диде халык контроле вәкиле.

Ике сәнгать белгече шунда ук ишегалды буйлап китте, аларның әле бер, әле икенче экспонат янында ах-ух килүләре ишетелде. Хуҗа кешегә аларның һәрберсенә, бигрәк тә бу керамиканың кайсы каталогта булуы һәм кайда күрсәтелүе хакында аңлатмалар бирергә туры килде. Белгечләр прокурор авызыннан чыккан һәр сүзне таушалып беткән дәфтәрләренә терки бардылар. Прокурорның белгечләр белән сүз куешуыннан курыккандай, халык контроле вәкиле аның үкчәсенә басып йөрде һәм сүзен сүзгә язып алды. Калган икесе исә бакчага хирыс кешеләр идеме, тәбәнәк агачларга, сирәк куакларга, чәчәкләргә, чирәмлеккә сокландылар, биргән сораулары да бакчага кагылышлы иде.

Бакчада сәгатьтән артык йөреп, «күк йөзе белән капланган музей» экспонатлары белән танышкач, өйгә керделәр. Йортнын коллекция тупланган ике иң зур бүлмәсен, Балан мәчете савытларын өлкә комитетына кайтарып биргәннән соң, тәртипкә салырга өлгергән иде. Кунаклар монда озак тоткарланмадылар, ул экспертларның сорауларына җавап кайтарды. Ә түрәләр авызыннан бары өч сорау гына чыкты. Теге йә бу әйбергә күрсәтеп, ул: «Моны күпмегә алдыгыз?», «Кайдан алдыгыз?», «Кемнән алдыгыз?»—дип сорады. Нәкъ менә шушы сорауларга, бигрәк тә беренчесенә җавап бирүдән читенсенде ул, чөнки эшләнмәләрнең бик сирәге генә сатып алынган иде. Күпчелеген таныш булмаган кешеләр китерде, дуслары, күршеләре, хезмәттәшләре бүләк итте. Тик ул түрәнен,—мөгаен, ул комиссиянен житәкчесе дәдер, чөнки үзен бик рәсми, һавалы тота,—күзләреннән күрде: прокурорның җаваплары аны ышандырмады.

Язгы җылы көн булуга карамастан, бүлмәдә салкынча, почмакларда дым тарткан, күрәсең керамикадан әле кышкы суык чыгып бетмәгән, шуңа комиссия альбомнарны, күргәзмә каталогларын ишегалдында карау теләген белдерде. Җәйге ачык верандада торган өстәл тирәли урнаштылар, хуҗа тикшерүчеләр сораганның барысын да шунда алып чыкты. Альбомнарны бүлгәләп алып, комиссия членнары җентекләп карарга тотындылар, вакыты-вакыты белән үзләренең дәфтәрләренә ниндидер өземтәләр күчерә бардылар. Сәнгать белгечләренең мавыгып карауларыннан, ул аларның бу альбомнарның кайберләрен беренче мәртәбә күрүләрен аңлады. Прокурор комиссия рәисе дип кабул иткәне аеруча тиз кыланды. Өстәл янында аның тавышы гына:

—Менә сиңа мә, Испаниядә басылган...

Яисә:

—Карале, кара, менә имән астында яткан хум Швейцариядә чыгарылган альбомда!

Балан мәчете савытлары композициясен караганда ул:

—Кирәк бит, ә, аучы нинди зур бүрене шундый борынгы корал белән атып алган...—дип, озак кына башын селкеп, көенеп утырды. Альбом һәм каталогларны карау шактыйга сузылды. Алар әле тагын берәр сәгать утырырлар иде, әмма ике машина белән җибәрелгән кеше йорт хуҗасына кунаклар өчен өлкә комитетының шәһәр читендәге резиденциясендә төшке аш әзер икәнен хәбәр итте. Дөрес, чакырулары әллә ни катгый ишетелмәсә дә, төшке ашка прокурорны да дәштеләр, тик ул баш тартты. Комиссия китеп барды. Тикшерү нәтиҗәләре белән ул бер атнадан соң, партия өлкә комитетында аның шәхси эше буенча җыелган бюро утырышында танышты.

*Дәвамы киләсе санда*



Илдус
Гыйләҗев

## ФИКЕРДӘШЛӘР, БЕРГӘ БЕРЛӘШИК ТӘ...

### Үзебезчә булыр!

**Ничек тату яши алсын**
**Кол белән кол биләүче?—**
**Сатылганмы, саташамы**
**Дус булырга өндәүче?**
**Суксалар да, ексалар да,**
**Без бит ипкә килмәүче.**
**(Тәре асып куйсалар да,**
**Башны түбән имәүче...)**
**Яучы булып ялланадыр**
**Үз кадерен белмәүче.**
**Ә без:—«Сами с усами...»—**
**Кирәк түгел димләүче!**

### Һаман аңламыйлар

**Хатыннары шуннан килгән булгач,**
**Электәрәк урыс патшалары:**
**«Ауропача яши башлыйбыз»,—дип,**
**Ниләр генә эшләп ташламады...**
**Сакал кисеп кенә ни үзгәрсен,**
**Исән калгач бояр башкайлары?**
**Парик асларында чәч яңарды,**
**Җиту тормыш кына башланмады.**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) — *шагыйрь; «Җир китабы», «Серле мәгарә», «Ятратканга күрә» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге премиясе лауреаты. Азнакай районы Түйкә авылында яши.*

Рәсәйдән бугай да бит бүгенгеләр,
Ник үзгәреш һаман мәсләкләре?
Үзебезчә матур итеп яшәү
Түгелме соң әллә максатлары?
Үрнәк итеп алып Көнбатышны
Аз булдымы михнәт кичергәннәр?!
...Мәктәпләрдә гел дә макталмады
Кеше дәфтәреннән күчергәннәр...

## Гаҗәпләнәсе юк

Татар бүлегенә яшьләр бармый,
Бозылды шул гадел бүленеш,
Телне яратмаудан түгелдер ул,
Урыста да шул ук күренеш...
«Коры кашык авыз ерта»,—диләр,
Матди нигез—милләт саулыгы.
Рәсәй үзе телсез калмый микән,
Чит илләргә качкач байлыгы?

## Иманым камил

Эволюциягә ышанам мин,
Хәрәкәттә тормыш—тик тормый,
Тереклекнең серен төшенергә—
Коерыгын гына тоттырмый...
Эзләнәбез, бик еш ялгышабыз,
Белем эстәп—«меңне екканбыз».
Имеш, без бит суда яралганбыз,
Соңрак җиргә шуып чыкканбыз.
Кемнәр күргән, кемнәр исбатлаган,
Нигә кире анда төшмибез?
Шунда туган булгач, океанның
Тозлы суын нигә эчмибез?
Ник таныргә һаман теләмибез:
Без—Алладан! Нәрсә дисәк тә...
Бернәрсә дә юктан бар булмый бит,
Ник алынмый шул сүз исәпкә?!

## Фикер үзгәрту

*Мин калырмын җирдә соңгы*
*Татар булып.*

Рәфикъ Юныс

Мин дә шулай уйлап йөри идем,
(Милләт бетәр лә ул.. юл куйгач.)
Үзгәрде дә куйды бу фикерем,
Синең ниятеңне укыгач...
Икебез дә соңгы булабызмы?—
Кире кагам мондый мантыйкны:
Татар булуыңны дәлилләргә
Соң сәгатьне көтеп ятыйкмы?!
Милләтпәрвәр гавам тагын бардыр,
Асыл затлар күп ул татарда.
Фикердәшләр бергә берләшик тә,
Торып басыйк телне якларга!

«Бетсен...»,—диеп теләп йөрүчеләр
Күп болгана безнең тирәдә.
Өметләрен кисеп, алга чыгыйк!
Соңгы булу—бирмәс дәрәҗә...

## Үзгәрмәстер инде

Яшең узгач, бил бөгәргә
Булмый икән өйрәнеп,
Юккамыни урыс иле
Артта йөри сөйрәлеп,
Империя корган чакта
Ташлаган ул күрәген,
Аңлатучы булмаган шул
Эшләп ашау кирәген...

***

Җитен-киндер нигә чәчәбездер,
Сүс-пәҗесен талкып тукымагач,
Пычагымамы бу «сүз ирәге»,
Язганыңны кеше укымагач?

## Кайсысы калынрактыр

Һич кенә дә булмый качып калып,
Нишләсәң дә барып эләгәсең:
Кемдер туплый безнең «шәхси эш»не,
Фәрештәләр—«Гамәл кенәгәсен»...

## Хәерлегә юрыйк

Очрашмады кабат юлларыбыз,
Үтә гомер күрә алмыйча,
Күрешсәк бит беләм: синең арттан
Киткән булыр идем калмыйча.
Һәм янып та беткән булыр идем...
Исән калдым, Ходам саклады.
Истән чыкмый шашып яратудан
Аңкы-тиңке йөргән чакларым.
Бераз суынсам да, дус-ишләрдән
Сораштырып торам хәлеңне.
Курка-курка йөрим сине эзләп,
Ахырлары булсын хәерле!
...Очрашулар булсын хәерле...

## Учак янында

Ничә еллык истәлекләр
Сыйды ике кочакка:
Иске-моски кием-салым
Яндырабыз учакта.
Чүпрәк-чапрак, ут ялмаса,
Кулны, битне пешерә.
Дулкыннары үткәннәрне
Никтер искә төшерә.
Бу куртканы алган идек

**Бөгелмәдә базарда,**
**Күлмәк-ыштан сайлап җыйдык**
**Йөргән чакта Казанда.**
**Һәрберсенең үз тарихы...—**
**Уйлап хәйран калырлык.**
**Артта калган елларыңны**
**Күз-күмергә салырлык.**
**Үткәннәргә кайтып килү**
**Кирәктер ул кайчакта.**
**Күз алдында күпме гомер**
**Көлгә очты учакта.**
**...Шәп яна.**

## Ташламадым...

**Өйләнештек... икебезгә**
**Ике калак, бер урындык.**
**Гарип өстәл—музейларның**
**Шәп экспонаты булырлык.**
**Бер кешелек ятакка бит**
**Сыя идек—җан тартылгач.**
**Егылып төшкән чаклар булды,**
**Борылырга дип талпынгач...**
**Өч атламлы шул бүлмәгә**
**Дуслар килде көн аралаш.**
**Идәнгә үк чүмәштеләр,**
**Утырырлык җир калмагач.**
**Әй, бәхетле фәкыйрь чаклар!..—**
**Яшим искә гел төшереп:**
**Нигә шулай сагындыра,**
**Җитә алмыйм ла төшенеп.**
**Бүген өем—зур гүрнидә,**
**Дусларыма түр булырлык,**
**...Чоланымда исән тора**
**Кыек өстәл, бер урындык...**

---

## «Казан утлары»н арзангарак алырга телисезме?

«Татарстан почтасы» аша «Казан утлары»на язылу бәясе 2010 елның беренче яртыеллыгына 6 айга 254 сум 10 тиенне тәшкил итә. Кемнәргәдер әлеге бәя кыйбат тоелса, арзангарак яисә берәмләп алуның берничә вариантын тәкъдим итәбез.

Хәзер көн саен диярлек яңа ваклап сату сәүдә нокталары, альтернатив рәвештә подписка белән шөгыльләнүче оешмалар туып кына тора. Бүген «Казан утлары»н түбәндә санап киткән ысуллар белән дә алырга була.

**1. Редакциягә килеп язылу.** Бу очракта яртыеллык подписка сезгә 150 сумга төшәчәк. Адресыбыз: Казан, Декабристлар урамы, 2 йорт, 10 кат. «Яшьләр үзәге» тукталышына кадәр барасы.

**2. «Идел—Пресс» басмаханәсе кибете.** Шушы ук бинада, типографиягә керү юлында урнашкан. Монда журналның һәр яңа санын берәмләп сатып алырга була.

**3. ООО «Пресса для Вас».** Әлеге оешма аша сез «Казан утлары»на арзанрак бәягә языла аласыз. Телефоннары: 2—910—940, 2—910—999

**4. «Альянс Пресс» (элек «Горпечать» дип атала иде) сәүдә нокталары.** Биредә дә журналны берәмләп сатып алу мөмкинлеге бар.

**5. Шулай ук, әгәр оешмагызга 20 яки аннан да күбрәк журнал яздырырга телисез икән**, редакциянең подписка белән шөгыльләнү хезмәте бу эшне үзе оештырачак. Ярты елга 150 сумнан, оешмагызга журналларны ай саен без илтәчәкбез.



Рашат
Низами

# СӘЙДӘШНЕҢ СОҢГЫ ЕЛЫ

КЫЙССА

*Мескен илнең баласына*
*һич сан булмас.*

Акмулла.

**1954 ел, март...**

Тышта март тамчылары чурлый, чәнечкеле җил исә.

Театр ишегалдындагы ике катлы флигельдән өстенә карасу пальто, башына көрән эшләпә кигән, ак күлмәге өстеннән галстук таккан ыспай кыяфәтле кеше чыкты. Урамга чыгу белән пальто кесәләрендә капшана башлады. Бу—композитор Салих Сәйдәшев иде.

Менә ул кесәсеннән шул заманның данлы-затлы папиросы саналган «Казбек» кабын тартып чыгарды. Уч төбе хәтле генә җыйнак тартма күркәм, зәвыклы эшләнгән. Тагын да күңелгә хуш килеп торганы—капның тышлыгындагы рәсем иде: киртләч-киртләч таулар, алга ыргылган кара ат сурәте, елгыр җайдак. Калын-тупас штрихлар белән ясалган шушы рәсемнән ниндидер көч, омтылыш, романтика бөркелеп тора... «Дукат» сигаретын да читләгәне юк Сәйдәшнең, дуслары аңа ни өчендер күбрәк әнә шуны тәкъдим итәләр. Кем кайсыннан тәм таба—хикмәт шундадыр, күрәсең.

Тәмәкесен озаклап кабызганнан соң җәяүләп кенә Горький урамыннан өскәре таба китте. Берән-сәрән чабулаган машиналар, абайламый калсаң, өстеңә карлы су пычрагын чәчрәтеп узарга да күп сорамас. Шунлыктан юлның читеннәнрәк барырга тырышты.

Әйе, март ае, бигрәк тә аның соңгы атналары—табигатьнең авыр, күңелсез чагы. Чөнки ул кышның да, язның да иң начар сыйфатларын үзенә туплаган була. Юеш-салкынча һава, аяк асты лыжырдык. Тротуардагы иске кар түмгәкләре чулыккан, шиңгән. Аларның өсте чүп-чар, ком-балчык

Рашат НИЗАМИ (1950) – *ЖЗЛ сериясеннән композитор Фәрит Яруллин турындагы «Ут һәм җыр» роман-хроникасы, «Тормыш трамвае» h. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең h. Такташ исемендәге премия лауреаты.*

белән капланган, дегет катыш машина пычраклары да күзгә ташлана әнә. Тимердәй авыр-тыгыз җил исеп, шуның өстенә җепшек кар катыш яңгыр да сибәли башласа, эшләр харап инде. Өендә тик ята бир. Апрель-май айлары җитсен әле, андый чакларда дүрт стеналы таш бүлмә эчендә озаклап юанасың килмәс.

***

Казан әле кайчан гына хәл кадәри табыннар, бизәлгән чыршылар, тәрәзәдә балкыган утлары белән Яңа 1954 елны каршылаган иде! Ул чактагы мамык карлар ап-ак һәм хуш исле иде. Камал театры бинасына, флигель-йортка һәм көләч тәрәзәләргә ышкыла-ышкыла озаклап яуды кар. Ике катлы флигель—үзе бер тамаша йорт. Аулак урында ул. Икенчедән, театр янәшәсендә генә. Аннан килеп, театр артистларының тулай торагы шикеллерәк бер бина ул. Гаилә белән дә яшиләр, ялгызаклар да юк түгел биредә.

Нәгыймә апа Таждарова. Революциягә кадәрге атаклы «Сәйяр» труппасында эшләгән данлы артистка. Үзе гади, үзе акыллы. Чехов әсәрләреннән «сикереп» төшкән бер героиня диярсең, валлаһи! Язучыларга, артистларга һәм театр эшчәнлегенә ул һәрвакыт ярдәм итеп торды, көченсәләтен кызганмас иде. Мондый татар кызы, татар апасы ничек инде истә калмасын икән...

Сәйдәшнең күршеләре—артистлар Хәким Сәлимҗанов һәм аның хатыны Галия Нигъмәтуллина. Сүз әйтерең юк, бик яхшы кешеләр, кунакчыл күршеләр, талантлы артистлар. Әле аларның түгәрәк-ачык йөзле, ут борчасыдай хәрәкәтчән, Марсель исемле 18 яшьлек уллары да бар. Казан университетының юридик факультетында укый, фехтование белән җенләнә.

«Театр сәхнәсендә, артистлар дөньясында әвәрә килеп йөргән бу үсмер егет ничек әтисе юлыннан китмәде икән?»—дип кат-кат гаҗәпләнде Сәйдәш. Тик бу хакта сорарга кыймады, чөнки бу—кешенең эчке дөньясына, теләкомтылышларына тыкшыну булыр иде.

Хәким белән Галия Яңа ел белән котларга керделәр, үзләренә чәйгә чакырдылар. Марсель әти-әнисеннән, Салих абыйсыннан уңайсызланды, әдәп саклады, ахрысы, каядыр чыгып югалды. Шампанский ачылды, теләк теләп тостлар әйтелде. Иң якын дусларыннан булган драматург, актер һәм режиссер Кәрим Тинчуринның фаҗигасен дә искә алдылар. Бу чакта ике ир-атның да күзләрен моңсулык пәрдәсе, сагыш-сагыну билгеләре каплап алган иде...

Сәйдәш урамга чыкканда кар яву туктаган иде. Кинәт кенә вакыт та туктап калган шикелле тоелды. Яңа ел кичендә күңелле дә, моңсу да иде аңа. Күңелле—чөнки, ни әйтсәң дә, бәйрәм бәйрәм инде!

Укылмаган яңа китапның беренче битләре ачылып киткән кебек, һәр Яңа ел таңында да кешеләрне зур, әһәмиятле вакыйгалар, өр-яңа шатлыклар, очрашулар көтеп тора шикелле. Яңа ел, гүя, адәм балаларын үзенең михрабына чакыра. Ләкин... ач күзеңне, дөнья бу: кемгә михраб, кемгә нинди михнәтләр әзерләп куелгандыр бит әле...

Бу бәйрәм кичендә Сәйдәшкә моңсу да бүген. Заманындагы иң ышанычлы якын дуслары калмады диярлек, алар, кара коега төшеп баткандай, әллә ничек кенә югалдылар, бахыр. Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш... Татарның шушындый зур титаннары, шәм кебек егетләре, халык өчен җанын да кызганмыйча армый-талмый эшләгән, коммунистлар партиясенә чын күңелдән хезмәт иткән бу зур шәхесләр юк инде. Үзенең затлы, каһарман улларын ашый, йота, юкка чыгара торган нинди ил соң бу?

Күнел эчкәресе белән бу хакта йөз тапкыр борчылганы, уйланганы бар аның. Әмма бу хакта кычкырып әйтүдән, тфү-тфү, Ходай сакласын! Баш очында очып йөргән кара козгыннарның шомлы тавышы әле дә булса колакта. Алар йокламый, алар һаман уяу, алар һаман сакта... Аллаһының рәхмәте белән алга таба яхшы үзгәрешләр генә була күрсен иде тормышта...

Сәйдәшнең хәтереннән, гүя, тулы бер гасыр узып бара иде. Бәйрәм кичендәге монсулыкның тагын башка сәбәпләре дә бар иде. Болар өстәвенә, аның иҗади омтылышларын, канатын сындырдылар. Кайбер көнчел затлар аның музыкасына тыю, «табу» салмакчылар, халык яратып өлгергән иҗатын кара таш белән томалап куярга тырышмакчылар... Юк, мондый да гаделсез эш ансат кына барып чыкмастыр.

Җир астында күпме җан дуслары гына ята түгел, беренче хатыны Валя-Валентина да, мәхәббәтләре чәчәк атып килгәндә генә, кинәттән бакый дөньялыкка күчте.

Менә шулар барысы искә төшә дә, Сәйдәшнең йөрәк пәрәсен телгәли, аның җанын каядыр күкләргә дәшә, чакыра...

Күнеле сизенә: быел аның тормышында ниндидер зур үзгәрешләр булыр сыман. Заманында Төркестан якларыннан эләктереп кайткан малярия зәхмәте дә үзен сиздерә башлады, хәерсез. Кайчак төннәрен йөткереп уяна. Тәмәке тартуны да вакытында ташлый алмады ичмасам...

Уйлары әнә шулай озаклап агылды.

«Ниләр алып килерсең син, Яңа ел!»

Әнә шушы сүзләрне күңеленнән генә кабатлаганда ул янадан флигельнең ишегалдында басып тора иде инде. Күзләрен жетерәк ачып, тирә-юненә караш ташлады. Ишегалдының түрдәге бер почмагына кышын ягу өчен ташкүмер өеме бушатканнар иде ләбаса. Яңа ел карлары астында күмелеп калган ул. Ләкин кемдер үзенә кирәкле өлешен, әлерәк кенә булса кирәк, көрәк белән чокып-казып алган. Әнә шул урында көрәк яссуы зурлыгында кап-кара тап чекерәеп тора. Аклык янәшәсендә бу күренеш гайре табигый бер хәл сыман тырпаеп, күзгә бәрелде. Бу кара тап, кара чокыр үткәннәрдәнме, киләчәктәнме бер хәбәр? Нинди фал бу?

Әлеге сорауларга җавап эзләргә Сәйдәшнең теләге дә, вакыты да юк иде. Ул тизрәк аклык дөньясына ашыкты... Кинәт кенә аның сихри тылсым белән балачагына кайтып төшәсе килде. Их син тиле, хыялый! Бөтен җенең белән тырышсаң да чынлыкта гомереңне, бигрәк тә балачак елларын кире кайтарып булмый. Булмый!

***

Яңа ел хатирәләре шушы урында капылт кына киселеп, өзелеп калды. Ниндидер машина, дуңгыз тавышыдай чинап-кычкыртып, аның өстенә килә иде. Сәйдәш балачагына түгел, мизгел эчендә чынбарлыкка кайтып төште. Тротуардан чыгып, ул бит урамның кыл уртасына килеп кергән ләбаса! Машинадан читкә чак тайпылып өлгерде. Ул да түгел, колак төбендә милиция сыбызгысы шырыйлап кычкырта башлады!

Секунд эчендә яшь кенә милиционер егет аның янәшәсенә килеп баскан иде. Ашыгып честь бирде.

—Сез нәрсә, гражданин...

Капыл гына туктап, каударланып-тотлыгып калды үзе:

—Салих абый, юл кагыйдәләрен бозучы кем дисәм... сез икәнсез!

—Гафу итегез...

Егет елмайды, йомшара төште. Аның юл күрсәткеч таягындагы аклы-каралы билгеләр зебраны түгел, юк-юк, пианиноның аклы-каралы клавишаларын хәтерләтә иде. Шуны уйлап, Сәйдәш тә елмайды.

—Салих абый, бүтән бер кеше булса, штрафсыз котыла алмас иде бездән. Ләкин сезгә...

Аның нәрсә әйтергә теләгәне сүзсез дә аңлашыла иде.

—Рәхмәт, энем... Уйга баткан чагым иде.

Сәйдәш Горький исемендәге парк ягына чыгып басты. Парк каршындагы карт агачлар, шәрә ябалдашлары белән җилдә бер-берсенә бәрелеп, нидер аңлатырга, нидер сөйләргә тели иде шикелле. Чү, әлерәк кенә колак төбендә яңгыраган сыбызгы тавышы нәрсәне хәтерләтте соң аңа?

Бу аваз аны, чыннан да, балачагына—Ташаяк ярминкәсенә йөздереп алып киткән иде.

***

Салих атлы малай әтисез үсте.

Әтисе сәүдәгәр Җамалетдин, улы туып өлгергәнче үк, салкын тидереп, рәхимсез тормышка үпкәләп, дөньядан китеп бара. Кин күңелле, миһербанлы, эшкә-төскә унган әнисе Мәхүбҗамал кочагында азмы-күпме иркәләнеп, ятимлек ачысын бик татымыйча гына үсә ул.

Язмыш малайга карата мәрхәмәт күрсәтә. Яшәсен олы җизнәсе Насретдин! Әгәр Салихның үз көче белән аякка баскан әтисендә приказчик булып эшләгән, куллары хезмәттә чыныккан бу кеше Җамалетдин Сәйдәшевлар токымына кияү кеше буларак кушылып китмәгән булса, малайның язмышы, ай-һай, музыка дигән олы дөньяга барып ялганыр иде микән? Татар җанлы, чын татар кыяфәтле Насретдин, өлкән абыйларының каршылыгына карамастан, тол бикә Мәхүбҗамалны, алма апасы Әминә белән кечкенә Салихны үзенең житешле йортына сыендыра. Насретдинның хатыны Рауза һәм аларның тупырдап торган дүрт кыз балалары—барлыгы тугыз җан бер түбә астында әнә шулай тату яшиләр.

Алар яшәгән йорттан Ташаяк ярминкәсенә барып житү ерак түгел. Салихның алты яшендә базар янәшәсеннән бер тапкыр узганы бар иде инде. Ат арбасына утырган килеш, билгеле. Кардәш тиешле олаучы Харис абыйсы белән Кремль астына, Ташаяк төрмәсенә бардылар берчакны.

Кузгалып киткәнчегә кадәр Харис абый жигүле айгырын ихата келәсенә бәйләп куйды. Өйдәгеләр чышын-пышын килеп нидер сөйләштеләр. Насретдин җизнәсен менә ни өчен өтермәнгә тыкканнар икән! Имеш, ул бишенче ел революциясе көннәрендә завод-фабрик эшчеләрен фетнәгә өндәгән, яшерен листовкалар тараткан... Хәзер менә ниндидер амнистия буласы, имеш.

Ул чакта кечкенә Салих өлкәннәрнең «революция», «амнистия» дигән сүзләрен юньләп аңламады, билгеле. Аның өчен иң кыйммәте—җизнәсен менә-менә төрмәдән азат итәчәкләр икән!

Атны юртып, чокыр-чакырлы юллардан байтак бардылар.

—Күрәсеңме, шушы була инде ак төрмә!—дип, Харис абый берничә катлы бинага төртеп күрсәтте. Җирән айгыр, ишләрен сәламләгәндәй, гайрәтле генә пошкырып куйды. Халык төркеме, савылып, төрмәнең шөкатьсез тимер капкасына таба юнәлде.

Бераздан...

Төрмә капкасының теге ягыннан чыгучылар арасында кара кәләпүш һәм таушалганрак җилән кигән Насретдин җизнәсе дә күренде. Күктән төшкән бәхет! Куанычтан Салихның йөрәге ныграк сикерә башлады... «Сабыем-нарасыем!»—дип, җизнәсе аны дәү куллары белән кочагына алып эретте. Бу жылы кочактан төрмә исе килә иде.

Өлкәннәр белән кочаклашып алганнан соң, атны юртып, Яңа бистәгә таба юнәлделәр.

—Ходайның рәхмәте, ул мине менә шушы сабыйларым хакына гына коткарды бугай таш капчыктан,—дип, жизнәсе Салихның башыннан сыйпап алды.—Исән-сау котылсам, Салихжанга үзе теләгән бирәр нәрсә алып бирермен дигән нәзер әйткән идем. Ни телисең, олан?

—Гармун...

Малайның монаеп, тыйнак кына әйткән сүзләре шушы иде. Бервакыт әтисенең туган авылы Өбрәгә кайткач, кичен йоклаганда өй чикерткәсенең ничек сайравына гаҗәпләнгән иде ул. Аннары таш сыбызгы белән сихерләнде. Хәзер инде менә «гармун...» диеп саташкан көннәре.

Шулай беркөнне Салих ишегалдындагы иптәш малайлары белән Ташаяк ярминкәсенә барды. Базар гөрләп тора, базар кайный. Андагы тамаша! Шкафчылар һәм сәүдә рәтләре мәш килә. Һәркайсы үз товарын мактый. Почмак саен диярлек ит, он-ярма, җимеш өелеп тора. Мануфактура, кулдан теккән кием-салым, калфак, читек-кәвеш, бүрек, түбәтәй, комган, шәмаил, чалма, нәфис үрелгән чабаталар дисеңме—һәммәсе өр-яңа, күз явын алырлык. Кәләпүшле, сакаллы бер агай әнә кибетчедән бохари тышлы китаплар сорый.

Икенче бер якта чыпта, утын, күмер кабы төялгән олаулар. Йөкле атлар бер хәл, бирегә хәтта фаэтон белән килүчеләр дә күзгә чалына. Әдәпсез көлешеп, бер почмакта кырыктартмачылар гайбәт чәчә.

Әнә, бер атның авызына солылы капчык бәйләгәннәр. Кештер-кештер килеп, ул шундагы солыны соса гына. Моны карап тору кызык булды малайларга. Чү! Бер сатучы, авызына капкан да, таш сыбызгысын чурлата! Әллә ниткән тавышлар, авазлар чыгара бу: әле кош сайраган кебек, әле чишмә суы челтерәгән сыман...

Әмма Салихны иң нык әсәрткән күренеш икенче бер нәрсә иде. Гармун! Менә кайда тәмам якыннан күрде ул аны. Бер абый әнә, кулындагы гармунын сайрата гына! Ачылып-ачылып киткән яшел күрекләренә сандугач кереп оялаган диярсең... Сыгылмалы бармаклары әле берсенә, әле икенчесенә күчә-күчә гармун телләре өстендә елдам бииләр. Кара төймәле бакаларына басып, кайчакны аккордлар да биреп куя ул. Гармунның елтыр яңаклары исә кояш нурларында чагылып-чагылып китә... Бу инде сина әргән ише генә түгел!

Бераздан гармунчы озынча моңлы бер көйгә күчте. Нинди көй икән бу? Ул чакта кечкенә Салихҗан моның «Шахта көе» икәнен каян белсен икән!

Ташаяк ярминкәсеннән әнә шулай әсәрләнеп кайтты Салих. Насретдин жизнәсенең эштән, сәүдә юлыннан бушаганы юк, гармун артыннан йөрергә вакыты тар аның.

Ә шулай да сүзендә торды ул: малайга Вараксиннар остаханәсеннән җыйнак кына бер гармун күтәреп кайтты. Салихның бер-ике көннән соң «Әпипә» көен уйнап күрсәтүе өйдәгеләрнең исен китәргән иде.

***

Март җилендә әнә шулай шактый гына какланып йөргәннән соң Сәйдәш янадан флигель ишегалдына әйләнеп кайтты. Эңгер-меңгер куерып, инде кичке караңгылык пәрдәсе шәһәр өстенә каплана төшкән иде.

Ишегалды нигә соң шулай яктырак тоела дисән, күктән-биектән тулган ай карап тора икән. Җете саргылт-ефәк нурлары җиргә кадәр ничек килеп җитә аның—гаҗәп бит. Кояшта да таплар була, диләр. Моны күргән кеше юктыр. Ә менә айда, чыннан да, сизелер-сизелмәс таплар бар әнә. Күңел күзен белән текәлеп карасаң, татар халык әкиятләрендәге чиләк-көянтә аскан Зөһрә кызны төсмерләү дә кыен түгел.

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә...

Монысы—халыкның җырлар хәзинәсеннән. Иген чәчеп, урман кисеп, иң авыр эшләрне башкарып кына калмаган безнең халык, матур итеп хыяллана да белгән. Ә менә айга менә торган баскычны кайчан да бер уйлап табарлар, мөгаен. Шагыйребез, халык зур ул, көчле ул, дип юкка гына язмагандыр.

Өенә ашыкты, агач баскыч басмаларын акрын гына шапылдатып икенче катка күтәрелде. Аның ялгызы гына каласы килә иде. Нигә шулай бүген? Моны тел белән анлатып булмый...

Өстәлдә калган салкын чәен бер-ике йотып куйганнан соң өйдә генә кия торган халатын җилкәсенә элде. Йортка юньләп якмыйлармы, әллә инде җылысы юньләп тормый, өй эче һаман салкынча иде. Йокы бүлмәсенә кереп китте. Иң яхшысы—юрган астына кереп каплану, кичләрен кайчакта үз җылыннан да ышанычлысы юк.

Никтер күзләренә йокы керми иде.

Бер-ике кат як-якка әйләнгәләп тә карады.

Вакытында ул дәртле, моңлы, халыкчан җырларны күп язды. Зарланасы юк, яхшы музыка, дип гел мактап тордылар үзен. Газеталар да мәдхия сүзләрен җәлләмәделәр. Ә шундый музыканы ничек, ни өчен язды соң ул? Халыкка хезмәт итү теләге беләнме? Хәзер инде уйлап карасаң, халыкка хезмәт итү дигән нәрсә иллюзия, ягъни чынбарлыкны бозып күз алдына китерү дә булган түгелме? Чөнки баштарак большевиклар кулына, соңрак инде тагын да ныграк итеп Сталин режимына коллыкка төшкән халыкны юатуга караганда аның рухын-җанын үлемнән коткару мөһимрәк булгандыр бәлки? Ә моның өчен өстәгеләргә кул чәбәкләү түгел, барыннан да элек хакыйкатьне ачып салу кирәк. Ул музыкасында шуңа иреште. Чөнки тулы дөреслек бары музыкада гына була ала. Сүзләр аша түгел, авазлар аша әйтелгән хакыйкать. Бу дөньяда әйтеләсе яки әйтелмәгән сүзләр һәрвакыт музыка булырга омтыла...

Әлеге уйлар дулкыны Сәйдәшне җылытып кына калмады, бөтен тәнен пешереп алгандай итте! Чү, аның уйлары фетнә фикерләргә кереп бара түгелме?.. Юк, үз-үзеннән куркырга ярамый.

Юк, аның иманы дөрес уйлый.

Алайга китсә, ни өчен соң татар профессиональ музыкасы сәхнәгә, зур мәйданга шулай сонарып чыкты? Аның бит рухи, мәдәни мөмкинлекләре зур һәм тирән булган. Уйласаң, «Гөлҗамал»ны янгыратып, Европадагы теләсә кайсы халыкны моңайтырга, хәтта елатырга мөмкин. Җырларыбыз, үлмәс моңнарыбыз булган, алар безгә кадәр дә яшәп килгән бит...

Гаҗәеп бер феномен бар: музыка терминнарының барысы да диярлек йә латин, йә итальян, француз яисә греклар теленнән кергән. Бу вакытларда рус халкы күбрәк сугыш-талау, байлык-ганимәт җыю, үз биләмәләрен киңәйтү эшләре белән шөгыльләнгән. Шунлыктан патшалы Россия хәтта үзе дә олы музыка дөньясына соңлабрак килеп керә. Шулай булгач, анын биләмәсендәге башка милләтләргә, бигрәк тә дәүләтчелеген югалткан, чукынырга теләмәгән «кан дошман» татарга ни сан кала соң? Анын мөмкинлекләрен кискәннәр яисә һәрвакыт чикләп торганнар. Олуг музыкага омтылыш, үсәрдәй талантларын, җыр чишмәсен кара таш белән бастырып куйганнар... Хикмәт менә бит нәрсәдә. Октябрь революциясе, ни генә дисән дә, яңа мөмкинлекләр ачкан, милли сәнгать үсешенә ирек биргән икән шул...

Төнката шушы уйлар чолганышында озак газапланды Сәйдәш. Ләкин ул

инде үз уйларында да, тормышта да ирекле иде. Ул инде табасын тапкан, югалтасын югалткан... Тәрәзә пыяласына әнә март җиле сугылып-сугылып нидер әйтергә, искәртергә тели шикелле. Ни әйтергә теләве аның?

Тиздән апрель, яз килә дип тәрәз кага булса кирәк. Апрель... Сәйдәш өчен бик тә серле, гамьле, күңеленә сагыш уты коя торган айларның берсе. Аңа 13 яшь вакыт иде, 1913 елның 2 апрелендә, Тукай вафат булды... Тукай үлгән көн...

Ничек тә акча юнәтеп, шул көнне шагыйрьнең каберенә зиярәт кыласы, чәчәк саласы иде...

## Тукай белән очрашулар

Тукай белән очрашуларга кадәр ниләр булды соң әле аның нәни тормышында?

Салихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә биргәннәр иде, ул бик тырышып шунда белем эстәде. Бу атаклы мәдрәсәдә Кәрим Тинчурин, Фатих Әмирхан кебек асыл затларның укып чыкканлыгын белгәч, горурлыктан малай бер башка үсеп киткәндәй булды. Шулай булмый ни, алар бит икесе дә Салих яшәгән өйдә, дөресрәге икенче җизнәсе Шиһаб Әхмәров йортында бик еш кунак булалар. Театр, әдәбият-сәнгать турында озаклап гәпләшәләр, уенкөлкеле сүзләр чыктымы, шаулатып көләләр. Ике Габдулла—Кариев белән Тукай, йөзек кашыдай, мәҗлес күрке. Салих һәммәсенең сөйләшкәннәрен игътибар белән тыңларга тырыша. Шушындый мөхтәрәм кунаклар барында үзенне «зур» кеше шикеллерәк хис итми кара син!

Шундый чәй мәҗлесләренең берсендә Салих өчен язмышын тамырдан үзгәрткән искитмәле хәл булды. Табындашлар арасында Казанга Чистайдан килеп төшкән халык музыканты Заһидулла Яруллин да бар иде. Аңа Салих ишектән килеп керүгә үк игътибар итте. Мөлаем генә исәнләште бу кеше, озынча трость-таягын бер читкә сөяде. Куе-калын чәчләре ике яклап артка таба кайтарылып төшкән. Нindидер мәгънә салгандай, ике бармагы белән чем-кара мыегын сыпырып куйды. Табын артында күп сөйләшми, нindидер серле абыйга охшаган иде ул.

Сүзне Кариев башлады:

—Менә нәрсә, Шиһаб әфәнде, каенишең Салих турында әйтер сүзебез бар иде безнең... Бер кавымга тынып торды да дәвам итте:

—Театрыбыз труппасы музыкантларга мохтаҗ. Яруллин әфәнде яшьләрне тупларга, аларны өйрәтергә дип ашкынып тора. Сезнең Салихны да шунда тартмакчы булабыз!

Көтелмәгән бу яңалыктан җизнәсе баштарак аптырап калгандай булды шикелле. Аннары:

—Укытырга дисезме?

Заһидулла Яруллин сүзгә кушылды:

—Малайның музыкага бәрвәрлеге бар. Аны, һичшиксез, пианинода уйнарга өйрәтергә кирәк. Иске пианиногызны ремонтлауны үз өстемә алам. Салихны музыка мәктәбенә әзерләргә кирәк!

Музыка җене кагылган Салихның эченә җылы йөгерде, йөрәге ешрак тибә башлады. Аның хакында сөйләшәләр бит!

—Дусларым!—диде Әхмәров, капыл гына урыныннан күтәрелеп, җан яраткан каенишенә караш ташлап.—Музыканың ни икәнен беләм, аңлыйм. Тик менә бу һөнәре белән киләчәктә мантый алыр микән соң ул? Әллә, мәйтәм, хисап эшенә, сәүдәгә өйрәтсәк, дөресрәк булмасмы... Татарда музыкага укыган кешене белмим. Бу бит күбрәк руслар, яһүдләр эше...

—Салих шәкерт беренчеләрдән булып укыса, аңардан соң бүтәннәр дә

шушы сукмактан китәр. Музыкада татарның киләчәге калкып чыгачак...

Тагын күпмедер сөйләшә-аңлаша торгач, ниһаять, уртак бер фикергә киленде. Хуҗаның ризалыгын алганнан соң мәртәбәле кунаклар бигуш булдылар.

Салихка исә чын-чынлап бәхет елмайган иде.

Салихның пианиносыз бер минут та яши алмый торган чагы.

Яруллин абый дәресләр бирә башлагач, дөнья аңа тагын да кызыклырак, гаҗәбрәк тоела башлады. Биш сызыклы нота буразналары, кармакка һәм бака маймычларына охшаш нота билгеләре сихерләде, үзенә тартып алды аны. До... ре... ми... фа... соль... ля... си... Күр әле, менә шушы җиде аваз ярдәмендә ничаклы җырлар, тагын-тагын әллә нинди могҗизалар тудырып була икән!

Малайның күңеленә сандугач кереп оялаган иде. Ул аны үзе сизә дә, сизми дә кебек... Сайрый гына күрсен бу сандугач!

Остазы-укытучысы Яруллин кайбер дәресләрдә кайчакны икешәр сәгать буе диярлек Салихка күнегүләр ясата. Бармакларның йөгерек хәрәкәте, уйнаган чакта аларны талчыбыктай дөрес итеп бөгә белү, югары һәм түбән тоннарга күчү, гаммалар агышын һәм аккордлар бирү осталыгына ирешү дисенме—боларның берсе дә калмады. Салихның хәтта бармаклары арып чыга, тәмам талчыга иде. Җаны теләгән шөгыль булгач, ул боларның барысына да түзде, түзде...

Яруллин беренче дәресләрдән соң ук: «Сүбхәәналла, малайда бит галәттән тыш ишетү сәләте... Мотлак тоемлау!»—дип үзалдына куана иде. Бу сүзләрне ул бер мәлне Салихҗанның үзенә дә, җизнәсенә дә кычкырып әйтте.

Ике көннең берендә шөгыльләнү өчен күнекмәләр, өй эшләре бирә остазы. Тора-бара аңа катлаулырак эшләрне бирүдән дә тайчынмады. «Өйрән, һөнәреңне үстер!»—дип әйтеп кала киткәндә. Ә инде дәресләр вакытында: «Син музыканы йөрәгең белән сизәсең»,—дип дәртләндерергә дә онытмый.

—Сиңа тәҗрибәле рус музыкантларыннан да дәрес алырга кирәк булыр,—диде көннәрнең берендә.

Остаз белән Шиһаб җизнәсе бу эшне дә тиз тоттылар. Салих пианистка Анна Сергеевнадан һәм аннары фортепиано буенча профессор О. Родзевичтан дәресләр ала башлады.

Шулай итеп, 12 яшьлек Салих музыка баскычларыннан һаман саен биеккәрәк күтәрелә барды.

***

Тукай тикле Тукай белән беренче очрашу...

12 яшьлек Салих шәкерт белән 26 яшьлек шагыйрь Тукай кайда, ничек очраштылар соң? Моны, шул чактагы әгъләә хәлләрне Сәйдәшнең үзеннән дә яхшы белүче булмастыр, мөгаен.

Әүвәлге танышу Шиһаб Әхмәровлар өендә булды, билгеле. Өйнең түренә өч көзгеле трельяж урнашкан. Урам якка караган өч тәрәзәле уртача зал. Ян-якта йомшак кәнәфи һәм урындыклар. Кечкенә көзгеле комод. Урта бер җирдә чиста эскәтер җәелгән өстәл. Дәү шкаф. Түр почмакта пианино.

Җизнәсенең Тукай белән дуслыгы, томанлы гына булса да, шәкерт малайга азмы-күпме билгеле иде. Буадан Казанга кайтып төшү белән Шиһаб атлы мөгаллим «Болгар» номерларының берсенә урнаша. Күрше бүлмәдә—шагыйрь Тукай! Дуслашалар. Бер-берсенә ишек кагып, рөхсәт сорап та тормыйча кереп-чыгып йөриләр. Өйләнмәгән ике буйдак әнә шулай дүрт-биш ел буе кардәш-фикердәш, табындаш булып яшиләр. «Болгар»ның өске катындагы кечкенә залда еш кына бергә ашап-эчәләр.

Салихнын да Тукай белән «танышлыгы» юк түгел. Ул инде Насретдин жизнәләрендә яшәгәндә үк шагыйрьнең «Туган тел», «Шаян песи» һәм башка шигырьләрен укып та, яттан да әйбәт белә иде. Кич життеме, Әминә апасына ялвара башлый:

—Алма апаем, бүген миңа нинди шигырь, нинди әкият укыйсың?..

Әминә апасы белән, өлкән жизнәсенен күбәләктәй киенгән кызлары белән өстәл тирәли урнашалар. Алар каршында туган тел ачкычлары, Тукайнын йотылып тыңлый торган шигырьләре, тылсымлы бер яна дөнья ачыла...

Әйт әле, күбәләк,
Сөйләшик бергәләп.
Бу кадәр күп очып,
Армыйсын син ничек?

Болары—бәләкәйрәк чакта. Ә инде «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда әле кайчан гына ул дәрестә Тукайның «Туган тел» шигырен искитмәле мәкам белән көйләп-жырлап укыган иде. Шәкертләр генә түгел, хәтта мөгаллиме—коръәнхафиз Вәли Кари да таң калган иде ул чакта.

Шулай беркөнне Шиһаб жизнәсе кунак белән кайтып керде. Юкачарак гәүдәле, үзе көләч тә, үзе монсурак та күренгән бу абый өйдәгеләр белән итәгатьле генә исәнләште. Жизнәсе:

—Шагыйрь абыең килде. Син яттан белә торган «Туган тел», «Алтын тарак» шигырьләрен язган Габдулла Тукай абыең үзе була инде,—дип, кайнише Салихны да аның белән таныштырырга онытмады.

Көтелмәгән очрашудан, шатлыктан Салихның башы түшәмгә тиде! Менә нинди икән ул чын шагыйрь абый... Үзе гади, үзе кул житмәслек серле дә кебек... Баштарак ул аның белән бик оялып сөйләште, аның сорауларына сабыйларча тартынып кына җавап бирде. Менә бит, тора-бара кыюланып китте. Хәтта шагыйрь абыйсына үзе үк сораулар бирә башлады:

—Габдулла абый, тагын нинди яна шигырь яздыгыз?

Кул биреп күрешкән абыйсы ана фәрештә шикеллерәк тоела иде. Алай дисән, ул бит әнә уен-көлке сүзләр әйтүдән дә бер дә тартынып тормый. Хәтта бала-чага уеннары белән дә кызыксына.

—Бишташ, кузна уеннарын беләсенме?

—Белмичә ни, беләм. Ишегалды зур ич безнең.

—Кузналарын күпме, таягын төз сугамы?

—Таяк бит ул, Тукай абый, кулын төз бәрсә генә төз суга. Төз бәрмәсән, читкә оча...

Бу сүзләрне ишеткәннән соң Тукай галибанә елмая, аннары кинәт кенә житдиләнеп китә.

—Юк, Салих энем... маяны читкә очырырга ярамый. Төз бәрергә тырыш син... Кузнадан да бигрәк, менә бу телләргә әнә шулай төз бәрергә тырыш,—дип, кулы белән пианино клавишларына таба ишарәли.

—Габдулла абый, гармун картая микән?

Бу сорауны Салих юкка гына бирмәде. Печән базары чатында уйнап утырган сукыр гармунчы белән танышкан иде ул. Ачык һавада, жил-яңгырда уйный-уйный, аның гармуны нык таушалган, бетәшкән иде шул.

Габдулла абый шундук житдиләнеп китте, күзләре кысыла төште. Бу минутта аның маңгаена юка бер жыерчык кунаклады шикелле.

—Шуны әйтәм, балам... гармун картаямы-юкмы, белмим, әмма халык жырлары беркайчан картаймый... Кешеләр генә картаерга мөмкин, жыр белән моң һичкайчан искерми дә, картаймый да!..

Тукайның бер үк сүзләрне дәрт белән кат-кат кабатлавы аккорд сыман яңгырады.

Салихҗан ана үзе белгән көйләрне һәм, әлбәттә, «Әллүки»не пианинода уйнап күрсәтте. Киткәндә Тукай:

—Яхшы уйный бит, шельма!—дип, тагын бер кат соклануын белдерде һәм өйдәгеләрнең һәммәсе белән җылы итеп саубуллашты.

Җизнәсе белән дуслыклары шулкадәр нык булган, күрәсең, кайчакларны ул кунарга ук кала иде. «Болгар» номерларындагы суыктан соң ялгызак шагыйрьнең гаилә, йорт, дуслык җылысын да татып карыйсы килгәндер шул...

Күпме, күпме, булды мондый очрашулар, чәй мәҗлесе корулар!

Ә менә соңгысы...

Монысы инде фаҗига белән тәмамланды.

1913 елның март азаклары иде. Ниндидер бәйрәм уңаеннан зур кунаклар Әхмәровлар өендә табынга җыйналганнар. Тирән кара эчле түбәтәй, ак күлмәк өстеннән зәңгәрсу камзул кигән Салихны бераздан залга чакырдылар. Аны шулай матур итеп Әминә апасы киендергән иде. Кереп утыргач та Салих кунакларга күз салды. Мәгърур кыяфәтле Гафур Коләхмәтов, күзлек пыялаларын ялтыратып утыручы Фатих Әмирхан. Аның кырыендарак әдипнең арбасын этеп йөртүче Мәхмүт исемле егет. Тукай ничектер пианино янындарак урнашкан һәм юка бармаклары белән аның аклы-каралы телләрен капшап карагандай итә. Нишләптер җизнәсе әлегә күренми... Эш-мәшәкатьтән бушаганы юк ич аның.

«Хуҗа озаклады...»—дип аптырашты кунаклар Хуҗа әйләнеп кайтканчы Салихҗанның уйнавын тыңлауны мәгъкул күрделәр. Теләкләре—«Уел»ны тыңлау иде. Инде кече концертларда чыныгу үткән Салих ялындырып тормады, камыштай озынча бармаклары белән клавишлар эченнән үзенә кирәкле көйне тартып чыгарды.

Арыслан ла киек, ай, алдырмас,
Каршысында биек тау булса...

Акрын тавыш белән кемдер көйгә кушылып та китте. Кунакларга аркасы белән утырганлыктан, уйнауга бирелгәнлектән, Салих аның кем икәнлеген чамалап та өлгермәде. Шулай ук акрын, тыйнак тавыш белән җырны башкалар күтәреп алды:

Егет тә генә кеше һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса-а-...

Җырның аккордлары тәмамлану кая, Әхмәров җизнәсе Кариев белән Яруллинны ияртеп кайтып та керде өйгә. Табын түгәрәкләнде. Табын уртасына хуш исләре аңкып торган чөмәкле зур бәлеш чыгарылды. Алъяпкыч япкан җиңгәләре, күз тимәсен, аш-су эшен оста йөртәләр...

Байтак кына утырулар, сөйләшүләр, уен-көлке сүзләрдән соң берзаман Тукай Салих энекәшенең «Әллүки»не уйнавын үтенде. Салихның уенчак бармаклары тагын эшкә җигелде. Ана инде соль-мажорларны кай төштән эләктереп алу турында баш ватасы юк иде. Шагыйрь абый, ничәмә кат өйгә кереп, күпме тапкыр шушы көйне уйнавын сораганы бар аның... Яруллин оештырган кыллы оркестрда гармун, скрипка, курай, кубыз, чүмечтәй мандолиналар катнашында бу көйне данлы «Шәрыкъ» клубында да ничә тапкыр яңгыратканнары булды аларның!

Бүлмәгә Салих башкаруында «Әллүки» моңнары сирпелде... Яшь уйнаучы

бу көйгә кушылып, әле аякларын хәрәкәтләндерә, әле гәүдәсе белән алгаартка бөгелә биреп үз-үзенә һәм клавишларга дәрт бирә. Терсәкләрен, яшь бөркет канатыдай, ян-якка җәеп җибәрә кайчакны...

Тукай түзмәде булса кирәк, кинәт җилкенеп музыкага кушылып китте. Аның ягымлы, бәрхет тавышы тәрәзә пәрдәләренә килеп сарылды... Бөтен табын оеп, тынып калды.

Менә икәү уйный-җырлый...

Икесе дә ятим, әтисез үскән табигать балалары. Бәләкәй Апуш гел кагылып-сугылып үскән... Салихҗан исә яшьтән үк туганнарының гаилә учагына сыенды, кайгы-хәсрәтләр кичмәде. Ләкин аларның икесенә дә ата мәрхәмәте эләкмәгән, әтиләре берсенең дә маңгаеннан яисә чәченнән сыйпамаган... Шәхси фаҗига сыман, ләкин бу моңлы хәл тагын әле меннәрчә сабыйларның язмышына, күз яшенә сиздерми генә кагыла кебек.

Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди моңлы, зарлы көй.
Әллүки, бәллүки,
Әллә нинди зарлы, моңлы көй...

Тукайның эчкәредән алып җырлаган бәрхет тавышы гадәти булмаганча калтыранып чыга башлады... Чү, нәрсә булды?! Менә бер мәлне, ап-ак йөзен ике кулы белән учлап, пианино өстенә капланды ул. Башкалар абайлап, култыклап өлгергәнче, йөткерә биргән шагыйрьнең авызыннан кан китте... Аларның беренче тамчылары клавишлар өстенә тамды. Аккаралы клавишлар өстендә—кып-кызыл кан сурәте. Гүя, җырга, моңга, пианинога—бар дөньясына кайнар ут капты! Салихның бармаклары пешкәндәй, утка эләккәндәй булды бу мизгелдә... Көчле тетрәнүдән җанын кая куярга белмәде ул...

Тукайның Әхмәровлар йортындагы соңгы тукталышы булган икән бу. Аны кичекмәстән Клячкин больницасына салдылар.

Тукайның тып-тын гына сүнеп, аннары кинәт якты кояш булып кабыначак соңгы көннәре бара...

...Тукайны мәңгелеккә озатканда халык диңгез кебек кубарылды. Шушы кыска гына вакыт эчендә остазы-укытучысы Яруллин «Тукай хатирәсе» дигән мәрсия җырын да язып өлгерткән икән. Бу маршны тыңлагач, Салихның баштарак тез буыннары калтырады, аннары җаны күккә ыргылды сыман...

Шагыйрьне югалту ачысы әллә ничәмә төсмерләрдә тетрәтә, уйлата иде.

...Кояш-йолдызлары белән бөтен дөнья чайкала кебек. Һәр үлән, агач, яфрак елый... Әй син, кеше, кылган эшләрең дөньяның кай җирен булса да яктырттымы? Адәм баласы—көньяшәр күбәләк түгел. Ул тәне белән дә, рухы белән дә көчле, гайрәтле зат. Аның тормышында бөеклек сукмагы белән фаҗигале упкыннар һәрвакыт янәшә. Киләчәк каршына шулар аша узарга тиешсең. Үлем—яшәүнең, халык күңеленә күчүнең башы гына...

«Тукай маршы»ның моңнары «Юк, без үләргә хөкем ителмәгән! Без яшибез, алга таба барабыз!» дигән оран белән тукылган иде. Шушы девиз Сәйдәш өчен гомер буена илһам чыганагы һәм маяк булды.

Әй, Тукай, сөекле Тукай! Син бит Казан шәһәрендә кайнап яшьнәдең генә түгел, Казанның үзен дә яшьнәттең, кайнаттың лабаса...

## Кызылармееҗ Сәйдәш

1954 ел, 1 май.

Шәһәр өстен бизәп, канатлы хыялларны хәтерләтеп, күктә ак күгәрченнәр оча! Биек-биектә ап-ак юл сызып, бәйрәмне сәламләп, самолет узып китә. Башкала демонстрантлар агымына, аллы-гөлле шарлар, чәчәк түтәлләренә күмелгән. Хезмәт ияләренең бәйрәме бөтен тирә-юньдә гөрләп тора...

Горький исемендәге Үзәк ял паркы. Сәйдәшне Кызыл Армия маршына шәхсән үзе дирижерлык итсен дип чакырганнар иде. Менә бит ничек күңелле—онытып бетермиләр үзен!

Бу тәкъдимгә ул бик теләп риза булды, билгеле. Чөнки аның кайчандыр үзе хезмәт иткән Кызыл Армиягә, кызыл йолдызга мәхәббәте беркайчан да сүнмәслек иде.

Халык ифрат күп җыйналган. Алар түземсезләнеп тынлы оркестрның уйнавын көтәләр. Нечкә таякчыгын тоткан хәлдә, Сәйдәш пульт алдына килеп басты. Хөрмәтләү билгесе итеп, көчле кул чабулар белән каршыладылар аны.

Ялт иткән дирижер таякчыгы винтовка очындагы штыктан да куәтлерәк иде бу минутларда. Аның бу мизгелгә һавада тынып-тукталып калуы тылсымлы өн белән сугарылган иде. Башланды! Менә барабаннар, торбалар маршның беренче дәртле авазларын эләктереп алды... Шуларның агымына тау чишмәседәй скрипка, кларнет, гобой моңнары кушыла... Чиратлашып, башка уен кораллары да бердәм хәрәкәткә килә... Көчле ритм, күтәренкелек, ашкыну һәм батыр моңнар паркның барлык почмакларын били ала. Саф-саф тезелгән солдатларның кирза итекләр белән тигез атлап барганы аермачык рәвештә күз алдына килеп баса. Яшел бакча тагын да киңәеп, ачылып китә кебек. Андагы рәт-рәт агачлар, тын алырга туктаган кошлар оеп калган, алар да бу дәртле музыканы сихерләнеп тынлыйлар...

Оркестрның җиз торбаларында, литавра тәлинкәләрендә чагылып-чагылып кояш нурлары уйный...

Нәрсәне, кайсы көннәрне хәтерләтә соң бу илһамлы күренеш, оркестрның шашып-дәртләнеп уйнавы?..

Соңрак, өеңә әйләнеп кайткач та, Сәйдәш яшьлегендәге озын сәфәр хатирәләреннән һич кенә дә аерыла алмады.

***

1919 ел. Илдә гражданнар сугышы кайный. Колчак армиясе Идел буйларына һөҗүм итә. Үзе адмирал, үзе дингезче, әнә шул башы белән җир өсте гаскәрләре белән җитәкчелек итмәк, илне большевиклардан азат итмәк була.

Нәкъ шул көннәрдә Казанга кызыл комиссар Шамил Усманов килеп төшә. Акларга каршы көрәшү өчен кичекмәстән Беренче мөселман бригадасы оештырырга кирәк. Сугышка керәчәк солдатларның рухын күтәрү, алар арасында сәяси-агарту эшләре алып бару, артистлар труппасы төзү бик мөһим. Эшлекле Шамил Усманов, үҗәтлек белән, әнә шушы эшкә керешә. Ирекле отрядлар янына ирекле артистлар, музыкантлар да кирәк.

Сәйдәшнең биографиясендә, Кызыл Армия сафларына үзе теләп китте, дигән сүзләр кызыл җеп булып бара. Чынлап та, үзе теләп киттеме соң ул хәрби сәфәргә, хәрби походларга? Әйе, һәм юк... Әйе, чөнки татар хәятына, аның сәнгатенә яңа сулыш ачкан инкыйлабка ихластан хезмәт итәсе килә иде аның. Дөнья күреп, яңа кичереш, уй-тойгылар белән баеп кайтасы килә аның. Юк дигәндә... хәрби тормыш шартлары аның күңел канатын

сындырмасмы, моңга-жырга сусаган күнелен тупаслатмасмы?..

Ике ут арасында калган чаклары иде анын. Үзенен гражданлык бурычын аңлаган, үгетләүгә тиз бирелә торган Сәйдәш Беренче татар укчы бригадасына трубачы һәм капельмейстр булып китәргә ризалык бирде. Әнә шулай итеп, яраткан шәһәре Казаннан китәргә туры килде аңа.

Казаннан аерылуы беренче тапкыр түгел. 1917 елда аны, гармунчы Фәйзи Биккинин белән бергә, Буа шәһәренә озак сәфәргә юллаганнар иде. Бергәләп, анда музыкаль студия оештырдылар. Һәвәскәрләр оркестрына житәкчелек иткәндә япь-яшь Сәйдәш көйнең күптавышлы булып яңгыравына әнә шул чакларда ук өйрәтә башлады. Азмы-күпме тәжрибәсе бар иде инде анын.

Сугышчан юллар, походлар... Ул йөргән, күргән-белгән шәһәрләрне санап чыкканда гына да илнен никадәрле киңлекләре ачыла: Самара, Бузулук, Оренбург, Ташкент, Сәмәрканд, Коканд, Бохара, Ашхабад... Биредәге күпме юлларда, сукмакларда Сәйдәш эзләре уелып калган...

Оренбург өлкәсе. Анын борын-борыннан ук татар-башкорт жирләре булуы үзен сиздереп тора. Бузулук станциясенең «бозаулык» сүзеннән алынуын ишетеп, Сәйдәш гажәпләнгән иде. Оренбург уртасындагы Кәрвансарай исә анын бөтен игътибарын, күнелен жәлеп итте. «П» хәрефе рәвешендә салынган бу гажәеп бинанын кыл уртасына мөселман мәчете салынган. Манаралар очындагы ай сурәте күккә, кояшка, болытларга тоташкан. Ак дивардан һәм кызыл кирпечләрдән тарихи бер моң сирпелеп тора сыман. Азан әйтелгән минутларда илнен кайсыдыр почмакларында аклы-кызыллы сугыш барганлыгы тәмам онытыла кебек.

—Алла-а-а...һе.. әкбә-ә-әр...

Хәтеренә төште: «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган чакта корьәнхафиз мөгаллимнәре Вәли Кари да Корьән сурәләрен әнә шундый затлы мәкам белән, күнеленне эретердәй итеп укый торган иде...

Хәзер инде Сәйдәшев бөтенләй бүтән сурәттә. Башында анын кызыл йолдызлы шлем, өстендә солдат шинеле, аякларында чолгаулы ботинка. Иң мөһиме: ул—капельмейстер! Пианинода уйныйсы бармакларга ярый әле пычак, кылыч, утлы корал тоттырмадылар! Югыйсә Салихнын күнеле, вөжүде моны бөтенләй кабул итә алмас иде.

Анын жилкәсендә хәзер өр-яңа йөк, яңа бурычлар: репертуар сайлау, жыр һәм нота дәресләре бирү, музыка инструментларынын торышын күзәтү, дирижерлык итү.

Капельмейстр... Бит бу сүз аңа кечкенәдән, дөресрәге, Ташаяк ярминкәсеннән бирле таныш. Базар рәтләрен күзләп йөргәндә ул кин тәрәзәле, биек ишекле кибеткә юлыкты. Биредә бер немец агае музыка уен коралларын сатуны оештырган икән. Малайның бар уйлаганы, хыялы—гармун! Хәзергә бүтән уен коралларын юньләп аңламый ул. Шулай да табактай олы авызлы кәкре торбаларны һәм аккош муеныдай сыгылмалы скрипкаларнын ни икәнен аера иде. Тик менә көзгеле ялтыр киштәләрдә гармун гына күренми...

Ишектән төз гәүдәле, хәрби киемле берәү килеп керде. Анын башында кокардалы фуражка, ялтыр сәдәфле мундир, ә кулларында сөт шикелле ап-ак перчаткалар иде.

—Күрсәтегез,—диде ул, башын жинелчә генә иеп.

—Рәхим итегез, капельмейстер әфәнде,—диде сатучы, мыеклары белән кин елмаеп.

Шулай диде дә бер як читтәге кара чаршауны ачып жибәрде. Менә әттәгенәсе! Киштәнен бер почмагында чып-чын гармун посып утыра иде. Насретдин жизнәсе эшли торган урынга барып, тиз генә хәбәр итәргә

кирәк... Чү, әлеге хәрби кеше гармунны сатып алырга чамалый, ахрысы... Салихка берни дә калмас микәнни?

Бәхетенә, гармунны төрлечә тоткалап караганнан соң ул нидер әйтеп, честь биреп кибеттән чыгып та китте. Салих кабаланып, магнитка ияргән булавка кисәгедәй, хәрби артыннан йөгерде.

—Капельмейстер абый, туктагыз әле!..

—Нәрсә, энем, берәрсе кыерсытамы әллә?

Тынына каба-каба, Салих аңа гармун эзләве турында сөйләп бирде. Бу вакытта капельмейстерның ак перчаткалы кулы малайның башыннан сыйпый иде:

—Күз тимәсен, музыкага һәвәс малай икәнсең. Күңеленне төшермә, гармунлы да булырсың әле... Мин Ак кремльдәге хәрби капельмейстер Хәйбулкин абыең булам. Кем белә, үскәч син дә минем шикелле капельмейстер булырсың әле. Ярый, перәннеккә ал моны...

Салихның учына көмеш тәңкә салды да Кремль ягына таба китеп барды хәрби. Күңеле нечкәрүдән малай, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, ике кулы белән йөзен каплады...

Хәйбулкин абый әйткән сүзләрнең рас килүен кара син! Әйтерсең, күрәзәче булган ул...

Кыш җиттеме, Казанда йомшак карлар ява башладымы—ул еш кына Үзбәкстандагы мамык җыючы кызларны, андагы мамык бураннарын исенә төшерә... Менә гаҗәп: дарыны мамыктан ясыйлар икән! Шундый йомшак нәрсәкәй, «киемен» алмаштыргач, әнә ничекләр итеп йортларны, тау-ташларны җимерә, кешеләрнең гомерен өзә...

Ут белән, дары белән шаяруның ни икәнен үз җилкәсендә татыганы бар Сәйдәшнең. Бервакытны Бохарада, кечерәк клубта, кызыл сугышчылар кино карап утыралар. Кинонын исеме истә калмаган. Кача-поса килгән басмачылар бинага ут төртәләр. Янгын кинәт башлана һәм клубның ишек-тәрәзәләрен томалап ала. Байтак кеше янып, сытылып һәлак булды әлеге мәхшәрдә. Җирнен-күкнең нинди көчләре ярдәм иткәндер, Сәйдәш икенче каттан сикереп котыла алды, ут эченнән исән чыкты. Берара аксабрак йөрергә туры килде килүен...

Аларның бик күбесен тагын бер афәт сагалап торган икән әле. Кызылармеецларны да, иҗади труппадагы артистларны да Ашхабадта чакта малярия бизгәге газаплый башлады. Биредәге москит дигән бәләкәй-вак чебеннәр тешли, тәнеңне бимазалый. Аннары инде тән кычыта башлый, температура күтәрелә. Өстәвенә, күңел болгана, аяк буыннары авырта, тән чабырып чыга. Бу бәладән ничек саклану чараларын баштарак юньләп белмәделәр шул...

Сәйдәшнең ил буйлап беренче зур сәяхәте, беренче мәртәбә музыка әсәрләре язарга омтылып каравы әнә шул чакларда килеп чыкты. Мөстәкыйль иҗат икән беренче җырына «Озын сәфәр» дигән исем кушты. Үзбәкстан якларында сәфәр йөргән вакытта алган, күргән-белгән тәэсирләрен әнә шулай итеп җырга, музыкага салды ул. Беренче иҗат җимешенең исеме бик тә мәгънәле куелды булса кирәк: үзенең дә гомере озын булсын, музыкасы да озак яшәсен, озын-озак юлларда халкына юлдаш булсын...

Чынлап та шулай булып чыкты: «Озын сәфәр» дигән беренче җырына таянып, аның моннарына нигезләнеп, өр-яңа хәрби «кием» киертеп, 1929 елда ул атаклы Кызыл Армия маршын яза алды да инде. Элек күргәннәренә яңа музыкаль тәҗрибә килеп кушылганнан соң өр-яңа марш әнә шулай дөньяга туды.

Малярия чиреннән соң Сәйдәшевне армия хезмәтеннән азат иттеләр. Кая диген—тагын Оренбургка җибәрделәр. 1921 елның җәй айлары бу. Әлерәк

кенә оешкан театр труппасы Мирхәйдәр Фәйзинең «Асылъяр»ы буенча репетицияләр алып бара икән. Труппа житәкчесе Камал I залга ишарәләп нидер әйтә, нидер аңлата:

—Иптәшләр, бер генә минутка дикъкать!

Шул вакыт залга солдат киемендәге Сәйдәшев килеп керде. Өстендә соры шинель, башында кызыл йолдызлы шлем, аягында чолгаулы ботинкалар. Менә алар икесе ир-егетләрчә кочаклашалар. Аннары Камал I яңа кунак белән таныштыра:

—Бу солдат... Казан егете. Музыкант Салих Сәйдәшев. Ул Оренбургның музыка мәктәбендә укытырга калачак...

Әйе, укытырга калды Сәйдәш. 200ләп татар баласы укыган Көнчыгыш музыка мәктәбенә мөдир итеп билгеләделәр үзен.

Күр әле, Сәйдәш тә үзенә күрә кечкенә генә бер түрә була ала икән!.. Юк, ул беркайчан да үзен түрә, чиновник итеп санамады. Андый урыннарга ашкынмады. Яшь алмаш әзерләү эшенә бөтен тәне-җаны белән бирелде. Бары шул. Музыкант буларак нәкъ менә бирелдә ул үзен дә үстерде, музыканың бәллүр сараена яңа адымнарын атлады.

Ул балачактан сөеп-сөелеп үскән Казанның сагына. Казан аның үзен дә сагынмый дисенме?!.

Барлык юллар Римга илтә кебек, язмыш та Сәйдәшне гел Казанга тартып-йолкып кына тора...

### Без кабызган утлар...

Татар уяна!

Бу инкыйлаб дигәннәре Россиянең алагаем карынында бөялеп яткан халыкларга да йөз белән борыла, ахрысы. Буа шәһәрен инде әйткән дә юк, Самара, Оренбург, Ульяновск, Ташкент кебек калаларда татар дөньясы уяна, мәгърифәт-театр учаклары кабына! Татар милләтен мәрткә киткән дип дөрес әйтмиләр. Карагыз, уяна татар!

Казанда татар дәүләт театры оеша, анда музыка бүлеге мөдире һәм дирижер итеп яшь-яшь музыкант Салих Сәйдәшевне чакыралар икән, бу бер дә юкка түгел. Кем чакыра диген! Үзе драматург, үзе актер, үзе режиссер Кәрим әкә Тинчурин лабаса... Беренче татар театрын төзү кебек дәрәҗәле эш нәкъ менә аңа йөкләтелгән. Ул инде иң яхшы артистларны үзе тирәсенә туплап та өлгергән икән. Болар—Мохтар Мутин, Хәким Сәлимжанов, Ситдыйк Айдаров, Нури Сакаев, Фатыйма Ильская, Рокыя Кушловская, Мәрьям Сульва, тагын-тагын әллә кемнәр... Майданга яңадан-яңа сәнгать әһелләре килә.

Бүгенгедәй хәтерендә Сәйдәшнең: теге чакта, Мәкәрҗә ярминкәсендә концертлар куеп йөргән чакта, ни дип җырлады соң әле атаклы Камил Мотыйгый...

> Ятма йоклап, уян, татар,
> Уянырга вакыт җитте!..

Кара фрак, ак күлмәк кигән, баритон тавышлы Камил Мотыйгый бөтен залны, бинаны, тамашачыларны тетрәтте ул чакта. Аның җыры, инеләй ачык тәрәзәләрдән тышка ташып чыкты да, Мәкәрҗә майданын һәм Нижнийның якындагы урамнарын көрәш авазларына күмде.

1905 елгы революция татар йөрәгенә, милли уҗанына ут салган, театр мәгыйшәте шуннан башланган, диләр. Театр! Гаҗәеп көчле, тылсымлы, магнитлы сүз. Күрегезче, Казанда зур, яңа театр оешып килә. Житмәсә,

килде-китте генә түгел, дәүләт театры... Димәк, дәүләт турыдан-туры үзе булыша, шәфкатеннән калдырмый, химаячелек итә дигән сүз. Оркестры да оешачак—бу бит инде күктән төшкән бәхет!

Тинчурин 22 яшьлек Сәйдәшне:

—Оркестрны төзү һәм дирижерлык итүләр синең җилкәгә төшәчәк, аркадашым!—дигән сүзләр белән каршылады. Әхмәровлар йортында музыка белән җенләнеп үскән, вакытында Император музыка җәмгыяте училищесында укыган үсмер малай хәзер инде аңа байтакны күреп, сәнгати тәҗрибә туплап өлгергән затлы егеткә охшаган иде.

Карап-карап торганнан соң болай дип тә өстәде әле:

—Син һәрчак шулай яшь бул! Мин дә яшь булыйм. Мин синнән хәйранга өлкәнрәк икән, кирәк чакта син дә өлкән була бел... Килештекме?

Мәгънәле бу сүзләрдән соң, килештек дигәндәй, бер-беренә туры карашып алдылар. Күренеп тора: Сәйдәштән унике елга алданрак туып, ипине күбрәк ашап өлгергән Тинчурин тел сәхнәсеннән йомры сүзләрне тәгәрәтеп кенә тора, сүзгә кеше кесәсенә керми. Алайга китсә, Салих үзе дә төшеп калганнардан түгел. Бигрәк тә шаян-тапкыр сүзләр дигәндәй...

Сөйләшүләренең берсендә Сәйдәш, оркестрны тагын да көчәйтү, аның мөмкинлекләрен киңәйтү ихтыяҗын алга сөреп, театрга арфа кайтарту кирәклеген үзенчә бәйнә-бәйнә аңлатып караган иде. Тинчуринның күзләрендә шундук якты очкыннар кабынды:

—Менә идея! Чынлап та шулай бит. Мөмкинлек табып, оркестрны мөкәммәл дәрәҗәгә җиткерергә кирәк... Мин өстәге җитәкчеләр белән сөйләшеп карармын...

Аннары, калын чәчләрен артка чөеп, көлемсерәп куйды:

—Үз һөнәреңнең осталарын яратам да соң! Башың түгәрәк синең...

—Берәүнең дә башы шакмак түгел.

Сәйдәшнең көтелмәгән бу тапкыр җавабыннан икесе дә рәхәтләнеп көлештеләр.

Шактый кыска вакыт эчендә Сәйдәш, беренче татар дирижеры буларак, оркестрны төзү һәм тулыландыру эшен уңышлы ерып чыкты, үзе тирәсенә талантлы музыкантларны туплады. Аларны ул рухи-иҗади дәрте белән генә түгел, шәхси үрнәге белән дә зур эшләргә рухландырып торды булса кирәк...

Күп вакытларында, бигрәк тә дирижерлык иткәндә, ак костюм-чалбардан, яка турысындагы ап-ак бантиктан яисә кара «күбәләк»тән булыр. Артка ыспай итеп таралган куе коңгырт-кара чәчләр. Төс-кыяфәтеннән, йөзеннән эчке бер нур бөркелә. Күк йөздәй зәңгәр күзләре кешене сихерли, әсир итәрдәй якты моң белән мөлдерәмә. Үзе беркайчан кычкырып көлмәс, бары елмаеп кына торыр. Затлы, зыялы кеше. Менә шушы барлык күркәм сыйфатлары аңа табигатьтән һәм әнисе Мәхүбҗамалдан килә. Бер карасаң, иртән торып кырына-юына, булганда шикәрләп чәй эчә торган гап-гади кеше, Алла колы ул. Ләкин, дирижер пультына бастымы, камыштай таякчыгын кулына алдымы—бүтәннәр генә түгел, хәтта Сәйдәш үзе дә үзен-үзе танымаслык илаһи бер халәткә керә иде.

Оркестр да оешты, музыкантлар төркеме дә тупланды. Ләкин моның белән генә эш бетәрлекме соң?!. Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Тажи Гыйззәт бер-бер артлы янадан-яңа пьесаларын табадан төшереп кенә торалар. Татар хәятында музыкаль драма дигән яңа жанр чын-чынлап чәчәк атып килә. Күз күрмәгән бу ярыш, ренессанс Сәйдәшнең дә төн йокысын алды. Пьеса, драматургия әсәрләренә музыка язар өчен бар вакытын исраф итә хәзер. Увертюра, ария, дуэт, хор, балет биюләре—болар бар да татар дөньясында зур яңалык!

Мәскәүдә Бизенең «Кармен» операсын караган-тыңлаганнан соң

Сәйдәшнең күнеленә бер тәшвиш килгән иде килүен: «Бәдәвәм»не тыңлап үскән татар баласы опера жанрын кабул итәргә әзер микән сон?..»

Хәзер инде аның бу шикләре таралды. Әшне, чынлап та, музыкаль драма жанрыннан башлау дөрес. Көй-җырларның һәммәсе халыкчан, шул ук вакытта интернациональ да булырга тиеш. Асылда музыкага тәрҗемә кирәкми. Сәйдәш үзендә иге-чиге булмаган иҗат мөмкинлекләре сизә! Җирдәге һәм күктәге көчләр ана янадан-яна музыкаларны язарга булышлык итә. Моң, музыка упкын кырыенда торганнарга, җылы сүзгә мохтаҗ булганнарга терәк, таяныч булырга, көч бирергә тиеш! Кеше җаны барыбер яктыга, яхшылыкка, җылыга омтыла... Менә шушы җәһәттән музыка—моңлы-зарлы адәм балаларының рухи юлдашы, маягы, күңел юаткычы. Музыканың төп миссиясе—кешеләрне матурлык өчен көрәшергә, яшәргә чакыру...

Остазы, беренче укытучысы Заһидулла Яруллин яшь-яшь Салихны нотага ничекләр итеп өйрәткән иде вакытында! Хәзер инде Сәйдәш үзе укытучыга, өйрәтүчегә әверелеп бара шикелле. Спектакльдә уйнаучы артистларны хорда яисә аерым арияләрдә җырларга өйрәтү бер дә ансат бирешмәде. Бишәр, унар кат өйрәнү-кабатлаулар гадәти бер хәл иде. Түзеләр, бәгырьләр, рәхмәт үзләренә. Әмма спектакльдән соң яуган алкышлар барысының да җанына татлы бәлзәм булып тамар иде—иң зур бәхет менә нәрсәдә!

Театрга эшкә килгәндә Сәйдәшнең эчтән генә, борын астыннан гына нидер көйләве—аның өчен гадәти бер хәл. Чире, рухи халәте шундый. Аның иҗади дулкында кайнап яшәгән чагы. Ноталар аның колагына үзләре бәреп керә!

Менә аның эш бүлмәсе. Театрның беренче катында ул. Барлык җиһаз—өстәл, рояль, берничә урындык... Ялангач өстәл һәм рояль өсләрендә—кочагы-кочагы белән нота кәгазьләре. Аларның байтагы тәртипсез рәвештә тәрәзә төпләрендә дә чәчелеп ята.

Аның эш бүлмәсендә иң яраткан бер рәсем-сурәт бар... Менә Идел киңлекләре буйлап аккоштай ак пароход йөзә... Үзе ялгыз сыман, ләкин аның янәшәсендә—ак болытлар, яшеллеккә баткан ярлар, зәңгәр күктә самолет төтене эзләре. Рәссам дусты бүләк иткән бу иҗади манзара аңа барыннан да элек җәйләрен бик еш ял итә торган, җанга якын Кызыл Байрак авылын, Ослан тауларын, дус-ишләрен, яшьлеген хәтергә төшерә...

Авыл табигатен, аның кешеләрен үлеп яраткан Сәйдәш җанына Кызыл Байрак—ял итәр өчен бер дигән урын, тукталыш, Ходай бүләге иде. Иртә таңнан торыр, йорт каршына егып салынган бүрәнәләр өстенә утырып папиросын кабызыр, авылның ничек уянганын күзәтер. Күзләре белән генә түгел, колагы белән дә. Кошлар җыры—иртәнге серенада... Елга буеннан исә балыкчы картның ишкәк чупылдатканы, авылдан чыгып барган сыер-сарыкларның мөгрәү авазлары ишетелә... Агачларның кәүсә-ябалдашларын төнге йокыдан уятып, яфраклар серләшә... Табигатьне, авыл күренешләрен тасвирлаганда, хыялый-уйнак настроение биргәндә гобойдан да кулай инструмент юк, билгеле. Шушы мәлдә композиторга илһамлы минутлар килү гаҗәпмени? Шуңа да аның бик күп җырлары-мелодияләре, вакыты гына җитсен, бик тиз һәм ансат туа диярлек.

...Менә улы Нәүфәл белән Идел буена балык тотарга төшәләр. Кармак сабын тотып, балык чирткәнне көтеп яр буенда тын гына озаклап утыруларның аерым бер ләззәте бар. Күңелнең туарылып ял иткән чагы да бу. Сәйдәш, гадәтенчә, онытылып китеп, ара-тирә авыз эченнән нindидер моңны көйли башлый.

—Әти, бик шаулама, балыкларны куркытасың бит...

Сәйдәш улына елмаеп җавап бирә:

—Киресенчә, мин аларны безнең янга килсеннәр дип махсус сихерлим. Алар да музыканы ярата, улым.

Ә Иделдә су коенулар дисенме! Моның ләззәтен исә сүз белән генә аңлатып бетерерлек тә түгел. Кергән шәпкә су салкыны, дулкыннар айкалышы баштарак тәнеңне куырып алгандай итә. Ә инде колач салып әчкәре керә башлагач, аякларыңны йөзү хәрәкәтләре уңаена көйләгәч, кайнарланып китәсең, күзәнәкләреңә көч-дәрман тула. Куе-тыгыз су агымы сине үз итеп, кочагына алып тибрәтә кебек. Идел үзенә хас ритм белән ухылдап сулыш ала. Кайчакны утлы-кылычлы орышлар авазын, җилкәсен аркан кискән бурлакларның аһ оруларын ишеткәндәй буласың. Идел аша, аның киңлекләре аша тарих җилләре, биниһая манзаралар узган шул заманында...

Сәйдәшнең менә шушы эш бүлмәсенә кемнәр генә килеп кермәс икән! Тансыклап та, йомышлары төшеп яисә яңа язганнарын тыңларга теләп тә. Җырчылардан кычыткан чыпчыгыдай Сара Садыйкова, шәм кебек төз-гүзәл Галия Кайбицкая... Алар ана ярдәм дә итә, кайчагында комачаулый да кебек. Ләкин Сәйдәш аралашу, шау-шулардан беркайчан качмас иде. Җырчыларга яңа арияне өйрәтү яисә яңа язганыңны рояльдә уйнап күрсәтү шатлык кына лабаса.

Ул үзе дә әнә Кәрим Тинчуринның эш бүлмәсенә керергә ярата иде. Сөйләшеп утыра торгач, бу кеше кырыенда ничәдер миллиметрга үсеп киткәндәй буласың. Язган пьесаларында бер хәл, хәтта гади генә сөйләшүләрдә дә ул әллә ничаклы тапкыр сүзләр, көтелмәгән гыйбарәләр чөеп ташлый. Әйтәсе дә юк, Ходай аңа талантны мулдан биргән. Хатыны Заһидә камыр ризыклары пешерүдә оста куллы иде. Кәрим әкә әбәдкә еш кына сумса, өчпочмак яисә алма бәлешеннән өлеш алып килгәли.

Болар хәтердә түгелмени?

Тинчуринның үзенең эш бүлмәсе дә әллә нәрсә түгел. Ерактан калган таза-борынгы урындыклар, эш өстәле. Өстәле тулы таза-симез папкалар, кара савыты, үткен итеп очланган карандаш ише әсбаплар.

Керә-керешкә аягүрә каршы алыр, беренче соравын биреп тә өлгерер үзе:

—Йә, Салихҗан дус, эшләр ничек бара? Ноталар урманында адашып, сөрлегеп калмадыңмы?

—Сөрлегергә вакыт юк. Бүген дә төнлә язылды...—дип ашыкмый гына җавап бирә Сәйдәш.

Очрашу-сөйләшүләре, гадәттә, иҗатка кагылышлы әнә шундыйрак сүзләрдән башланып китә. «Кайчан уйнап күрсәтәсең?»—дип сорап та тормый Тинчурин, чөнки композиторның кайчан-ничек уйнап күрсәтәсен ул болай да яхшы белә. Аның биш пәрдәлек «Зәңгәр шәл» дигән мелодрамасы инде төгәлләнгән. Пьесаның баш геройлары Булат белән Мәйсәрәнең бергәләп җырлаулары колак төбендә генә түгел, күңел төпкелендә үк аермачык яңгырап тора:

Бергә-бергә көн итәргә
Кочагыңа мине ал.
Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үткән гомер бигрәк җәл...

Шулай берсендә Тинчурин аңа Ишанның һәм дүрт хатынының әрепләшеп-талашып торган өлешләрен укып күрсәткән иде.

—Ничек булган бу?—дип сорады.

—Әйбәт булган ич... Бик кәкре, бик туры...

Сәйдәшнең бу сүзләрен драматург ни тәнкыйть, ни мактау дип тә кабул итә алмады:

—Нәрсә, ошамыймы әллә?—диде турыдан-туры.

—Синең Ишанынны һәм аның хатыннарын салкын суга чумдырып алырга кирәк. Юкса тиз кызалар, ике сүзнең берендә начар-ямьсез сүзләр кушып сөйләшәләр.

—Ярар, уйлап карармын мин моны! Синең эшең, дускай, музыка ярдәмендә спектакльгә мәңгелек канат кую. Язганнарың һәрвакыт матур һәм халыкчан килеп чыга әнә... Мин йөзем орлыкларын сибәм, ә син, Салих, алардан бриллиант ясыйсың.

Тинчурин, вакыт төшенчәсен онытып, пьеса арты пьеса яза. Аның язганнары үзләре үк музыка сорап тора. Каторжан кебек эшли. Сәйдәш үзе дә анардан ким түгел ләса. Язганнарын исәпләсәң, күктәге йолдызлар саныннан ким булмас. Әгәр кулларыннан килсә, бу ике дус, ике иҗади шәхес тәүлекне дә 25 сәгатькә озайтырлар иде. Сәйдәш белә: нотаның бер тамгасы тарихта уелып калырга мөмкин.

—Композитор таланты йолдыз нуры шикелледрәк,—ди Тинчурин.—Аны ни күреп, ни кулга тотып булмый. Аны фәкать ишетеп, тыңлап кына була.

—Ләкин язучының китабын кулга тотып укып була. Монысы үзе бер бәхет.

—Салпы якка салам кыстыруың өчен рәхмәт. Пьесаларым сәхнәдә барганда минем исемем, артистлар белән музыкантлар арасында эреп, каядыр арткы планга күчә. Даны сезгә. Мин моңа тамчы да үпкәләмим. Ә тамашачылар гөрләтеп, аягүрә басып кемгә кул чабалар? Режиссерга түгел, артистларга һәм дирижер Салих Сәйдәшевкә! Дөрес анла, монысына да үпкәм юк. Безнең кебекләргә дан соңрак киләдер, мөгаен...

—Алай димә, син беркайчан да заман арбасыннан төшеп кала торган кеше түгел. Илдә хөрмәтең зур. Европа өлгесендәге татар театрына нигез салучы бит син. Театрыбыз нур чәчә!

—Әйе, бөегебез Тукай: «Театр—яктылыкка, нурга илтә, унга илтә»,—дип юкка әйтмәгәндер. Әүлия кебек барысын алдан белеп торган ул.

—Театрыбыз тиздән Академия исемен алачак дип ишеттем. Кәрим абзый, дөресме бу куанычлы хәбәр?

—Дөрес, Сәйдәш туганым! Ул көн ерак түгел.—Аннары Тинчурин үзенең пәке йөзедәй үткен мантыйгы белән кистереп әйтеп куйды:

—Театр кемгә хезмәт итә? Халыкка, революциягә, эшче-крестьяннар сыйныфына. Мотлак дөрес хәл бу. Миссиябез җиңелдән түгел. Без теләсә нинди хәлләргә әзер булырга тиеш!

«Теләсә нинди хәлләргә...» Бу сүзләрен Тинчурин эчке бер сиземләү белән әйттеме икән ул чакта, әллә гади бер очраклыкмы?

Тора-бара әнә бит ничекләр килеп чыкты! Тимер чукмарның иң авыр башы Тинчурин җилкәсенә килеп төште. Ә хәзергә...

Ә хәзергә театр әһелләре, алга таба нәрсә буласын да белмичә, революция һәм ил сулышы белән яшиләр, дәртләнеп-канатланып иҗат итәләр. Йөзләреннән иман нуры бөркелә... Кыскасы, фидакарь җаннар. Бөтен гомерләре зур сәнгатькә, халыкка хезмәт итүгә багышланган. Алар тарихта тиңе булмаган гадел җәмгыять төзеләчәгенә ышаналар...

Хәер, Сәйдәш үзе тулаем шундыйлар җөмләсеннән булды. Иҗатка, театр эшчәнлегенә җаны-тәне белән бирелгән, музыка дөньясына баштанаяк чумган. Базар хәлләре ничек, кибетләрдә ни-нәрсә? Дөресен әйткәндә, мондый көнкүреш вакытларын, базар-кибет бәяләрен ул юнләп белмәде дә.

Аның бөтен уен-гамен, яшәү рәвешен театр һәм музыка шулкадәр биләп алган ки, тормыштан тәм табу дигәндә башкача яшәүне ул күз алдына да китерә алмас иде. Пианино яисә рояль клавирларында—нибары ак белән кара төс... Ләкин алардан никадәрле моң, аваз һәм гаммалар тәңгәллеге,

гармония һәм аккордлар актарылып чыга! Манзаралар жетеләнә, төсләр фантасмагориясе туа...

Театр Сәйдәшнең сихри музыкасыннан башка яши алмый инде хәзер. Биредә һәр яна куелган спектакльнең пәрдәсе ул язган, ул ижат иткән музыка белән ачыла. Пәрдә ачылганга кадәр...

Әйе, пәрдә ачылганга кадәр әле фойеда тамашачылар кырмыска урынына кайнаша, аларның бер ише буфет тирәсендә мәйханә килә. Оркестр чокыры да тик тормый, анда музыкантлар үзләренчә мәш килә. Кемдер «оркестрның короле» саналган скрипкасын көйли. Виолончельнең кеше тавышына охшаш куе, татлы, жырлап торган авазы ишетелеп куя. Тынлы, кыллы, бәрмә, бакыр һәм агач инструментлар оя-оя булып оркестр чокырында бер тирәгәрәк урнашканнар. Мандолина, контрабас, саксофон, труба, фагот, бубен, кларнет, курайның якын кардәше флейта—болар үзләре бер мөстәкыйль дәүләт! Бу дәүләт белән «идарә» итүче берәү генә—ул да булса дирижер.

Сәйдәш... гармун шыгырдатып утырган бер малайдан—инде рәсми игъланнарда урын алган исемле кешегә әверелде.

Татар дирижеры, пианист-композитор Салих Сәйдәшев. Егерменче елларда бу—Казан каласы өчен һич көтелмәгән хәл шикеллерәк тәэсир итә иде. Композитор музыка сараеның ишекләрен бик иркен ачып керә.

Вакыт ягы кысканлыктан, Сәйдәшкә партитура язып торуның кирәге дә калмый: чөнки табигать аңа искиткеч камил сәләт, абсолют ишетү, музыкаль хәтер биргән. Ул аеруча катлаулы һәм күләмле әсәрләрне башкарганда гына партитурадан файдаланырга тырыша иде.

Дирижер—оркестрның үзәге, жаны, кайтавазы. Жырчы-башкаручылар, инструментлар кайсы кай урында күтәрелеп китәргә һәм нинди тоннарда уйнарга тиеш? Акрын яисә көчле мотивлар, ярымтоннар белән ул идарә итә һәм төрледән-төрле инструментлар ансамблен тамашачыга житкерә. Уен эш түгел бу. Моның өчен илаһи талант, белем дә, осталык һәм тәжрибә дә, хәтта кул хәрәкәтләренең үтә камиллеге дә кирәк. Өстәвенә, дирижерга музыка өлкәсендәге барлык фәннәрне—гармония, полифония, сольфеджио, аранжировка, альтерация, хәтта музыка сәнгате тарихын да яхшы белергә кирәк. Залдагы тамашачы боларның берсен дә белми, әлбәттә. Ул—күнеле-йөрәге, жаны белән музыканы бары кабул итә, моңнар кочагында эри, елый, тетри яки шатлана.

Менә дирижер пультына Салих Сәйдәшев килеп баса. Менә ул озынча нәфис бармаклары белән күперенке чәчләрен артка сыпырып залда утыручыларга зур ихтирам белән баш ия. Горур башын салмак кына йөретеп, әле бельэтажга, әле партердагыларга карап елмая. Кулларын кушырып, ян-якка йөртеп, тамашачыга карата булган дуслык мәхәббәтен житкерә...

Рампа утлары. Зал тынып кала. Ак костюмлы Сәйдәшнең нәфис таякчык тоткан уң кулы өскә күтәрелү белән яшел бәрхет пәрдә тылсымлы-акрын хәрәкәт белән ачыла башлый. Һәрбер спектакль әнә шулай башлана. Оркестр чокырыннан кайнап-кайнап музыка авазлары күтәрелә.

Авазларны бер-берсенә ялгый-ялгый, музыка дулкыннарын әле контрабас, әле флейта, әле трубалар күтәреп ала. Урыны-урыны белән кече һәм олы барабаннар дөпелдәвеннән яшен яшьнәгән, әле туплар аткан тавышлар ишетелгәндәй була... Боларның барысыннан да, залны тутырып, музыка дигән могжиза туа! Театр стеналары тетри сыман. Рампа утларына ияреп, ике як диварлар буйлап музыка күләгәсе шуыша.

Тамашачылар болындай иркен михрабта утыралар шикелле. Музыка һәм спектакльдәге вакыйгалар аларның бөтен күнел халәтен үзе белән әллә кайларга йөздереп алып китә. Тамашачы сәхнә геройлары дөньясында

эреп бетә. Әйтерсең, ул спектакль карамый, ә бәлки драматик вакыйгалар ташкыны эчендә үзе яши башлый. Залда гаҗәеп тынлык, сулыш алырга да кыймый утыралар төсле...

Ә соныннан... зал бердәй урыныннан кубарыла. Алкышлар, озын-озаклап кул чабулар, кочагы белән чәчәк бәйләмнәре ява! Кайбер спектакльдән соң аягүрә баскан тамашачылар, пәрдәне яптырмыйча, ярты сәгатьләп диярлек кул чабулар белән сәхнәне, артистларны һәм музыкантларны сәламли. Ниһаять, оркестр, рәхмәтен изһар кылып, аккордлар суга—тамаша тәмам!

Тажи Гыйззәтнең «Наемщик» музыкаль драмасын куйгандагы хәлләрне искә төшерсәң, кызыклы да, моңсу-сагышлы да булып китә.

Драматург буларак, ул пьесаларының нигезе итеп, гадәттә, халык тарихындагы зур вакыйгаларны, гаделлек, якты киләчәк өчен көрәш темасын ала. Социаль, сәяси, тарихи катламнарны кешеләр арасындагы мәхәббәт аша да бик оста ачып бирә белә. Аның сөю-мәхәббәт турында язганнары үзе уйлаганнан да киңрәк полотнода килеп чыга булса кирәк. Әнә бит, гади генә сөю-ярату хәлләре аша крепостное право, Столыпинның аграр реформасы мәсьәләләрен бик ансат, җайлы колачлый алган ул. Аның спектакльләренә ясак, имана, зәкәт, недоимка, староста, урядник, адвокат, ришвәт кебек яңачарак яңгыраган сүзләр ташып керә.

«Наемщик»та дуэт, хор, марш, кереш өлеш—увертюра, бию көйләре, балет элементлары, масса җырлары кыю рәвештә татар сәхнәсенә атлап менде.

*Кызлар:*

Кичке салкын һава ярып
Чыңлый чалгы тавышы.

*Ирләр:*

Дошман явы ауган кебек
Ава печән покосы.

*Хор:*

Әй, ямьледер җәйнең айлары,
Матур була болыннары, кырлары...

Ә инде Батыржан белән Гөлйөзем ариясе—татарда моңарчы ишетелмәгән сүзләрне, моңнарны тамашачы күңеленә уеп сала!

Геройлар икесе дә—авыл яшьләре, ярлы крестьян баласы. Репетицияләр вакытында бии-бии, аларның чабаталары тәмам тетелеп бетте берзаман. Ярый әле менә шулчакны язмыш елмайды үзләренә. Озак та үтмәде, иҗади сәфәрдән кайткан Сәйдәш елмаеп килеп керде алар янына. Уенын-чынын бергә кушып, әйтә салды:

—Театрның чабата үргәнен көтеп торып булмас... Менә, бер пары Батыржанга, икенчесен сиңа дип авылдан алып кайттык!—дип, тугыздан үргән өр-яңа чабаталарны актриса Галия Кайбицкаяның алдына чыгарып салды. Шатлыктан рәхәтләнеп көлештеләр шул чакта.

...Золымга каршы баш күтәргән, башкаларны да фетнәгә өндәгән Батыржанны кулга алу өчен кылычлылар килгән. Мирзабикә Шәрифә шул чакта нәрсә ди бит әнә:

—Бүген үк, хәзер үк алып китегез ул башкисәрне!

Йөзкәй түрә кырт кистереп җавап бирә:

—Юк... Әгәр дә мин аны көпә-көндез тотып алып китә башласам, халыкның чуалу куркынычы бар. Анын белән бер фикердә булганнар күп... без аны кеше аяк эзе басылгач, төнлә, таң вакытында тотып алырбыз да туп-туры шәһәргә озатырбыз.

Патша охранкалары да сәяси тоткынны төнлә кулга алганнар. Йә Хода, Тинчурин, Бурнашларны да төнлә, кешеләр тирән йокыда чакта «таш капчык»ка илтеп тыкканнар лабаса... Җасусларның эш алымы, кылган гамәлләре тамчы да үзгәрмәгән, димәк...

Ә хәзергә—илдә тәртип, алгарыш, колхозлар төзү һәм индустрияне күтәрү текә адымнар белән алга бара... халык партиягә, хөкүмәткә, халыклар атасы Сталинга мөкиббән. Илдә «урра-патриотизм» чәчәк ата.

Кәрим Тинчуринның данлы вә парлак чагы. Колхоз тормышын сурәтләгән «Кандыр буе» пьесасыннан соң ул инде хәзер шул ук темага «Йомгак» исемле өр-яңа драмасын тәмамлады. Татар академия театрының баш режиссеры, Татарстан АССРның атказанган артисты, утыздан артык пьеса авторы. 1936 елның ямьле май аенда киң җәмәгатьчелек анын иҗат эшчәнлегенә 25 ел тулуны зурлап бәйрәм итте. Республика хөкүмәтеннән бүләк—язу машинкасы: яз, янәсе, иптәш Тинчурин, туктама! Казанның хәрби гарнизоны исә сәхнәдә анын кулларына ау мылтыгы тоттыра: янәсе, ял итүләрне дә онытып бетермә, ауга да чыккала...

Ауга чыкты микән ул, монысын Сәйдәш анык кына хәтерләми. Әмма бәйрәмнең икенче көнендә болай дип мөрәҗәгать итте Тинчурин:

—Тиздән сунар вакыты җитә. Урманда көртлекләр, төлке-куяннар җитәрлек, диләр. Бергәләп тәвәккәлләрбез. Килештекме?..

—Һм-м... Киек, кош-корт атарга кулым күтәрелмәс минем. Кирәкмәстер.

Шулай итеп, Сәйдәш бу тәкъдимнән баш тартты.

...Колак төбендә бик еш кына «Кандыр буе» моңнары яңгырый:

Без кабызган утлар сүнмәс алар,
Сүнмәс алар хәтәр җилләрдә.
Без кабызган утлар якты янар,
Якты янар хезмәт илендә.

Әйе, тарихның нинди хәтәр җилләре исмәсен, охранкалар кеше язмышлары белән ничек кенә уйнамасын, сәнгать сараена күпме генә кизәнмәсеннәр—очкыннан ялкын дөрләде, алар кабызган утлар барыбер сүнмәде!

## Мәхәббәтнең соңгы елы

Ничек, кайчан, кайда танышып китте соң ул Валя-Валентина белән?..

Боларны сөйли башласаң—үзе бер дастан, риваять, өр-яңа Таһир-Зөһрә кыйссасы.

Кәрим Тинчурин чакыруы буенча 1922 елны Оренбургтан Казанга кайтып төшү белән, Сәйдәш янәдән җизнәсе Шиһаб Әхмәров йортына килеп сыенды. Җизнәсе инде хәзер Вторая Гора[1] урамындагы ике катлы тагы да иркенрәк йортта яши. Гаилә ишле: җизнәсе белән Әминә апасының өч баласы тәгәрәп үсеп ята. Алар белән бергә тагын йорт башының сеңлесе Зәйнәб, Салихның әнисе Мәхүбҗамал, Шиһаб белән Зәйнәбнең әнисе Зөләйха җиңги. Аллага шөкер, өй зур, тынычлап йоклар өчен бүлмәләр һәркемгә җитәрлек.

[1] Вторая Гора—хәзерге Мөштәри урамы.

Жилкәсенә ташып төшкән куе кара чәчле, буй-сыны, бите-йөзе белән мөкәммәл чибәр туташ Зәйнәб—Казан дәүләт университетының медицина факультеты студенты. Шул заман татар кызлары өчен сирәк очрый торган хәл.

Алардан бер йорт аша гына диярлек Костромадан күчеп килгән Мухиннар гаиләсе яши. Дворяннар нәселеннән булган, шәһәрнең абруйлы гражданнарыннан саналган әтиләре үлеп киткәч, тол калган хатыны Анна Ивановна Мухина инде нишләсен икән? Гимназия тәмамлап, Казан университетына укырга кергән кызы Валентина янына яшәргә күчеп килә. Аларның да гаиләсе кечкенәдән түгел: ике улы Юрий һәм Анатолий, Валентина, күкрәк анасы Надежда Ивановна һәм газиз әниләре. Болар—дворян тәрбиясе алган затлы, зыялы, укымышлы нәсел. Өстәвенә, Валентина да, Анатолий да—музыкантлар...

Анатолий—үзе рәссам, үзе скульптор, үзе музыкант. Кыскасы, күпне булдыра торган алтын куллы егет. Әтисез калган, күчә-күчә байтак байлыкларын исраф иткән Мухиннар тормышы әлләни мактанырлык түгел. Кызлары Валентина, буш вакытында өйдән-өйгә йөреп, берничә балага өстәмә дәресләр бирә.

Әмма ләкин гаиләне төп туендыручы—абыйлары Анатолий. Ачык күңелле бу егет белән Салих бик тиз дуслашып китте. Алар, икәүләшеп, еш кына «акча эшләргә» дә чыгып керәләр. Нэпманнарның чәчәк аткан чагы. Менә шундыйларның ишеген шакып, күп һөнәр иясе Анатолий кайсының да булса пианиносын баштарак сәгать урынына сүтеп ташлый да аннары инде майлап-җайлап ремонтлый. Салихка исә эшнең ансатрагы, почетлысы эләгә: пианиноның аклы-каралы телләренә баскалап, уен коралын ул мастерларча карый, нәфис яңгырашлы итеп көйли. Инде берничә милли көйне дә уйнап җибәргәч, нэпман агайның авызы ерыла, акча янчыгы да киңрәк ачыла...

Бу ике гаилә үзара еш аралаша. Бөтен хикмәт шунда ки, Валя-Валентина—Зәйнәбнең ахирәте, сабакташы. Алар икесе дә университетның медицина факультетында укыйлар. Кечерәк кенә почмак бүлмәдә Зәйнәб белән бергәләп дәрес әзерлиләр, микроскоптан карап, Салих шаярткаңча, чикерткә тәпиендә ничә күзәнәк барлыгын өйрәнәләр. Ул гына да түгел, Валентина Әхмәровларның өченче сыйныфта укучы улы Үзбәккә математика һәм рус теле фәннәрен үзләштерүдә ярдәм күрсәтә. Менә шунлыктан ул бу өйдә һәрвакыт үз кеше буларак кабул ителә.

Салих, өйдә булган чакта, бу хәлләрнең күбесен читтәнрәк карап тора, билгеле. Ләкин егет кешенең йөрәге таш түгел. Жай чыкканда ул Валяга яшертен генә игътибар итәргә тырыша, каләмкашлы, тулган айдай түгәрәк йөзле бу кызның оялчан елмаюын, нурлы карашын күңеленең түренә салып куя. Ничек сокланмассың: күтәреп алсаң—уч төбенә сыярдай, бөтереп алсаң—кашыкка салып йотардай нәфис бер кыз лабаса!..

Сөйләшкәндә чиядәй иреннәренең ачылып-ябылып китүенә кадәр ифрат матур, килешле. Коңгырт чәчләре ут яктысында гәрәбәдәй ялтырып тора. Нинди дер чәчкәне хәтерләтә ул. Юк, кыр чәчәкләренә түгел, йомры түтәлдә үскән алсу розага күбрәк охшаган ул. Аның бәрхет тавышында кояшның сүнмәс яктысы, салават күперендәге барлык төсләр, елга-чишмәләрнең талгын челтерәве бар кебек. Ә инде фортепианода уйный башласамы?..

Аклы-каралы клавишларга кагылды исә аның кул-бармак хәрәкәтләре, җилдә тирбәлгән камышлар сыман, гаҗәеп бер табигыйлек белән йөзә-талпына! Кайларда үскән дә, нинди укытучылардан дәрес алган бу табигать баласы, дип гаҗәпләнә егет.

Әхмәровларның иркен залында яшьләр еш кына музыкаль кичәләр ясыйлар.

Фортепиано һәм скрипкадан агылган моңнар тәрәзә пәрдәләрен чайкалдыра, хәтта түшәмдәге бәллүр люстра алкаларын зеңләтә шикелле. Кичәнең бер өлешендә Салих белән Валентина парлап, бергәләп, дүрт кул белән поляк композиторы Шопенның полонезын яисә Жиденче вальсын уйнаганда залны тутырып гүя яшьлек, нәфислек, романтика үзе бии, сикерә, чайкала, тантана итә. Бу минутларда бу икәүнең тәне дә, җаны да бергә кушылып китә, бербөтен була шикелле. Яшьләр үзләре дә скрипкага вальс әйләнәләр. Менә шул чакта Валяның озынча кара юбкасы Салихның аяк арасына тиеп-уралып китә икән, егетнең тәненнән электр чаткылары чабып узгандай була.

Вакытында Деникинга каршы сугышкан гаскәрләргә шәфкать туташы булып киткән бу кыз сызыклы-нечкә кашлары белән композитор егеткә карата үзенең хисләрен яшертен генә сиздерә килде бугай. Яшь, тәҗрибәсез, риясыз Салих баштарак бу ым-ишарәләрне тулысынча аңлап та өлгермәде. Бары дуслык билгесе дип кабул итте. Ләкин тора-бара аның йөрәгенә чын-чынлап ут капты, һәм бу ут егетнең төн йокысын качырган иде.

Яңа пьесаларга көй язу, театрдагы эш мәшәкатьләренә чуму, атаклы теоретик Ксаверий Корбуттан гармония дәресләре алу Салихның хисләрен күпмедер тыеп-аралап торды торуын. Ләкин болар бар да—вакытлыча. Йөрәктәге теге ялкын дөрли, көчәя, хәтта кайчакны күлмәгенә менә-менә ут кабар төсле!

Иң мөһиме: Сәйдәштәге талант—Аллаһ бүләге икәнлеген аңлый Валентина. Тәкъдир дигәненең барысын да алдан ук күреп, алларына ак юл хәстәрләп куйган лабаса. Алар икесе гел янәшә. Сонармаска, учына килеп кунарга әзер торган асыл кошны кулдан ычкындырмаска кирәк...

Эчке аваз, йөрәк тавышы әнә шулай ди.

Бар дөньяны шаккаттырып, 1925 елның көзендә алар өйләнешеп тә куйдылар. Бөтен хикмәт шунда ки, бу хәлне әниләре, туган-тумача бөтенләй белмичә дә калды. Болай «яшертен» эш йөртүнең житди генә сәбәбе бар иде шул. Әхмәровлар йортында яшәүче, ислам дине тәрбиясе алган ике әби, ай-һай, башка диндә булган бу кызга өйләнергә рөхсәт бирерләр иде микән? Ике яшь йөрәкне шул куркыта иде ул чакта. Әмма икесенең ике милләттән булуы Салих белән Валентина өчен берничек тә киртә була алмастыр.

Икесенең дә фикере тач туры килеп тора иде: бәхәсләрдән, артык сүздән, кирәкмәс аңлашулардан качып, ике як гаиләне дә аптырашта һәм билгесезлектә калдырап, берничә көнгә «юкка чыкты» алар. Эскерткә төшкән энәдәй югалдылар, гаип булдылар.

Әйтерсең, чит бер планетага качып киткән иде алар.

Ничек булды соң әле бу?

Композитор Мансур Мозаффаров—Салих Сәйдәшевнең «Шәрыкъ клубы»нда танышкан балачак дусты. Әнә шул дуслыклары хәзергәчә дәвам итә. Күрештеләр. Сәйдәш, тел яшермичә, үзенең «яшертен» планын сөйләп-аңлатып күрсәткәннән соң, Мозаффаров башта рәхәтләнеп көлде. Җавабы исә бик кыска булды:

—Телисез икән, дачам сезнеке!

Күктән төшкән бәхет шушы буладыр инде ул. Берничә сәгатьтән соң Валентина белән Салих тәбәнәк рәшәткәле, чия, алмагачлар үсеп утырган бакчаның җыйнак агач йортына аяк бастылар. Әбиләр чуагына хас җылы-мөләем август киче аларның икесен дә үз кочагына алды... Салих үзенең Валясын таныды да, танымады да кебек: чөнки кызның сөт-томандай аксыл тәне әйтерсең лә фарфордан коеп ясалган иде... Валя Салихта үзенең булачак ирен һәм яхшы әти кешене күрә иде, шуңа да ул аның назларына карышып тормады. Шулай итеп, алар, кулга-кул тотышып, мәхәббәтнең тылсымлы бусагасыннан атлап керделәр бу кичтә...

—Синең күзләреңдә зәңгәр күл тирәнлеге бар, Салих,—диде Валя, текәлеп.

—Синең күзләреңдә көндез кояш иде, хәзер менә якты күләгә бар...—диде Салих, сер бирмәскә тырышып.

—Син пианинода уйнаганда минем кайчак әнә шул клавишлар буласым килә...

—Ә син уйнаганда минем канатлы кош буласым, болытларга, йолдызларга хәтле күтәреләсем килә, Валя...

(Менә бит нинди романтик чаклар булган! Әйтер сүзләр дә табылган.)

Бакчага чыгып, кулдан ясалган агач эскәмиягә утырдылар. Салих, йомшак булсын дип, кечерәк бер җәймә алырга да онытмаган иде. Август төне. Күктә аксыл шәүлә. Яшьләрнең мәхәббәтенә Ай шаһит иде бу кичтә. Бөтен тирә-юнь гаҗәеп моңга сергә, тылсымга, илаһиятка манчылган. Бакча ай белән тулган иде. Ай яктысында ботаклар шәүләсе шәйләнә. Ниндидер төнге бер кош очып узды. Аның канат җиле төнге һавада арфа кылларыдай талгын зеңләп алды... Ул да түгел, сынар бер алма «дөп» итеп җиргә өзелеп төште. Әйтерсең лә барабанга таякның юан башы белән сугып алдылар... Кайдадыр урман эчендә ялгыз бер эт өргәне колакка чалынды...

Мондый илаһи кичне, андагы төнге авазларны шәһәрдә ишетү, тоемлау мөмкинме соң!

—Беләсеңме, Салих..

—Дәшмә! Сүзсез генә...

Шулай диде дә Салих капланып, онытылып сөйгәнен үпте. Сулышын тәмам йотып бетерә язды бугай ул бу минутларда...

Алар икесе дә үзләрен биектә, биек-биек йолдызлар янында кебек хис иттеләр. Валяның күзләре хәтта караңгыда да мәхәббәт яктысы белән сугарылган иде. Гашыйкларның йөрәк утын исә берни белән дә сүндерерлек түгел... Валяның һәр әйткән сүзләреннән музыка һәм чәчәк исе аңкып тора диярлек!

Балдай татлы сәгатьләр-минутлар янына икенче көнне... шулай да Валяның күз яшьләре килеп өстәлде. Аны аңларга була: һаман саен качып ятып булмас бит инде биредә, барыбер өйгә, туганнар янына әйләнеп кайтырга кирәк. Менә шунарга борчыла, хыялларының челпәрәмә килүеннән шикләнә ул:

—Чынлап куркам, Салих... Әниең, туганнарың безнең өйләнешүгә риза булмаслар кебек...

—Юкка өзгәләнәсең, акыллым,—дип юата аны Салих.—Менә ике-өч көн сагынып торсыннар әле алар безне... Борчылма, бар да әйбәт булыр. Минем синнән аерыласым юк.

Әнә шундый юату сүзләре белән егет кызның яшьле күзләреннән, битләреннән үбә. Шуны аңлады: хатын-кыз таифәсенең күз яшьләре ирләрнекенә караганда йомшаграк, татлырак була, ахрысы...

«Кыйгак... кыйгак...»

—Әнә, күрәсеңме, киек казлар безне сәламли, еламаска куша,—диде Салих, җылы якка китеп баручы кошлар кәрванына кулы белән ишарәләп.

Аулак бакчада сәгатьләр, көннәр генә түгел, алар өчен тулы бер гасыр узып китте шикелле.

«Югалып торган» көннәренә нокта куеп, бәхетләре ташып чыккан ике яшь өйләренә кайтып керделәр... «Урланган кыз»ны кичерделәр. Саф күңелле, игелекле Валентина, киявенең һәр туганы белән аңлашу табып, гаиләдә үз кешегә—һәммәсе дә яраткан киленгә әверелде... Тиз арада фатирга кереп, мөстәкыйль тормыш белән яшәп тә киттеләр. Бәхетләре

булсын! Бәхет исә... ике яклы булып чыкты шул. Тормышлары чәчәкләнеп китте дигәндә генә...

Күршедәге бер карчыкның «икәү ятып өчәү торыгыз...» дип теләк теләгәне, шөкер, раска килде! 1926 елның 26 октябрендә көтеп алган уллары туды. Ике телдә дә бозылмый янгырасын дип, алдан ук сөйләшкәнчә, малайга Альфред дигән исем куштылар.

Сәйдәшнең үз гомерендә беренче тапкыр тирән фаҗига кичерүе! Бер атна узды микән, кинәттән өзлегеп, Валентинасы... якты дөньдан китеп тә барды. Өйгә кайтсаң да, эшкә барсаң да менә ничә айлар инде бүлмә эче моңсу, анда һава да, яктылык та юк шикелле Сәйдәш өчен...

Эх, Валя-Валентина! Нинди тәкъдирләр белән газиз улыңны, сөекле ireңне мәңгелеккә ташлап киттең син?

Мәхәббәтенең соңгы елындагы истәлек-хатирәләргә бирелдеме, Сәйдәшнең һәрвакыт күңел җәрәхәте ачыла, йөрәк мае сызлый...

Юк, мәхәббәтнең соңгы елы була алмый, була алмый! Валя аның бәгърен гомер буе сызлатып торачак.

Валентина—Сәйдәшнең кем, нинди талант икәнлеген тирәнтен аңлый иде. Ә менә киләчәктә, алай-болай кабат өйләнә калса, аның җанын һәм ирекле очышын аңлаучы табылырмы соң... табылырмы?

## Ялта. Галимҗан Ибраһимов белән очрашу

Ак пароход, саубуллашу билгесе итеп озын-озак кына кычкыртты да, Казан причалыннан җай гына кузгалып китте. Якыннарның, туганнарның, таныш-белешләрнең кул болгап калулары, «Хәерле юл!» дип кычкырулары әле дә булса күз алдында. Гудок авазларын исә баш өстендәге ак болытлар үзләренең кочагына алды.

Бер айдан артыкка сузылачак сәфәрнең маршруты акка-кара белән язып, тәгаенләп куелган: Казан—Әстерхан—Махачкала.—Баку—Ереван—Тбилиси—Симферополь—Ялта—Харьков—Мәскәү—Казан.

Сәяхәттә катнашучылар—егермедән артык кеше. Тугандаш республикаларга барасы әлеге иҗат төркеменең җитәкчесе Галимҗан Нигъмәти.

Максим Горькийның турыдан-туры ярдәме белән бу олуг һәм мәртәбәле сәфәрне Пролетар Татар язучылар ассоциациясе (ТАПП) рәисе Кави Нәҗми оештырган, диделәр. Шунлыктан сафтагыларның иң зур күпчелеге—каләмен кулында нык тоткан исемле язучылар: Шәриф Камалдан алып Һади Такташка кадәр...

Һәркемнең кәефе күтәренке, күңел капкалары шәрран ачык иде. Палуба һәм каюталарда уен-көлке, бәхәс, шаярту, көлешүләр тынып тормады. 1929 елның 10 августында башланган сәфәр үзенең тулы куәтенә кереп бара иде. Көн искиткеч матур—кояшлы, ягымлы, Ослан таулары ягыннан искән йомшак җил битләрне иркәли, чәчләргә елыша. Дулкыннар өстендә эреле-вакылы кыйпылчыклар булып, кояш чагылышы тирбәлә. Пароход эзеннән кайнап-кайнап чәчрәгән көмеш тамчылар җырында чулпы чыңнары бар шикелле...

Боларны Сәйдәш күңеленә «төреп» салырга да өлгермәде, терекөмештәй җитез Гадел Кутуй аны үзе тирәсендәгеләр янына дәшеп алды:

—Әйдәле, Сәйдәш, синең хәзинәдән дә бер мәзәк хәл булсын әле бүген! Кызганма...

—Сезгә мәзәк житкереп буламы соң... Ә шулай да тырышып карыйк.

Сүзнең тәмен, ләззәтен белеп сөйләүче Сәйдәш ялындырмый. Үзенең уен-көлке капчыгыннан яңарагын тартып чыгарырга тырыша.

—Шулай бервакыт театрыбызга яңа директор билгеләделәр... Оркестр

белән ясаган репетицияне беренче тапкыр үз колаклары белән тынлап, үз күзләре белән карап утырганнан соң, үзенә чакыра бу мине. «Теге барабанчы егет барабанны һәрвакыт шулай аз кагамы?—дип сорый. «Булгалый»,—дим мин моңа. «Икенче тапкыр мине чакырырсың. Төшәрмен дә барабанны үзем кагармын. Ә аны эшеннән кыскартыгыз»,—ди.

Төркемдәгеләр шаулатып көлештеләр!

—Дусларым, беразга ялгызымны калдырыгыз, зинһар. Кызыл Байрак авылына таба якынаябыз әнә...

Сәйдәш янадан палубаның аулаграк бер почмагына барып баса. Таныш ярларны, яр өсләренә кадәр ташып төшкән яшеллекне ләззәт белән күздән кичерә. Вакытның алагаем зур балтасы белән кырт кисеп төшергәндәй кызыл, урыны-урыны белән аксыл ярлар... Анда гаҗәеп тигез һәм төгәл сызыклар нота дәфтәрен хәтерләтә түгелме соң? Актара һәм укый белсәң, вакыт җилләре анданиләр генә язып калдырмагандыр!

Биредән, аяк астында биниһая җәйрәп яткан су өсте кинлекләреннән Кызыл Байрак күренми, билгеле. Аны киртләч-киртләч таулар, уйдык-уйдык яшел әрәмәләр каплап тора. Әмма хәтерең һәм күңел күзең үткер булса, әлеге авылның урамнарына, аның тирә-юнендә колач җәеп үсеп утырган биек наратлар биләмәсенә кайтып төшү берни түгел.

Кызыл Байрак... 1920 еллар башында өр-яңа нигезгә оешкан бу авылга исемне татарның танылган әдибе Галимҗан Ибраһимов кушкан, диләр. Ихтимал, шулайдыр. Татарның байтак кына зыялылары кебек, ул да кайчандыр ханнар яшәгән бу гүзәл җиргә еш килә торган булган, бирегә ял итәргә дә, уйланырга, язарга да яраткан бит.

Мең рәхмәт: Идел ярына урнашкан бу авыл Сәйдәшне дә тормышының һәм шатлыклы, һәм кыен чакларында үзенең җылы кочагына сыендырды. Җизнәсе Шиһаб Әхмәровның дача йорты—аның икенче туган йорты шикеллерәк иде. Табигать кочагына, һич югы яшел чирәмлеккә чыгып, дус-ишләре һәм авылның кунакчыл кешеләре белән азмы самавыр кайнатты алар! Идел дамбасына балык тотарга төшүләрне инде әйткән дә юк...

Хатирәләр әнә шулай акты. Идел өсләтеп тә, биектәге болытларга хәтле орынып та...

Кичен пароходның салонына җыйналдылар. Язучылар, шагыйрьләр язганнарын укый. Ә Сәйдәшкә нәрсә? Ана фортепиано булсын. Кичәнең иң гүзәл өлеше Сәйдәш моңнарыннан башлана. Тәрәз пәрдәләре аккордлардан соң сискәнеп киткәндәй була, салон эче кинәттән сихерләнеп кала... Көе дә, сүзләре дә үзәкләренне өзәрлек шул:

Хуш, авылым, сау бул,<br>
Сәламнәр көт<br>
Таң җилләре искәндә.<br>
Мин җырлармын сине сагынып,<br>
Өзелеп искә төшкәндә...

Салонның ачык тәрәзәләрен сырып алган пассажирлар да җырның сүзләренә кушыла. Әдәбият-сәнгать әһелләре белән аралашу, әңгәмә һәм бәхәсләр төн уртасына кадәр диярлек дәвам итә.

***

...Әкияттәгечә әйтсәк, жиде дингез, урман-таулар кичеп, бик күп җирләрне күрделәр. Кая гына килеп чыксалар да—җылы, матур очрашулар, янадан-яңа дуслар, концерт арты концертлар.

Ә шулай да, җанга якын үзебезнең татар кешесе булгангамы, Ялтада әдип

Галимҗан Ибраһимов белән очрашудан да истәлеклесе юктыр, мөгаен.

Үпкә авыруы көчәеп китү сәбәпле, 1927 елдан бирле менә шушында, коры-татлы һавасы шифалы булган данлы Кырым якларында яшәп иҗат итәргә дучар ителгән иде ул.

Менә үзләре көләч, үзләре житди кыяфәтле Татарстан кунаклары таш баскычлар буйлап өскә күтәрелә. Югарыда аларны Ибраһимов яшәгән йорт көтә. Тигез плитәләр җәелгән тротуар читендә яшел күлмәк кигән зифа буйлы кипарислар оеп утыра. Гомумән, тирә-юнь яшеллек, розалар, үрмә гөлләр белән уратылган. Сулыш алуларга хәтле рәхәт, иркен биредә.

Алдан белеп торгандыр, күрәсең, бу хәтле кунакларның, каләмдәшләренең килеп төшүен Галимҗан ага бик табигый, җылы, ихласый кабул итте. Иркен веранда, камыштан үреп ясалган җиңел урындыклар, шуларның берсенә әдипнең җәйге ак пинҗәге эленгән. Авыру димәссең, бу кешедән эчке бер энергия, иҗдиһат, тәвәккәллек, күзләреннән нур һәм иман бөркелеп тора. Куе кара чәчләре арыслан ялыдай артка кайтарылып төшкән. Бераз ябыга төшкәнгәме, яңак сөякләре калкыбрак тора.

Кунакларның һәркайсы белән аерым күрешеп чыкты.

Зур-биек тәрәзәләрнең бер ягыннан офыккача җәелгән күгелҗем диңгез, икенче ягыннан болыт чалмаларына уралган Ай-Петри тавы күренә. Шушы мәлдә бөтенесенең диярлек игътибары мәһабәт тауның күккә ашкан текә таш диварларына текәлде. Боларны Сәйдәш катып-оеп калган музыка рәвешендәрәк кабул итте. Күз күреп ияләшмәгән бу күренештә бер карасаң никадәрле хаос, ташлар чытырманлыгы; икенче карасаң—никадәр мантыйк, камиллек, җир белән күкләр тоташкан симфоник манзара, табигать гармониясе!

> Ай-Петри!
> Баш очында ай тетри...

Такташ, калын чәчләрен артка чөеп, әнә шундый экспромт әйтеп ташлады. Кыска, йомры бу сүзләр һәммәсенең күңеленә хуш килде.

—Әйдәгез, табынга рәхим итегез!—дип, әдип аларны ак эскәтер җәелгән түгәрәк өстәл янына дәште.

Хатыны Хәдичә пешергән аш-ризыклар белән тукланып, кат-кат чәйләр эчеп, озын-озаклап сөйләштеләр. Галимҗан Ибраһимов Казан хәлләрен, мәдәният тормышын җентекләп сорашты, җавапларны игътибар белән күңеленә салды.

Язу-сызу дәртенә күмелгән, сөйләшү-аралашуга сусаган, киң карашлы өлкән әдип кунаклар каршында үзе дә байтак кына уй-фикерләрен чәчте:

—Казан каласының кайнап ятканына, мәдәниятебезнең ныклы адымнар белән үсәчәгенә мин ышанам,—диде ул, бер мәлдә Сәйдәш ягына да караш ташлап.—Әмма вәзгыятебездә адашулар, саташулар һаман да бар әле. Урыслашуга омтылучы акыллыбашлар күбәйде. Аларны тыңласаң, янәсе, уртак, интернациональ мәдәният тудырырга кирәк. Татар мәдәнияты башкалар тарафыннан йотылмасмы? Менә кайда мәсьәлә!.. Бу—бер татар өчен генә түгел, грузин, чуваш, украин, казакъ һәм башка халыклар өчен дә уртак сораулар... Татар халкы, үзенекен ташлап, башка берәр көчле мәдәниятkә кушылып китмәскә тиеш. Мотлак дөрес бу. Иптәш Сталин әйтте: без яңа мәдәният төзибез, аның эчтәлеге пролетариатча, әмма формасы милли булырга тиеш, диде. Иң дөрес формула шушы... Татар совет чиновниклары халыктан, аның теленнән, гореф-гадәтләреннән читләшергә тиеш түгел. Моның киресен күзәткәнебез хәлдә бу—мәдәниятебез үсеше өчен куркынычлы, зарарлы бер нәрсәдер. Партия бит әнә идарә эшенә үз халкыннан, аның тормыш-көнкүрешеннән ераклашмаган хезмәткәрләр куюны хуплый. Мин партиягә ышанам!..

Бу соңгы өч сүзен ул аеруча басым ясап, күтәренкелек белән әйтте. Боларның барысына да йомгаклау рәвешендәрәк әйткәннәре катгый һәм ышанычлы иде:

—Патшачылык хөкүмәтенең реакцион алымнары артта калды, дусларым... Революция шаярырга теләми. Ул инде артка чигенмәячәк!..

Аннары ир затлары, рәхмәтләрен әйтеп, бердәм кубып, тәмәке көйрәтергә дип верандага күчтеләр.

—Салихҗан, ә син беразга калып тор булмаса,—диде Галимҗан. Тартмаган тәмәкең түгел... Аерым да сөйләшик бер...

Әдипнең көтелмәгән бу сүзләреннән соң Сәйдәш «Казбек» тартмасына дип үрелгән кулларын кесәсеннән кире тартып чыгарды. Һич көтмәгән иде.

—Безнең Кызыл Байрак ничек анда?

—Урынында,—дип көлемсерәде Сәйдәш, күз карашын киштә-киштә тезелгән китаплардан аерып.—Сез кушкан исем белән үз көенчә яшәп ятмак аның хәле. Киләсе җәйгә кайтыгыз, Галимҗан ага!

—Белмәссең... Саулык һәм вакыт ягы кулдан тота ләкин. Үзебезнең «татар Швецариясе»ннән соң бирегә дә ияләнеп, үзләшеп киттем менә.

Шулай сөйләшә-сөйләшә өстәл янына кара-каршы утырдылар.

—Шиһаб җизнәннең хәл-әхвәле ничегрәк? Миннән сәламнәр күндерергә онытма...

Сәйдәшнең җавабыннан соң кинәт кенә калкып, чем-кара мыеклары астыннан елмаю билгеләре йөгертеп, кызык бер хәлне сөйләргә җыенганы сизелде...

—Беләсезме, теге чакта... теге чакта дигәнем, ак чехлар Казанга бәреп кергәч, Шиһаб Әхмәров мине беркадәр үз өендә качырып яткырды. Аннарымы... Аннары,—дип тагын да киңрәк елмайды ул,—хатын-кыз күлмәгенә төрендереп, кавалер сыйфатында култыклап, мине шәһәр үзәгеннән Арча кырына хәтле озата барды... Хәзер генә көлке тоела, ә ул чакта почмак саен диярлек мылтыклылар иде, энем... Менә шулай котылдым мин чехлардан.

Чехлар димәктән, 1919 елның җәендә мин дүрт ай чамасы Колчак тылында йөрдем. Кызыллар штабы кушкан буенча. Олаучы кыяфәтендә күрсәң иде мине!.. Башымда ак киез эшләпә, аякта чабата-оек, киҗеле ыштан, сизрәгән иске казаки, кулда чыбыркы... Фронт буендагы крестьяннарны агитлыйм, дошман гаскәрләре арасына да үтеп керәм. Менә шунда күрәм: солдатларның бик күбесе Колчак станына ак-караны аермастан саташып килеп кергәннәр. Туган-туганына мылтык күтәргәннәр дә юк түгел... Минем «Кызыл чәчәкләр» хикәясен хәтерлик. Анда да бит бергә-бергә уйнап, су коенып үскән Шаһбазлар, Фазыллар гражданнар сугышы вакытында берберсенең күкрәгенә мылтык териләр... Кыскасы гына, ул еллардагы аклар-кызыллар сугышы икегә бүленеп кардәшләренне, үз туганнарыңны корбан итү белән бер булды дип саныйм мин хәзер. Кирәксезгә кан кою...

—Революция дип җан аттык бит, Галимҗан абый...

—Әйе, нәкъ шулай!

Аннары сүзләре театр тормышына, иҗат эшләренә килеп ялганды.

—Татар театры батыр адымнар белән алга атлый дисең алайса. Мәрхәбә! Патшачылык заманында өй спектакльләреннән уза алмады татар... Үзем шаһит булдым: татар артистлары беренче адымнарын каты көрәшләр эчендә атлады. Кара көчләрне җиңү фәкать Октябрь инкыйлабыннан соң гына булды. Егерме еллык көрәшендә татар театры якты бер мәдәни коралга әверелде. Ул буржуйларга түгел, үзебезнең хезмәт халкына хезмәт итә, фаразан...

Галимҗан Ибраһимовның музыка өлкәсендә дә хәбәрдар шәхес булуы һәр фикереннән ташып тора:

—Язучының әйтер сүзе була. Ә композитор иҗаты аның әйтер сүзе түгелмени? Ул безне матурлыкка, батырлыкка чакыра, дөрес яшәргә өйрәтә! Кешеләрнең яралы күңелен терелтү, канны сафлау, яшәүгә дәртләндерү—музыканың да максуды әнә шунда. Минем уем һәм каләмем, ә синең музаң төрле киртә һәм тыюларны җимереп алга барырга тиеш! Менә синең «Совет Армиясе» маршы ни өчен ифрат популяр? Хикмәт аның иркен, колачлы, дәртле, якты, җиңүчән-батыр авазларга бай булуында.—Әдип үзенең әйткән фикерләрен кайчакны кул хәрәкәтләре белән дә нигезләп, тулыландырып бара иде.—Сәнгать эшләренә административ чиновникларның тыкшынуы кирәкми. Музыка өлкәсендә бигрәк тә. Эткә сөяк ыргыткандай калжа ташлап, муенчаклап йөртү лязем эш түгел... Ә бездә хөҗрә-кабинетларында утырган, күпне «белгән» акыллыбашлар һәм дамалар җитәрлек... Вакыттан, булдыксызлардан, көнчелләрдән үч алып эшләр чагыбыз!..

Аннары ул сәгатенә карап алгандай итте, кинәт гамьле карашын Сәйдәшкә күчерде.

—Ходай сиңа чибәрлекне дә, талантны да кызганмаган. Онытма, берәүләрдәге тышкы һәм эчке матурлык икенче берәүләрнең мүкле җанында көнчелек корты уята... Менә шушы хәтәрлекләрдән сак бул, туганкай!

—Юк ла, Галимҗан ага... Тирә-юньдә яхшы кешеләрдән күп хәзинә юк.

—Ярый, иптәшләрең күтә әнә. Саубуллашырбыз... Тукта! Партиягә керергә уйламыйсыңмы? Кирәксә, рекомендацияләрнең берсен үзем бирермен...

—Юк ла, Галимҗан абый. Музыкант кешегә партия түгел, барыннан да элек партитура кыйммәт...

—Хәйләкәр!—дип, дусларча бармак янады Галмҗан абыйсы, елмаюын шуның белән капларга теләп.—Музыкага тәрҗемә кирәкмәс, диләр. Ул партиягә, төрле фиркаларга да мохтаҗ түгелдер, мотлак...

Әдипнең үзе сораулар куеп, үзе үк аңа җавап кайтарып сөйләүләре кызыклы да, мавыктыргыч та, гыйбрәтле дә иде Салих өчен.

Галимҗан Ибраһимов дәресләре анарга яңа канатлар куйды.

## Шәһәрнең тын бакчасында...

1954нче елның апреле сизелми генә узып та китте.

...Йокысыннан уянгач, Сәйдәш иң беренче эш итеп тәрәзә пәрдәләрен ике якка ачып җибәрде. Кояш нурлары тулып, бүлмә эче яктырды. Иртәнге тынлык. Менә шуны оеп калган тынлыкны кузгатып, сәгать телләре иртәнге сигезне сукты.

Юынырга, кырынырга кирәк. Көн дә шулай: уянасың, бит-кулларны юасың, кырынасың, ашыйсың-эчәсең, җәяү йөрисең, урам-бакчалар гизәсең... Нишлисең бит, үзең белә-белгәннән бирле ике дөнья, ике үлчәмдә яши Сәйдәш. Берсе—фани чынбарлык, икенчесе—музыка, авазлар патшалыгы... Музыка дөньясына атлап керер өчен исә кулларың һәм күңелең чиста булу фарыз. Такташның мәгълүм сүзләренә таянып әйтсәк, Сәйдәштә дә ике «мин» яши...

Пәкеләрне барлап, шуларны актара-актара җентекләп, озаклап тәм табып кырыну ошый аңа. Тагын да кызыгы, рәхәте—аннары инде башны янтайта төшеп, көзгедән үз-үзенә карап, төс-кыяфәтеңне бәялисең, тышкы мөкәммәллегенә күңелдә эчке бер ышаныч ныгытасың.

Ул—татарның газиз бер баласы, исемле композиторы. Аңа кырынмаган, таушалган, ямьсез сурәттә, пөхтә булмаган кием белән йөрүләр килешмәс иде. Сәйдәш аңлы рәвештә һәрвакыт матурлыкка, пөхтәлеккә омтыла. Бигрәк тә җәйләрен ак костюм-чалбардан киенергә тырыша. Ул әнә шулай

актан киенгән булыр. Ихлас күреп урамда кемнәрдер килеп кочаклый яисә жилкәсеннән кага икән, кәчтүменең инбашында тап калган чаклар бер генә булмады түгел...

Әле дә ярый булышып, анын өс-башын карап-кайгыртып торучы бар. Бу кешелекле, ярдәмчел хатын—Ксения Ивановна. Опера һәм балет театрында керләр юуучы, өстәвенә, татар дәүләт драма театрында җыештыручы булып та эшли. Ире Иван дәдәй—шушы ук театрда декорация һәм мебельләр ясаучы. Ксения Сәйдәшнең ак күлмәген, якаларын, бигрәк тә алмаш-тилмәшкә кия торган ак «күбәләк» бантикларын крахмаллап юа, үтүкләп бирә. Мондый игелекле хезмәте өчен аңа гонорарлардан өлеш чыга, билгеле.

Казан каласында Сәйдәшнең яратып ял итә торган урыннары икәү генә диярлек: «Эрмитаж» һәм халык телендәге Лядов бакчасы. Ленин бакчасын да үз итә итүен, ләкин анда кешеләр, бигрәк тә студент халкы гел кайнап тора. Үсмер чакта яратып йөргән Бакыр бабай бакчасы исә күптәннән юк инде. Революциядән соң большевиклар аксөяк дворян Державин һәйкәлен төбеннән үк кисеп аудардылар, гөлләр-агачлар үсеп утырган бакчасын җир белән тигезләделәр.

Көн матурлыгы, кояш җылысының муллыгы бүген ирексездән урамга чакырып тора. Ике көн элек кенә шәһәрне 1 май бәйрәме шаулаткан иде. Әле йорт диварларындагы кызыл комачлар һәм транспаратлар да җыеп алынмагандыр.

Күңел урамга ашкына.

Сәйдәш, челтәр капканы ачып берничә адым китәргә дә өлгермәде, каршысына яшь кенә чибәр кыз килгәнен күрде. Һичшиксез, студент кыз. Кулларында тамчы-тамчы тамарга торган ак ландышлар букеты. Имтихан тапшырырга барышыдыр аның. Алай дисәң, нигә шулай балкып, нур чәчеп елмая ул? Чү, бу кыз бала нәкъ аның каршына төбәп килә түгелме соң...

—Салих абый, бу чәчәкләр сезгә...

Кыз, йомшак-нәфис тавышын чишмәдәй челтерәтеп, оялып кына ландышларны аңа таба сузды.

—Мин сезне ике көн элек кенә күргән идем...

—Ничек, кайда?..

—Трамвайда. Институтка барышым иде.

—Берни аңламыйм. Сөйләп бирче, кызым...

—Көтмәгәндә сез сикереп тордыгыз да: «кәгазь, кәгазь!..»—дип кычкырдыгыз. Кемдер дәфтәр бите сузды. Менә шунда трамвайдагылар сезне урап алды. Мин дә шулар янына тартылдым. Сез анда кәгазь битенә нота билгеләре төшерә идегез... «Бу кем?» дип сорады берәү. «Шуны да белмәскә! Сәйдәш ич»,—дип җавап кайтардылар аңа... Бу беренче ландышлар минем сезгә, хезмәтегезгә хөрмәтем билгесе!

Кыз бию хәрәкәтләренә охшаш гүзәл адымнар белән китеп тә барды. Аны күздән югалганчы карап калганнан соң Сәйдәш, шиңмәсеннәр дип, ландышларны кертеп тәрәзә төбендәге сулы стаканга утыртты. Кысан гына бүлмәсенә яз сулышы, урман исе таралды... Менә бит, кайбер тити башлар аның иҗатына «мәгарә җыры» дип мөһер сукканда, таныш түгел шушы кызның бер рәхмәте ун бәягә торырлык булды! Өйдә музыка язу җайлы җайлысын. Ләкин элек-электән... шау-шу, кешеләр арасында язганнары кайчакны яхшырак та, җиңелрәк тә килеп чыга иде шул.

Сәйдәш 54нче яшенең уртасына җитеп бара. Нәрсә, картлыкмы бу, әллә яшьлектәге кебек яшьнәр чакмы? Юк, икесе дә түгел. Асылда узган гомергә, үткән көннәргә йомгак ясар чак. Уйланыр чак. Уйланыр өчен бирелгән форсат, җай үзенең сәгатен көтеп тора лабаса. Җитмәсә, эшсез йөргән еллары...

Башыннан байтак уйлар, хатирәләр кичте.

Бер сәгать чамасы урамнарны таптап йөргәннән соң, ике кулын артка кушырган хәлдә, Лядов бакчасына кереп утырды. Нигә бакча шулкадәр үзенә тарта соң аны? Чөнки биредә, табигатьнең аулак почмагында тыныч, жанга рәхәт. Чөнки биредә үскән мәңгелек үләннәрнең, колачлы нарат, каен, юкә агачларының сиңа баглы бернинди бәйләнеше, мөнәсәбәте юк. Алар иреклe, бәйсез. Алар янында син дә үзеңне ирекле һәм бәйсез тоясың. Кешеләргә хас тәкәбберлек, хыянәт, бәйләнчеклек сыйфатлары аларга бөтенләй ят... Уйлап карасаң, табигать белән музыка арасында гаҗәеп тәңгәллек бар. Икесе дә бәйсез. Икесен дә кыерсытып, гарипләтеп буладыр, ләкин үтереп була микән...

Кешелек җәмгыяте кайный, ашыга, кабалана, меңгә төрләнә, кайчак андагы чын дөреслекнең ни икәнен дә белеп бетереп булмый. Тулы, чын дөреслек фәкать музыка аша гына чагыла. Дөньяда һәрбер нәрсә камиллеккә, музыка булуга омтыла. Кошлар да, үләннәр дә, агачлар да. Чыршыны гына кара син: очарга җыенган канатлы кош сыман, өскә, югарыга таба чөелгән!

Җәмгыять—икейөзле, аңарда монафыйк сыйфатлар да житәрлек. Тукайның «Туган тел»еннән соңгы куплетын өзеп ташладылар... Тыйды моны дәһри-атеистлар, совет хакимияте түренә үрмәләгән түрәләр...

> И Туган тел, синдә булган иң элек кылган догам:
> Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм—әнкәмне, Ходам!

Йә, шушы мөкатдәс сүзләр, әткән-әнкәңне зурлаган бу юлларның кемгә, ни зыяны булды икән? Тулы бер буынның дин сабакларыннан мәхрүм ителүе дә һич акылга сыярлык гамәл түгел. Кешеләрдән әдәп-әхлак качты.

Сәйдәш үзе әдәпне заманында мәдрәсәдән, әнисе Мәхүбҗамалдан, Әхмәровлар гаиләсеннән алды. Гайбәт сөйләмәс, гайбәт сөйләгәннәрнең үзләрен сөймәс. Кешене түгел, чебенне рәнҗетергә дә кулы күтәрелми аның. Саф күңеленә кер кунмаган. Көнләшү, мактану, масаю кебек чирләрдән ерак тора. «Менә мин шуны эшләдем»,—диючеләргә исе китә аның. Әгәр берәр мактанчыкны күрсә, «Бу адәм көзгедән дә үз-үзе белән «әфәндем» дип кенә сөйләшәдер инде» дигән төртмәле укларын җибәрә иде.

Юк, ул беркайчан ырык-шырыклар, ялкаулар рәтендә йөрмәде. Үз дәрәҗәсен белде. Ул—теләсә кем сызгырганга йөгереп килә торганнардан түгел. Сәйдәш белән утырдаш, әңгәмәдәш булуны һәркем үзе өчен хөрмәт һәм горурлык саный санавын. Әмма ул очраган берәүгә кул бирергә ашыгучылардан да түгел. Кеше ихлас булсын, сатлыкҗан булмасын—эш менә нәрсәдә!

Сәйдәшнең бар сүгенгәне, ачуланганы—«Корт чаккыры!» яисә «Эх син, чебен дагалаган нәрсә!» Шулардан ерак китми. Аңа бит, вакыты белән, сәхнәдә эпизодик рольләрдә дә катнашырга туры килгәне бар. Уфада гастрольләрдә йөргән чакта бервакыт, «Җилкәнсезләр»дә татар сәүдәгәре булып уйнарга туры килгәч, үзеннән әнә шундыйрак сүзләрне кыстырып җибәргән чаклары булды, булды... Бу сүзләре белән артист дусларын да, тамашачыларны да мәмнүн итте.

Бакчада тирән тынлык хөкем сөрә иде. Җирдәге җиләс күләгәләр япмасын яфраклар шыбырдавы, кошларның сызгыргалап куюы гына кыймылдатып куя шикелле. Кемдер тактадан ясап элгән сыерчык оясыннан әнкәләре уктай атылып чыккач, андагы сарытомшыкларның чыелдаганы колакка чалынды.

Җил тыну белән һава тукталып калды кебек. Йөрәкнең ничек итеп

типкәненә хәтле ишетелә. Тән белән жан, бергә кушылып, истирахәт кичерә...

Ялгызы калганда анын күнеленә әллә ничаклы уй-фикерләр өерелеп килә!.. Ә инде танышлар, дус-ишләр арасына яисә табынга килеп эләктеме, Сәйдәш— әңгәмәнең уртасында; бай хыялы, фантазиясе уйный башлый. Әйтүләренчә, ул сүзгә бик тапкыр, ашыкмый гына тәмләп сөйләргә оста, мәзәк хәлләргә үзеннән кушып та жибәрергә маһир кеше икән, янәсе. Хак анысы, Сәйдәш тапталган, кешеләрдән калган мәзәкләр белән мавыкмый, күргән-белгән-ишеткәннәрдән ничек тә үзенекен китереп чыгарырга ярата.

Хәтерендә: бервакыт анын театрга карап торган тәрәзәле бүлмәсенә ике яшь егет килеп керде. Театрда инде үзен күрсәтеп өлгергән артист Вәкил Закиров һәм Сәйдәшнең балалар өчен язылган жырларын русчага тәржемә итеп радиода янгыраткан Госман Әхмәтжанов.

Керүләренен сәбәбе болай икән. Вәкилгә радиода эшләнә торган бер тамаша өчен музыка кирәк булган. «Әйдә, Салих абыйга кереп чыгабыз»,— дигән ул дустына. «Унайсызланам...»—дигән иптәше. «Юк ла, бик ачык, алчак кеше бит ул, берәр шәраб алабыз да керәбез»—дип үзенекен тукый Вәкил.

—У-у, яшьләр мине онытмыйлар икән әле!—дип каршылады аларны Сәйдәш. Урын тәкъдим итте, эшләрен сораша башлады.

Йомышларын тынлагач, әйтте:

—Радиода минем сезгә яраклы бер балалар жырынын язмасы бар. Шуны файдаланыгыз,—диде һәм шәмдәлле пианиносында уйнап та күрсәтте. «Минем дәү әни» дигән бу жыр, чыннан да, бик кулай булып чыкты.

Шатлыгыннан Вәкил:

—Каяле, Салих абый, без монда бер «төрек малае» белән кергән идек,— дия-дия шәраб савытын тартып чыгарды.

—Салыгыз, егетләр, тик мина менә шунысын гына,—дип, бүлмә хужасы бәләкәй мензурка чамасындагы чәркәсен чыгарды. Һәм ахыргача шундагын йоткалап кына утырды. Күнелле булсын дип, егетләргә бер мәзәк тә сөйләп күрсәтте:

—Бер кыз белән таныштым шулай. Бик чибәр, бик унай сөйләшә, күнелгә ятышлы кыз инде. Кабат күрешергә сүз куештык. «Кайчан күрешәбез?»—дип сорагач, кыз ерактан: «Биш... балта... арасында!..» дип кычкырды. Икенче көнне, фырт киенеп дигәндәй, киттем Бишбалта белән Казан арасындагы дамбага. Озак кына йөргәч, булмады бу дип, өйгә кайтып киттем. Икенче көнне үк очрады бу.

—Ник килмәден?—дим, үпкәләгән булып.—Мин сине иртәдән кичкә кадәр көттем.

—Кайда?—ди кыз.

—Ник? Бишбалта арасында диден ич үзен...

—Һи, тиле! Мин сина, Бишбалта арасында димәдем, биш белән алты арасында элекке урында, дидем!

Озатты егетләрне. Аларның баскычтан төшкәндә сөйләшкәне колагына чалынды:

—Әллә керүебезне яратмады инде, эчмәде бит...

—Юк, ул гел шулай, юньләп эчми. Сүз куертып, әңгәмәне жанландырып жибәрү өчен генә бераз иренен чылаткалап утыра.

Әйе, озын телләр, тар күңелле көнчел адәмнәр Сәйдәшнең хәмер белән «дуслыгы» турында ясалма гайбәт, уйдырма чәчеп өлгергәннәр иде. Әйе, театрда чакта ул иртәдән алып кара төнгә кадәр эшләде, сәнгать кешеләре, дуслары белән аралашты. Мондый аралашулар вакытында өстәлгә сыра яисә шәраб куелмыйча калмый, билгеле. Премьера арты премьера уйналган ул

еллар өчен—гадәти хәл. Ләкин Сәйдәш банкет өстәлләре янына эчү-исерү өчен түгел, ә бәлки аралашу, сүз җилемен куерту өчен утыра. Бер чәркәсен әнә шулай сәгатьләр буена йоткалап утыра ул. Мондый бәйрәм, күңел ачулар—аның өчен күтәренке бер ял вакыты.

Аның хәтта хәмер суын куллануга карата үзе уйлап тапкан «теория-формула»сы да бар иде: тукран эчәрлек кенә! Әйе, фәкать шулай—«тукран эчәрлек кенә...» Шушы эчке уена беркайчан хыянәт итмәде ул. Дирижер пультына күтәрелергә һәрвакыт әзер булды.

Шөкер, тирә-юнендә моны белеп торучылар да житәрлек иде. Сугыш елларының азагында бер спектакльдән соң аларны, сәнгать әһелләрен, хәрби кеше үзләренә кунакка алып китте. Тукай заманында ук билгеле булган Ишми Ишан дигән затның улы икән ул, офицер булган. Яна Бистә ягына кайткач, өендә чемоданын ачып күрсәтте. Бер кочак акча! Кемнәрнедер йөгертеп, аракы кайтартып та өлгерде... Хәмер парыннан бөтенесе изелеп йоклый... Сәйдәш кенә йокламый, ишекле-түрле йөренә.

Юкса аның бик хәсрәтле чагы... Икенче хатыны, Яна Бистә кызы Сафия белән аерылыштылар... Унөч яшьлек улы Нәүфәл һәм биш яшьлек сабые Эмильне хатыны үзе белән алды. Хәзергә шулай, тора-бара ничек килеп чыгар, Ходай белсен... Нигә хыянәт юлына басты Сафия?

Тылдагы түрәләр, спектакльләрдән соң алып китеп, рестораннарда сине пианинода уйнатып күңел ачкан чакта, фатирында икенче бер ир-егет өйдәш булып торганда гаиләнне саклау мөмкин эш түгел икән шул. Кин күңелле Сәйдәш үзе дә күпмедер гаепле түгелме соң? «Кунар урыным юк»,—дип яңгыр астында басып торган артист Ибраһим Гафурны жәлләп өенә алып керде. Күшеккән Ибраһимны җылыттылар, ашаттылар, эчерделәр... Ә ул әнә «Тартюф» булып чыкты! Беренче кичләрдән үк Сафиясен кочты, этлек кылды...

Шулай берчакны театрда штат кыскартулар башланды. Монысы—сугыштан соң. Сәйдәшне театрдан аермас өчен, актерлык төркеменә, ягъни артист штатына күчерделәр. Салих Сәйдәшев белән Тажи Гыйззәт менә шул чакларда эпозодик рольләр өчен бик тә ярап куйдылар.

Инде шушы штаты да «киселү»гә эләккәч, Сәйдәшнең матди ягы авырайды. Радиодан яңгыраган әсәрләре өчен түләнә торган гонорар хакына гына яши башлады. Соңгы еллардагы җан дусты, фронтовик шагыйрь Мөхәммәт Садри белән бервакытны алар капка төбендә боегып утыручы артист Зәйни ага Солтановны күрделәр.

—Нишләп болай күңелең төште, Зәйни абый?

—Акча ягы такырайды. Үзем авырыйм. Театрның бюльлетеньгә түләрлек тә рәте юк.

—Борчылма!—ди оптимист Садри.—Язучылар берлеге әгъзасы да бит әле син! Шунда бар әле, литфонд ярдәм итми калмас...

—Зәйни абыйны акчалы иттен бугай, бәгырь. Минем дә радиодан бераз аласы бар. Мин оялчан кеше. Әллә син кереп карыйсыңмы?

Батыр Садри, күкрәк орденнарын җемелдәтеп, иртәгесен радиога килә: «Сәйдәшнең 250 сум акча аласы бар икән, бик авыр чагы» ,—ди.

—Менә әле беркөн генә соңгы акчаны кырып-себереп Нәжип Жиһановка өч мең сум гонорар биреп җибәрдек,—ди икән житәкчеләр.

Сәйдәшкә: «Сүзсез дә аңлашыла»...—дип әйтүдән бүтән сүз калмаган иде.

Сәйдәшнең ике тапкыр елаганы гонорарга һәм Зәйни Солтановка бәйле.

Бервакытны радио бинасына гонорарга дип үзе керде ул. Әдәби-музыкаль тапшырулар бүлеге мөдире, ут борчасыдай хатын аны бик төксе һәм тупас каршылады. Хәтта мыскыллы сүзләр белән:

—Бездә алкашларга дигән акча юк!—дия-дия ишек төбеннән үк борып чыгарган иде.

—Ни булды, нигә елыйсын, Салих абый?—дип каршылады аны театрнын Илдус исемле шофер егете.

—Юк, бәгырь, болай гына...—дип егетне дә, үзен дә тиз тынычландырды ул.

Нишләп хөсетлек кылалар аңа карата? Бәхәс купса, чәүкә карганы яклар, дигәннәр. Жиһановнын куштаннары бар да бер чыбыктан сөрелгән...

1952 ел. Зәйни ага Солтановны күмгәннән соң халык таралды. Сәйдәш ялгызы гына зиратның бер читенәрәк чыгып баскан иде. Менә культура министры Хажи Рәхмәтуллин машинасы белән анын янынннан узып китте.— Сәйдәш аны баш игәндәй хәрәкәт белән озатып калды. Аның артыннан ук Салих Вәлиди, Язучылар союзынын машинасына утырып, эшенә кузгалып китте—утыртмады. Шулчакны юстиция органнарында эшләүче танышы Садыйк Дәүләткилдиев үзенен «Победа» машинасы белән килеп туктады:

—Салих абый, әйдәгез минем белән, теләгән жирегезгә илтеп куям.

Рәхмәт әйтеп кереп утырды. Кузгалып киттеләр. Бераздан машина хужасы, артка борылып карагач, композиторның жылап барганын күрде. Анын:

—Ни булды?—дигәненә «Хурлык, хурлык!»—дип кенә әйтә алды.

—Ташлагыз, Салих абый, алар сезнең кисеп ташлаган тырнагыгызга да тормый!

Хатирәләрнең күбесе, нишләтәсең, монсулыкка манчылган. Ә шулай да...

***

Язучыларнын ТАПП дигән оешмасын бик тиз арада яптылар. Анын урынына Татарстан Язучылар союзы оешты. Монысынын да рәисе—тынгы белмәс, энергиясе ташып торган шул ук Кави Нәжми. Дәрәжәсе зур, сүзе кайда да үтә. Совет түрендә утыручыларның ишекләрен кагып, алардан акча да, файда да каера белә. Әдәби фонд директоры Сәмитов белән берлектә,Түбән Ослан авылында үз йорты белән яшәгән кешеләрнең өеннән, акча түләп, жәйгелеккә язучылар өчен егермеләп бүлмә хәстәрен табалар.

1933 елнын кояшлы жәе. Идел буенда, Ослан итәгендә ял итүче язучыларны Кави Нәжми иртә таннан озын жәтмә белән балык тотарга алып чыга. Балык тотунын тәмен белгән ихлас жаннар—Шәриф Камал, Гадел Кутуй, Кәрим Тинчурин, Тажи Гыйззәт һәм ин активы—Салих Сәйдәш.

Кави абыйның жиде яшьлек улы Тансык өлкән абыйлары тирәсендә бөтерелә. Көттереп туган тансык малай булганга күрә, аңа шундый исем кушканнар. Чиләкне малайга тоттырып, челтәрле жәтмәне жилкәсенә салып, Сәйдәш төркемнең алдыннан диярлек атлый.

Яр буенда чишенеп, балык сөзә башлау белән Сәйдәш белән Кутуй арасында гауга чыга: жәтмәнең тирән яктан йөздергән очын кем тота да кем йөртә, янәсе. Кутуй аны терсәге белән читкәрәк этә, үзе көлә-елмая:

—Син, атаклыбыз Сәйдәш, балык-балык дип тирәндә батып үлсән, Тинчурин пьесаларына кем көй язар? Шутка түгел! Шунлыктан сине, татарның бөек композиторын, без һәрчак сакларга тиешбез.

Елмаеп, Сәйдәш аңа төрттерә:

—Мине саклыйм дигән булып үзең батып үлсәң?

—И-и, Салих дускай! Минем кебек язучылар Казан урамы тулы. Мин батканнан, балаларны хәзер кем туендырыр дип, хатын еласа гына инде...

Балык сөзү тәме һәркемнең канын кыздыра, күнелләренә елдырым сала.

Дулкын асларына чумган җәтмәне кайсы якка ничегрәк өстерәү эшләре белән Шәриф Камал җитәкчелек итә. Уен-көлке капчыгыннан аның җилкәсенә дә шаярту уклары килеп төшә. Бигрәк тә Сәйдәш «тырыша»:

—Каспий промыселларында балык тотып тәмам шомаргансың син, Шәрифулла абзый! Каспий дингезе, акчарлак тавышлары һаман исеңдә, ахрысы. Тавышың да кәр чыга, чуртанның зурысы эләгә болай булгач...

Гөбер-гөбер килеп, чуен казанда уха кайный.

Балык чистартканда аның тәңкәләре, энҗе йолдызлар сыман, төрлесе төрле якка чәчелгән, чәчрәгән иде.

Араларыннан берәү дә белми: берзаман язмыш аларның төрлесен төрле якка чәчеп ташлаячак... Кави Нәҗми дә белми: берзаман аның үзен һәм каләмдәш дусларын, сәяси җәтмә белән сөзеп, «халык дошманы» дигән утлы табада кыздырачаклар...

Мәскәүгә укырга китәр алдыннан композиторның Казандагы соңгы җәе иде бу.

***

Сәйдәш, кинәт уянып киткәндәй, пинҗәгенең эчке кесәсеннән чылбырлы сәгатен тартып чыгарды. Мәскәүдә маршал Ворошилов бүләк иткән исемле сәгать. «Сәйдәшкә—Ворошиловтан» дигән сүзләр уеп язылган аның арткы капкачына. Һай, бу сәгатьнең күргәннәре! Күпме генә кадерләп сакласа да, ике тапкыр югалтты ул аны. Беренчесендә, капкачындагы язуыннан кемнеке икәнен белеп, дусты—укытучы Вәлиев аша тапшырдылар. Икенче хәл 1950 елда булды. Нindiдер бер концерттан кайтып килгәндә, төнлә ике кеше кычкыртып талады аны. Пальтосын, кесәсендәге сәгате-ние белән костюмын, бүреген салдырып алдылар... Икенче көнне иртән кемдер ишек шакый. Ишекне ачып җибәрсә, бусага төбендә икәү таптанып торалар. Гафу үтенеп, Сәйдәшнең киемнәрен суздылар да тиз генә таймакчы булалар.

—Туктагыз...—диде хуҗа, эшнең нидә икәнлеген абайлап.—Пиджакны пычратмагансыз бит, «юмыйча булмас» моны! Тегеләр юмор хисеннән гел дә мәхрүм түгелләр икән. Тиз төшенделәр. Берсе, җәһәт кенә чабып, коньяк шешәсе күтәреп керде. Әнә шулай, сәгате табылу шатлыгыннан, үзен талаган караклар белән табын корырга да туры килде аңа. Сәгатенең кире үзенә әйләнеп кайтуы—аның өчен хөкүмәтнең теләсә-нинди орденнарыннан да кыйммәтрәк иде шул!

Кабат сәгатенә күз төшерде. Унбер тулып килә икән инде. Көн кызган, эсселәнгән. «Тукран эчәрлек кенә» итеп азрак сыра йотып куйса, рухи сусыны да басылыр иде, мөгаен...

Нәкъ шул чакта, җирдән калкып чыккан сыман, каршысына икәү килеп басты.

—О-о, маэстро! Исәнмесез! Сезнең хакта роман язарга җыенып йөрим менә...

Эче-тышы янып торган бу кеше—танышы, яшь язучы Мәгъсүм Латыйфуллин иде.

—Әй, кабәм, син аны язсаң да, минем хакта булганлыктан, аны барыбер басмаслар,—диде Сәйдәш.

—Нибуч, басарлар!—Бу сүзләрне егет гайрәт белән әйтте. Әйтерсең, китапларны басу-басмау аның үз кулында. Аннары иптәше белән таныштырды:

—Менә бу егет Әхмәт Рәшитов исемле. Студент. Шигырьләр сырлый.

—Бик хуп. Шигырь язган кеше иманлы була ул.

—Салих абый! Гонорар алган чак минем. Каршы килмәсәгез, сыра эчәргә чакырыр идем...

—Мәйлен. Бераз гына мөмкиндер, энем.

Кекин йортындагы хәрчәүнәгә кереп утырдылар. Юмор-мәзәк сөйләү—Сәйдәшкә авыр минутлардан читләшү, үзен-үзе юату, күнеленә бераз ял бирү өчен кирәк. Ул кеше гайбәтенә керми, үзенең белгән-күргәннәрен кызыклы сүзләр белән баетып, тыңлаучысына житкерергә тырыша. Бары шул. Ике егетне дә буш итмәде, башыннан кичкән бер хәлне сөйләп бирде:

—Беләсезме, сугыш вакытында Казандагы эвакогоспитальләргә яралы бик күп солдатларны китереп тутырдылар. Алар алдында без еш кына концертлар куябыз, акчасы фронт өчен ярдәмгә китә. Берсендә сынар аягы тездән өзелгән солдат янына килеп бастык. Елый гына бит, бичаракаем! Сынар аяк белән хатын янына ничекләр кайтып егылыйм, ди.

—Хафаланма, егет! Башың-кулың сау, шунысына шөкер ит. Бездә әнә Рәхмәтуллин дигән бер башсыз министр бар. Башы юк үзенең, әмма урынында нык утыра, бер дә сыгылып төшкәне юк әле,—дип юаттым үзен. Менә шундый хәлләр, бәгырьләрем...

Тукталып, карашын кинәт кенә еракка төбәде.

—Әле ике-өч көн элек кенә Мамадыштан остазым Заһидулла Яруллин килгән иде. Кече улы Мирсәетне дә ияртеп килгән. Җәй життеме, Заһидулла абый Казанга килеп чыга, миңа кермичә калганы юк. Менә кичә аның белән тукран эчәрлек кенә чеметтек бераз. Менә шул чакта күз яшьләре белән елады картыбыз:

—Улым Фәритнең башына шул гына житте, ләгыйнь! Юкса, Мәскәүдә бергә укыдылар,—ди. Кемне сүккәнен яхшы беләм, исемен әйтергә күнелем бармый. Агач белән көрәшмә, үгез белән сөзешмә, дигәннәр. Имәндәй тап-таза егетебез ут эчендә хәбәрсез югалды менә... Каберенең кайда икәнлеген дә белүче юк...

Өенә кайткач та Сәйдәш үзендә Фәрит Яруллинның әтисе белән төшкән бердәнбер фотосы барлыгын исенә төшерде. Эзләде, тапты. Карады. Менә ниләр хәтеренә төште аның...

## Ярулиннар дәвам итә...

Җәйге ачык сәхнәдә концерт бара. Гел яшьләрдән диярлек төзелгән уен кораллары оркестры халык көйләрен сайрата. Аларның күбесе—сәнгать техникумы студентлары. Тамашачылар гөрләтеп кул чаба.

Концерт бетүгә, Сәйдәш Фәрит янына килде. «Булдырасыз, афәрин!» дигәндәй, егетнең аркасыннан ук сөеп куйды. Театрдан килеше генә булганга, ул әле муеныңдагы кара күбәләгеп салырга да өлгермәгән иде.

Үзләрен халык урап алганчы дип, Фәритне читкәрәк алып китте дә үзенең фатирына чакырды. «Эрмитаж» бакчасыннан бергәләп чыктылар да сөйләшә-сөйләшә театр урамына борылдылар.

Концертны игътибар белән тыңлаган Сәйдәш әйтә куйды:

—Сөенечле хәл, музыкабызда сәләтле яшьләр үсеп килә. Татар халкының гомерлек хыялы бу. Күрәсеңме, ничек итеп кул чабалар. Сәхнәгә кабат-кабат чакыралар, әттәгенәсе!.. Кемдер әйткәнчә, халык киң бер һөҗүм белән музыкага ташланды хәзер. Яшь кызлар, яшь егетләр арасында музыка коралларыннан берсен белүне максат итеп куймаганнар сирәктер... Синең уйнавыңны да яратып тыңладым. Алда ниләр булмас әле, киләчәгең өметле синең, канатым.

Фәритнең йөзеннән: «Мактанырлык эш майтарган юк әле. Менә үзең дә көйләр язсаң, шуларны сәхнәдә үзең чыгып уйнасаң икән ул...» дигән сүзләрне укып була иде бу минутта.

Аулак сәгатьләр—Сәйдәшевнең өендә берәү дә юк иде. Бүлмә хуҗасы примуска чәй куярга дип чыгып керде. Сәгать гере тәмам авырайган, аяклы

этажерка өстендә нота өемнәренә менә-менә орынырга тора. Чылбырыннан тартып, аны өскәре күтәрде. Шәмдәлле пианиносына ишарәләп:

—Минем язганнарның шаһите менә шушы була инде, энем,—диде.

Тәрәзәдән кояш нурлары төшкәнгәме, пианино өстендә тылсымлы нурланыш белән таякчык балкып ята. Дирижер таякчыгы. Сәйдәш аны, бик кадерле нәрсә итеп, бәрхет чүпрәк өстендә саклап тота. Камыш сабагыдай шушы кеп-кечкенә нәрсәгә дөньяны актарып салырлык көч, олуг бер тылсым яшеренгән. Өнсез-телсез яткандай тоелса да, дирижер кулларына барып эләктеме, ул оркестр хәтле оркестрны дәррәү хәрәкәткә китерә: урман шаулый, диңгез кубарыла, күкләр елый башлый... Әле шулай яшел бәрхет өстендә хәрәкәтсез килеш оеп ятканда да таяк очыннан менә-менә очкыннар чәчрәп чыгар да яшен яшьнәр төсле!

Фәрит дәшми генә үз-үзенә йомылып торган арада, Сәйдәшнең күңеленнән әллә ничаклы әнә шундый образлы уйлар йөгереп узды.

—Фәрит энем, беләсеңме нәрсә... Дирижер таякчыгын кулда тотар өчен тормышның төрле ваклыкларыннан азат һәм өстен булырга кирәк. Әйе, азат булырга... Мескен кол яисә ялагайлар, табан ялаучылар кулында ул камил, тулы хәрәкәтләр ясый алмый... Маймылның кул хәрәкәтләре сукыр бер тиенгә дә тормый әнә. Халыкта: «Маймылланма!» дип юкка гына әйтелмидер...

Бу сүзләр, бу фәлсәфәне ишетү—яшь Фәрит өчен ачыш иде. Аның тирән күзләрендә очкыннар җемелди иде.

—Салих абый, киләчәктә мин дә дирижер була алыр идем микән?

—Һичшиксез. Ләкин моның өчен күп укырга, күп эшләргә, максатның зурысына тотынырга кирәк!

Сәйдәш, кунак егет янынннан сүзсез генә узып китте дә, пианиносы каршына утырды. Беренче аккордлар өйдәге һаваны электрлады, челпәрәмә китерде кебек. Бүлмә эчендә күзгә күренмәс дулкыннар йөгереште... Сәйдәшнең уйнавы моңлы, тәэсирле килеп чыга иде. «Туган тел» моңнары йөрәкне татлы итеп телем-телем кискәли кебек, әллә рәхәтлек, әллә авыртумы бу—аңламассың. Сузынкы көйнең алдына төшә-төшә, колак төбендә бик тә таныш, сөекле сүзләр яңгырый:

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле...

Уйналып беткәч тә моңнар үзләренең яшәвен дәвам итәләр. «Без бар... без яшибез...»—дип әйтә сыман алар. Шушы кайтавазның тынып-туктап калуын көткәндәй, композитор тагын күпмедер сүзсез утырды, аннары гына күтәрелә төшеп Фәриткә борылды:

—Беләсеңме, наным, шушы көйне уйнаган, тыңлаган саен өр-яңадан тугандай бер халәт кичерәм мин... Халкыбызның күңел сафлыгын, сагышын, ана телебезнең бөеклеген гап-гади чиста моңнар белән әйтә дә бирә бу җыр. Әйе, халыкта билгесез моң иясләре җитәрлек булган. Безнең бер «Гөлҗамал» гына да, яңгырата белсәң, Европаны тотарлык! Менә кемнәрдән өйрәнү кирәк безгә...

Чәй дә өлгергән икән, чынаяк-тәлинкәләр куеп Сәйдәш үзе дә табынга утырды. Кайнар чәй янына йомры савытта шикәр вaклары да куелган иде.

—Кап, уңайсызланма, мондый тансык нәрсә теләсә кем алдына куелмый,—диде бүлмә хуҗасы. Кунагының тормыш һәм уку хәлләрен сорашты. Фәритнең әтисе Заһидулланың заманында ничек итеп үзенә дәрес биргәннәрен сөйләде. Аннары, елмая төшеп, болай дип тә өстәде:

—Аның кылган яхшылыклары, хезмәте кайтарасы бурыч булып һаман

жилкәмдә тора. Инде дә сина булышыйм дисәм, син инде музыкада тәмам аякланып беткәнсең...

Фәрит тыйнак кына җавап кайтарды:

—Алга таба да укыйсы, өйрәнәсе иде, Салих абый. Композициядән хәзергә белемем сай тоела.

—Шулай, бик дөрес уйлыйсың, энем. Сина гынамы, алга таба барыбызга да нык укырга, рояль капкачын кимерердәй дәрәҗәдә нык эшләргә кирәк әле... Ә беләсенме, Мәскәү консерваториясе каршында ачылган рабфакта укудан да кулае булмастыр синең өчен. Уйлап йөр әле, бәлки шунда тәвәккәләвең хәерлерәктер...

Музыкага җаны-тәне белән бирелгән Сәйдәш милли музыкабызның үсеше, аның киләчәге хакында сөйләгәндә тагын да җитдиләнеп, дәртләнеп китте:

—Үзең дә беләсеңдер, бездә хәзер кайнар бәхәсләр купты. Янәсе, татар музыкасы нинди юлдан барырга, үсәргә тиеш? Бик вакытлы һәм урынлы сорау. Берәүләр безне рус һәм европалылар үрнәгенә чакыра. Икенчеләр исә «европалашу»дан сак булырга, милли кысалардан читкә китмәскә куша. Мина калса, дөреслек менә шуларның уртасында шикелле. «Гөлҗамал», «Карурман» кебек җырларыбызны ничек инде искелек калдыгы дип атарга мөмкин? Аларда—халыкның гасырлар буе саркылып килгән моңы, язмышы, хәсрәте. Болардан йөз чөерү чеп-чи ахмаклык булыр иде... Шул ук вакытта без нигә әле башка халыкларның хәзинәсен, алдынгы культурасын өйрәнүдән куркып торырга тиешбез? Милли чикләнгәнлек шулай ук ярлылыкка китерә...

Бу урында Сәйдәш, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, берара туктап калды.

—Бородинның оркестр өчен язылган «Урта Азия»сен тынлаганым бар минем. Дала. Бушлык. Киңлек. Менә шушы киңлеккә берзаман шәрык моннары, аннары инде рус көйләре агылып керә. Шуларның бербөтен булып кушылуы, тора-бара әкрен генә сүнә, ераклаша баруы, беләсенме, нинди тәэсир тудыра! Хәер, моны тел белән аңлатып булмый, моны тоярга гына мөмкин...Нәрсәдә калдым соң әле? Әйе, милли музыкабыз, үз йөзен саклаган хәлдә, башка халыклар туплаган тәҗрибәгә дә таянып үсәргә тиеш. Боларны сина киләчәктә уйланып карау өчен дигәндәй әйтүем...

Аның әйткән-сөйләгәннәрен Фәрит йотылып тынлый.

—Менә мин спектакльләргә бию һәм балет элементларын керттем. Йә, кемгә ни зыяны бар моның? Пылау өстенә татлы бер җимеш кенә ләбаса, шулай бит.

Фәрит башын кага, әйтә:

—Балетка тартым урыннар миңа бик ошый, Салих абый!

Бер сәгатьтән артык әнә шулай сөйләшеп утырдылар ике җан, ике моң иясе.

—Минем сина ике киңәшем бар, Фәрит энем,—диде Сәйдәш, саубуллашыр алдыннан.—Юмор хисеннән читләшмә. Сәламәтлеккә, шат күңелле булмакка файдасы зур аның. Менә мин кайчакта кешеләрдән: «Тарагым онытылган, берәрегездә тарак юкмы?»—дигән булам. Үзем кешедән тарак алмыйм.

—Һәй, җегетләр, кичерегез, үз тарагым табылды!—дим дә биш бармагым белән чәчне артка сыпырып куям. Үзара бер настроение ясарга шул да җитә кала. Синең үзеңнең дә чәчләрең, Аллага шөкер, куе, артка ятып тора. Сина да таракның хаҗәте юк бугай...

Монысы булды бер... Икенчесе. Дөньяда көнне матур итеп башлап җибәрү өчен бик яхшы бер кагыйдә бар. Улмы? Ул боладыр болай: иртән уянгач та, бүген мин кемгә нинди шатлык китерә алырмын икән, дип гоман

кылу фарыз. Менә шул яхшылыгын көннәрнең берендә барыбер үзенә әйләнеп кайта. Мыегына чорна, борынына киртләп куй боларны...

Фәрит мәгънәле итеп ым какты.

***

Сәйдәшнең юраганы юш килде: 1933 елны 19 яшьлек Фәрит Яруллин Мәскәү дәүләт консерваториясенең рабфак бүлегенә белем эстәргә китеп барды.

1934 елда исә шул ук Мәскәү консерваториясе каршында, илдә беренче буларак, татар опера студиясе ачылды. Татарстан композиторларын берәмләп тә, «пачкалап» та әнә шунда юлладылар: Нәҗип Җиһанов, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин... Рабфагы белән саубуллашып, Фәрит Яруллин да алар төркеменә кушылды.

Мәскәү дигәч тә, Сәйдәш моңа әллә ни егылып китмәде. Студиягә алган вакытта ук күнелен күпмедер суытып ташладылар аның. Композиторлар бүлегенә укырга керер өчен алар Җәүдәт Фәйзи белән бергәләп данлы профессор Генрих Ильич Литинскийда сынау узарга тиешләр иде.

—Салих абый,—диде Җәүдәт,—сынауга башта мин керимче, юкса синнән соң югалып калуым бар.

—Шулай итәрбез, бәгырь. Син сүзгә оста, имтиханны син алдан узарсың.

Профессор исә аларның икесен берьюлы чакырып алды. Исемләп таныштылар.

—Бик мактаулы эш, егетләр,—диде Литинский, аларның Мәскәүгә килүен хуплап.—Бик мактаулы. Укырга, белемегезне арттырырга кирәк.

Сәйдәш үзе белән «Наемщик» һәм «Совет Армиясе маршы»н алып килгән иде. Шуларны уйнап күрсәткәннән соң:

—Салих Жамалетдинович,—диде профессор.—Сез, һичшиксез, талант иясе. Мин сезне зур канәгатьләнү белән үз классыма алам. Тик бер шарт белән: бу язган әсәрләрегезне онытып торырсыз. Мин таләп иткән әсәрләрне генә язарсыз! Ә инде Фәйзигә килсәк, ул доцент Борис Семенович Шехтерда укыр.

—Сине «шахта»га, мине «латать» итәргә җибәрделәр,—дип көлде Сәйдәш соңыннан.

Көлке бер хәл, консерватория хәтле консерваториядә композитор кешене йөгәнләп тотарга җыеналар икән ләбаса! Бөтен кешегә симфонияләр язарга димәгән, бит Сәйдәшнең барыннан да элек үзе теләгән нәрсәләрне, күнеле кушканны язасы килә... Вакыты-вакыт белән ул үзен судан ярга чыгарып ташланган балык сыман хис итә иде.

Моннан егерме ел элек булган хәлләр бу.

Менә хәзер, 1954 елның түбәсендә басып торган хәлдә уйлый Сәйдәш: татар өчен, татар музыкасы өчен Яруллиннар токымы кирәк, бик тә кирәк булган! Заһидулла абый—халык музыканты, беренче татар пианисты. Улы Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты әнә Ленинград сәхнәсенә кадәр күтәрелде. Кече Сөндә әтисе белән яшәп яткан төпчек улы Мирсәет татар көйләрен баянда өздерә генә!

Кан гына түгел, җан, рух, мәңгелек моннар да берләштерә Ярулла бабай оныкларын...

*Ахыры киләсе санда*



Рифә
Рахман

# ӘЗЕР КАЛЫПЛАРГА СЫЙМАС ХИС БУ...

***

**Әзер калыпларга сыймыйсың син,**
**Башкалардан үзгә, ят инсан.**
**Рифма килми, үлчәм җитми төсле,**
**Шигырь язам диеп тотынсам.**

**Мин моңарчы күреп белгәнемдә**
**Сез бит—килер гасыр кешесе.**
**Фәгыйләтен-фәгыйләләр генә**
**Бирә алмый сезгә хас хисне.**

**Яңа үлчәм эзлим, яңа алым,**
**Килер гасырларга ярарлык.**
**Кабат җиргә Сөю хуҗа булгач,**
**Укучысын эзләп табарлык**

**Шигырь язасылар килә минем**
**Күңел дәфтәрләрен тутырып.**
**Әзер калыпларга сыймас хис бу.**
**Әйдә әле тып-тын утырыйк.**

## Ачык-ябык чираты

**Ачык-ябык иҗек чираты бар**
**Калыбында һәрбер шигырьнең.**
**Бер ябыла, бер ачыла: минем—**
**Шигырь кебек икән күңелем.**

**Килеп кердең аңа җиңел генә**
**Ишекләре ачык чагында.**
**Син артыгын анда тыпырчынсаң,**
**Келәләрен тора салырга.**

Рифә РАХМАН—*шагыйрә, прозаик, публицист, әдәбият галиме; «Сиңа», «Дөньям кызыктырса», «Айлы күлдәвекләр» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Калдырырга сине чыгармыйча
Мәңгелеккә йөрәк түрендә
Булдырам мин! Ишек ачык чакта
Бик җиңелдән анда керден дә

Чыгам димә, аяк очы белән
Ишекләрен тибеп, җил япса.
Төшәр куяр усал келәләре,
Күңелемә сине тиң тапса.

Ачык-ябык иҗек чираты бар.
«Ачык ишек» көне—күңелдә.
Вакансия патша урынында—
Алтын тәхет тора түрендә.

Сайла, җаный: китәр-калырың бар,
Рухи түрең, ризык табының бар.
Күңел ритмы шуны таләп итә:
Ашык әйдә, вакыт ябылырга!

* * *

Тәрәзең капкачына җил «шык»ласа,
Чык кичен капкаң алдына, күр, бәгырь:
Көндезен кояш эзләп тапкан тамчы
Түбәдән тамып, кардан юлын ярыр.

Мин торган якка таба карап агар,
Тамчыдан ясалырдай булса чишмә.
Чык, бәгырь, җилнең әле юаш чагы,
Ул тына, берәр шакып куйса кичтә.

Ул җилнең бүген ихлас чагы, сине
Җилдертер кулдан тотып йортка кадәр.
Ул шакып куйса тәрәз капкачыңа,
Мин юньсез биргән булам сиңа хәбәр.

## Сорамакчы булдым

Күрдеңме, дип
Сорамакчы булдым синнән.
Ә күрмәсәң?
Күрмәвеңнән күңлем кайтса?

...Ахмак теләк
Бер-бер артлы туа тора,
Казан өстендә агарып
Ай калыкса.

Сорамакчы булдым синнән:
Күрдеңме дип.
Син кочканчы керфегем
Юпь-юеш иде бит!

## Бүген таңда

Чәчемне тарарга—
Тарак булмады,
Урындык кагарга
Кадак булмады.

Ә өйдән
Сине табарга
Берни кирәкми!—
Бик җиңел
Йөрәккә кадарга.

* * *

Алда әле санап яшәр сәгатьләрең:
Көч беткәнче, эш калмасын, үч калмасын.
Ә син, гомрең менә бүген бетәр төсле,
Шул эшләргә хәзердән үк тотынгансың.

Яшәсеннәр мин юкта дип бөтенлектә,
Балаларның йортын-җирен карагансың.
Җитәрме дип чирләп китә-нитә калсам,
Кассаңдагы акчаларны санагансың.

Фатир алып, гамәл кылып фанилыкта
Һәр көнеңне тик эш белән үткәргәнсең.
Менә хәзер типкән синең башка бер уй:
Өлгермәссең кебек фарыз үтәргә син...

Артка чигәр гамәлләрең, сөю килсә,
Баш очында бер кош кебек бөтерелсә.
Фарыз шундый, аңа авыр—яңабаштан
Тотынуы, көтмәгәндә бер бүленсә.

## Тыңлаучы

Кич
Сине тыңларга дип
Шомарткан колакларын.
Ишетелә коридордан
Ишегемә атлавың.
Мин чакыргач киләсеңне
Белсәм дә,
Торам мин дә тыңлап:
Төннең колаклары аша
Үтеп киттең
Югары катка.

Әллә мин саташам,
Әллә кич—колаксыз?!
Әллә син адашкан...
Атлачы
Яңабаштан!

## Эзләргә чакыру

Без—
Оҗмах кошлары.
Арада бар да бар:
Сөт сулы елгалар,
Чытырман урманнар.

Яшибез әкияттә.
Без—
Оҗмах кошлары...

Нәкъ шушы минутта
Син миңа оч әле?!

Канатың сындырмый,
Томшыгың канатмый,
Син эзләп тап әле.
Ә минем...
Төнбоек чәчәген
Ашарга
Уйлаган чак әле.



Рәзинә
Мөхияр

# УЯН, ХАЛКЫМ!..

## Томан

**Томаннар таралалар**
**Агыйделгә, Иделгә.**
**Чулпаннарга, Ыкларга,**
**Базыларга, Сөннәргә,**
**Чәрмәсән, Кармасанга—**
**Татар халкы яшәгән**
**Тагын әллә кайларга.**
**Томаннар таралалар,—**
**Татар аңын томалап,**
**Нинди генә төрләрдә,**
**Нинди генә көйләрдә,**
**Нинди генә өйләргә?!**
**Елгалар өсте томан,**
**Милләтем, хәлең яман.**
**Томаннарга чолганып**
**Яшәү сәбәбең каян?**
**Күз күреме күренми**
**Томаннары артыннан.**
**Җилләр исә котыптан,**
**Калтыратып салкыннан.**
**Елгалар өсте томан...**
**Әй, томан, томан, томан..**

## Мәскәү урамында

**Мәскәү урамында яфрак оча.**
**Әле берәр, әле күмәкләп.**
**Карт агачлар моңсуланып карый**
**Төшкән яфракларга чүмәкләп.**

Рәзинә МӨХИЯР—*шагыйрә, галимә; Казан һәм Чаллы нәшриятларында дөнья күргән бернечә китап авторы. Чаллыда яши.*

Күпне күргән агач иңсәсенә
Күпме язмыш үткән кагылып.
Текәлебрәк озак карап торсаң,
Тарих китә кебек чагылып.

Күпме милләтләрнең язмышлары
Агач тамырыдай юл алган.
Күпме милләт, күпме бәндә башы
Мәскәү эчләрендә югалган?!

Югалтулар кайтавазы сымак
Агач шаулый көзге җилләрдә.
Такыр башлы агач шомлы карый,
Ниләр булыр диеп илләрдә.

Әй, агачның күргән-белгәннәре!—
Ничә буыннарга җитәрлек:
Барысын да әгәр сөйләп бирсә,
Башы Себерләргә китәрлек...

## Мин кемгәдер кирәк кебек

Бу дөньяда мин кемгәдер кирәк кебек,
Тормыш җебен челтәр итеп барам үреп.
Җиргә басып кеше булып йөргәндә
Эзләремә берәү карап калыр күреп,
Хисләремне чәчми саклый алыр төреп.

Бу дөньяда мин кемгәдер кирәк кебек,
Күзләрем дә бертуктаусыз карый көлеп.
Тормыш җебем кинәт кенә өзелгәндә
Карап калыр микән берәү миңа сөеп?—
Мин киткәнгә сыкрап, җаны-тәне көеп.

## Елмаюың калсын йөземдә

Күңелеңә шатлык булып керим,
Моң-сагышы... калсын үземдә.
Татар хатыннары сабыр булган,
Сабыр булган гомер-гомергә.

Йөрәгеңә сөю булып керим,
Газаплары... калсын үземдә.
Кайта-кайта искә төшерерсең,
Искә төшерерсең көзен дә.

Җанкаеңа шифа булып керим,—
Яралары... калсын үземдә.
Күз алдында булсын елмаюым,
Елмаюым калсын йөземдә.

## И, туган телем...

Чылбырларда, зынҗырларда булсаң да, телем,
Синнән күркәм тел юк бит ул,
и туган телем!

Чордан-чорга залимнәргә кучсә дә илем,
Яшисең бит, аптырарлык,
и татар телем!

Кысрыклауга, мәсхәрәгә түзәсең, телем.
Теле барга—иле кирәк, и ана телем!

Хокук булса, илең булса, ни булыр, телем?!
Синнән башка татар булмас,
син минем көнем!

Хокукларың бер дә юкмы соң синең, телем?!
Йөрәкләрне ник теләсең син телем-телем?!

Буыннардан-буыннарга күч, татар телем!
Зиһен чиксез, белик әйдә, ятларның телен.

Битарафлык—упкын, төшмә, ул синең телең!
Каплаганмы әллә, халкым, май—калын тирең?!

Гасырлардан, Тукайлардан килгән, үз телем!
Күрмәсәкче янып юкка чыккан ут-көлең!

Уян, халкым! Саклар өчен үз телең-көнең,
Сөремнәрдә исердеңме?! Тирә-як—сөрем...

## Җир шары түгәрәк

Җир шары түгәрәк,
Кырыен тапмассың,
Почмагын япмассың.
Дөньяда шуңамы
Куласа законы:
Бүген син иң өстә,
Куласа әйләнгәч,
Тәгәрисең аска.
Җир шары түгәрәк,
Кырыен эзләмә,
Тиргәнмә, сүзләмә!
Кануннар бик кырыс,
Аңларга гел тырыш!
Дөньялар кендеге—
Тәкәббер залимнәр
Гомере чигендә
Дөньяны яраткан
Даһига тезләнә.
Җир шары түгәрәк...
Күз салчы, һавада—
Бер көнлек күбәләк.

## Өр-яңа көн

Иртә-таңны мактап мәдхияләр язам,
Кошлар сайравына акылымнан язам.
Кояш карый назлап, иплап көлеп кенә,
Җилләр баштан сыйпый санлап—
Җайлап кына.

Бөтен дөнья изге сихри нурга чумган,
Иртәнге һавалар хуш исләргә тулган,
Хозур бакча буйлап атлыйм, күңел тулган,
Җиргә гаҗәп матур өр-яңа көн туган.

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

Барлас Камалов

## ГОМЕР КИЧЕНДӘ

Жәйге көн сүнеп бара иде. Көнбатыш тарафтагы аккош мамыгыдай кабарынкы җиңел болытларны алсу төскә манып, кояш баерга җыена.

Наратлыкта һава сулап йөргәч, кичке ашка дип төп корпуска кайтып кергән Хәмдүнә карчык, ачык ишектән директор бүлмәсенә күзе төшкәч, эсселе-суыклы булып китте. Аның каны качкан юка иреннәре: «Кәбисә ел могҗизасымы соң бу әллә?—дип пышылдадылар.—Фәррах лабаса!»

Аның тамагын кайнар сулыш каплады, аякларының хәле китте. Ул тиз-тиз коридорның урам як тәрәзәләре буендагы диванга барып утырды. Тын алуы читенләште. Тамырлары шәмәхәләнеп бүрткән сул кулының бармак очлары белән гәрәбә муенсасын кыймылдаткалап куйды. Әйтерсең лә сулышын шул буып тора иде.

Чакырткан булгандыр, күрәсең—шәфкать туташы белән кастелянша директор бүлмәсенә үттеләр.

—Менә шулай, иптәш Әсфәндияров. Әйбәтләп урнашыгыз, аннары кичке ашка рәхим итегез. Зур гаиләбез белән сезне шунда таныштырырмын... Сез, иптәшләр, Фәррах Шиһаповичка урын-җирен, кирәк-яракларын җайлагыз...

Картлар йорты башлыгы сүзен шулай түгәрәкләде. Хәзер һәммәсенең кабинеттан чыгасыларын чамалаган Хәмдүнә үз-үзен сикереп торырга мәҗбүр итте һәм, әллә кайсы буыны чатнап куюга карамастан, ашыгып үз бүлмәсенә юнәлде, ләкин кереп китмәде. Шәфкать туташына һәм урын-җир, кием-салымнар белән эш итүче ханымга ияреп чыккан Фәррахны читтәнрәк күзәтеп калды. Тегеләр, өчәүләшеп, бинаның аргы башына киттеләр.

—Бетеренгән икән Фәррах та, бик бетеренгән,—дип куйды Хәмдүнә.—Кайда ул теге чактагы солтанатлы кыяфәт, киң җилкәләр! Кайда ул идән сайгакларын сыгардай гайрәт белән атлаулар! Чәчләре нинди иде! Баш түбәсе, әнә, ындыр табагыдай такырайган. Чигә чәчләре дә сирәгәеп калган һәм гомер карыннан ап-ак булган. Тулы каратут йөзе суырылып, төз борыны сузайган. Зур күзләре эчкә баткан. Күрүе дә чамалы бугай. Колгасар кешеләрнең байтагына хас булганча, яшьлегендә дә азрак бөкрәеп йөри иде, хәзер бөкре дигәнe күзгә күренеп арткан.

—Июньдә житмеш өчен тутырды шул инде,—диде Хәмдүнә.—Житмеш өчен... Ни гомердән соң кайлардан жил ташлады икән үзен? Суга төшкән кебек юкка чыккан иде бит. Әй, язмыш! Әй, күрәчәкләр!..

Тилемсә кеше сыман ишек бавына ябышып торып булмый иде. Хәмдүнә бүлмәгә керде. Шулчак аны әйтеп аңлаткысыз халәт биләп алды. Жаны тынгысызланды, күнеле тулды, бер өшеде, бер кызышты. Йөрәге чыгымчылап типте. Аркасына тир бәреп чыккан кебек булды, башы әйләнгәндәй тоелды. Ул, гайре табигый талчыгу сизеп, урынга ятты. Кичке ашка кермәскә ниятләде. Әмма белә иде, медсестра килеп житәчәк, кәефен сорашачак. Аңа ни дип әйтер? «Бүген кабул иткән кешегезгә күренәсем килми. Ул бит...»—диярме? Бүген күренмәсә дә, барыбер күренергә туры киләчәк ич инде. Бер йортта бергә яшәргә насыйп булгач, очрашмыйча ни хәл итәсең ди?!

Аннары ул икенче төрле уйлап бакты. Торыр, юынып-таранып алыр, кешелеккә дигән киемнәрен кияр дә ашханәгә горур гына барып утырыр. Директор һәммәсен Фәррах белән таныштыргач, ул да барып күрешер... Юк, болай булмый. Булмый! Алай итсә, Фәррахны да кинәт читен хәлгә калдырыр, үзенең дә нишләп бетәсен каян белә?! Йә хәзер үк бүлмәсенә кереп күрешергә кирәк, йә инде иртәгә иртүк очратырга...

Бер исәпләгәндә, Фәррахның бу йортка килеп урнашуы—анын бәгырь жәрәхәтенә учлап тоз сибү. Икенче уйлаганда, Казанга кайтып төпләнүе, ничектер, аның бәхетенә дәдер сыман. Бер мизгелдә башын әллә кайларга алып чыгып китәрдәй булып жилкенде ул (белә инде югыйсә: бу яшьтә, бу хәлдә беркая да китә алмаячак!), икенче минутта, гомере соңында үзенә арка таянычы табар сыман, әллә ниләр өметләнеп алды...

Ярты сәгать эчендә бик күпне уеннан кичерде Хәмдүнә. Башы катты. Чигә тамырлары шулкадәр көчле типте, гүя анда кемнәрдер бәләкәй чүкечләр белән өзлексез сугып торалар иде. Азак килеп, ул катгый карар кабул итте: мондагы барлык кешене шаккатырып, ашханәдә күрешкәнче, үзе генә чакта кереп сүз башларга!

Өс-башын алыштыргач, Хәмдүнә теге хатыннарның Фәррах яшәячәк бүлмәдән чыгуларын көтте. Алар анда бик озак тордылар кебек тоелды, бик озак... Медсестра белән кастелянша икенче катка менеп киткәч, Хәмдүнә уникенче бүлмә ишеген килеп шакыды. Фәррах русчалап жавап бирде:

—Войдите!

Ишектә биек бусага да юк-югын, тик карчыкка аяк күтәреп атлаулары бик авыр булды. Исәнләшергә кирәк иде, ләкин игәүгә әйләнгән теле аңкавына беректеме соң әллә? Көч-хәл белән әйтте, ниһаять:

—Исәнме, Фәррах!—диде.—Картаймышлы көнебездә менә кайда очрашырга язган икән безгә...

Анын тамагына кайнар яшь тыгылды.

Фәррах сын булып катты да калды. Ул өнсез иде. Аннары, иңнәренә еллар өйгән йөкне дәррәү читкә ыргытырга теләп һәм нindидер ярсу көчкә буйсынып, Хәмдүнәне кочагына алырга ниятләде шикелле, тик миендә кисәтүле яшен чаткысы кабынып сүнде: «Нишлисең?» Газаплы вак адымнар белән ул күктән төшкәндәй бүлмәсенә килеп кергән карчык каршысына атлады.

—Хәмдүнә! Синме бу, күземә генә күренәсенме?

Картның тавышы да, куллары да калтырый иде. Шулай да ул кушучлап күрешергә үрелде, билдән бөгелеп, башын түбән иде. Аның күзләреннән тәгәрәгән яшь бөртекләре Хәмдүнәнең кулларына тамды. Карчыкның кулларын үз учларында тотканда, картның жанын алыштырып куйдылар

диярсең. Фәррах үзен кечкенә бүлмәдә итеп түгел, даладан да киң иркенлектә сыман сизде. Әйтерсең ул җәйге сәхрәдә гүя чәчәкләрнең җилдә чайкалу тавышын, бөҗәкләрнең үзара серләшү авазларын ишетә, мең төрле үләннәрнең тәмле исен йотлыгып исни, бихисап төсләрне күңеленә сеңдерә иде. Кабатланмас авазлар, бер-берсеннән көчлерәк хуш исләр, чәчәкләрнең күз явынны алырлык төсләре һәммәсе бергә кушылып, аның яшәү бөтенлеген тәшкил итә кебек һәм боларның барысын да чүгеп, кечерәеп калган карчык белән күрешү китерде...

Хәмдүнә белән Фәррахның кайчандыр ирле-хатынлы булганнары, картның туган якны җирсеп, Казанга Казахстаннан кайтуы интернатта гомер итүчеләрнең һәммәсенә тиз арада мәгълүм булды. Шуннан соң Хәмдүнә белән Фәррах арасындагы мөнәсәбәтләргә бәрәү дә—картлар да, интернат персоналы да—гаҗәпләнми башлады. Карт белән карчык исә, гомерләре агышындагы сикәлтәләрне һәм базларны бөтенләй оныткан кебек, татлы-ләззәтле, назга-нәзакәткә уралган сөешүләре кире кайткандай, пар күгәрченнәрдәй гөрләшәләр иде. Тик аларның ниләр сөйләшүен, нигә үкенүләрен, нәрсәгә шөкрана кылуларын берәү дә чамалый алмады. Әмма картларның татулыгы, бер-берсенә ихтирамы сокланып туя алмаслык иде.

Ләкин... тормышта шатлык белән кайгы, юаныч-сөенеч белән сагышкөенеч җитәкләшеп йөрүчән була.

Интернатка килгәндә, Фәррах абзыйның кәефе ару гына иде кебек. Уена да китермәгәндә Хәмдүнәсен очрату чамасыз тетрәндердеме, әллә күптәннән тула килгән чуанның тишелүе булдымы, монда яши башлавына ике атна тулып узды дигәндә, август уртасында, Фәррахны каты сырхау бөгеп салды. Больницага урнаштырмыйча булдыра алмадылар. Хәмдүнә тәүлекнең күп өлешен аның янында уздыручан булып китте.

Сентябрь кергәч, картның хәле катлауланды. Ул бавырындагы яман шеш интектерүенә тәкать итә алмый башлады. Врачлар операция ясатырга инде кичеккәнлеген аның үзенә аермачык әйтмәделәр һәм бинһая әрнүләрен басар өчен әледән-әле укол кадый торырга мәҗбүр булдылар.

Төннәр озая бара иде. Фәррах йокыга талган минутларда, Хәмдүнә, аның көннән-көн сулучы йөзенә карап, еракта калган көннәрнең хәтерне тырнап канаткан, җанга суелып кергән вакыйгаларын фикер иләгеннән уздырды.

...Алар мең тугыз йөз кырыгынчы елның башында өйләнештеләр. Сугышка кадәрге чамадан чыгып фикерләгәндә, никахлары шактый олыгайгач булды. Хәмдүнә егерме өченче яше белән бара, Фәррах анардан ике яшь тирәсе өлкән иде.

Техникум тәмамлап килгән агроном кыз белән ветфельдшер егет (ул ветеринария техникумын балалар йортында тәрбияләнгәннән соң тәмамлаган иде) читтән килгән булсалар да, Танчулпан авылында аларны үз итеп өлгергәннәр иде, кызыл туйны гөрләтеп уздырдылар. Яшьләр тәрәзәләрен кадаклап, Донбасс якларына киткән берәүнең йортында көн итә башладылар. Дәһшәтле елның язында Хәмдүнә белән Фәррахның мәхәббәт җимеше—Сөмбел дөньяга килде. Фәррах Бөек Ватан сугышына чыгып киткәндә, кызчык яшь ярымлык булып килә иде.

Илгә-көнгә кан-яшь, үлем, кара кайгы, хәрабәләр, бихисап газаплар алып килгән сугыш Танчулпан авылын да ярты ел дигәндә ир-атсыз калдырды. Хуҗалык йөген, михнәт арбасын карт-коры белән бала-чага төпкә җигелеп тартты. Кырык икенче елның язында агроном Хәмдүнә Гатинаны «Кызыл Танчулпан» колхозының рәисе итеп сайладылар. Теләмәгән иде, бер генә

дә күңеле тартмаган, курыккан иде, ике сөйләштермәделәр...

Таннарны төннәргә ялгады яшь рәис, сенере тартышканчы тырышты. Сөмбеле тәүлек әйләнәсенә күрше карчык хозурында булды. Атлар кимеп калгач, сыерларны җигәргә өйрәттеләр, басу тикле басуны көрәк белән казыдылар. Язгы ташу суларын ерып, район үзәгендәге Заготзерно пунктыннан чәчүлек орлыкны җилкәдә ташуга да исләре китмәскә әйләнделәр. Кемнендер ире, кайсыныңдыр агасы яки этисе үлү турындагы хәбәрләр гадәти булып күренә башлады. Гарипләнеп кайтучыларны бәхетлегә санадылар. Ничек кенә булмасын, «Кызыл Таңчулпан» йөз егермегә якын хуҗалыклы колхоз, алда бармаса да, иң арттагылардан да саналмады. Фронтка ашлык, бәрәңгеяшелчә, ит озаттылар. Авызларыннан өзеп озаттылар. Егылмаска, авып-аунап калмаска, ничек тә чыдарга дигән үҗәтлек, кодрәт арттырмаса да, дәрт бирә иде. Мәгәр кырык дүртенче елның язындагы ачлыкның шыр сөяк кулы адәм балаларының бугазыннан буып алды. Кешеләр шешенә башладылар. Шуны күреп, белеп торган, үзе дә кычыткан һәм чөгендер яфрагы пешереп кенә җан асраган Хәмдүнә Гатина, яңа уңыш өлгерү белән, колхозчыларның хезмәт көненә аванс бирде. Белә иде: дәүләткә тапшырганның унбиш процентына гына кагылырга хакы бар иде аның, ләкин ул халыкка өләшкән ашлык шул көнгә илгә биргәннең яртысыннан да артып китте.

Сугыш чорында мондый хилафлык дәүләткә каршы сәясәт санала иде. Райком бюросында Хәмдүнәне соң дәрәҗәгә җиткереп кисәттеләр. Тик эш моның белән генә чикләнмәде. Ул елларда райком бюросында беренче секретарьдан да битәр күкрәк киереп утыручы милиция начальнигы Гатина эше белән шәхсән үзе шөгыльләнәсе итте. Раймилиция башлыгы иптәш Сөбханкулов анлатты Гатинага: «Башың китә!»—диде. Сабый баласын язмыш кочагына калдырып, төрмәгә озатыласын сизенгәч, рәис хатын күзеннән яшь түгел, кан тукте. Колхоздашларыннан берәү дә аны яклап сүз әйтә алмады. Сөбханкулов иптәшләргә авыз ачар заман түгел иде.

Иптәш Сөбханкулов, Гатинаны үз кабинетына берничә чакыртып тинтерәткәч, әйтте: «Башыңны саклыйм дисәң, назланма»,—диде.

Хәмдүнә назланмаска мәҗбүр булды. Сөмбел хакына дип юатырга тырышты ул үз-үзен. Акланыр ният белән рәшәгә таянмакчы иде. Төрмәгә утырмыйча калды, шуның нәтиҗәсе буларак, дөньяга Гөлгенә туды. Ни хикмәт, Таңчулпан кешеләре арасыннан Хәмдүнәнең йөзенә бәреп авыр сүз әйтүче булмады. Җанының өзлексез дер калтыраганы көннәрдән бер көнне Фәррахның исән-сау кайтып килү ихтималы иде.

Чыннан да, зилзилә никахлы ире демобилизацияләнеп кайткач купты. Ярты Европаны диярлек җәяү гизеп кайткан фронтовикның Сөмбел күтәреп йөргән бәбинең кем баласы булуы белән кызыксынган минутыннан дөнья җимерелде, җир убылды...

Фәррах Таңчулпаннан башын алып китте. Яше чыкмаган иде әле, ветеринария институтына укырга керде. Студент елларында, йөрәгенә чыдаша алмыйча, төнге поезд белән кайткалап, инде янә гади агроном булып эшләүче Хәмдүнәнең тәрәз төпләрендә йөрде. Ишек шакыйм дип батырайган минутлары да булды. Тик, хатыны кочагында изрәп йоклаучы Гөлгенә дигән кызчык күз алдына килүгә, кире тимер юл разъездына йөгерә иде.

Институт дипломы алгач, чәнчелсен бөтен дөньясы, дигәндәй, Хәмдүнә янына кайтты да, бергә булыйк, диде, бүтән районга күчеп китәргә кирәген әйтте. Хәмдүнә исә күңел эчкәресенең әллә кайсы почмагы белән сизенә иде: барып чыкмаячак уртак тормыш! Фәррах гафу итә алмаячак. Итә алмаячак,

чөнки яшьлегендә бик-бик яратты ул Хәмдүнәне. Ирмен дигән ир-егет хатынын ятка бирмәс. Горур сабый да үз курчагын бүтәнгә тоттырмый. Ә Хәмдүнә, изаланып-жирәнеп булса да, бүтән кулыннан үтте...

Бәла ялгыз йөрми. Бәхетсезлек чылбыр-чылбыр. Тормыш Хәмдүнәгә Фәррахтан нык сагаердай, гомере калтырап-куркып яшәрлек тагын бер фажига китергән иде: мәктәпкә керәсе елны Сөмбел язгы ташу вакытында Зөядә батып үлде. Хәмдүнәне ире белән азмы-күпме бәйләп торуы мөмкин булган жеп тә өзелде. Ялгыз хатын пәрәвез ефәгедәй генә өметен дә саклый алмады.

Шул рәвешчә, Хәмдүнә Фәррахны үзе читкә тибәрде булып чыкты. Ветврач, бер-ике ел күрше районда эшләп йөрде дә, чирәм жирләр күтәрү башлангач, сукырлар мәхәлләсенә күзге сатып дигәндәй, яшәүдән гарык булып, казах даласына китеп барды.

Еллар үтә торды. Гөлгенә, исәя барган саен, әтисенең кемлеген һәм аның ни сәбәпле үзләре белән түгеллеген белергә теләп, Хәмдүнә йөрәгенә утлы күмер булып коелган сорауларны өзмәде дә куймады. Хәмдүнәнең ана дөресен сөйләүдән гайре чарасы юк иде. Кыз бала ана бәгырьле була, диләр. Гөлгенә әнисен аңламадымы, аңларга теләмәдеме, әллә сабый чагында яшьтәшләренең «Зина алмасы» дип битәрләүләре күңелен таш иткән идеме, буй житүгә, Хәмдүнәдән йөз чөерде. Бу хәл ананың үзеген беренче кызы фажигасеннән дә битәр өзгәләде...

Больница палатасы тып-тын. Ак тынлык. Монда һәрнәрсә ак бит: урын-жир, стена, түшәм, тәрәзә яңаклары... Хәмдүнәнең истәлекләре генә табигатьнең ямьсез төсенә буялган. Кара елларга барып тоташкан хатирәләр шул алар...

*1988*

***

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

Исән булса, Барлас Хәмит улы Камаловка 17 январьда 80 яшь тулган булыр иде. Проза һәм публицистика жанрында актив эшләүче язучыларыбызның берсе булган Барлас ага моннан алты ел элек арабыздан китте. Үзеннән соң матур-матур әсәрләр калдырды. Аның «Йөрәк давыллары», «Ярсөяр әрәмәсе» исемле повесть һәм хикәяләр җыентыклары, «Өметең өзелмәсен», «Җир күчәре» романнары, «Мирхәйдәр Фәйзи» повесте укучыларга яхшы таныш.



Камил
Кәримов

# КҮРШЕ АВЫЛ КЫЗЫ

БӘЯН

Безнең әни күрше авылда туган, ә без, әтием белән, шушында—Арышлыда. Үзем дә аптыраган инде бу хәлгә... Туган авыл турында җыр ишетсәк, әнием Камышлыны мактый башлый, ә әтием белән без—Арышлыны. Шуннан, мин сиңа әйтим, кызып китә бәхәс: безнең авылда тегесе матур да монысы шәп, тегесе чибәр дә монысы көчле! Түзеп тыңлап кына тор... Әти белән икәүләшеп яклый торгач, Арышлы өскә чыга һәм шулчак әниемнең керфек очында «чык бөртеге» җемелди башлый. Әти белән без күзгә-күз карашып алабыз да тиз генә әниләр авылын мактый башлыйбыз. Теге «чык бөртеге» шундук юкка чыга.

Әле ярый Арышлыда туганмын... Ул чаңгы шуам дисәң—көн саен берәр тау алыштырсаң да кышкы каникулыңа җитәрлек. Сәяхәткә чыгам дисәң—нарат урманыбыз компассыз ерып чыкмалы түгел. Җиләкле аланнарыбыз да кеше саен берәү. Мишә елгасын әйткән дә юк—ул әүвәл безнең Арышлыга килеп керә. Нинди эш кушарсыз икән дигәндәй киң җәелеп тукталып тора да, аннары гына Камышлыга юнәлә. Бик теләсәк, буалап та куя алабыз... Ярар инде, әйдә, без алай саранннар түгел, аксын күршеләргә, коенсыннар малайлары... Әти әйтә, без малай чакта сөйли торганнарые, элек Мишә елгасын әллә ничә төшеннән буалап куя торган булганнар, ди. Мишәне тегермән ташларын әйләндерергә күндергәннәр... Ә хәзер авыл тегермәннәре Чулман-батырдан килгән электрга әйләнә. Мишә елгасы, җигелүдән өреккән тай кебек, элеккеге буа урыннарын әйләнеп, йөгереп кенә үтеп китә.

Арышлы белән Камышлы арасында элгәре кара урман шаулап үскән дип сөйлиләр. Хәзер юк инде ул—киселеп беткән. Ике арада чакрымлы иген кыры гына җәелеп ята. Кыл бер уртада колхозларның чиген аерып торучы межа—коры елга да бар.

---

Камил КӘРИМОВ (1950)—*прозаик; дистәләгән китап, шул исәптән «Ком сәгате» һәм «Сакау кукe» романнары авторы. Казанда яши.*

Хәзер Камышлыда әнинең ерак апасы гына исән, башка туганнарыбыз юк. Анын белән бик сирәк күрешәбез. Бәләкәйрәк чагымда мине дә алып баралар иде. Хәзер, берәр йомышлары төшсә, мин урамда уйнап калам, әти белән әни ат жигеп Камышлыдан көнендә әйләнеп кайта.

Әниең күрше авылныкы булса шунысы кыен—кичләрен ерак апаны сагынудан бушамыйбыз.

—Әни, әни дим, син ничек Арышлыга күчеп килдең соң?

Әни өчен әти жавап бирә.

—Сина ничә яшь әле, Зөфәр улым?

—Ундүрт икәнне беләсең ич инде...

—Вәт. Нәкъ унбиш ел элек әниең безнең авылга утырмага килгәли иде.

—Ә хәзер ник килмиләр?

—Утырмагамы? Элеккеге йолалар беткәнгә... Әллә, улым, кунак кыз күрәсең киләме?

—Белмәгән кешеләрне күрәсе килә димени?! Болай гына сорашуым.

—Ярар, сине ачуланган кеше юк, тел яшереп маташма. Әйт дөресен... Кунак кызлар алар үз авылың кызларына караганда назлырак тоелалар, чынлыкта исә...

Әтинең сүзен бүлеп әни кушылды:

—Йә, йә, чынлыкта нинди ләр?

—Ягымлылар, эшчәннәр, сөйкемлеләр...—дип, әллә ничә купшы сүз тезеп китә әти.

Әни елмаюын ничек яшерергә белмичә, чәчен төзәткәли дә кулына ак чиләк тотып сыер саварга чыгып китә. Чыгып барышлый, жинен сыпырган булып кына, ишек катындагы биек көзге янында тукталып ала...

Ул сыер сауган арада тизрәк әтине сөйләндерәсе иде.

—Әти, ник мине Камышлыга алып бармыйсыз?

—Кунак кызлар сайларгамы? Жәйгә чыккач инде...

—Озак көтәсе икән әле...

—Ә син хат яза тор, кыш үткәнне сизми дә калырсың.

—Кемгә? Кемгә языйм?

—Камышлыда бер кыз бар, Гөлназ исемле.

—Гөлназ... Исеме бик матур.

—Исеме дә, үзе дә. Синең кебек ул да жиденче класста укый.

—Чәче нинди?

—Матур.

—Ә күзләре? Сөйләшүе?

—Матур инде, матур. Жәйгә чыккач үзең күрерсең. Ә хәзер утыр да хат яз. Ике-өч көннән жавап килеп житәр, менә әйткән иде диярсең.

Ышанырга да, ышанмаска да белмим. Ышанир идең, әллә ничек, бер дә белмәгән кызга нәрсә дип кенә хат язмак кирәк? Ышанмас идең—әти белән сөйләшкәннән соң башыма уй килде... Яшьтәшләремнең күбесе кем белән дә булса хат алыша. Партадашым Мөдәррискә әнә Әнисә исемле кыздан хат явып кына тора.

Мөдәррис белән ныгытып киңәшкәч, көн саен, укудан кайтып аннан-моннан гына чаңгы шуып керәм дә хат язарга утырам. Ун көн дигәндә язып бетердем. Күбрәк тә язылды бугай—дәфтәр битенең бер ягы тулды. Конвертка салдым, адресын яздым. Яна ел үткәнче генә жибәрми торам, хат ташучы апаларга бәйрәм арасында болай да эш күптер, каникул озын әле, өлгерермен.

Без, малайлар, каникулга бик тиз күнегәбез. Кыш көне өй тирәсендә әллә ни эш тә кушмыйлар. Итеккә чаңгы бәйләп иске елдан Яңа елга шуып кердек. Инде гыйнварның дүртенче көненә дә чаңгы эзе төште.

Кичкырын мич тутырып утын керттем, тимер чанага салып бер калай мичкә су да алып кайткач, урамга чыгып сыздым. Чаңгы шуган булам, ә үзем почта тартмасы тирәсеннән ары китә алмыйм. Куен кесәмдәге хатны бөгәрләмәскә тырышып, үрә катып кына йөрим. Нәрсәгә дип авыл уртасындагы кибет бурасына кагып куйганнардыр шул тартманы?! Монда кеше бетәмени, җибәрәсе һәр хатны башкаларга күрсәтеп салырга димәгән лә. Баксана, атлысы да килеп туктый, тракторлысы да сугыла, өчәрләп тә киләләр, ялгыз гына йөрүчеләр дә бар. Гел кибет тирәсендә таптануымнан шикләнепме, узган-барган этләр өреп китә, чаңгы таягымнан да курыкмыйлар. Китим әле, кибет ябылганчы авыл очын айкап килим.

Яңа ел бураннарыннан соң көн тәмам юашланган, әгәр кышкы каникул икәнен белмәсәм, яз көне дип ялгыш гөрләвек эзләп йөрүем бар. Урамдагы рәхәтлек—туйгысыз.

Мөдәррис күрсә күрер, ул минем Гөлназга хат җибәрергә тиешлекне болай да белә, тик башка малайлар күзенә чалынмаска иде. Мөдәррис Камышлының Әнисә исемле кызы белән ел буе хат алышты. Ә минем мактанырлыгым юк әле.

Авыл капкасыннан чыгып киттем. Авыл очында кар тип-тигез, куна тактасына җәелгән шикелле. Сизелер-сизелмәс кенә ат эзе беленеп тора. Камышлылар безгә килде микән, безнекеләр анда киткәнме? Ат эзендә чаңгы шумыйлар, Мишә яры буйлап барып карыйм. «Коры елга»ны юл уртасы диләр. Кибет ябылганчы шул араны урап кайтыйм.

Баштарак икеләнеп кенә атладым, аннан кызулаттым. Шушындый яңа кичтә Гөлназ да өйдә утырмас әле. Әгәр ул да «Коры елга»га чаклы шуып килсә? И кызык булыр иде дә соң! Кырда берәр таныш түгел кыз очраса, исемен сораштырасы булыр...

Кибет янындагы зәңгәр тартмага салгач, минем хатны үзебезнең район үзәгенә алып китәрләр инде. Аннан Казанга. Казаннан Гөлназлар районына. Камышлыга, Гөлназ кулына илтеп тапшырып, җавап әйләнеп кайтканчы ничә көн көтәргә кирәк икән?! Әгәр Камышлының һәр кызы, һәр егете безнең авылныкылар белән хат алыша башласа, ә?! Ул чагында ике арага махсус хат ташучы да билгеләрләр иде.

Дәфтәр битенең читендәге калын сызык кебек итеп Мишә ярына чаңгы эзе салып барам. Башка эзләр күренми. Әнә, боз өстендәге нәфис карда куян белән төлке әбәкле уйнап йөргәннәр. Эләктерә алмагандыр. Төлке—кыска торык, озак куалмый, тиз алҗый. Ә менә куян үзе шәп йөгерә, төлкене ике сикерүдә тота алыр иде ул, куркаклыгы гына ирек бирми.

«Коры елга»га килеп җиткәндә караңгы төшеп бетмәгән иде әле. Чаңгы таягына таяндым да уйга калдым. Кире кайтырга кирәк, кайтасы килми. Бераз гына көтеп торсам, Гөлназ килеп җитәр кебек. Караңгыга калмасын иде инде, кайтырга куркыр. Аны озатып куярга да туры килер әле. Хәер, алайга китсә, озатып куябыз ла... Ундүрт яшьлек малайга... егеткә җиде чакрым ара ни торган? Әллә тагын бераз атлыйм микән?

«Коры елга» кар белән күмелгән, язгы ташу мул булыр әле быел. Мишә дә котырып-котырып агар, Гөлназларның бөтен чишмәләрен су басар. Самавыр куярга су эзләп, тилмереп безнең авылга килеп җитәр.

Элеккеге кара урманнан истәлек булып калган әрәмәлекне дә үткәч, тукталып тормадым инде. Нибарысы биш чакрымлап юл калгандыр... Әйләнеп кайтыйм. Гөлназга атап язган хатны үз кулым белән тапшырыйм. Җавап язганын көтеп тормасам да, ризалыгын белеп китәрмен.

Чаңгыларны тыяр хәл юк, үзләре чаба. Үтелгән юлны адымлап санап торгандай, берәм-берәм йолдызлар кабына. Ә инде Камышлы уртасындагы багана башына эленгән радиодан аермачык итеп мәхәббәт турында яңа җыр яңгыраганда аяк астындагы ап-ак кар, караңгылык белән кушылып, язу карасы төсенә кергән иде.

Ерак апаның өен хәтерлим, туп-туры шунда юл тоттым. Капка төпләренә килеп җиткәч тә чаңгыны салырга ашыкмадым. Бәлки кереп тормаскадыр? Гөлназлар өен табам, чакырып кына хатны тапшырам да кайтып китәм... Килешеп бетмәс шул, ерак апаның хәлен белешмәсәм, әти-әнигә ни дип җавап бирермен?

Ерак апа мине күргәч сөенечтән бигрәк куркып калды:

—Нәрсә булды, утка төшкәнсең?

—Чаңгыда килдем, эсселәтте бераз.

—Берәр хәл бармы әллә? Төнгә каршы, үзең генә...

—Исәнлегеңне белеп кайтыйм дидем.

—Яшермә, яшермә, ялгызыңны гына җибәрмәсләрие. Әллә әниеңә улбу булдымы?..

Һәм ерак апа минем җавапны ишеткәнче үк елап та җибәрде. Тәки дөресен сөйләп бирергә туры килде. Ерак апам бик сөенде, мине көлә-көлә тыңлады. Аннан мамык шәлгә уралды да:

—Утырып тор, хәзер Гөлназны чакырып киләм,—диде.

—Юк инде, мин дә урамга чыгам. Өйдә сөйләшә торган сүз түгел. Син аңа әйт, мин Мишә ярында көтеп торам.

Мин Гөлназны көткән арада җиде җирдә эт өрде, ике кешенең аты кешнәде, ундүрт капка ябылды, ике машина кычкыртты, бер самолет очып үтте, ике йолдыз атылды... Ерак апа әйтергә оныткандыр, ахрысы, дип кире борылган гына идем, аяк тавышына туктап калдым. Кар шыгырдый, алай нык түгел, куян кишер кимергәндә чыккан тавыш хәтле генә. Гөлназ каршыма килеп бассын да авыл ягыннан җемелдәгән утлар йөзен яктыртсын дип, аның килүен сизмәмешкә сабышып Мишәгә карап торам.

—Әллә Мишәгә ташу төшкәнме?

Һи, бу күрше авыл дигәнеңнең кызлары, сәламләшүләре дә безнеңчә түгел икән!

—Арышлыда яз җитмәгән әле. Мишә бездән агып килә бит сезгә.

—Боз каплагач, елганың кая таба акканын кем белгән инде?

Тавышы да тавышы Гөлназның, магнитофонга яздырып иртә-кич җыр итеп тыңларлык. Төне караңгы шул, кызның йөзен күреп булмый. Тавышына караганда бик чибәрдер бу...

—Гөлназ исемле кыз синме инде ул, таныш булыйк.

—Мин шул, ник чакырдың?

Каушады бугай, исемемне сорарга да онытты.

—Хат китердем.

—Моңарчы хатларны өйгә китерә торганнар иде. Мишә буена чакырып почта таратмыйлар. Сәер почтальон икәнсең син.

Ну, шушы күрше авыл кызларының кыстымлыгы...

—Үзем яздым, үзем тапшырам.

—Мине каян белдең соң син? Күрешкәнебез дә юк шикелле.

—Әти әйтте.

Шундый итеп кычкырып көлде Гөлназ, тавышын тыңларга бөтен Камышлы халкы җыела икән дип торам.

—Хатны да әтиең әйтеп торып яздырдымы? Кызык икән: әтисе мактагач, малае дә ошаткан. Әтиеңә ошар да бит...

—Әти малае ла мин!

—Укы, кычкырып укы хатыңны.

Йолдыз яктысында хатлар укып йөргән юк әле, анысы. Бездә дә горурлык бар. Хатны кесәдән чыгармыйча гына сөйләп бирәм. Ун көн буе яза торгач, яттан беләм инде мин аны.

—...Исәнме, Гөлназ.

—Аллага шөкер,—дип бүлдерде ул мине.

—...Исәнме, Гөлназ. Бу хатны Арыш авылыннан...

—Болары хат саен языла торган сүзләр. Син кызыграк төшен укы.

—Кызыгы шул: мин синең белән хат алышырга телим, җавап язасыңмы?

—Ун хатыңа бер җавап җитәме?

—Юк. Бергә—бер!

—О-һо! Ә син яхшы укыйсыңмы соң? Үскәч кем булырга телисең?

Әнә Кибәч малае беренче класстан бирле гел отличник иде, ә Аппакай авылындагысы үскәч космонавт булырга җыена... Аларга да хат саен җавап тәтеми әле.

—Мин анысы космонавт булырга җыенмыйм, укуда да иң алдынгылардан түгел... Ләкин җавап мәсьәләсендә—бергә—бер!

—Ярый. Өч хатыңа бер җавап—ризамы шуңа? Ялындырма, горур булганың өчен генә чигенәм. Юкса сөйләшеп тә тормас идем.

—Бергә—бер!—дидем мин, базардагы үҗәт агайлар төсле.—Кешечә юньләп хат алышырга теләмәсәң, хуш, ашыгам.

Гөлназны аптырашта калдырырлык тагын нинди сүз әйтергә микән дип уйлап тордым да кырт кистердем:

—Вакыт юк, клуб ябылганчы Арышлыга кайтып җитәсем бар. Исемем Зөфәр иде минем.

—Ярар...

Бу сүзләрдән соң җәһәт кенә китеп бармыйча ярамый иде инде миңа. Ә Гөлназ Мишә буенда, нәкъ минем урында, боз өстенә карап басып калды. Тизрәк, тизрәк, авылга, авылга! Куен кесәмдәге хат тәнне пешерә.

Ичмасам ерак апа чаңгыларымны яшереп куйган. Шаярып торыр чакмы?

—Төнгә каршы чыгарып җибәрергә, әллә син мине?!

—Бүген кайтып җитмәсәм өйдәгеләр ни уйлар? Чаңгы шуарга чыккан җирдән генә югалдым бит.

—Хәзер, әтиең ат белән килеп алам диде. Телефоннан чакыртып сөйләштем...

Әти нинди җәза бирсә, шуңа риза идем мин бүген. Тик ул орышмады, усал итеп карамады, хәтта колакны да бормады. Эндәшмәде генә. Сөйләшсен иде ул. Бу минутта иң зур җәза тынлык икән... Тояк дөпелдәве, коры карны чыелдатып чана табаны елавы, йөрәгем тибешенә кушылып, гарьләнүемне арттыра сыман.

—Гөлназ чибәрме соң?

—Караңгы иде... Әллә ни күрмәдем. Тик, кыланышларына караганда, бик чибәр, ахрысы.

Тапшырылмаган килеш кесәдә йөрмәсен дип, хатны ерткаладым да безгә каршы йөгергән җәяүле буранга бирдем. Бәлки, кайбер сүзләрен генә булса да Гөлназга илтеп җиткерер әле ул...

Башка мәктәпләрдә ничектер, ә менә Арышлыда җәй җитте исә өч кыңгыраулы электр звоногына күчәләр. Кышкы тәнәфесләр булса, безне урамнан дәрескә чакырыр өчен көтү башлыгында

йөрүче кәҗәләрнең муенына бәйли торган уймак хәтле кыңгырау зыңлавы да бик житә.

Календарь буенча санаганда яз дип аталса да җәй иде инде бу! Ялындырмыйча, икеләнмичә, ышандырып килә быелгы җәй. Көннәр гел аяз. Кояш безне мәктәпкә кадәр илтеп куя, дәресләр беткәнче көтеп тора. Өйгә кайтып уйнарга чыккач та житә әле кояшлы көн. Дәресләрдә утыруы кыенрак хәзер. Форточкадан җил килеп керсә, барыбыз да бер булып урам ягына борылып карыйбыз. Кыш буе безнең класс тәрәзәсен чәбәкләгән өрәнге чыбыкларына конгырт күбәләкләр килеп кунды диярсең. Бер карасаң, тәрәзәдән тиз генә аерылам димә, урамдагы ыгы-зыгыны да күзәтеп өлгерәсең. Кышкы авыр киемнәрдән котылган авыл халкы, җинеллеккә күнегә алмыйча, гел йөгереп кенә йөри шикелле. Без дә котылдык ул авыр якалы,калын түшәүле пәлтәләрдән, безнең дә ишегалдындагы җылы җир өстендә йөгерәсе килә. Шуна күрә тәнәфескә чыгар алдыннан кыңгырау тавышын шылтыраганчы ук ишетеп алабыз. Ә бер чыксак.. безне чакыра-чакыра мескен звонокның өч кыңгыравы да хәлдән тая...

Ниһаять, дәрескә җыйналдык. Кояш яктысына күнегеп житкәч кенә тагын кысан бүлмәгә кереп ябылдык. Күз алды караңгыланып киткәндәй тоелды.

Күз ияләшкәч кенә, безне әллә кайчаннан бирле көтеп утырган укытучыны күреп алабыз, парталарда буш урыннар да сизелә... Нәрсә бу? Парта өстендә—чәчәкле ак конверт. Хат булырга тиеш: ике төшендә почта пичәте. Мин, дәфтәр актарганга сабышып, Мөдәррискә сиздермичә генә адресын укыдым. Конвертта: «Арышлы урта мәктәбе, 7 «А» классының унберенче укучысына», диелгән. Журналдагы унберенче кеше—мин, димәк, хат дөрестән дә мина тиешле. Ниһаять, мина да хат килде! Әни әйтмешли: кышка төшсәң, яз үзе килә ул!

—Адресын укып бетер,—ди партадашым Мөдәррис, ниндидер астыртын мәгънә белән,—бәлки кире җибәрерсең.

Хат Камышлы авылыннан икәнлекне белгәч, кинәт кенә әйтеп бетергесез комарлану хисе биләп алды үземне. Гөлназдан! Нинди зур сөенеч! Җәяүле буран ана минем хат кисәкләрен илтеп тапшырган! Әлбәттә, озаграк илткән, биш ай вакыт үтте бит инде... Хәер, ул очрашудан бирле күпме кар, күпме яңгыр яуды. Хат кисәкләреннән төссез кәгазь таплары гына калгандыр. Бу хатны Гөлназ үз теләге белән язган. Язган, ләкин ник Зөфәргә дип, атап җибәрмәгән? Ул бит әле класс журналындагы исемлектә минем исемнен ничәнче кеше икәнемне белми. Бәлки, хат очраклы рәвештә генә мина килеп эләккәндер? Хәер, белмәссең, кызлар алар, горурлыкларына сүз тидертмәс өчен, теләсә нинди мажаралар да уйлап чыгара ала...

—Ярар инде, икеләнмә. Мондый хатларны башка укучыга тапшырсаң да ярый. Кире җибәрүчеләр дә бар. Тик менә класста гына келәрләр... Әгәр кулыңнан килмәсә, икәүләшеп язарбыз. Минем тәҗрибәм житәрлек...

—Хат минамы, мина! Җавабын да үзем язармын. Һәм мин Гөлназ хатын дәфтәр арасына шудырдым.

Башкаларга сиздерергә ярамый дисәләр, гомер буе түзеп, сер саклый алам, әмма зарыгып көтеп алган хат килсә, укымыйча көтүләре бигрәк кыен икән. Укытучы аңлатасы дәрес тә, такта янына чыгып сөйлисе сүзләрем дә, өйгә бирелгән эш тә—барысы, барысы шушы конверт эчендә диярсең. Тизрәк тәнәфес житсә иде!

Мөдәрриснең кабыргама төрткәләвен сизми торам икән. Ул чеметеп алгач кына сискәнеп, уянгандай булдым. Ачуланырга иде исәп, өлгермәдем—кулыма кәгазь кисәге тоттырды. Кисәк дип, элеккеге солдат хатлары сыман өчпочмаклап бөкләнгән дәфтәр бите иде ул.

—Монысы Ләйсәнәдән!—диде Мөдәррис. Пышылдап эндәшкән була, мәхәббәт хаты диярсең.

Мин капылт кына Ләйсәнәгә таба борылдым, ул бездән ике генә парта арттарак утыра. Мине күрмәмешкә сабыша, беләм инде, сабыша гына! Мине күргәнлеген күреп торам ла. Менә сиңа ике хат. Юк чагында берсе дә юк иде, ә бүген ике хат! Хәер, Ләйсәнә язган хатны хәзер үк ачып укыйм, ә Гөлназдан килгәне торып торсын.

«Зөфәр!

Миңа да бер малайдан хат килде. Әйдә, адресларны алышабыз. Син бу малайга яз, ә мин... Гөлназга.

Ләйсәнә».

Кызык икән, миңа хат килгәнне, хәтта кемнән икәнлеген дә белеп өлгергән бит, ачу китергеч! Дәфтәр битен шатырдатып ертып алдым да җавап җибәрдем:

«Малай кеше белән хат алышып торырга әллә мине исәр дип белдеңме?!»

Мин бакчабызның куе карлыганнары арасында. Бөре сүрүеннән ташып чыккан яшел тамчылар һәм канат ярган нәни, сусыл яфраклар сарып алган ботаклардан гайре берни дә күренми.

Беренче... Беренче хат... Конвертны ертмаска тырышып кына, ябышкан җиренә өрә-өрә куптарам. Хатның кызлар кулы белән язылганы әллә кайдан күренеп тора: хәрефләре вак, тигез—жепкә тезелгән сәйлән төсле. Җиңелчә генә ислемай исе дә килә бугай (әллә кызлар хаты булганга күрә генә шулай тоеламы?).

«Исәнме, таныш булмаган дустым...

Сиңа пионер сәламе белән хат язучы Гөлназ дип белерсең...»

Хат бик кыска тоелды. Кат-кат укыдым. Аңламаганнан түгел, укып туйгысыз. Гөлназ рәсемемне сораган, үзе дә җибәрермен дигән.

Хатның дәвамын күк йөзеннән эзләдем бугай... Кояшның утлы нурларыннан кайнап чыккан яңгыр болытлары җитәкләшеп авыл өстенә җыела. Җир яңгыр көтә. Яңгырдан соң җәй башланыр. Җәйне яратам мин. Тынгысыз җәй, бәлки шуңа якындыр. Кошлар сайрый, елгалар ярсый, күк күкри, трактор-машиналар гөрли, басуларда икмәк шавы—барысы бергә җәй авазы. Җәй төсләргә дә иң бае: салават нурлары, төсле болытлар, чәчәкләр бәйләме, яшел урман, яшен яктысы.

Бәрәңге бакчаларыбызга терәлеп үк иген кыры җәелеп үскәч, Арышлы исеме авылыбызга килешеп тора. Һава юлы да якын гына безгә. Арышлы өстеннән очканда самолетлар канатларын чайкый, ай-һай матур авыл икән бу дип соклануларыдыр инде...

Җавап яздым язуын, тик хәзер көн саен диярлек берәр сорау туа тора. Иртүк торам, абзар тазартам, мәктәпкә китәм, кешечә укыйм, өйгә кайткач дәрес әзерләргә, урамда уйнарга да өлгерәм. Вакытында ятып йоклыйм, төннәрен әйләнеп-тулганып интекмим, ничек яткан—иртүк шулай уянам. Уйланып вакыт әрәм итәргә ара калмый сыман... Ә уй дигәнең көннең-төннең теләсә кайсы вакытында башка килә дә керә. Уй түгел, сораулар дидем... Менә хәзер дә химия дәресе бара, укытучы миннән өйгә бирелгән эшне сорыйсы урында мин үземнән-үзем сорау алып утырам.

Гөлназ үзенең хаты минем кулга барып керәсен алдан ук белгәнме? Бу бик мөһим сорау. Әгәр хат унберенче укучыга, ягъни Зөфәр «абзагызга» ялгыш кына эләккән булса?.. Ул чагында Гөлназ җавап язмаячак, без аның белән дуслашып-татулашып өлгермәдек. Белеп язуы хак дисәң, ник соң ул теге кышкы төндә ялындырып, кәнфитләнеп маташты: имеш, аңа бик күпләр хат яза, имеш, ул ун хатка бер генә җавап салачак. Ай-һай,

бу күрше авыл кызлары, ну характер үзләрендә... Анламассың! Хат алышу мәсьәләсендә Мөдәрриснең тәҗрибәсе җитәрлек. Пышылдашып кинәшергә туры килә.

—Карале, безнең класстан тагын берәр кеше Камышлы белән хат алышамы?

—Синнән башка тагын мин генә инде. Әнисә Камышлыныкы ич.

—Ниме... аның синнән безнең журнал исемлеген сорап язганы юкмы?

—Язгы каникулга чыгар алдыннан сораганые.

—Җибәрдеңме, Мөдәррис?

—«Өлгергәнлек экраны»ннан күчереп алдым да җибәрдем. Андагы исемлек журналдагыча. Ник сорыйсың, әллә хата киткәнме?

—Юк, киресенчә, бик төгәл күчергәнсен, рәхмәт әле сиңа.

—Нәрсә өчен?

—Әнисәң белән Гөлназ бер класста укыйлар, менә шуны ачыкларга булышканың өчен...

Ярый, дәрес вакытында артыгын сөйләшеп торырга, без алай ук тәртипсезләр рәтендә түгел... Гөлназдан җавап хаты киләчәге билгеле инде хәзер. Ләкин сизмәгәнгә сабышыйм, теге җилгә очкан хат турында исенә төшермим, бик кирәксә, үзе искәрер әле...

Бу арада мәктәптә җыелышлар күбәйде. Безне түгел, укытучыларны җыялар. Нишлиләрдер анда, дигән идем, Мөдәррис әйтә, гәҗит укыйлар, ди. Ялган сөйләсә ояты үзенә булсын, тик ни хикмәттер, дәресләр башланыр алдыннан атнага бер үткәрелә торган сәяси әңгәмәләр дә озаеп китте. Халыкара хәлләр турында сөйләп кенә калмыйлар, киләчәктә мәктәбебездә хезмәт дәресләре күбәячәк, техника серләрен, электрон-хисаплау машиналарын өйрәнү булачак, төрле түгәрәкләр эшли башлаячак дип сөйлиләр. Боларын Мөдәррис түгел, укытучыларыбыз сөйли, димәк, буш хыял гына түгел. Әгәр сүзләре рас килсә, мин фототүгәрәккә язылыр идем. Юкса фото кирәккә тәмам аптыраш.

Альбомнан күпме генә эзләсәм дә, Гөлназга җибәрерлек рәсем таба алмадым. Районга барып килсәң, кулыңа әзер фото алганчы атналап вакыт үтә. Алай озакларга ярамый, беренче булып мин җибәрергә тиеш ул фотоны, Гөлназ да озакка сузмас. Их, көпә-көндез күрәсем килә шул кызны, үзгәрде микән? Хәер, мин аны юньләп хәтерләмим дә инде, матур кыз икәнлеген генә беләм. Яктыга чыгып, күзгә-күз карашып сөйләшеп утырганың булмагач...

Безнең авылда фотога төшерүче бер генә кеше бар—«Бабай» Мөхәммәт ул. Кулыннан килмәгән эше юк. Радио да ясый белә, җилдән ут ала. Аның кулы тисә еллар буе күгәреп яткан тимер-томырга да җан керә дип сөйлиләр. Матаен күрсәгез—керосинда эшли: алгы тәгәрмәче зур, арткысы бәләкәй генә. Барганда гел тауга менәдер төсле. Билемә шулай җайлырак дип әйтеп әйтә ди. Җитмеш төрле һөнәр иясе инде, әйтәм ич, авылга бер белдекле кеше. «Бабай» кушаматы яшьтән үк күпне белгәнгә, көч җитмәстәйне майтара алганына күрә такканнар. Хәер, ул үзе дә шундый ук олы яшьтә инде, мина бабай тиешле. Ләкин без ана Мөхәммәт бабай дип дәшә алмыйбыз, чөнки беләсез инде—кушаматы «Бабай». Бабай дип әйткәнне яратмый торгандыр—сакал йөртми. Яшьтәш картларының ияк астына кыраулы чирәм шикелле сакал сарган булыр. Ә Мөхәммәт егетләрчә көн саен кырынып йөри. Кара-каршы туры килгәндә күрешмичә генә үтмибез, абзый да, агай-бабай да димибез: «Исәнме, Мөхәммәт!» дибез. Ә ул елмая...

Өй саен ике-өч альбом бар хәзер, альбом саен иллеләп фото, аларның

барысын диярлек «Бабай» Мөхәммәт эшләгән. Йөз капкалы Арышлыга шактый җыела әле ул!.. Шуңа күрә, кайчан килмә—гел эш өстендә, ял иткәнен күрмәссең. ...Мин аның төшке ашка әзерләнеп йөргән чагына туры килдем. Ул бил тиңентен чишенгән килеш ләгән уртасындагы сулы комганга карап тора. Аңлашыла инде, су салып торырга кеше юк. Өйдәгеләре онытканнар димме, әллә хатыны йорт мәшәкатьләреннән бушап өлгермиме?

Мин аның кин-таза җилкәсенә су койдым. Мөхәммәтнең улакланып эчкә баткан умырткасы буйлап җылы су ага. Әле май аенын уртасына гына життек, ә ул инде аркасын кояшта каралтып өлгергән, баштарак мин аны тузан дип торам... Кара сана, күрешергә дә онытканмын ич!

—Исәнме, Мөхәммәт?

Елмайгандырмы, юкмы, йөзе күренми, чөнки бөгелеп башын аска игән.

—Куштанланам дисең инде...

—Алай ук түгел лә.

—Йә, йә... Күлмәгенә су чәчрәтмә, рәсемдә эзе кала.

—Каян белдең, Мөхәммәт?

—Бакча парланган чак, тотылмаган унлык төсле яна күлмәк киеп килгәнсең. Аннан соң, безгә үз кирәге белән йөрүчеләр генә керә.

—Фото кирәк иде шул, хет берне генә...

—Әйтәм ич, безгә «мә» дип кергән кеше юк.

—Мөхәммәт, мин бушлай түгел...

—Дисеңме,—дип ялгап китте Мөхәммәт.—Ниятең изге икән ләбаса. Хәзер, кечтек кенә сабыр итсәң, берне түгел, унны алырсың. Килештекме?! Бар, фотобүлмәгә керә тор!

—Ә сине өйдәгеләр ашарга көтәме?

—Борчылма, чәчең агарыр, фотода беленер. Өстәлдәге аш качмый ул.

Мөхәммәтнең «фотобүлмә» дигәне тар гына караңгы чолан икән. Мин озын эскәмиянең кыл уртасына килеп утырырга күзгә төбәлгән лампа кабынды. Торып карадым—лампа сүнде. Кешеләрне «электр урындыгына» утыртмасаң, «Бабай» кушаматың харам булыр шул... Мөхәммәт өч аяклы фотокамера тирәсендә чуалган арада, утырган килеш кенә бүлмәне күзәтергә дә онытмадым. Жыйнак кына ике өстәл, аяклары шыксыз биек—аяк өсте генә эшләргә җайлангандыр, күрәсең. Өстәлләрнең берсендә кызыл тәрәзәле фанер тартма, икенчесендә—сай табаклар. Бүлмә стенасы фоторәсемнәр белән капланган. Кемнәр генә юк анда: йөзләре таныш сыман, үзләре генә сәеррәк—миңа абый һәм апа тиешле бик күпләрнең балачакта ук төшкән рәсемнәре бугай алар.

—Туры утыр, менә монда кара!—диде Мөхәммәт, объектив янына ябыштырылган бер сумлыкка имән бармагы белән төртеп.

Мин капылт кына кесә төбемне капшап алдым.

—Тик утыр дим, кырмыскалы! Сурәтең ике катлы чыга бит... Күзенне тик тот, көмеш тәңкә шикелле ялык-йолык итмә... Аска да карама, йомык булып чыга.

Теге бер сумлыкка текәлеп эскәмиягә ябыштым.

—Чәченне сыпыр, кызың «шалапай малай икән бу» димәсен. Кулларыңны җибәр, егылмассың. Вәт. Бер, ике... һоп!.. Авыртмадымы?.. Иртәгәләргә кереп чыгарсың.

Авыр биштәреннән котылган юлаучыдай тирән суладым да, күз ияләшкәч тагын бүлмәдәге рәсемнәрне карарга булдым. Дөресрәге, шул рәсемнәр арасыннан әтием белән әниемнең яшь чакларын эзлим. Тик, әлеге бер сумлыкка ут аша озак итеп карагангамы, бүлмәдәге рәсемнәр бермәлгә ябыштырылган акчалар булып күренде.

—Мөхәммәт, фотога төшерү катлаулы эшме?

—Эш дип, һөнәр инде... Ник алай дип сорап куйдың әле кинәт кенә?

—Минем дә өйрәнәсем килә.

—Ну, Зөфәр, ну братлар, сезне һичбернәрсәгә якын китерерлек түгел, күргән нәрсәгезне хәзер үк «давай» дия башлыйсыз. Бер тәнкәгә ике янчык дигәндәй, бер авылга ике фотограф нигә кирәк? Син башка һөнәр тап. Әйтик... хәзер телевизор модада, ачуым килмәгәе, йорт саен икәү. Ватыла торган нәрсәме? Кәнишне! Вәт, өйрән син аны, төзәтергә өйрән... Акыл сата димә, яшь әле син, үзеңне иртәгә ни көткәнен дә белмисең. Юлыңны дөресләп җибәргәндә гаеп булмас.

—Син үзеңне ни көткәнен беләсеңмени?

—Беләм. Мөхәммәтне берни дә көтми. Эшкә барам—эштән кайтам, буш вакытларда фото белән шөгыльләнәм, көн саен шулай... Ә менә синең, Зөфәр, брат, киләчәк өчен үзеңне ныклап әзерлисең бар.

Дәресләкләрнең соңгы битләрен укыйбыз. Ел башыннан «их, тизрәк уку бетсә иде», дип хыялланган малайлар әллә ничек кенә үзгәрдек тә куйдык, кисәк ямансу булып китте. Мәктәп—күче ташлап киткән умарта оясы кебек, тәнәфес вакытларында коридорда, классларда ник бер кеше калсын—тып-тын. Тамгалы парта-өстәлләрне, кара төсе уңган язу такталарын, маңгайлар, терсәкләр белән сыдырылган класс стеналарын, һәр сайгагына менәрләгән туфли үкчәсе белән баскан идәннәрне, исемнәребез тирән уелып калган ишек яңакларын каплар өчен мәктәпкә мичкә-мичкә буяу ташый башладылар инде. Без аларга комачауламыйбыз, урамга чәчеләбез. Юк, чәчелмибез, өч төркемгә бүленеп басабыз. Минем чамадагылар өченче класстагы малайларга һәм кызларга кызыгып торабыз. Үзләренә түгел, уеннарына. Малайлары түгәрәк сызык сыза да шуңа пәке белән кадап «җир бүлеш» уйный. Кем күпме җир ала, янәсе. Түлке куллары оешмаган, ыргытылган пәкеләре җиргә кадалмый, егыла. Аны соң, иң очыннан тотып, бераз селтәнебрәк ыргытырга кирәк, күрсәтер идем инде ничек кирәк икәнен... Тик без «картларга» килешми шул. Кызларын күр, кызларын! Сабыйлар! Вазелиннан бушаган түгәрәк савытка ком тутыралар да шуны аяк очлары белән типкәләп шакмактан шакмакка сикерәләр... Бездән дә картраклар әллә кая читкә үк китеп басканнар, сөйләшкәннәрен без ишетмәсен дип, ахрысы. Үзләренә күрә, көн саен берәр юаныч табалар тагы. Кичәгенәк берсе кесәгә сыя торган радиоалгыч алып килгән иде, ә бүген җыйнаулашып көнбагыш яралар... Егетләре кызлар кулыннан ашаган була, үләрсең хурланып, әллә кем булып кыланалар. Кызлары да бит аның—китмиләр, тәки тегеләрнең көнбагыш чүпләгәнен көтеп учларын җәеп торалар.

Мөдәррис белән икәүләшеп тегеләрен дә, боларын да күзәтеп тик торабыз. Киләсе елга безнең дә көнбагыш ашар чак житә. Киләсе елга без югары класс булып исәпләнәчәкбез, чөнки мәктәбебез тулы түгел безнең. Тагын берәр елдан имтиханнар тапшырасы. Ә әлегә быелгы каникулыбызны ничек теләсәк шулай үткәрә алабыз. Хәер, үз иркебездә түгел, жиләнчене бетергәч, соңгы тапкыр димәктән, колхоз пионер лагеренда бер ай хезмәт итәсе бар әле. Укытучылар телендә «пионер лагере» дип олылап әйтелсә дә без—малайлар телендә «лагерь» гына ул. Эшләп ял итү лагере диләр аны. Әй, жәй буе шунда чиләнгәч, беләм инде мин аның ни икәнен. Көндез суган чүбе, кәбестә арасы, бәрәңге бураэнасы, төнлә—ял. Дөрес, кичләрен төрле уеннар оештырган булалар, ләкин көнозыны басуда бил бөгеп, тузан эчеп, кояш астында кызып алжыгач, әллә ни уйнарлык рәт калмый. Кабыл-тибел ашап, кояш офыкка чумганчы Мишә суы жылы чакта

коенып өлгерергә дип йокының ярты сәгать вакытына зыян китерәбез. Шушы рәвешле тәрбияләп, безне авыл эшенә өйрәтәләр янәсе. Өебездә дә шундый ук эшләр бар инде ул. Әйтерсең лә, анысын без үзебез түгел, Казан малайлары кайтып эшли!..

Менә тиздән, бик тиздән, тәнәфескә дип чыккан җирдән таралышып, портфельне чөйгә элеп куярбыз. Колхозның яшелчә бакчасында чүп үләннәр калыкканчы гына юанырбыз да лагерьга китәрбез. Бер ай буена Гөлназдан хат килмичә калмас, авылга барып почтаны белешеп торырга туры килер.

Мин мәктәптән кайтканчы почта таратылмаган була әле. Анысы шәп, хат ташучы Зәкия апаны капкадан ук каршы алырга тиеш мин. Моның бер сере бар. Безнең оч почта ягында, Зәкия апаның сумкасы—бөтен классның китап-дәфтәрен бергә тутырсаң да аның чаклы булмас! Ну, язышып та карыйлар түлке безнекеләр. Юка-юка хатлар, гәҗитләрдән генә дә ничаклы йөк җыелган. Әгәренки, таш гасырда хат ташучылар йөрсә, бу хәтле хәбәрне җиткерер өчен Тянь-Шань тауларының ташы да җитмәс иде... Зәкия апа иң әүвәл миңа гәҗит тоттыра, аннан, сумкасының алгы кесәсенә тыгылып, хатлар бәйләмен чыгара, ашыкмыйча гына күздән кичерә. Мин сулыш алырга онытып һәр конвертка күз ияртәм. Сумкасында хатлары күп булганда рәхәт—ул аларны озак актара, арасыннан менә-менә Гөлназ хаты килеп чыгар шикелле.

Өстәл артында арыш ипие белән көнбагыш маена манылган «чикмәнле бавырсакның» (кабыгы белән пешерелгән бәрәңгене әни шулай атый торган иде) тәмenә онытылып, капка ачылганны да сизми калдым. Мин абайлап өлгергәнче, Зәкия апа бусагадан атлап кергән иде.

—Сезгә бүген бер хат белән бер посылка килде.

—Хатның кемнән икәнен беләбез,—диде әти миңа таба карап.—Ә менә посылкасы кемнән икән?

—Бүләк көтәрдәй беркемебез дә юк ләбаса!—дип аптырашка калды әни.

—Мәскәүдән. Тик акча түләп аласы.

Әни бөтенләй гаҗәпләнде.

—И, Зәкия, акча түлисе булгач, ниткән бүләк ди ул?

—Бәлки Зөфәрегез беләдер, аның исеменә язылган.

Зәкия апа чыгып киткәч, мин берни белмәгәнгә сабышып утырган булдым. Өй эчендәге тынлыкта әнинең тирән итеп сулаганы ишетелде. Әти, хәзерге сөйләшүнең ахыры ни белән бетәчәген алдан ук белгән кешедәй, өйдән чыгып китте. Эш акча мәсьәләсенә килеп терәлсә, әни сүзе законга әверелә безнең өйдә.

—Нәрсә сорап яздың?

—Фотоаппарат.

—Кем өйрәтте?

—Хат салырга дип барган җирдән, почта аркылы алдыра торган товарлар турында бер китап күрдем. Шундагы адрес белән сорап яздым.

—Ник шулхәтле кыйммәт соң ул?

—Кирәк-яраклары бар. Коры фотоаппарат белән генә берни дә эшләп булмый ул...

—Җүнлерәк әйбер, кием-салым сорап язсаң лутчы кана...

—Әни, мин Мөхәммәт абый шикелле фотограф буласы килә дә...

—Пәлтәнә дип җыйган акчаң бар, теләсәң нишләт, хет ике аппарат асып йөр, бер сүзем юк.

—Алайса, посылканы кире җибәрик. Тик авылда сүз генә таралыр: «Икәүләшеп эшләп бердәнбер малайларына җаны теләгән нәрсәсен алып

бирергә дә кызганалар. И ходаем, хәзерге халыкның саранлыгы. Акча җыйганчы мал җый ичмасам, сөенече күбрәк»,—диярләр...

—Җитәр, җитәр,—дип бүлдерде әни,—минем бит әле посылкаңа түләргә акча бирмим дигән сүзем юк.

Әни белән икәүләшеп барып, посылканы алырбыз дип кузгалмакчы идек, көтмәгәндә капка келәсе шалтырады.

Кабаланып килеп кергән кеше Мөхәммәт иде. Күрешеп, гадәт буенча хәл-әхвәлләрне дә белешкәч, өй эче тагы тынып калды, өчәүләшеп баз эчендә утырабызмыни!.. Мин почтадагы посылка тартмасына бикләнгән фотоаппаратны күз алдына китерергә тырыштым. Әни, әллә кайчан онытылган мәшәкатьне исенә төшергәндәй, кирәкмәсә дә юеш чүпрәк белән өстәл өстен сыпырып алды, каушады. Ә Мөхәммәт...

—Тау Мөхәммәт янына килгәнче Мөхәммәт тау янына барып килергә тиеш, шулаймы, Зөфәр?

—Кем инде ул тау?—дидем мин, «Бабай» Мөхәммәтнең сүзләренә артык игътибар итмичә генә.

—Син тау!—диде ул, шушы сүзе белән генә мине үстерергә теләп.

—Ниткән тау ди әле мин, түмгәк диген...

—Тау түмгәктән ярала ул. Син үсәсе кеше, һәрхәлдә, безнең эше көрәк мөдире түгел. Заманы да башкачарак, сез дигәндә бөтен җәннәтләрнең ишеге йозаксыз. Өстегезгә кигән пинҗәгегез дә мин сиңа әйтим, биш кесәле. Безнең заманда өч кесәлесе дә бик җитә иде... Кыскасы, шул, энем, фотоаппарат алгансың икән, күрсәтерсең дип уйлыйм.

Минем өчен әни җавап бирде:

—Почтадан алып кайту белән...

Мөхәммәт, акча тапкан кешедәй, минем кулымдагы посылка кәгазенә текәлде.

—Маркасы нинди?

—«Киев»,—дип җавап бирдем мин. Үз тавышым үземә ыңгырашу булып тоелды.

—Нәкъ мин хыялланганы икән.

—Вспышкасы белән бергә.

—Яшене дә бармы? Меңә бит әй, сат син аны миңа.

—Соң... үзеңнекенә ни булган?

—Әйттем ич инде... Бер авылга нигә кирәк ике фотоаппарат. Син телевизор төзәтүче һөнәренә өйрәнәсең дип тә килешкән идек.

Мин гүя Мөхәммәтне танымадым. Шушы минут эчендә аның урынына башка кешене китереп куйдылар диярсең. Бу кеше тупырдап торган таза гәүдәле, киң күкрәкле дә түгел, әллә нинди зәгыйфь кыяфәтле, юмагай телле, кәкре борынлы, комсыз күзле...

Югалтудан куркып, посылка кәгазен учыма кыстым да әлеге комсыз күзләрдән яшердем.

Сез ничектер, ә менә мин кызлардан килгән хатны кеше янында укый алмыйм. Конверт эчендә мин генә белергә, мин генә укырга тиешле сере бардыр. Өйдә кеше юк чакны туры китереп Гөлназдан килгән хатны кесәдән чыгарган гына идем, әти кайтып керде. Ул минем кызлардан хат көткәнемне белә. Ләкин хатны язучы кеше Камышлы кызы Гөлназдыр дип башына да китерми. Әйтмим дә. Мактанырга иртәрәк әле.

Кая качыйм икән? Туфраксага менсәм, өй кыегы тәрәзәсеннән төшкән кояш нуры җитә инде, тик анда тузан шул, рәхәтләнеп утырып укырлык түгел—кием пычрана. Печәнлеккә менсәм... Тезмәләр буш хәзер, кыш буе

ашатып чыккан печәннең вагы гына коелып калган, тик анда караңгы. Капка төбенә чыксам, кулымдагы хатны күреп Мөдәррис килеп житә. Су буена төшсәм... Чишмә юлы шунда гына, су кирәкме, юкмы, кызлар барыбер чишмәгә йөри, Ләйсәнә кебекләр улак яныннан китми, кая куядыр шул тиклем суны?.. Менә сиңа мә! Бөтен Арышлыда хат укырдай бер рәтле урын юк! Агач башына гына менмәсәң... Су буенда өянкеләр житәрлек, барысы да таныш. Яшьрәк чакта ул өянкеләргә менеп чәүкә ояларына «инвентаризация» ясап төшә торган идек.

Кроссовкаларны салып тормадым, шул килеш кенә үрмәлим. Агач башына менү үр менү эше генә түгел, шактый тырышасы. Ботак аерына житкән саен тукталып хәл алам да аска карыйм—күз алды иркенәя. Мин югарырак менгән саен авыл кечерәйгән сыман. Ниһаять, жайлы гына аерчага атланып, өянке кәүсәсенә жилкә терәдем. Шушында туктыйм, карга оясына ук менеп хат укымассың ласа.

Конверты бик калын күренсә дә, хаты бик кыска иде Гөлназның, куш битле кәгазьнең бер ягына гына сырлап шул килеш салып жибәргән... Иң әүвәл хатка күз йөртеп чыктым—кышкы кичтә Мишә буендагы очрашуыбыз хакында язгандыр, әнә шул юлларны тизрәк табып алдан ук укып куйыйм дигән идем. Ләкин Гөлназ ул турыда һичнәрсә язмаган. Әйтерсең лә кышкы кичнең бүгенге хатка бер катнашы да юк. Хет теләсән ничек аңла... Бәлки, сиздермәскә тырышуы әйбәтрәктер, ике арада серле билгесезлек барында хат ташучылар аркылы аңлашу тагын да мажаралырак ич. Гөлназның унберенче укучыга дигән булып кына миңа хат язуын гафу үтенергә теләве дип аңлыйм, кышкы кичтә жавапсыз калган сүзләрем өчен, чамасыз тәкәббер сөйләшкәне өчен. Күрешкәч, бәйнә-бәйнә сөйләшербез, көлешербез әле. Ә хәзер бу агач башыннан төшәргә кирәк. Кирәк, ләкин төшәсе килми. Өянкенең яшел челтәре аркылы тирә-як мохитны күзәтәм. Кояш, әнә, жылы һава өрелгән сары шар кебек һаман жиргә төшә алмый, авыл артында йөри. Азрак жир исни торсын дип урамга куылган ала сыер кысыр чирәмлектә ял итә. Ул өянкегә сөялеп дигәндәй баскан да көн жылысына ләззәтләнеп саф һава сулый, башын югары күтәреп сагыз чәйнәгәндәй итә. Көтү чыгар чаклар житкәнне сизенеп, күңеленнән генә Мишә буендагы болыннарны барлый. Көньяктагы жилләр кич житкәндә илаһи-уптым төньякка күченеп бетте. Шушы тынлыкта өянке песиләренә сарылган бал кортларының жыры, күмәк безелдәүгә әверелеп, агач башында үзенчә яңгырап тора. Ә жирдә—урам юлы, юлның чишмәгә илтүче сукмагы, сукмактан, сулы чиләкләрен уйнатып, Ләйсәнә килә. Әллә кайдан гына Мөдәррис пәйда булды. Көянтәсез-нисез генә ике чиләк тоткан. Аның да чишмәгә барышы, әнисе пенсиягә чыкканнан бирле тырыш су ташучыга әверелде егет. Менә Ләйсәнә белән Мөдәрриснең аралары якынайганнан-якыная, менә Мөдәррис тар сукмакны кызга калдырып читкә чыгып юл бирер... Юк. Икесе дә тукталдылар. Ләйсәнә юл сорый. Ә тегесе, үткәреп жибәрәсе урында, чиләкле кулларын жәеп аркылы басты. Ләйсәнә көтте-көтте дә түзмәде, узган елгы кычыткан кураларын таптап, Мөдәррисне әллә кайдан ук әйләнеп үтте. Их, фотоаппарат юк, ичмасам, төшереп аласы иде.

Фоторәсем дигән нәрсә, ябалак шикелле, ут яктысыннан курка икән дип, тикмәгә генә әйтми инде әни. Күпме кәгазь, күпме тасма һәм реактивлар әрәм иттем.

Өйрәт әле, дип «Бабай» Мөхәммәт янына да барып караган идем. Тик ул минем фотоаппаратның яшенеңнән дер селкенеп куйды да шуннан жайга килмәде.

—Кеше әйтеп торып кына күп нәрсә ала алмассың, ялгыша-ялгыша үзең өйрән. Кулыңнан килмәсә, әнә, Казанга бар, анда адым саен лаборатория, рәсемнәреңне эшләп бирерләр,—диде.

Бөтен сөйләгән сүзе, биргән киңәше шул булды. Аның каравы, физика укытучысы унлап укучыдан фототүгәрәк оештырды. Җәйге каникул чорында да өйрәнүләр тукталмаячак икән.

Хәзер, мин сиңа әйтим, фасонын китерә беләм: кая гына барсам да, фотоаппарат муенда, күлмәк кияргә онытмаган кебек, аны да өйдә онытып калдыру юк. Вакыт күп, укулар бетте, лагерьга барганчы ун көнләп көтәсе бар. Иренмим: Мишәгә коя торган инешебезне буеннан-буена фотога төшердем. Берәмләп-берәмләп һәр өйне, үткән-сүткән һәр машина-тракторны, этләрне, мәчеләрне, болытларны, хәтта карга ояларын да фотоаппарат эченә «җыйдым».

Беркөнне утырам шулай, объектив каршысындагы рәшәткә башына чыпчык кунганын көтеп... Мөдәррис килә.

—Әйдә, тизрәк,—ди бу мине чын-чынлап ашыктырып,—әти өй саклый торган бурсык алып кайткан.

Гадәттәгечә, фотоаппарат муенда инде, чабам гына Мөдәррис артыннан. Ишегалларына килеп керүгә каккан казыктай үрә каттым да калдым: болдыр баскычына башын куеп бурсык ята, борын очыннан җилкәсенә чаклы тасма ябыштырылган төсле, күз тирәсе, колак өлеше кап-карага маныйлган кебек. Үзе кыймылдамый да.

—Кешедән курыкмыймы, ник безгә исе китми?

—Үлгән ул,—диде Мөдәррис мине тынычландырырга теләп һәм аның тавышы шундук горурлык авазы булып яңгырады.—Әти урманга баргач, каеннар арасында күргән дә күсәк белән бер генә тондырган—ләх! Мингерәгән дә мәңгегә мәрткә киткән. Арт саның кара әле син аның—ничек симез. Кәнишне, көз көне очраган булса иләмсез таза булыр иде ул. Әти әйтә, ничава, ди, бик тырышсак бер кило маен сыгып алырбыз ди. Үпкә авыруыннан бик файдалы икән аның мае.

—Атаңның үпкәсе ниткән мәллә?

—Юк ла инде, калага барып сатам ди, анда «эһ» тә итмичә, ялынып дигәндәй алалар икән. Әйдә, фотога төшер. Мин башыннан сыйпагандай итим, яхшылап төшер, чын кинодагыча матур итеп чыксын.

Мин Мөдәррисне бурсык сыйпаган килеш фотога төшердем.

Кич җиткәнне үк көтмичә безнең өйнең идән астына төшеп бурсыклы рәсемне эшләп карадык. Урамда—кояш яктысында төшерелгән фотолар күбесенчә яхшы килеп чыга, Мөдәррис тә үз рәсеменнән үзе канәгать иде. Ул аны беррәттән бишне эшләтеп алды, миңа берсе—бары тик кап-кара булып уңышсыз чыкканы гына калды. Мин аның әлеге фотолар белән нишләргә теләгәнен абайлап өлгермәдем, соңыннан гына аңлашылды... Ничек кенә аңлашылды әле... Ахыры болай бетәсен алдан ук белсәм... Миңа ул фотоларны бөтенләй эшлисе калмаган икән... Кул эшләгән эшкә акыл соңрак килеп җитә, ди әни, әгәр мин берәр гаеп эш кылсам...

Каникулга чыгып Мишәдә йөз илле тапкыр чамасы су коенып өлгердек микән, белмим, шуның белән вәссәлам. Июньнең уртасы җитүгә пионерлагерьга алып киттеләр. Лагерьда бөтен нәрсә чама белән генә, уены да, эше дә, су коенуы да, ашы да.

Ачылу тантанасына колхозыбыз председателе килде. Килде дә, без линейкага тезелгәннән файдаланып, тиз арада доклад ясап алды. Аның сөйләве, нарат ботагына эленгән зур репродуктордан яңгырый да агачтан-агачка бәрелеп яңадан безгә әйләнеп кайта. Аның бу чыгышы

колхозчыларның бик зур җыелышын хәтерләтә иде.

—Кадерле пионерлар! Яшь колхозчыларым минем! Чүп үләне котырды быел, яшелчәләр күтәрелә алмый. Бөтен өмет сездә! Әгәр билгеләнгән участокларны тазартып чыксагызмы... Сез социалистик ярышка кушылыгыз. Сменагыз беткәндә җиңүчеләрне билгеләрсез. Мин аларны үз «Волга»ма утыртып алдынгылар слетына алып барачакмын. Слетка бөтен республикадан җыелачаклар.

—Председатель «Волга»сына дүрт кенә отличник сыяр шул,—дидем мин, үзем ише ударникларны яклап.

—Җиңүчеләр күп булмый. Ләкин слетта катнашу өчен лагерь эшендә иң алдынгы итеп танылган пионерларны гына алачакбыз. Пионерлар! Колхозыбыз эше өчен көрәшкә һәрвакыт әзер бул!

—Без һәрвакыт әзер!—дидек беравыздан... Бу минутта алтмышыбыз арасыннан кайсыбызны гына әйтсәң дә теге «дүртәү» дигән алдынгы булырга риза идек.

Председатель китте, без черки оясында калдык.

Лагерьда беренче көнне гел бәйрәм инде ул. Көн сүрелгәч, Мишә ярында пионер учагы ягарга дип кәсне каезлап зур йолдыз сурәте ясадык... Утын өчен нарат ботаклары җыясы бар.

Кем ничектер, нарат ботагы җыюны яратам мин. Урман үстерүчеләргә ел саен икешәр-өчәр капчык нарат күркәсе җыеп тапшыра торгач, агач башына менәргә бөтенләй һәвәсләндем.

Наратның кирәкмәгән бер гадәте бар: кәүсәсен кочаклап өскә үрмәләсәң тәнеңә чәер сылап куя. Очына тиклем менәм дисәң, эшкә тотынганчы матур күлмәгеңне салып тору хәерлерәк.

Коеласы ботакларны җыешырга дип килгән Ләйсәнә читкәрәк китеп басты да миңа җилкәсе белән борылды, чалбар салганны күрмәс өчен, янәсе. Нарат саен бер малай бар, белмим, нәрсәгә дип миңа ияргәндер ул?

Агачы нык—томырылып яуган янгырыңа, зил-зилә кубарып искән «шайтан өермәләренә» дә бирешерлек түгел. Төп буе ботаксыз, җыерчыклы кабык, бераз күтәрелгәч кәүсә бөтенләй үзгәрде: үзе шома, үзе башлы суган кабыгы шикелле кыштырдап тора.

Бу якка таба борылып баскач күрер әле Ләйсәнә, иллә дә шәп менәм мин агач башына. Хәер, классташым алдында мактанып тору нигә кирәк? Менә Ләйсәнә урынында Гөлназ булсамы... Ул чагында мин нарат кәүсәсе буйлап болытларга кадәр менеп җитәр идем, чын әгәр!

Сәер кыз ул Ләйсәнә, башкаларга бер дә охшамаган. Бишенчедә укыганда безгә класс җитәкчесе булып яшь укытучы кыз килде, бик тә, бик тә матур иде ул. Чәчен кистергәнгә генә матур микән әллә дип, аның кебек үк чибәр күренергә теләп, кызларыбыз бер атна эчендә чәчләрен кистереп бетерделәр. Ә Ләйсәнә кистермәде.

Алтынчы класста җитәкчебез алышынды, тагын бер матур апа килде: кашы озын, керфекләре озын, чәч толымнары сигез тармакланып итәк очына кадәр үсеп төшкән. Шуннан соң кызларыбыз тотындылар чәч үстерергә: әче су белән дә юалар ди, кычыткан төнәтмәсе белән дә чайкыйлар икән, башларына суган боламыгы сылап йоклаучылар да булган дип сөйләделәр... Барыбер Ләйсәнәнең чәче иң озыны, һичкемнеке дә куып җитә алмады... Жиденчедә тагын класс җитәкчебез алышынды, прическасы минеке сыман гына... Кызларыбыз янә кулларына кайчы алды, хәтта класста ук, озын тәнәфес җитте исә, чәкән мунчаласы хәтле чәчләрен кыркырга тотыналар. Ә Ләйсәнәнең аларга исе китми, чәче гел үсә. Инде йөргәндә бик комачауламасын дип толымының очларын ак керфекле кызыл кофтасының капюшонына бөгәрләп сала. Үзе бик аз сүзле тагы. Аның тавышын дәрес

вакытында җавап биргәндә генә ишетергә була. Башка чакны гел конфет суырып йөргән төсле, авызын ачмас...

Кызлар турында уйланып, нарат башына менеп җиткәнне сизми дә калдым. Аска карасам—Ләйсәнә агач төбеннән чытырлар, кипкән күркәләрне читкәрәк ыргытып йөри. Егылып төшә калсам йомшаграк булсын диптер инде. Егылды ди, тот алъяпкычыңны. Шулай да артык югарыга менмәскә кирәк, юкса укытучыларның килеп җитүе бар. Югарыдагы кеше күзгә күбрәк күренә ул!

Ботакларны өскесеннән кисә башлыйлар. Киселгән берсе астагы ботакларга эләгеп өелә тора. Соңыннан авырайган иң аскы ботакка балтаны тидер генә—бер арба утын җиргә килә дә төшә. Җиргә төшкәч, Ләйсәнә тизрәк киенергә кушты. Әзер дигәч, мине баштанаяк җентекләп күзәтеп чыкты:

—Беләген сыдырылган.

—Төкереклəп яфрак ябыштыргач бетә ул.

—Авыртамы?—дип, йомшак бармак очлары белән җәрәхәт тирәсенә баскалап карый.

Шулчак көтмәгәндә генә Мөдәррис пәйда булды.

—Әһә, менә кайда икәнсез. Әллә кая китеп, куллар тотышып, күзгә-күз карашып... Эзләп тә табарлык түгел.

Ләйсәнә Мөдәррисне гүя күрмәде дә, ишетмәде дә, һаман саен минем кулны тоткан, инде сыдырылган төшне сулышын өреп җылыткандай итә.

—Авыртмыймы, Зөфәр?

Мөдәрристән унайсыз ласа. Әллә нәрсә уйлар. Нарат урман эчендә кул тотышып торганнарын үзем күрдем, дип Гөлназга язып җибәрсә...

—Нәрсә бәйләнден әле син, Ләйсәнә, авыртмаган килеш...

—Егыласың икән дип курыктым.

—Минме, егыламмы?!

Ләйсәнә үпкәләде, бүтәнчәрәк сөйләшер дип көткәндер. Ә мин...

Ләйсәнә тикле Ләйсәнәнең авыз ачып сүз әйтүенә дә сокланмыйча, әллә ничек дорфа итеп җавап кайтардым,юатасы иде кызыйны.

—Мөдәррис, председателебез «Волга»сының алдагы утыргычына арка терәп алдынгылар слетына барасы кешене беләсеңме?

—Юк, малай, билләһи белмим,—ди Мөдәррис, күзен уйнатып. Сизәм, үзенең дә слетка барасы килә...

—Ләйсәнә ул!—дидем мин, һәм абый кешеләрчә кыланып кызның аркасыннан сөймәкче идем, сөйдермәде, читкә китеп басты. Аның каравы башыма бер уй килде әле.

—Мөдәррис, безгә бүген үк хат язарга кирәк. Әлеге слет турында минем Гөлназ да, синең Әнисә дә белсеннәр. Алар да тырышып эшләсеннәр. Ә аннан соң без алар белән Казанда, слетта күрешәчәкбез. Дөрес әйтәмме?

—Дөрес.—Ләкин Мөдәррреснең тавышында сөенечнең әсәре дә юк иде.

—Дөрескә чыгар өчен ай буе тырышасыгыз бар әле,—диде Ләйсәнә, читкә сөйләгәндәй генә.

Минем бераз кәефем төште.

—Ләйсәнә, ә син агач башыннан—югарыдан кечкенә генә булып күренәсең.

—Һе, югарыдан, имеш! Бер чыпчык өйгә кереп чыккач, җылы якта булдым, дип мактанган ди... Китер монда балтаны!

—Н-н-нәрсәгә-ә-ә?!—дидем мин котым очып.

—Балтаны үзем күтәрәм. Ә сез, геройлар, утыныгызны сөйрәгез!..

Шәфәкъ алсулыгы нарат очларында дөрли, алсулык яшел төсне каплап алган... Учакның ялкыны сүрелде. Жиргә уелган йолдыз эчендә утлы күмерләр жемелдәшә. Йолдыз яна... Бу минутта Жир-батырның күкрәгендә күпме йолдыз яна икән?.. Мишә дә, алсуланып, Гөлназлар ягына таба ага. Минем өчен генә шулай алсу күренәме бу дөнья?! Их, хәзер шушы йолдыз яктысына Гөлназ да килеп бассын иде. Алар да учак якканнардыр әле бүген. Гөлназның бит алмасы Ләйсәнәнеке төсле алсуланып янадыр...

Алтмыш бала арасыннан илле алтысын сызып ташлап слетка баручылар исемлегенә дүртне генә сайлау жинел түгел икән. Пионер бүлмәсе дип аталган алты кешелек палаткада зур кәгазьгә исемнәребезне тезеп «экран» эленде, ай буена житәрлек. Көн азагында, ягъни, йокларга таралышыр алдыннан линейкага тезәләр дә тантаналы төстә «плюс»ларны һәм «минус»ларны санап чыгалар. Беренче көннәрдә, барыбызга да гел «плюс» куеп, исәп тигез иде. Ләкин бит слетка алтмыш кеше бара алмыйбыз, димәк, кемнәргәдер «минус»лар эләгергә тиеш. Кемгә сон? Иртәнге физзарядкага соңгы кеше булып барсаң—«минус»! Чүп үләне утаганда норманны үтәмәсәң, киенгән килеш урын-жир өстенә утырсаң, рөхсәт сорамыйча лагерь чиген бозып берәр метрга читкә чыксаң... кыскасы, аз гына ярамаган эшең сизелсә, экрандагы исеменне «минус»лар сырып ала. Тора-бара күзәтү тагын да катыланды: иптәшең белән кычкырып сөйләшсән дә, йоклаганда гырылдаучыларга да шул җәза эләкте.

Баштагы мәлне минем хәлләр зарланырлык түгел иде: көн саен бер «плюс»! Сүз тыңлыйм, рөхсәтсез йөрмим, нормамны үтим, йоклаганда гырламыйм, ярты тавыш белән генә сөйләшергә дә өйрәндем.

Көтмәгәндә генә...

Лагерьга ризык ташучы машина яна газета-журналлар алып килгән иде. Төшке ашка кайткан чагыбыз, бөтенебез дә бер тирәдә. Кинәт Мөдәррис, район газетасын күтәреп, өстәл тирәли йөгерә башлады. Газетаны әләм иткән, үзе «Ур-ра!» кычкыра. Кулыннан тартып алып укысам—шаккаттык. Урта биттә зур гына һәм таныш рәсем: Мөдәррис бурсык сыйпап тора. Рәсем астына минем фотоэтюд дип язганнар. Каян килеп этюд булсын инде бу! Бурсык үлгән ласа! Мөдәррисне әйтәм, тәки теге фотоларның берсен редакциягә жибәргән икән, сиздермәде үзе, йә басарлар, йә юк дигәндер, күрәсең.

Классташлар бик сөенде бу хәлгә. Газетаны экран белән янәшә элеп куйгач, мин дә сөендем инде... Ә атна азагында йокларга яткач, көнозын чөгендер басуында ялан тәпи йөгереп кызган табаннарыбызны суытып та өлгермәдек—Мөдәррис белән икебезне чакырып чыгардылар. Кая, ни өчен, кемнәр чакырган дип озак баш ватарга туры килмәде, Мөдәрриснең йомшак жиренә чалбар каешы чалтырауга шундук исемә килдем. Әтисе икән лә... Мина да кизәнгән иде, лып итеп жиргә утырдым, үземчә йомшак жиремне каештан саклыйм. Мөдәрриснен әтисе каеш чыжылдаткан саен берәр сүз өстәп такмаклый...

—Менә сина гәжитең өчен, менә бурсык рәсеме өчен, монысы өйгә инспектор китерткәнең өчен, айлык акчамны штрафка түләткәнен өчен, башка вакытта акыл булсын өчен тагын бер...

Каеш тавышына бөтен лагерь аякка басты, хәтта баганалардагы барлык лампаларны да кабыздылар.

Башкаларга нәрсә—алар читтән карап тик көлеп тора. Хурланып үләрсен, салкынча торсын өчен Мишә суына батырылган сөтле бидоннар янына бәйләнгән кәрлә көчеккә хәтле: «Во!», «Во!», «Во!»,—дип, тән жәзасы белән тәрбияләү чарасын хуплап өргән була.

Район газетасын милиция бүлегендәгеләр дә укыйлар, күрәсең, кулга ияләшкән бурсык турында ныграк белешеп, якыннан танышыгыз әле, дип, урман хуҗалыгы инспекторына күрсәтмә биргәннәр. Алар, Мөдәррисләргә килеп, бернинди дә тере бурсык тапмагач, эшнең нидәлеген шундук аңлап, җәй башында ау тыелган килеш җәнлеккә кул күтәргән өчен ярыйсы гына штраф салып киткәннәр.

Мөдәррис еламады, бәлкем, пионервожатый чыгып әтисенең кулына ябышмаса, елатканчы кыйнар иде әле ул аны.

Бөтен гаеп миндә, Мөдәррисне бурсык янында фотога төшереп торасы калмаган. Фотоаппарат тотмаска антлар эчәрсең. «Отбой!» дип кычкырыр алдыннан кичтән куелган «плюс»ны тискәрегә төзәттеләр. Ә Мөдәрриснекен үзгәртмәделәр, әтисенең каешына түзгәнгә күрә бу юлга гафу иттеләр, экран янындагы теге гәҗит тә юкка чыкты.

Икенче кисәтү дә һич көтмәгәндә генә эләкте.

Берара көннәр кызу торды. Төшке дигән ял вакытын озайттылар, хәзер инде кечке дүрткә кадәр куләгәдә ял итәбез дә аннан соң җидегә чаклы эшләп кайтабыз. Өйлә вакытында урын өстендә ял итү мөмкин түгел, чамасыз бөркү, кайнар җил палатка эченә керә дә чыкмый... Инде иртән торуга палатканың итәген күтәреп бәйләп куябыз, юкса бу кадәр эссегә матрацлар суынгысыз итеп ут йота.

Кичке дүрттә көн бөркүлеге сүрелеп өлгерми әле. Симәнә суган рәтләрен күмеп киткән чүп үләне ирендереп, өркетеп тора. Үзенә бүленгән рәтне утап бетермәсәң, лагерьга кайтырга рөхсәт юк. Ә кайту—ул ашау дигән сүз!

Чүп тамыры йолкыганда күз алдына тузан өерелеп бара, ул тузан тирләп пешеккән маңгайга, күз төпләренә кунып әчеттерә, сулышка утыра. Беренче көннәрдә рәтне чыгып бетермәгән малайлар, калып эшләгән булып, авылга кайтып ашап киләләр иде... Сизеп алгач, тыйдылар. Инде калып эшләүчеләрне бөтен отряд белән көтеп торалар. Карының бик нык ачса, әнә, артта калучыларга булыш...

Аш әзерләнгән арада су коеныргa рөхсәт иттеләр. Үзебез чишенәбез, үзебез Мишә ярына йөгерәбез. Мин чалкан ятып йөзәргә яратам, болай иткәндә гел күккә карап барасың—нәкъ болытлар эчендә йөргән кебек, хәл дә бетми, рәхәт тә, әкрен генә тик кыймылдыйсың шунда. Мине Ләйсәнә куып җитте, су өстендә түгәрәк иңбашлары гына күренеп-күренеп ала, чәч толымын баш түбәсенә әрдәләнәп өеп куйгач яулык бәйләгән.

Тәҗрибәм арта, ахрысы, кайбер нәрсәләрне күрәзәче кебек алдан ук сизеп торам. Менә хәзер дә безнең тирәгә Мөдәррис килеп җитәр, әллә кайдан беләм, әйтте диярсез...

—Ләйсәнә, ярдан ерагайма.

—Курыксаң, үзең кире борыл.

—Миңа иярсәң хәлең бетәр, кызый.

—Алайса, син миңаияр.

Безнең турыга яр читеннән сикергән иде, корсагы белән чалт итеп килеп төште Мөдәррис. Әллә ни йөзә белмәсә дә шәп сикерә торган иде ул суга. Бу юлысы җайсызрак төште. Аны күргәч, Ләйсәнә каршы як ярга таба йөзә башлады.

—Җитәр, ерак китмә,—минем тизрәк Ләйсәнәне туктатасым килде.

—Батсам коткарырсыз әле, икәү ич сез...

Мөдәррис ишетмәгәнгә сабышып су астына чумды, мин аны Ләйсәнәне куып тотар өчен хәйлә кора дип торам, ә ул лагерь ярына элдерде, шыртлака... Ирексездән Ләйсәнәгә иярдем, харап була бит кызый. Аның кәмите кемгә кирәктер, белмим, куып тотам дигәндә генә ул агым уңаена читкә чума, агып бара торгач тагын ерак ярга юнәлә.

—Житәр диләр сиңа, ишетәсеңме, Ләйсәнә!

—Ишетәм, кил әйдә, ярдәм ит, кул арыды...

Ерак ярга якынлаштык, ләкин су читенә таллар бөгелеп төшкән, шундый куе чытырман, чыгып аяк басарлык түгел. Ләйсәнә бер чыбыкка ябышып хәл алды, мин якынаюга тагын туктар исәбе юк. Барам иярep, инде чынлап та хәлем чамалы гына. Лагерь ягыннан:

—Тимә, Зөфәр, Ләйсәнәне батырасың, ник куасың аны?—диләр, диләр генә түгел, разбой салып кычкыралар. Ә Мөдәррис тавышы һәммәсенекеннән өскә чыга.

—Ишетәсеңме,—дим Ләйсәнәгә,—мине гаепле итеп калдыралар, теләсәң нишлә, кире борылам.

—Мин арыдым, батам, Зөфәр.

Күбекләр богырт-богырт иткән тавышка сискәнеп куйдым, баксам—Ләйсәнәнең чәч өеме генә күренеп тора... Әллә нишләдем, кинәт үземә яңа көч кушылгандай итеп тойдым. Ялт кына килеп кызның чәч толымыннан ярга таба сөйрәдем. Бәхеткә күрә, чытырманнар арасыннан печәнчеләр су керергә йөри торган чирәмле сукмак күзгә чалынды, шунда сөйрәп алып чыктым. Алай су эчмәгән, тончыкмаган иде үзе, хәле генә беткән икән, чирәм өстендә елмаеп ята. Әрлисем килгән иде, тик аның елмаюы җинде. Исән-саулыгы сөендерде әле.

—Туңам...—аның беренче сүзе бу.

—Нишләтим соң, салып бирергә пәлтәм юк ич.

—Җилкәнне җилкәгә тераp утыр.

Аркаларны терәштек. Туңам дигән була, карасана, тәне нинди кайнар.

—Син мине үлемнән коткардың, калган гомеремне сиңа бүләк итәм.

—Мәхәббәт турындагы китаплардан ятлый торгач, бөтенләй артистлангансың син.

—Слетка Гөлназыңны күрер өчен барасың киләме?

—Әллә ярамыймы?

—Турысын әйт, боргалап-сыргалап торма.

—Әгәр әйтмәсәм?!

—Әйтмәвең хәерлерәк, ни әйтәсеңне беләм лә. Кеше кешегә әкренләп күнегә диләр. Син дә миңа күнегерсең әле.

—Кем әйтә аны, кайсы китапта?

—Физикада... Бер-берсенә тартылыр өчен җисемнәр капма-каршы корылырга тиеш диелгән ич.

—Мөдәррис кызыга сиңа.

—Кирәкми.

—Ник, әкренләп аңа да ияләшерсең әле, үзең әйтәсең ич...

—Исемлек буенча хат язган әллә ниткән күрше авыл кызына хыялланып йөрисең. Әйләнеп карамаслык карачкыдыр әле.

—Минем ул кызны күргәнем бар. Исеме сыман матур... Гөлназ...

—Исем, исем... Ышан исемгә. Җир маен май диләр дә ипигә ягып ашаган кеше юк әле...

*Ахыры киләсе санда*

# КОРЪӘННЕҢ ТАКТАШКА ТӘЭСИРЕ

Коръән—мөселман халыкларының әдәбиятына гына түгел, бөтен дөнья әдәбиятына да нык тәэсир итүче чыганак булып тора. Коръәннең аерым сүрәләрен стильләштерү, андагы мотивларга шигъри иярүләр күп кенә Көнбатыш Европа һәм рус язучылары әсәрләрендә дә байтак. Мәсәлән, Вольтерның «Фанатчылык яки Мөхәммәт Пәйгамбәр»е, Монтескьенын «Фарсы хатлары», Гётенын «Көнбатыш-Көнчыгыш диваны», Һейне шигырьләре, Пушкинның «Коръән»гә нәзыйрә»се, Лермонтов, Фет һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләре.

Бөтен мөселман Көнчыгыш әдәбияты Коръәннән цитаталар белән сугарылган. Татар, гомумән, төрки әдәбиятына да изге китапның тәэсире зур. Әйе, Коръән татар әдәбиятына төп юнәлеш биргән, күп кенә шагыйрь-язучыларның дөньяны күзаллавында мөһим фактор булып торган. Үзләренең шигъри һәм проза әсәрләрендә татар шагыйрьләре, язучылары Коръәннең сурәләрен, аятьләрен, хәдисләр кулланганнар. *(Бу хакта Хатыйп Миннегулов та язып чыкты. Кара: (Миннегулов Х. Коръән һәм татар әдәбияты // Миннегулов Х., Садретдинов Ш. Әдәбият: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек.—Казан: Мәгариф, 1994.—Б. 41. 172)*

Коръән XX йөз башы татар шагыйрьләре өчен дә илһам чыганагы булып торган. Ул Һади Такташны да тәэсирләндергән. Такташ Коръән аятьләрен яхшы белгән. Моның дөреслегенә анын иҗатын Коръән белән чагыштырып карап та инанырга мөмкин.

Коръәннән кергән персонажлар, сюжетлар әдип иҗатында зур урын алган. Әлеге мотив «Караңгы төннәрдә», «Газраилләр» шигырьләреннән башлап, «Җир уллары трагедиясе», «Гыйсъян» кебек шигырьләренә кадәр килә.

Күзәтүне «Газраилләр» шигыреннән башлыйк. Биредә фәрештә һәм газраилләр—капма-каршы ике образ. Берсе анын кешелеккә яхшылык теләүче, тугры юлга күндерүче, иман индерүче; ә икенчесе—җан алучы, юкка чыгаручы, җимерүче, үтерүче. Авторның «монда патша—газраилләр!» дигән сүзләреннән үк идарә итүчеләр, җитәкләүчеләр үзләре үк үтерүчеләр икәнлеге аңлашыла. Фәрештә төзегән бәхетле тормышны исә шагыйрь «җәннәт» дип атый.

Ул фәрештә моннан бик күп еллар элек бу йолдызга күктән очып килгән иде, дип яза шагыйрь. Әлеге юлларда моннан бик күп еллар элек күктән индерелгән Коръән турында әйтелүе ихтимал. Аны Мөхәммәт пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә индерә. Бу хакта «Сыер» сүрәсенең 97нче аятендә күрсәтелгән: «Ий, Мухәммәд г-м әйт: «Кем Җәбраил фәрештәгә дошман булса, ул Аллаһы Тәгаләгә дә дошмандыр». Җәбраил Коръәнне Аллаһ әмере белән синең күнеленә индерде: Коръән Тәүрат вә Инҗилнең хаклыгын тәсдыйклаучы һәм тугры юлга күндерүче, вә мөэминнәрне җәннәт белән шатландыручы.»

«Күктән сөрелгәннәр»дә дә фәрештә—шәфкатьле, башкаларга яхшылык теләүче. Такташ дин, милләт сакчыларын, зыялы кешеләрне гәүдәләндерү өчен табигый гаделлекне, тугрылыкны, яхшылыкны үзендә саклаган һәм җирдәге бозыклыклардан саф

булган сурәтләр эзли. Унай типлар итеп фәрештә, пәйгамбәрләрне ала. Боларга контраст булганнары чиктән тыш явызлык белән характерлы: газраилләр, иблис һ. б.

Такташ үзенең идеалларын чиктән тыш көчле дулкынлану белән белдерә, шуна күрә аның сурәтләре дә гипербола һәм контрастлар белән сугарылган, ул кискенлекне югарыда әйтелгән сурәтләр аркылы бирергә тырыша.

«Үтерелгән пәйгамбәр» шигырендә лирик герой—пәйгамбәр. «Пәйгамбәр»—фарсыча—Аллаһы Тәгаләнең илчесе дигән сүз. Ислам дине өйрәтүенчә, Алла аерым ыругларга һәм халыкларга үзенең илчеләрен (рәсүлләрен) җибәрә торган булган. «Гыйбадәте Исламия» дигән дини кулланмада бу хакта болай әйтелә: «Бәндәләргә дин хөкемнәрене өйрәтмәк өчен Аллаһы Тәгалә бик күп кешеләрне пәйгамбәр кылмышдыр. Ул пәйгамбәрләр һәркайсысы адәмиләрдер. Анлар яшь вакытларында да бик гакыллы вә бик зирәк вә һәм бик тугры вә изге табигатьле булмышлардыр. Олугъ булганнан соң Аллаһы Тәгалә аларны пәйгамбәр кылмышдыр. Ягъни җәбраил фәрештә аркылы анларга үзенең хөкемнәрене җибәреп, шул хөкемнәр буенча бәндәләрне хак дингә вә гамәлләргә өндәргә боермышдыр. Шуннан соң ул пәйгамбәрләр Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча кешеләрне Хак дингә вә изге гамәлләргә өндәмешләрдер» *(Шәфигый З. Ислам: Белешмә-сүзлек.—Казан: Татар. китап нәшр., 1993.—Б. 128—129).*

Такташ шигырендәге пәйгамбәр дә хаклыкка, изге гамәлләргә, гаделлеккә өндәүче зат булып гәүдәләндерелгән.

Такташның үзен пәйгамбәргә тиңләве («Үтерелгән пәйгамбәр») шулай ук аның Ислам дине белән бәйләнешен күрсәтә. Бирелә аның үз исеменең мәгънәсенә дә ишарә бар. Пәйгамбәр һәм Һади исеме арасында мәгънә уртаклыгы күзгә бәрелеп тора. Мәгълүм булганча, безнең соңгы пәйгамбәребез—Мөхәммәд пәйгамбәр (Мөхәммәд бине Габдулла). Һади Такташның тулы исеме Мөхәммәтһади икәнен искә алсак, болай килеп чыга: Мөхәммәт макталган, мактаулы, данлыклы; Һади юлбашчы, башлык, алга баручы, сугышчы.

Шагыйрьнең «Антым» шигырендә шундый юллар бар:

*Язып куегыз, кирамән*
*Кятибиннәр, бер бөек антым:*
*—Хакыйкать мин басам; баскан*
*Эземдә тетриләр таулар!..*

Киләчәк турында уйлаганда, бер көн килеп, иҗатыма дөрес бәя бирерләр һәм мин әйткән хаклыкны анларлар әле дип ышанганда да ул Коръәнгә сыена; кешенең барлык яхшы, яман эшләрен язып торучы фәрештәләргә эндәшә.

«Айның нурлары арасында» шигырендәге түбәндәге юллар да дини ышануга барып тоташа:

*Күңелем дә, җаным да, иманым да, бергә*
*Кушылып айның нурлары белән,*
*Дулкынлы караңгылык өстеннән*
*Очтылар, офык буйлап, ераклашып җиргә...*
*Башларын иеп, кабер ташларын үбеп,*
*Шәһит каһарманнарның рухларына*
*Илнең сәламен ирештереп*
*Кайттылар аларның барына.*

Т. Галиуллин[1] фикеренчә, дини сюжетка корылган һәм чорның, гомумән, яшәешнең, кешелек тормышының катлаулы төенләнешләрен үзәккә алган «Җир уллары трагедиясе» яшь шагыйрьне дөнья әдәбиятының бөекләре белән бер рәткә куя. Әлеге фикерен галим язучыбыз М. Мәһдиев сүзләре белән раслап куя: «Такташның искиткеч талантлы—Шекспир дәрәҗәсендә! язылган «Җир уллары»

[1] Галиуллин Т. Бөек хыяллар,олы хисләр җырчысы: (Һ. Такташның 100 еллыгына) / / Татарстан. – 2001. – №1. – Б. 67-70. 174

бар, 1923 елга кадәр язылган гаҗәеп көчле шигырьләре бар. Совет баласыннан әнә шул шигырьләрен яшереп тотабыз без. Үз-үзен ихтирам иткән халыклар мәктәп дәресләкләрендә храмны, чиркәүне, мәчетне сүкмиләр. Бу хәл—бездә генә» *(Казан утлары.—1991.—№8.—Б. 164).*

Милләтнең җанын, рухын, теләк-омтылышларын яхшырак аңлау өчен, Һади Такташ Коръәнне өйрәнә. Коръән аятьләреннән турыдан-туры файдаланып иҗат иткән шигъри әсәре «Җир уллары трагедиясе». Такташ аны Майдә (Аш яулыгы) сурәсенен 27—31 аятьләре нигезендә иҗат иткән. Коръәндәге Майдә сурәсенең әлеге аятьләренә күз салыйк әле. Аятьләрдә язылганнар белән Такташ әйтергә теләгән фикер арасында уртаклык ни дәрәҗәдә икән?!

«27. Ий, Мөхәммәд галәйһиссәлам! Адәм г-мнең угыллары турындагы хәбәрне хаклык белән укыгыл. Кабил белән бер карында яткан Әкълимә Һабилгә тиешле иде. Әмма Кабил Әкълимәне үзем алам дигәч, Аллаһ икесенә дә корбан чалырга боерды. Ике егет корбан чалдылар, берсенеке, ягъни Һабилнеке кабул булды, икенчесе Кабилнеке кабул булмады. Кабилнең көнчелеге артты һәм әйтте: «Ий, Һабил, мин сине, әлбәттә, үтерәчәкмен»,—дип. Һабил әйтте: «Әлбәттә, Аллаһу Тәгалә тәкъва кешеләрнекен кабул итәдер», дип. 28. Һабил Кабилгә әйтте: «Син мине үтерергә кулыңны суза торган булсаң да, мин сине үтерергә кулымны сузачак түгелмен. Мин бөтен галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһ газабыннан куркамын»,—дип. 29. Әгәр мине үтерсәң, син минем гөнаһымны һәм үз гөнаһыңны йөкләп, Аллаһуга кайтуыңны телимен, бу золым эшеңне эшләсәң ут әһеленнән булырсың. Ут газабы: залимнәргә тиешле җәзадыр. 30. Нәфесе аңа галиб булды, ягъни нәфесе Кабилне җинде, Һабилне үтерергә аны өстерәде, Кабил Һабилне үтерде вә хәсрәтләнүчеләрдән булды. 31. Алла Кабил янына бер карга җибәрде, ул карга Кабилгә җирне казып күрсәтте, ягъни Һабилнең гәүдәсен күмәргә өйрәтте. (Чөнки Кабил Һабилне үтергәч, кайда куярга белмичә, берничә көн күтәреп йөрде.) Карганы күргәч, Кабил әйтте: «Һай миңа үкенеч! Каргадан да көчсезрәк идем мәллә? Карга белгәнне дә белмәдем, әгәр белгән булсам, кардәшемнең гәүдәсен ничә көннәр күтәреп йөрмичә, үтерү белән күмгән булыр идем»,—дип. Бу эшеннән соң үкенүчеләрдән булды.

Хәзер Һ. Такташның «Җир уллары» трагедиясеннән югарыда китерелгән Коръән аятьләренә охшаш сюжетларны барлап карыйк. Әсәрдә дә нәкъ шулай ук Кабил белән бер карында яткан Әкълимә Ходай әмере буенча Һабилгә тиеш була. Бу хәбәрне Җәбраил Канун җиткерә:

*Кил, Адәм! Тәңре сиңа*
*Күндерде кодрәт фәрманы,*
*Әкълимәне бир Һабилгә!*

Тик Кабил әлеге әмергә буйсынмый: Әкълимәне үзенеке итү өчен, туганы Һабилне үтерә. Менә ничек тасвирлый бу күренешне Такташ:

*Тукта, кем бу монда ялгыз?*
*Чү, Һабил мескен, синең*
*(Хәнҗәрен ала)*
*Җитте инде соңгы гомрең.*
*(Сәхнәгә газраил чыга)*
*Бу суык хәнҗәр минем*
*Өзгәләр бәгъремне сырган*
*Бар әсирлек бауларын,*
*Теткәләр алдымдагы барлык*
*Каанлык тауларын!!*
*(Хәнҗәре белән Һабилне чәнчә)*

Шуннан соң Кабил, нәкъ Коръәндә язылганча, кылган гамәле өчен бик үкенә, тынычлыгын җуя:

*Нишләдем мин?*
*...Тор, Кабил! Тор, суз кулыңны,*
*Мин синең хөкмең көтәм...*
*Канлы күкләр киртә итеп*
*Юлыма куйгач сине,*
*Үч итеп күкләргә үтердем...*

Һабил... Кичер мине!—дип, шашкын хисләр кичереп, Һабилнең канга баткан үле гәүдәсенә ялвара.

Кабил бу ялгышлыкны Газазил-Иблис коткысына бирелеп эшли. Идея Кабилне дингә каршы котырта, тормыш авырлыгында Ходайны гаепли.

*Кызганыч, мескен җир улгы!*
*Кул сузасың аллага,*
*Белмисең: ул күктә сиңа*
*Зур тамуг, утлар яга...*

Газазил үзен «гали», «ак күңел» дип атый. Кабил аңа бик тиз ышана:

*Булса, ул сузсын кулын,*
*Дуслык белән бәгърен ачып,*
*Мин явыз, вәхши түгел, ул*
*Тормасын миннән качып!.,*

—ди ул. Ә Газазил ялганлавын дәвам итә:

*... Бир кулыңны! Әйдә моннан*
*Кач ерак!*
*Монда аллалар, залимнәр,—*
*Кимсенеп торма елап...*

Кабил авыр, газаплы ач тормышның сәбәбен сорагач та Газазил янә Ходайны гаепли:

*Чөнки сез коллар,*
*Рәхимсезләр кулында кан сагып*
*Көн күрәсез, мәманәт*
*Вәхши ходайга буйсынып.*
*Уйный ул күктән торып,*
*Сезнең газаплардан көлә,*
*Калдырып ерткыч, котырган*
*Юлбарыслар иркенә,*

—ди һәм буш вәгъдәләр бирә.

Коръәндә Бәни Исраил (Ягъкуп балалары) сурәсенең (17нче сурә) 62 64 аятьләрендә Иблиснең кешеләрне хак юлдан яздыручы икәнлеген раслаучы юллар бар. 62. Янә Иблис әйтте: «Я, Рабби, ни өчен бу Адәмне миннән артык кылдың? Әгәр миңа кыяматкә чаклы яшәргә ирек бирсәң, әлбәттә Адәмнең балаларын йөгәнләп яман юлга, бозык эшләргә тартырмын, мәгәр бик азлары калыр». 63. Аллаһ әйтте: «Кит алдымнан! Кем сиңа иярсә, аларның һәм синең газабыгыз камил җәһәннәм газабы булыр». 64. «Ий, Иблис, тавышың белән өндәп кешеләрдән көчең житкәннәренә аздыр вә аларны аздыру өчен атлы вә җәяүле гаскәреңнән ярдәм сора һәм аларның малларында вә балаларында уртак бул, дәхи ялган вәгъдәңне әйт! Шайтанның вәгъдәсе алдаудан башка нәрсә түгелдер». Газраилнең буш сүзләр сөйләп алдаганын Әкълимә сүзләреннән дә күрәбез. Ул Кабилне кисәтергә тели.

*Нишләдең син? Нишләдең син?!*
*Куркыныч, аh! Куркыныч—*
*Алдыңда мин упкын күрәм;*
*Мәңгелек бушлык—караңгы,*
*Күз җиталмәслек тирән...*
*Син адашкансың,*
*Сине азгын Газазил алдаган,*
*Юлларыңны куркыныч нәрсә белән*
*Ул каплаган.*

Һабил дә, Кабилне Ходайдан ярлыкавын үтенеп, шушы ук фикерне әйтә; шул рәвешле Газазилнең алдакчы булуы кабатлана:

*Ул адашкан тугры юлдан,*
*Дәргяһын табалмаган,*
*Мәңгелек сөрген Газазил*
*Ул колыңны алдаган...*
*Сал үзең син тугры юлга,*
*Ярлыка гаебен, рәхим!*
*Кодрәтең тиңсез синең һәм*
*Шәфкатең чиксез вә киң!*

Әсәрдә Кабилнең туганнары да, ата-анасы да Ходайдан Кабилне ярлыкавын сорыйлар, тик Аллаһы Тәгаләдән ярдәм булмый, чөнки Кабил ата-анасы, туганнары, Канун үгетләвенә карамастан тәүбәгә килми, Ходайдан ваз кичеп, Идеягә иярә. Такташның әлеге сюжеты да Коръән аятьләрен нигез итеп язылган булса кирәк. Мәсәлән Гимран сүрәсенең 26нчы аятендә болай диелгән: «Аллаһу Тәгалә һичкемгә көче житмәгән эш белән көчләмәс, мәгәр көче житкән эш белән көчләр. Берәү Аллаһуга буйсынып изге гамәлләр кылса, файдалы эшләрне генә эшләсә—файдасы үзенәдер, әгәр берәү Аллаһуга карышып гөнаһларны, явыз эшләрне кәсеп итсә—газабы үзенә». Ниса сүрәсенең 173 аятендә дә шундый ук мәгънә бар: «Аллаһуга ышанып изге гамәлләр кылучыларга Аллаһу Тәгалә әҗерләрен тутырып бирер һәм юмартлыгы белән әҗерләрен арттырыр, әмма Аллаһуга итагать итүдән баш тарткан, гыйбадәт кылудан тәкәбберләнгән кешеләрне аллаһ газаб кылыр рәнжеткүче газаб белән.»

Менә тагын Бәни Исраил сүрәсеннән 65нче аять: «Әмма минем ихлас колларыма синең ихтыярың булмас, ягъни көчең житмәс. Үзе теләгән кешеләрне синең зарарыңнан сакларга Раббың үзе житәдер.»

«Жир уллары» трагедиясеннән аңлашылганча, Аллаһы Тәгаләгә буйсынмаган кеше гел бәла-казаларга очрап тора. Тәһа сүрәсенең 123—124нче аятьләрендәге Аллаһы Тәгалә сүзләрен мисалга китерергә мөмкин: «...кем һидаятьне сайласа, адашмас һәм бәхетсезлеккә юлыкмас, ә кем Минем сүземнән (Коръәннән) йөзен борса, аның тормышы тараер һәм Без аны Кыямәт көнне сукыр итеп тергезербез...»

Югарыда телгә алынган Майдә сүрәсенең 28 нче аятеннән аңлашылганча, Кабил үтерү белән янаган чакта да Һабил туганын үтермәячәген әйтә, андый кешегә газаплар киләчәк дип, Кабилгә дә аңлатырга тырыша. Әсәрдә дә нәкъ шушы ук фикер кабатлана. Такташ аны шигъри юлларга салып тагын да үтемлерәк итеп бирә. Һабил туганын ярлыкавын сорап Ходайга мөрәҗәгать кыла.

Һабилдә туганлык хисе бик көчле. Үз бәхете өчен туганын үтерү түгел, киресенчә, туганы өчен үзен корбан итәргә дә әзер.

*Ал кирәксә, ал җанымны,*
*Ал иләһым, ал да аны*
*Сал тамугларга, газапла,—*
*Тик, бөеклек солтаны,*
*Син азаплама Кабилне!*

Такташның үз әсәрләренә Коръән аятьләрендәге персонажларны кертүе юкка гына түгел. Ул бик уйлап, Коръәндә аңлатылган вазифаларын яхшы белгән хәлдә әсәрләренә урынлы китереп кертә.

Әйтик, унай геройларны Җәбраил Канун кебек Ходайга тугрылыклы фәрештәләр, пәйгамбәрләр образы аша бирә; тискәре күренешләрне, начар кешеләрне гәүдәләндерү өчен Газазил, Газраил кебек персонажларны куллана; мәрхәмәтле кешеләрне тасвирлау өчен шагыйрь Ходайга гыйбадәт кылучы Һабил, Әкълимә, Адәм, Һава образларын уңышлы файдалана.

Ә инде кем ни әйтсә, шуңа ышанучы, үзенең ныклы кыйбласы да, дине дә, әхлагы да булмаган кешеләрне бер образ Кабил образына җыеп бирә шагыйрь.

Кабил кебек динсез кеше туганын үтерү кебек иң авыр җинаять кылудан да тайчынмый, мәхәббәтне дә ул җил кебек иркәле булырга тиеш дип саный.

*Әйдә бу каргалган илдән*
*Без сәгадәткә таба*
*Юл салыйк, очыйк икәү*
*Иркен хәятле дөньяга!*
*Кайда юк алла, канун*
*Һәм эч пошу, хәсрәт, көек;*
*Кайда без иркен яшәрбез,*
*Хөр, азат җилләр кебек...*

—ди Кабил Әкълимәгә.

Гаилә тормышы турында сөйләгәндә, «Җилләр кебек хөр, азат яшәрбез» дигән чагыштыруның Такташ тарафыннан юмор белән сугарылганын аңлавы кыен түгел. Динсез тормышлы гаиләдә билгеле бер тәртип-кануннар юк, кем гаиләнең хуҗасы, ир һәм хатын вазифасы нидән гыйбарәт булуы да билгесез—кем ничек теләсә шулай яши. Нәкъ җил кебек.

Канун сүзләрендә исә диндә кушылганча, әхлаклы никах турында, ныклы мөселман гаиләсе төзү турында сүз бара.

*Әйе, Һабил алсын аны!..*
*Бергә торсыннар алар*
*Кушылып кыяметкә кадәр,*
*Бергә кылсыннар гыйбадәтләр,*
*Шөкерләр, сәҗдәләр...*

Биредә җил кебек иркәле гаилә турында сүз бармый инде, Коръән кушканча, гомер буе бергә җитди тормыш алып бару турында сүз бара.

Без Такташның биографиясеннән һәм гаилә проблемасын күтәргән әсәрләреннән чыгып, аның гаилә мәсьәләсенә бик җитди караганлыгын, мәхәббәт, гаилә ул— җаваплылык дип санаганын яхшы беләбез. Биредә дә Такташ Коръән аятьләренә таянып эш итә, фикер йөртә. Ислам дине гаилә тормышына зур әһәмият бирә. Динебез буенча гаилә тормышы никах белән башлана. Өйләнмичә, никахсыз тору динебездә хәрәм санала. Никахсыз ир-хатын якынлыгы зина кылу дип атала. Барлык диннәрдә дә зина кылу хәрәм булып исәпләнә; чөнки ул аерым кеше өчен генә түгел, милләт, җәмгыять өчен дә зарарлы. Коръәндә Аллаһы Тәгалә болай боера: «Зина кылмагыз. Шик тә юк, ул бер әдәпсезлектер һәм начар бер юлдыр» (Исра сурәсе, 32нче аять).

Такташ хатын-кыз образын сурәтләгәндә дә, Коръән аятьләренә таянып, идеаль хатын-кыз нинди булырга тиешлеген исбатларга тырыша. Исламда тәнне күрсәтү—гаурәт. Озын күлмәк хатын-кызны яман күзләрдән, тозсыз сүзләрдән саклый һәм шуның белән аның абруен күтәрә. Шагыйрьнең «Җырым сиңа булсын» дигән шигырендәге тәнкыйть уклары әнә шушы күркәм ышанычка, милли гореф-гадәтләребезгә нигезләнеп язылган.

Фатих Сәйфи-Казанлының: «Нигә соң Газазилләр, Газраилләр белән

маташасыз, жирдә кешеләр беткәнмени, дигән соравына Такташ: «Мине мәңгелек әйберләр, бөек проблемалар кызыксындыра»[2];—дип җавап бирә. Такташ иҗатындагы мәңгелек образларның нигезе халыкның тормыш-көнкүреше, тарихы, дине, фольклоры һәм, гомумән, культурасы. Такташның мәңгелек образлары—милли, дини. Шагыйрь иҗатында күтәрелгән мәңгелек проблемалар алар—милли традицияләрне саклау, аларга бәрәкәтле караш, сакчыл мөнәсәбәт булдыру мәсьәләсе.

Халкыньың үтмешенә борылып карау, тарихи-мәдәни җәүһәрләрне сакларга омтылу—Һ. Такташ карашынча, киләчәккә омтылу шикелле үк җәмгыять үсеше өчен бик кирәкле нәрсә. Әйтергә кирәк, милли, дини идеянең чыганагын әнә шулай Коръән аятьләреннән эзләп, Такташ татар халкының борынгыдан килә торган уй-фикерләрен, хыял-омтылышларын, акыл-зиһенен, рухи-әхлакый сыйфатларын тергезергә, шулардан үрнәк алырга чакыра. Коръәндә телгә алынган җәннәт, фәрештәләр, пәйгамбәрләр, Газраил, Иблис, җеннәр, алар белән бәйле риваятьләр, ул вакыйгаларда катнашкан төрле персонажлар Такташ шигырьләренә бик табигый кереп, тыгыз үрелеп баралар, шагыйрьнең әйтәсе килгән фикерен үтемлерәк бирергә ярдәм итәләр. Чөнки дин тоткан, аның тиешле кагыйдәләрен үти торган, Коръәнне, әдәбиятны яхшы белгән кешегә болар барысы да бик якын, аңлаешлы.


Шагыйрь күп гасырлык бай әдәби традицияләребезгә таяна. Әдәбиятыбызга яңалыклар алып килүче буларак танылса да, ул иҗатының бөтен тамырлары белән борынгы татар әдәбиятына, Көнчыгыш әдәбиятларына һәм тулаем Ислам мәдәниятенә, аның олы казанышларына-тарихи сюжетларына, мотивларына һәм форма-шәкелләренә тоташа, шулардан үсеп чыга. Кече яшьтән үк гади халыкның иң самими ышануларын, мәҗүсилек чорыннан ук килгән мифологиясен, мәдрәсәдә Ислам динен һәм аның риваятьләрен күңеленә сеңдереп, Ислам әдәбиятын укып үскән Такташ, иҗатында шуларны шигъри таланты, кодрәтле каләме аша үткәреп, элекке җирлектә, әмма яңа, югарырак дәрәҗәдә, үз заманына ярашлы һәм үзеннән соң да яшәячәк гүзәл әсәрләр тудыра алган. Такташның иҗаты борынгы әдәби мирастан һич аерылгысыз, аның шигырьләре шуңа күрә дә—бик халыкчан, вакыт сынауларын җиңеп үтә торган үлемсез әсәрләр. Такташ иҗатындагы дини мотив, фәлсәфә һәм образлылык гомумкешелек әхлакый кыйммәтләренә ирешүдәге үзенчәлекле бер баскыч буларак кабул ителергә тиеш.

**Минзифа ТАҖЕТДИНОВА,**
*Чүпрәле*

[2] Такташ Һ. Әсәрләр: 3 томда. Т. 1: Шигырьләр һәм поэмалар. Казан: Татар. китап нәшр. 1980. – Б.458.

# ТУФАННЫҢ КАЙТУЫ

2010 елда чорыбызның иң зур—Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлилләр белән бер рәттә торучы—шагыйре Хәсән Туфанның туына 110 ел тулачак. Шул вакытка аның биш томлык әсәрләре Татарстан китап нәшриятендә басылып чыгачак. Бу томнар 2007 елдан чыга башлады. Бүгенге көнгә биш томның өчесе басылып, укучыларга ирешге дә инде.



Бер яктан карaганда—куанычлы хәл. Моңача Туфанның мондый тулы басмасы чыкканы юк иде әле. Ләкин чыккан томнары белән танышу шактый каршылыклы—сөенечле дә, көенечле дә фикерләр тудыра. Шул фикерләрем белән уртаклашырга телим.

**Сөенечлесе.** Билгеле булганча, Хәсән абый үзе исән чагында әсәрләрен бастыруга әллә ни әһәмият бирми иде. Ярты гасыр дәвердә туган телендә аның нибары унлап җыентыгы басылып чыкты. Аларны да күбесенчә үзе түгел—башка кеше төзеп бирә иде. Нигездә бу җыентыклар бер үк әсәрләрдән тора.

Укучыларга ирешкән өч томда шагыйрьнең билгеле булган барлык шигырьләре һәм поэмалары урнашкан. Калган ике томда аның язмалары: татар шигыренең теоретик нигезләрен тикшерүче һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, публицистикасы, кайбер хатлары алачак. Әлеге томнар белән танышкач, шуны күрәсең—мондагы әсәрләрнең яртысы моңача Туфан китапларында беркайчан да басылмаган шигырь һәм поэмалардан тупланган. Яртысы ! Кайбер шигырьләре кайчандыр вакытлы матбугатта дөнья күреп тә, күптән онытылган, укучылар һәм әдәбиятчылар игътибарыннан читтә калган. Күбесе исә беркайда да басылмаган, каралама хәлендә шагыйрьнең өстәл тартмасында яткан.

Шулай итеп, әлеге томнар Туфан иҗатын бөтенләй яңа яктан, шактый тулы итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Моның өчен без төзүче, әдәбият белгече Мәсгуд Гайнетдиновка рәхмәт әйтергә тиешбез. Ул күп еллар буе Туфан иҗатын җентекләп җыю һәм өйрәнү белән шөгыльләнде, бу изге эшкә күп көч куйды. Кайбер әдәбият белгечләре теге яки бу классик шагыйрьнең берәр яна шигырен тапса да, түбәләре күккә тия яза, шуның нигезендә диссертацияләр яклыйлар, мактаулы исемнәр алалар. Монда исә тикшерүче Туфан иҗатының яртысын диярлек туплап, укучыларга яңадан ачып бирә алган!

Шулай итеп, бу томнарны чыгару әдәбият хәзинәбезне баета, әдәби әйләнешкә моңача билгеле булмаган яңа әсәрләр кертә. Поэзия үсешенә, аеруча яшь алмашка аларның шифалы тәэсире булыр дип ышанырга кирәк.

**Көенечлесе.** Туплавын туплаган, әмма тәртипкә салып, фәнни нигезле итеп

бирә алмаган. Томнар белән таныша башлагач, аларның бик буталчык булуын күрәсең.

Томнарны чыгаруда Татарстан китап нәшрияте шактый бай тәҗрибә туплады. Гадәттә шагыйрь әсәрләре хронологик тәртиптә, жанр буенча аерым бүлекләргә җыеп бирелә. Монда исә төзүче җинел, ләкин хата юлдан киткән. Ул башта китапларда чыккан шигырь-поэмаларны бирә. Аннан соң, янадан егерменче еллардан башлап китапларга кермәгән, вакытла матбугатта басылган яисә бөтенләй басылмаган шигырьләр тезелеп китә. Бу яна тәртипкә ияләшергә өлгермисен, әлеге тәртип тә бозыла. 1934 елда язылган шигырьләре артыннан 1957 елда иҗат ителгән, язган елы күрсәтелмәгән һәм төрле елларда язылган шигырьләр урын ала. Кыскасы, китап белән файдалану кыенлаша. Кирәкле әсәрне таба алмыйча җәфаланып, буталып бетәсең.

Югыйсә күп томлыкларда әсәрләрне урнаштыру тәртибенең үз фәнни кануннары бар. М. Гайнетдинов та, филология фәннәре докторы һәм танылган текстолог буларак, аларны белергә тиеш. Туфан шигырьләрен хронологик тәртипне саклап, берничә бүлеккә аерып, укучыга унайлы, аңлаешлы итеп бирергә кирәк иде. Беренче чор иҗаты—егерменче еллар уртасыннан утызынчы еллар уртасына чаклы. Икенче чор—утызынчы еллар уртасыннан 1940 елның ахырына, ягъни кулга алынганга чаклы. Бу чор кыскарак булса да, беренче чордан үзенең лирик җылылыгы, халыкчанлыгы белән шактый аерылып тора. Өченче чор—тоткынлыкта һәм сөргендә язылган шигырьләре һәм поэмалары. Сөргеннән кайтканнан соңгы иҗатын шулай ук берничә дәвергә бүлеп була. Әйтик, Хрущев чорында иҗат ителгән әсәрләре торгынлык чорында язганнарыннан күп ягы белән аерылып тора.

**Сөенечлесе.** Туфанны бик күпләр чын күңелдән ихтирам итә, әсәрләрен яратып укый, кайберләрен яттан белә. Аның китапларына рецензияләр, зур-зур мәкаләләр, истәлекләр язучылар да байтак. Әмма бөтен гомерен Туфан иҗатын өйрәнүгә багышлап, фәкать шул эш белән генә шөгыльләнүче кеше—бердән-бер. Ул—әлеге дә баягы Гайнетдинов.

Мәсгут ага—шагыйрь исән чагыннан ук көн саен диярлек аның янына барып, озак-озак сөйләшеп, әсәрләре белән танышып, күчермәләрен алып, кыскасы җаны-тәне белән бу эшкә бирелеп йөргән кеше. Туфан вафатыннан соң, шагыйрьнең туганы Мөнҗия апа янына йөреп, шагыйрьнең бөтен архивын җыеп, барлап, өйрәнеп чыкты ул. Шуна күрә дә Туфанның бөтен рухи байлыгы диярлек бүгенгесе көндә аның кулында тупланган.

Әсәрләрен туплап җыюдан тыш, ул шагыйрьнең гомер юлын да тирәнтен өйрәнде. Менә, әйтик, Туфанның 1918-1922 еллардагы тормышы әлегәчә ак тап булып кала бирә иде. Хәсән абый үзе бу турыда ләм-мим дәшмәде, төпченә башласаң—ачуланып китә, кәефе кырыла иде. Ни өчен?

М. Гайнетдинов тикшерүләре буенча, яшь Хәсән Туфан (ул вакытта әле «Галия» мәдрәсәсе шәкерте Хисби Хәзрәтев) 1917-1918 елларда Уфада Милли Мәҗлес утырышларында турыдан-туры катнашкан. Гади күзәтүче буларак түгел җаваплы сәркатиб—стенографист буларак, һәр чыгышны тынлап, язып-теркәп барган. Соныннан акка күчереп, гарәп шрифты белән матур, аңлаешлы итеп язып биргән. Большевиклар Мәҗлесне тыеп, анда катнашучыларны кулга ала башлагач, Милли Идарә Петропавловск шәһәренә күчә. Идарәнең барлык архивын саклап, шунда алып баруны да шул ук ышанычлы, тырыш, милләт эшенә җаны-тәне белән бирелгән Хәзрәтевкә тапшыралар. Ул гражданнар сугышының иң кызган чагында авыр йөкне күтәреп, көн-төн йокламыйча, (ул чорда угрылар мыжлап торган), тиешле урынга китерә. Әмма тапшырырга тиешле кешесен анда тапмагач, архивны Омскига, аннан соң Байкалның аръягына илтә, вазифасын намуслы итеп башкара.

Ул гына да түгел, Гаяз Исхакыйга Чита аша чит илгә эмиграциягә китәргә булыша, аны саклап, Россия чигенә хәтле озатып бара. Соныннан, Ерак Көнчыгышта калгач, Милли шура эшләрендә актив катнаша, яшьләрне милли рухта тәрбияли. Кыскасы, М. Гайнетдинов фикеренчә, бу чорда Туфан үзен чын мәгънәдә милләт каһарманы итеп күрсәтә. Совет чорында андый милләтпәрварларны җыеп-себереп атып бетерделәр. Бик сирәге генә чит илгә качып котылды. Туфанның бу турыда ләм-

мим дәшмәве шуның белән аңлатыла, ди М. Гайнетдинов.

Фәкать шуны гына ачыкласа да, М. Гайнетдинов әдәбият фәненә зур өлеш керткән булып саналыр иде.

**Көенечлесе.** Югарыда әйткәнчә, классик язучыларның томнарын чыгарганда фәнни нигезләргә таянып эш итәргә кирәк.

Ин элек төпле, бөтен иҗатын күзәтеп бәя биргән кереш сүз мәҗбүри. Беренче томда басылган, төзүче тарафыннан язылган кереш сүз исә бик йомшак, өстән-өстән генә язылган. Ул Туфанның 1974 елда чыккан икетомлыгында басылган Т. Галиуллин кереш сүзеннән шактый кайтыш. Биштомлыкны кулына алган укытучы М. Гайнетдинов кереш сүзеннән Туфанның иҗат һәм тормыш юлы турында тулы мәгълүмат ала алмый, һич югы биографик белешмә булса да бирергә кирәк иде.

Икенче таләп: һәр әсәрнең моңача кайда басылганы, басылмаган булса, кайда саклануы күрсәтелергә тиеш. Туфан иҗатына карата бу кагыйдә аеруча мөһим, чөнки аның әсәрләре катлаулы язмышка дучар булды. Аккош күлендәге язучылар дачасында күрше йортларда яшәгәндә мин шагыйрь янына еш кереп йөри идем, өстәлендәге кәгазь өемнәре турында сораша идем. Шунда ул мина кайбер шигырьләрен укып, аңлатма бирә иде. «Монысы—каралама гына... Бераз ятып торсын әле. Киләчәктә яңадан кайтып эшләрмен, яисә ертып ташлармын. Монысы—минеке түгел, кеше шигыре. Яраткач, язып алдым. Хәзер инде яттан да беләм. Башкаларның уңышларыннан өйрәнергә кирәк ич. Ә монысы исә—төрмәдә язылган, шәп, әмма «куркынычрак» шигырь. Аның әле вакыты җитмәгән. Ята бирсен. Мин үлгәч басылыр.»

Әйе, шагыйрь иҗат дәверендә искиткеч тыюларга, чикләүләргә юлыга. Соңгы көннәренәчә кайбер уй-фикерләрен яшереп торырга мәҗбүр була. Шул ук вакытта ул шигърияттә классик камиллеккә омтыла, үзенә карата искиткеч таләпчән була. Томнарны матбугатка әзерләүче боларны истә тотарга тиеш.

Туфанга хас тагын бер сыйфат—ул элек басылган шигырьләренен яна вариантларын яза иде, кат-кат төзәтә иде. Төзәтә-төзәтә үзе дә буталып бетә иде. Бирелә төзүче искәрмәләре булмагач, укучы да бу әсәрләр арасында үзен кара урманга кергән сыман хис итә, адашып бетә.

Туфан әсәрләрендә бүгенге укучыларга таныш булмаган исем-фамилияләр, ниндидер онытылган вакыйгалар телгә алына. Аларга да аңлатмалар кирәк. Андый аңлатма булмагач, биштомлыкның кыйммәте бик нык кими. Биштомлыкларны ел саен чыгарып булмый бит. Калган ике томда булса да искәрмәләр һәм аңлатмалар бирелсен иде.

Шагыйрь үзе исән чагында аның кайбер әсәрләре, әйтик Киров турындагы «Ант» поэмасы, каты тәнкыйть утына эләкте. Илленче еллар уртасында да андый вакыйгалар кабатланды. Боларның барысы турында да искәртеп китәргә кирәк иде.

Кагыйдә буларак, томнарда язучыны тулырак итеп күз алдына китерерлек фотолар бирелә иде. Монда алар да юк.

Бу житди кимчелекләрдә мин бер төзүчене генә гаепләмәс идем. Гадәттә күптомлыкларның махсус редколлегиясе, фәнни редакторы була. Монда алар юк. Тукай, Такташ, Җәлил томнарын әзерләгәндә ИЯЛИ галимнәре турыдантулы катнашып, еллар буе эшлиләр иде. Монда исә бөтен текстологик эш сиксән яшен тутырган галим өстенә йөкләнгән. Әлбәттә, ул берүзе моны ерып чыга алмаган.

Кызганыч.... Әкияти Феникс кошы ут-ялкында янып, яңадан туа. Туфан иҗаты да шуның шикелле ничә кат тыелып, яңадан халыкка кайта. Әмма аның укучыларга тагы бер кат, вафатыннан соң кайтуын матуррак итеп күрәсе иде.

**Рафаэль МОСТАФИН**

# ШАЯН ТАЛАНТ

Марсель Сәлим—башкорт, татар һәм урыс телләрендә иҗат итүче язучы-сатирик. Аның әсәрләре Башкортстан һәм Татарстанда гына түгел, Русиянең башка төбәкләрендә дә, үзәк матбугатта да еш басыла.




2007 елда Уфада башкорт һәм урыс телләрендә «Әйттем—бетте!» исемле шырпы кабы зурлыгында гына сувенир китабы, Казанда «Үзебезнен агай-эне» (Татарстан китап нәшрияты) исемле хикәяләр һәм скетчлар җыентыгы дөнья күргән иде. 2008 елда исә «Идел-Пресс» нәшрияты аның «Мәңгелек мәхәббәт» исемле шигырьләр китабын бастырып чыгарды. Ә Яр Чаллыда нәшер ителүче «Мәйдан» журналы үзенең бер санын Марсель Сәлим иҗатына багышлады.

Марсельнең иҗаты белән мин инде байтак еллар кызыксынып киләм. Сатирик һәм юморист буларак ул уңышлы эшли. Сатираның бүгенге халык тормышында хөкемдар икәнлеген ул яхшы аңлый. Аның каләменең төп көче—хаклык. Иҗат иткәндә ул, минемчә, беренче чиратка хисләрен түгел, ә акылын алга куя. Ул шундый тынгысыз җан, уйлаган әсәрен язмыйча түзә алмыйдыр сыман. Сон, шулай булмый, шаян, шаулы дулкынлы, ашкынып аккан житез Танып буенда туган бала бит ул! Юкка гынамыни малай чагында ук болай дип язган:

*Таныпкаем тынычлыгын җуйган—*
*Ярсып кага ярга ташкыны.*
*Аның кебек мин дә тынгысыз җан—*
*Кабаланып алга ашкынам.*

Әсәрләрен язганда ул кыскалыкка омтыла. «Кыскалык—осталык» дигәнне хәтерендә тотып, озын шигырьләрдән читләшеп, ялыктыргыч сүз боткаларыннан арынып, әйтергә теләгән фикерен үзенә генә хас булган сурәтләү чаралары ярдәмендә тыгыз шигъри юлларга сыйдыра. Хәлвакыйгалар нинди күренеш аша бирелсә дә, укучы аны укыгач, үзенчә уйлана, үз тормышындагы чынбарлык белән чагыштырып талантлы шагыйрьнең ни әйтергә теләгәнен тирәнрәк, ачыграк аңлый. Ә бит кыска шигырьләр тизрәк тә, күбрәк тә укылучан.

Мар. Сәлим—замана язучысы. Ул тормышыбыздагы төрле хәлләрне үз йөрәге аша уздырып тасвирлый. Шуңа күрә дә күпчелек шигырьләре укучы хәтеренә тирән уелып кала.

Шуны әйтәсе килә: безнең кайбер шагыйрьләрнең озын шигырьләрен укый башласаң, аның азагына житкәнче, башындагы фикерләр онытыла. Моннан котылуның юлы бер генә: озын шигырьләрне, аларның эчтәлегенә зыян китермичә, мөмкин кадәр кыскарту! Марсель моны аңлый, укучының китап укуга сарыф итәсе кадерле вакытын җилгә очырмаска тырыша.

Заман язучысы, үзе хәтта өстәге түрәләрнең кысымы астында авыр хәлләрдә калса да, дөреслек өчен аяусыз көрәшергә бурычлы. Марсель иҗатында кыюлык, курыкмаучанлык ачык күренә. Әсәрләре иле, халкы, чоры тормышына нигезләнгән. Әдип табан ялаучыларны, юхаларны, куркакларны, гомумхалык милкен талаучы комсыз, хәйләкәр каракларны—олигархларны, йөзләрен матурлап ялган битлек кигән астыртын бю-

рократ-чиновникларны сатира камчысы белән аяусыз каезлый. Дөреслек белән ялганның капма-каршылыгын уйланырлык итеп әсәрләрендә бирә белә.

Бер генә мисал. Үзе белән бергә уйнап, бергә укып, күршеләре бакчасыннан бергә яшелчә-җимеш урлап, яшьлектә бергә шаярып үскән дусларның берсе икенчесе янына килә. Тегесе бүген «югары борынлы» түрәгә әверелгән икән, аны танырга да теләми. Шулай да, көне буе көтеп торгач, кабул итә яшьлек дустын. Ләкин барыбер «танымый». Ахырда ана килүче:

*—Ярый инде, гаепләштән*
*Булмасын, дускай, һич тә.*
*Мин тикшерү белән килдем—*
*Төшерәм синең искә!—*

дин әйтергә мәҗбүр була. Шунда гына текә түрәнең исенә төшә иске дусы...

Заманыбызның рухи тормышына, проблемаларына язучының игътибарлы үз карашы бар. Аның максатында сатира үткерлеге, җылы юмор елмаюы. Бүгенге көндә сатира-юмор жирлегендә дөреслеккә әйдәүче буларак, ул әдәбият мәйданында ныклы басып тора. Тавышы гаделлек даулап, көчле янгырый. Аның иҗатында төрле жанрлар бергә култыклашып атлыйлар. Әдипне җаваплылыкка әйдәүче көч—аның әдәбиятка чын күңеленнән гашыйклыгы. Ул журналист буларак та тормыш серләрен аңлаган кеше. Менә инде өч дистә еллап Башкортстанның «Һәнәк» сатира һәм юмор журналында баш мөхәррир булып эшли. Бу язмышы да аны иҗади уңышлыкларга әйдидер диясе килә.

Марсель сүзләр белән бик сак эш итә. Тел—аралашу, аңлашу коралы гына түгел, кешеләрнең табигатен, холкын, рухи эшчәнлеген дә чагылдыру чарасы. Шагыйрь сөйләм теле үзенчәлекләреннән, халыкның тел байлыгыннан оста файдалана. Аз сүз белән тирән мәгънә аңлатуга ирешә. Аның шигырьләре—кыска юлларда, ә инде фикерләре—акыл киңлеге мәйданында. Ул бервакытта да көлкеле сүзләр белән урынсызга мавыкмый, югарыда әйткәнебезчә, кыскалыкка, сүзләр үткерлегенә омтыла. Шигырьләре яратып укыла, кем әйтмешли, көлдерә дә, көйдерә дә. Әйтик, менә мондыйлары:

*Күпме кызлар янар иде*
*Безнең гыйшык утында...*
*Ярый әле өебездә*
*Аш пешереп, уклау тотып,*
*Көтеп торган хатын бар.*

Әйе, Марсель көлеп яшәүне хуп күрә. Бу хакта ул үзе дә болай ди:

*Көлә-көлә киләм сезгә,*
*Көлке сөйгән дусларым.*
*Сезнең белән көрешергә*
*Кычый минем учларым.*

Мар. Сәлим сатира, юмор жанрының күптөрле алымнарын уңышлы үзләштергән. Аларда халык мәзәкләренә хас беркатлы көлүне дә, миниатюр мәсәлләрне дә, урынлы гына сүз уйнатуны да, пародия яки фельетон алымын да очратырга мөмкин. Сатира чараларының берсе булган диалог та уңышлы файдаланыла.

Шагыйрьнең кайбер дүртьюллыкларын «миниатюр мәсәлләр» дип тә атыйсы килә. Аларны мәсәл итә торган төп шарт—тискәре күренешләрне хайваннар яки кошлар, бөҗәкләр образында типиклаштыру, аллегория куллану. Автор азактан аңлатып бирүне кирәк дип тә санамый—мәсьәләне үткер әйтелгән ирония хәл итә:

*—Йокламабезне утәдек!*
*Кикриккүк! Тантана!—*
*Тавык салган йомыркага*
*Әтәч шулай мактана.*

Яки:

*Кияүгә чыккач Энәгә,*
*Әйтте Җеп эре генә:*
*—Миңа эләкмәсә башың,*
*Югалыр идең, Энә!*

Элек, совет чорында, матбугатта кайбер шәхесләрне мактаган әсәрләргә күп урын бирелде, тәнкыйтькә урын тар иде. Бүген исә цензура юк, тәнкыйтькә киң юллар ачылды, дибез. Әмма шулай булуга карамастан, кайбер мөхәррирләр, югарыдагылардан куркып, илдәге житешсезлекләр, түрә-каранын хилафлы эшләре турында материалларны тоткарлыйлар, аларны өстәл астына яшерәләр. Ә менә Марсель бу җәһәттән куркуны

белми. Әче дөреслекне мөхәррир буларак та, сатирик буларак та аңлый, халык, закон хөкеменә чыгарырга тырыша. Үз әсәрләрендә исә заманыбыз буталчыкларын, җәмгыятебездәге житешсезлекләрне аяусыз фаш итә. Менә ул бүгенге ветераннарнын тормыш хәлен ничек тасвирлый:

*Көрәштеләрме, килсен дип*
*Менә шундый заманнар?*
*Җиңелгән җиңүчемени*
*Бүгенге ветераннар?!*

*Йөриләр башларын иеп,*
*Сугышта җиңүчеләр.*
*Утыралар борын чөеп,*
*Берлинны бирүчеләр.*

Янә тагын бер күренеш:

*Тишелгәндер инде күкнең төбе!*
*Басуларда ятып еларлык.*
*Ямап куяр идем тишек күкне,*
*Ямаулык юк шуңа ярарлык.*

*Бөтен тормышыбыз тишек-тошык—*
*Ничек җиткерик соң ямаулык?*

Ә бусы илебез хуҗалары турында:

*Элекке хуҗалар тирги*
*Әлеге түрәләрне.*
*Бүгенгеләре аларга*
*Күрсәтә күрмәгәнне!*

Заманында Сергей Есенин «Прощай, немытая Россия!» тип язарга батырчылык иткән икән, ә нигә әле безгә өстәгеләр басымыннан куркырга?! Тиешле тәнкыйтьнең үз вакытында булмавы сәбәпле илдә җинаятьчелек чәчәк ата. Безгә, каләм ияләренә, ана каршы күмәк көрәш ачарга бик тә кирәктер.

Язучы үзе яшәгән чорны акыл күзлеге аша күрә белергә һәм шул вакытта күргәннәренә гадел бәя бирергә тиеш. Әдәби осталык—барыннан да элек тормыш хакыйкатен дөрес чагылдыра белүдә. Язганын укучы күнелен ышандырмый, анда шик уята икән, мондый әсәрне камил дип әйтеп булмый. Мар. Сәлим үзенен иҗатында шуна күрә хаклыктан читләшми, ана хилафлык итми. Анын үз вакытында ил хуҗаларына атап язган шаярудияларын алып карыйк:

**Калдык шул**

*Михаил Горбачевка*

*Кулымдагы балдагымның*
*Исемкәйләре Горбач.*
*Горбатый булып калдык шул,*
*Үзгәртеп кора торгач.*
*1990 ел.*

**Чүлмәк ватучы**

*Борис Ельцинга*

*Сабантуенда күз буып,*
*Татарны шаккатырды*
*Илебезнең иң-иң оста*
*Чүлмәк вату батыры.*
*1996 ел.*

**Кем калыр?**

*Геннадий Зюгановка*

*«Бурлар урыны—төрмәдә!»-*
*Дип сөйләп телең талыр.*
*Бурларны утыртып бетсәң,*
*Русиядә кем калыр?*
*1996 ел.*

**Катык батыр**

*Владимир Путинга*

*Бернәрсәне дә булмастыр*
*Аннан яшереп калып.*
*Соңгы тиенеңне алыр*
*Катык эченнән табып.*
*2000 ел.*

Язмамны Татарстаннын халык шагыйре Роберт Миннуллинның сүзләре белән тәмамлыйсым килә: « Марсель Сәлимовны мин утыз еллап беләм инде,—дип яза ул,—һаман да аңлап бетерә алганым юк. Әллә житди кеше ул, әллә шаян... Әллә житди итеп яза ул, әллә шаяртып кына... Ана көлдерергә, кытыкларга, авыз ерырга гына булсын. Югыйсә, житди генә урыннар да били инде: баш мөхәррир, рәис, тагын әллә кемнәр... Кыскасы, төзәлмәс бер кеше! Шаян талант, шифалы талант!»

Әйе, нәкъ менә шундый «төзәлмәс» кеше—үткер телле сатирик булуы белән якын да, кадерле дә безгә Марсель Сәлим.

**Рәшит ФАЗЛЫЕВ,**
*Уфа шәһәре.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Йомралы авылы

Йомралы елгасы ярына урнашкан Иске Йомралы авылы Апас районында, район үзәге Апастан 11 чакрымда, Каратун станциясеннән—23, Тәтеш пристаненнән 25 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл халкы күршедәге Әнәле, Иске Йомралы, Идрәс, Дүрт Өйле авыллары белән бергәләшеп июнь башында Шыкма җыенын бәйрәм иткән.

Йомралы сүзенең мәгънәсенә килик.

Безнең карашыбызча, йомралы —этноним. Күп кенә төрки халыкларны оештыруда катнашкан бу кавем-кабиләләр татарлар формалашуга да өлеш керткән. Исемнәре авыл атамасы булып ныгып калган.

Авыл картларының телдән-телгә сөйләп калдырган хикәятләренә караганда, башта авыл хәзерге Иске Йомралыдан ярты чакрым төньяктарак, урманга якын гына урынга утырган булган. Авылның тарихы XVI гасырның илленче елларында башлана (кайберәүләр 1545 ел дип төгәл датаны да атый). Әле хәзер дә ул урында чүлмәк, табак-савыт калдыклары, эш кораллары табалар. Шәһри Болгардан чыккан өч кеше Йомралы авылын нигезләгән. Ләкин бу урында аларны рәнҗетеп, талап торганнар. Шуннан соң болар, өч туган, хәзерге урынга күчеп утырганнар. Йомралы бабай хәзерге Иске Йомралы урынына, Карабай бабай хәзерге Карабай, ә Тинкә хәзерге Идрәс-Тинкә авылы урнашкан җиргә килеп төпләнгән.

Шулай итеп, өч авылның мөстәкыйль тормышы башлана.

Авыл халкының төп кәсебе игенчелек һәм терлекчелек булган. Бик ярлы яшәгәннәр, җир азлыктан интеккәннәр.

Революциягә кадәр авылда 2 мәчет эшләгән, 2 мулла булган. XX гасыр башында, 1900-13 еллар тирәсендә, патша армиясендә хезмәт иткәндә үзлегеннән русча укырга-язарга өйрәнгән 3-4 кеше исәпләнгән. Алар арасында Жамали карт, Фатыйх һәм Халик муллалар, Нәфигов Гайнетдин, Фәхриев Хисамилар булган. Иске Йомралы авылына Тәтеш районының Чолы авылыннан да күчеп киләләр. 1911 елга ул 270 хуҗалыкта 1000 җан яши торган зур авылга әйләнә.

Авылны икегә бүлеп Табанак елгасы ага. Ул Үләмә суына килеп кушыла. Табанак һәм Үләмә суларын җирле халык үз күңеленә якын атама—Инеш ди.

Авылга якын гына Юкә күле урнашкан. Биредә элек юкә кабыгыннан мунчала ясаганнар. Вәли күле авыл уртасында җәелеп ята. Вәли исемле кеше ул күлгә балыклар җибәреп, карап һәм чистартып торган. Тимерче күле дип аталган су чыганагы янында тимерче алачыгы булган. Авылның көнчыгышында Карабай белән ике арада Акчарлак күле бар. Олы буын кешеләре бу күл янына акчарлаклар килүен, бала чыгаруларын хәтерли әле.

Кызганыч, хәзер акчарлаклар да килми, күл дә бетү алдында.

Халык телендә авыл урамнарының элекке исемнәре кулланылышта йөри: Ачу очы, Черкен башы урамы, Тәтеш урамы, Табанак урамы һ.б.

Хәзерге көндә монда 141 хуҗалык исәпләнә. Соңгы 30 елда 40тан артык хуҗалык юкка чыккан. Сәбәбе: яшьләрнең авылдан китүе.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

## Иске Кади һәм Яңа Кади авыллары

Иске Кади авылы район үзәге Чирмешәннән—25, Яна Кади аннан 24 чакрым ераклыкта урнашкан.

Һәр ике авыл да Олы Сөлчә суына уң яктан килеп кушыла торган Сөлчә елгасы буена утырган.

Авыл оешу турында аксакаллар түбәндәгеләрне сөйли. Иске Кади оешуга 400 елдан да ким түгел икән. Авылга беренче булып Кади исемле бабай нигез салган. Аны Спас районындагы Әҗмәр белән янәшәдә урнашкан элекке Гөлбагар авылыннан килгән дип әйтәләр. Кади бабайның алты малае булганлыгын сөйлиләр.

Иске Кади авылы олы юлдан 3 чакрым эчкәрәк кереп, чокыр эченә утырган. Хуҗалыгы 600гә якын. Авыл ике зиратлы. Берсе авылның бер, икенчесе—икенче ягында. Өлкән яшьтәге кешеләр зиратларны карап һәм тәрбияләп тора.

Авыл житәкчеләре, укытучылар һәм врачлар—шушы авылдан чыккан кешеләр. 1992 елда куанычлы вакыйга була—мәчет ачыла.

***

Яна Кади авылы Иске Кадидан аерылып чыккан. Анын оешканына 350 еллар була икән. Бу авылда (элекке исеме Утыз Имән) 1754 елда шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни туа. Аның әтисе, Госман бине Сәрмәки, чыгышы белән хәзерге Лениногорск районының Тимәш авылы кешесе, әнисе исә Утыз Имән авылы кызы булып, өйләнешкәннән соң алар Тимәш авылында тора башлыйлар. Ләкин Габдерәхим туганчы ук аның әтисе Госман бине Сәрмәки үлеп китә. Ярдәмчесез калган яшь хатын янәдән үзенең туган авылы Утыз Имәнгә кайта, һәм шунда, үзенең әтисе йортында Габдерәхимне таба. Ике-өч ел да үтми, үзе дә дөнья куя. Шулай итеп, Габдерәхим, сабый чагында ук, ата-анадан ятим калып, туган тиешле бер җингәсе кулында тәрбияләнә.

Яна Кади авылында 90 яшьлек Суфиян бабайдан галим Әнвәр Шәрипов 1973 елда «Син безнең авыл кешесе түгел» дигән легенда-риваять язып алган.

«Күп илләр күреп, дөнья гизеп йөргәннән соң, бервакыт Габдерәхим янадан үзенең туган авылы Яна Кадига кайтып төшкән. Туган-тумачалары, дус-ишләре белән күрешеп сөйләшкән һәм авылда төпләнеп калырга булган. Ләкин авыл старосталары аңа: «Синең атаң Яңа Кади кешесе түгел, Тимәшнеке иде. Шулай булгач без сиңа йорт корырга җир бирә алмыйбыз, әнә, Тимәшкә барып ал»,—дигәннәр. Габдерәхим моңа бик кайгырган, ләкин нишләсен! Ул үзенең бөтен китапларын бәләкәй арбага төягән дә, хатынын, балаларын ияртеп, авылдан чыгып киткән. Киткән вакытта шагыйрь:

«Сау бул, сау бул, Утыз Имән, урман-кулләрең белән...

Мин дә сине сагынырмын, кайгылы көннәрен белән»,—дип жырлаган.

Авылны чыккач, ул мәһабәт булып үсеп утыручы утыз имән яныннан үткән. Алар янында туктап, кулы белән кайрыларын сыйпаган, күтәрелеп зәңгәр күккә үрелгән очларына караган. Шунда Габдерәхим: «Утыз имән түгел бу, алтын имән»,—дип әйткән. Аннан соң ул туган авылына соңгы караш ташлаган да көнчыгыш яктагы үрнең урман ачыклыгыннан чыгып киткән».

Ул урман ачыклыгы анда хәзер дә бар, халык аны «Габдерәхим хәзрәт ачыклыгы» дип йөртә.

Кади авылында һәм басуларында чишмә-кизләүләр бик күп. Авылның атаклы чишмәсе—Кади чишмәсе. Шарлавык чишмәсе дә бар. Элек аның суы бик көчле чыккан. Тирәнлеген үлчәү өчен аңа алты дилбегә бәйләп төшергәннәр, әмма төбенә житә алмаганнар, имеш. Булатовлар чишмәсен рус инженеры ясаткан булган. Аны хәзер дә чистартып торалар. Шәмсуаров Динмөхәммәт чишмәсен дә һәр елны әйбәтләп карап, тазартып куялар. Минлегол бабай коесының суы тәмле. Аны да авыл халкы тәртиптә тота.

Авылда 1989 елдан бирле мәчет эшли.

## Иске Камка авылы

Кече Чирмешән суы ярына матур-матур авыллар тезелешеп утырган. Алар арасында Иске Камка үзенең бай табигате белән аерылып тора.

Иске Камка Әлки районында урнашкан. Авылдан район үзәге Базарлы Матакка—19 чакрым, якындагы тимер юл станциясе Норлатка—67, су юлы Болгар пристанена кадәр 88 чакрым.

Иске Камка янында археологлар борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле авыл хәрабәсе билгеләгәннәр.

Иске Камка тигез жиргә урнашкан. Авылны беренче нигезләүчеләр урынның матурын, су буен сайлаганнар. Бу төбәктәге Чирмешән суы буеннан-буена тарихи жирлек. Аның яры буйларындагы авылларда Кала сүзе белән бәйләнешле атамалар күп очрый. Иске Камка авылы утырган жирдә дә Кала тавы, Кала сазы урамы исемен алган берәмлекләр бар. Димәк, бу урында элекке чорларда кала төзелгән булган. Р. Г. Фәхретдиновның археологик һәйкәлләрне барлаган чыганагында Иске Камка авылы янында шәһәр хәрабәсе билгеләнгән. Мәүләшә, Карамалы һ. б. авыллар янында да борынгы болгар чорына мөнәсәбәтле истәлекләр табылган һәм тикшерелгән. 1927 елда авыл янындагы Кала урынында казу эшләре алып барганда, эре-эре сөякләр чыккан. Бу урынга килеп, авыл аксакаллары дога укыйлар, аны кадерләп тоталар. Әлеге жирләр, һичшиксез, борынгы бабаларыбыз белән бәйләнешле. Менә нинди тарихи жирлеккә салынган ул Иске Камка авылы!

Авылны кемнәр, кайчан нигезләгән соң?

Иске Камкада яшәүче Мирза ага Дәүләтшин белән Зиннәт ага Хисамовларның сөйләвенә караганда, бу авылның оешу тарихы элекке Алатырь өязенең Пьяна суы ярына урнашкан Камка авылы белән бәйләнешле (хәзерге Түбән Новгород өлкәсе, Сергач районындагы Камка авылы). Түбән Новгород өлкәсендәге Камканың кайбер нәселләре, йомышлы татарлар сыйфатында, Кама аръягындагы ныгытмаларны саклау өчен патша хөкүмәте тарафыннан шушында китереп утыртылганнар. Иске Камка кешеләре Түбән Новгород өлкәсе Сергач районында урнашкан Камка авылына барып чыккач, бу авыл кешеләре аларны бик олылап, зурлап каршы алганнар. Сез безнең кадерле улларыбыз дип атаганнар, кунак иткәннәр.

1910 елның 4 июлендә Мәүләшә (Яңа Камка) авылында язучы Нәби Дәүли туа.

Сергач Камкасы белән жөмһүриятебездә Иске Камка халкын берләштерә торган фактлар шактый. Әйтик, Сергач районындагы Камка һәм бездәге Иске Камка авылы халкы «ц» авазы кулланып сөйли (мәсәлән, Чирмешән—Цирмешән, чакрым—цакрым, чирәм—цирәм һ.б.).

Шунысы да әһәмиятле: Сергачтагы Камка белән жөмһүриятебездәге Иске Камкада яши торган халыкның көнкүрешләре, рухи тормышлары, күп кенә гореф-гадәтләре (кыз бирү, туй итү, мәет күмү, янгыр сорау йолалары, им-том һ. б.) бер-берсеннән аерылмый.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Карамалы, Мәүләшә, Яңа Камка авыллары Иске Камкадан аерылып чыкканнар.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# К

**КАМАЛИЕВ** (чын фам. Камалетдинов) Тәүфикъ Салих улы (3.2.1940, Буа р-ны Ташкичү ав.—13.2.1980, Казан), шагыйрь. Казан ун-тын тәмамлый (1966). «Ялкын» ж-лында (1966-76), «Социалистик Татарстан» г-тасында (1976-78), ТАССР МС Телевидение һәм радиотапшырулар к-тында өлкән мөхәррир (1973-75) булып эшли. Лирик шигырьләре тупланган «Ромашкалар эзлим» исемле беренче җыентыгы 1967 елда басыла. «Сабыр канатлары сынмый» (1968), «Сезгә генә сөйлим» (1970), «Хәләл көчем белән» (1972), «Яшьлеккә кайту» (1978), «Ак өметләр» (1986) җыентыкларында яшьлек, дуслык турында шигырьләре кергән. К. шигырьләре туган җиргә һәм анын кешеләренә мәхәббәт белән сугарылган.

Әд.: Маннапов Ш. Яшел килеш яфрак коелды // Казан утлары. 2000. №2.

**КАМАЛОВ** Барлас Хәмит улы (17.1.1930, Чистай ш.—5.2.2004, Казан), язучы, ТАССРның, РФның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980, 1992). Казан педагогия ин-тын тәмамлый (1953). 1959-62 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында җаваплы мөхәррир, 1962-64 тә «Социалистик Татарстан» газетасы һәм «Чаян» ж-лларында бүлек мөдире, әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара. 1964-66 елларда ТАССР МС каршында радиотапшырулар һәм телевидение к-тында эшли. «Гомер иткәндә» исемле беренче хикәяләр җыентыгы 1959 да басыла. Гомумкешелек кыйммәтләренә, тарихка мөрәҗәгать итүе, публицистик язу стиле белән К.ның «Сыналыр чак» (1965), «Күршеләр» (1970), «Күнел кыңгыраулары» (1971; русчага тәрҗемәдә «Колокольчики души», 1976), «Йөрәк давыллары» (1980), «Ярсөяр әрәмәсе» (1983) исемле повесть һәм хикәя җыентыклары аерылып тора. «Өметен өзелмәсен» (1986), «Җир күчәре» (1990) романнары авыл кешеләренең авыр хезмәтенә һәм яшь буынны тәрбияләү проблемаларына багышланган. «Мирхәйдәр Фәйзи» (1987) повесте күренекле татар драматургының тормыш һәм иҗат юлы турында.

Әсәр.: Язмыш сәхифәләре. К., 1990.

**КАМАЛОВ** Хисам Нуретдин улы (14.4.1926, Әлмәт р-ны Кама-Исмәгыйль ав. туа), язучы, ТРның халык язучысы (2001). Казан педагогия ин-тын тәмамлаганнан соң (1954) Татар. кит. нәшриятында мөхәррир булып эшли. Әдәбиятка шагыйрь буларак килә. «Янадан сафта» дигән беренче шигырь җыентыгы 1955 елда басыла. «Чияле тау» (1956; русчага тәрҗемәдә «Вишнёвая гора», М., 1963), «Язмыш» (1967), «Тормыш дулкыннары» (1968), «Каен суы» (1972), «Күнел» (1976) җыентыкларындагы шигырь һәм поэмалары гражданлык хисе, оптимизм белән сугарылган. К. поэзиясенең төп темалары—Бөек Ватан сугышы, ул китергән кайгы-фаҗига, илдә барган социаль-экономик үзгәрешләр, бәхет, мәхәббәт турында фәлсәфи уйланулар. 1970 еллардан К. нигездә проза өлкәсендә эшли. Анын «Һәркемнең гомере бер генә» (1975; русчага тәрҗемәдә «У каждого жизнь—одна», 1983), «Безне өйдә көтәләр» (1985; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе, 1986), «Үлгәннән соң яздым» (1989), «Түләнмәгән күз яше» (1995) романнарында, шулай ук «Бердәнбер ул» (1982) җыентыгындагы повесть һәм хикәяләрендә сугыш чоры вакыйгаларын, фронт һәм тыл тормышын реалистик картиналар белән тасвирлый, совет кешеләренең батырлыгын, фидакарьлеген, намуслыгын ачып бирә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Әд.: Фәйзи Ә. Әдипнең эрудициясе. К., 1973; Маннапов С. Тормыш үзәненнән // Казан утлары. 1980. №3.

**КАМЕНЕВ** Гаврила Петрович (3.2.1772, Казан—1803, шунда ук), язучы. Рус романтизмы башлангыч чоры вәкилләренең берсе. Казандагы бай купецлар фамилиясе (ыруы) варисы. 1800 дән Мәскәү язучылары даирәсенә керә, 1802

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

дә Петербургтагы Тел, фәннәр һәм сәнгать сөючеләр иректә җәмгыятенә алына. Казан һәм аның тирәсе б-н «Громвал» балладасы мотивлары, «Төш» («Сон») элегиясе (Кизик монастыре, Хижица), «Казаннан өч чакрымда» («В трёх верстах от Казани») әсәрләре бәйле. Тулаем алганда К. иҗаты (элегия, баллада, юллама, сентименталь повестьлар) романтик характерда язылган. Аның балладалары В.А.Жуковский иҗатына зур йогынты ясыйлар. К.—әдәби тәрҗемәләр авторы. Аның әдәби мирасын А.С.Пушкин югары бәяли.

Әд.: Бобров Е. Первый русский романтик Г.П.Каменев // Изв. вестн. 1903. Т.43, №8; Чтения, посвящённые 225-летию со дня рождения Каменева... К., 1997; Валеев Э. Судьбою прерванный полёт... К., 2001.

*А.Н.Пашкуров.*

**КАНДАЛЫЙ** Габделҗәббар Габделмәҗит улы (1797, Самара губ., Ставрополь өязе, Иске Кандал а.—май 1860, шунда ук), шагыйрь. Татар һәм гарәп телләрендә яза. «К.» тәхәллүсе туган авылы исеменнән алынган. Мулла гаиләсендә туа. 17 ел дәвамында Казан губ., Ставрополь губ., Самара губ., Казан, Тәтеш, Чистай өязләре мәдрәсәләрендә белем ала. Мәдрәсәләрне еш алыштыру—шигырьләрендә бу уку йортларындагы тәртипне һәм уку системасын тәнкыйтьләү нәтиҗәсе. Укуга сәләтле булган өчен аны шәкертлек чорында ук мәдрәсәнең түбән баскычларында гарәп телен укытырга тарталар. 1824 тә руханилек вазыйфаларын башкарырга рөхсәт алып, К. туган авылына кайта, имам-хатип булып тора. Шигырьләрендә мөсельман руханиларын көлке утына тоткан, хатын-кыз образларына мәдхия җырлаган, кайбер шаригать нормаларын бозган өчен 1840 тә мөселман мәхәлләсе җыелышы К.ны руханилык дәрәҗәсеннән мәхрүм итәргә тәкъдим ясый. Бу тәкъдим тиешле тавыш санын җыя алмаса да, К. эшеннән китәргә мәҗбүр була. 1843 тә ул үзенең фикердәшләре тарафыннан оештырылган 2 нче мәхәллә б-н җитәкчелек итә. 1848 дә аның мәхәлләсенә власть тарафыннан яңа имам һәм мөдәррис куела. Шулай итеп К.не эшеннән читләштерәләр, мәхәлләгә аның йогынтысы сизелерлек кими. 2 елга якын ул төрмәдә утырып чыга (кулга алуның төгәл вакыты һәм сәбәбе билгесез).

К. күпкырлы белемгә ия була. Мәдрәсәдә өйрәнелгән гарәп һәм фарсы телләреннән тыш, ул үзлегеннән рус, мордва һәм чуаш телләрен үзләштерә. Аның кулыннан төрле эш килә: ул китап төпли, сабын кайната, мич чыгара, йозак төзәтә белә. Беренче «Рисаләи—л—иршад» («Тугъры юлга күндерүче китап», 1915/16 тирәсе) әсәрен К. мәдрәсәдә укыган чорда яза. Бу дини—дидактик әсәр кереш сүз, 28 бүлек һәм мөнәҗәт формасында язылган йомгактан тора. Автор укучыны, мөселман дине кысаларында гына булырга мөмкин булган, дөреслеккә өнди. Поэмада җир тормышының фанилыгы турында мотивлар яңгрый, бакый дөньяга үзеңне әзерләү зарурлыгы ассызыклана. Моның өчен К. фән йөрәнү, изге гамәлләр кылу, золым, хәйлә, мәкерлекне кире кагу, хискә артык бирелмәү, түземле булу кирәклеген әйтә. Гыйлемлелекне югары бәяләп, К. крәстиянгә карата беркадәр һавалылык күрсәтә. Аныңча укымышлы кешегә игенчелек хезмәте килешми.

К.ның шулай ук уку чорында язылган «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» этик-фәлсәфи поэмасы зур күләмне әсәрнең бер өлешен тәшкил итә (тулаем күләмдә сакланмаган). Поэманың исеме шартлы рәвештә, төп геройларның берсе исеменнән алынган. Аның прототибы реаль тарихи шәхес—солтан Балха Ибраһим Адһәм (874/875 ләрдә үлә). Хакыйкать эзләр өчен ул, тәхетен ташлап, дәрвиш киемен киеп, юлга чыга. Акылы һәм диндарлыгы б-н Ибраһим Әдһәм Харун әр—Рәшид хәлифкә охшый (763/766—809) һәм ул ана үзенең сараенда киңәшче булып калырга тәкъдим ясый. Ләкин Ибраһим Әдһәм дәрвиш тормышына тугъры калып, Аллаһка хезмәт итү юлын сайлый. Поэманың бүтән бүлекләрендә белем эзләп сәяхәткә чыккан «болгар ягы» Кәндиле авылы егете турында сүз бара. Шушы урында поэма өзелеп кала. Сакланып калган текстның күп өлеше урта гасыр әдәбияты рухында нәсихәт характерында язылган.

Заманасы өчен новаторлык рухында язылган «Сәхипҗамал» поэмасы К.ның соңгы иҗат чорына карый. Ул эпистоляр жанрда язылган, анда хәрәкәт тә, сюжет та юк. Татар әдәбиятында беренче тапкыр хатын-кызга карата мәхәббәт җырлый:

Сәңа, җаным, дога иттем, дога илә сәлам иттем,
Сәламнәрнең соны, җанкәм, язып гозер каләм иттем.
Сәхипҗамал, чибәрем лә, и матурым, сөярем лә!..

К. гади крәстиян кызының сөйкемле образын тудыра, авыр физик хезмәт һәм көнел газапларына дучар булган татар хатыны тормышының күнелсезлеге мәсьәләсен күтәрә. Шагыйрьнең кызларга, хискә бирелеп, сөйгәннәрен үзләре сайларга мөрәҗәгате искелек кануннарына туры килми, шуңа күрә мөселман руханилар тарафыннан тәнкыйть утына тотыла.

Төрмәдә утырганда К. Аллаһияр Суфинең «Сәбәтел-гаҗизин» поэмасына гарәп телендә комментарийлар яза.

К.ның башлангыч чор әсәрләренең теле катлаулы һәм архаик, үз эченә гарәп-фарсы, угыз, чыгытай лексика һәм морфологиясе элементларын ала. Соңгы чор иҗатында халык теленә тартым яза. Аның шигъриятендә сөйләм теле элементлары, эпик әсәрләрдән өзекләр, җырлар, әйтемнәр, мәкальләр, фразеологизмнар бар.

Үзе исән вакытта К.ның әсәрләре кульязма рәвешендә таралган. 1859 да чыккан С.Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» китабына беренче тапкыр шагыйрьнең, исеме аталмыйча, 8 юлы керә. Тагын 200 юлы «Император географик җәмгыятенең Оренбург бүлеге язмалары»нда («Записки Оренбургского отделения Императорского географического общества», кн. 1, 1870) басыла, алар анда «татар һәм башкорт халык җырлары» дип атала. 1881 дә күбесенчә К. шигырьләреннән торган «Мәгъшукнамә» китабы чыга, ләкин шагыйрьнең авторлыгы тагын күелмый. Беренче тапкыр К. авторлыгы К.Насыйриның «Фәвакиһәл җөләсә»сендә (1884) күрсәтелә, китапта шагыйрьнең 1 меңнән артык юллары урын ала. 1920 нче елларда ТАССРның Мәгариф халык комис-ты Академүзәге К.ның иҗади мирасын өйрәнергә һәм системага салырга дигән карар чыгара. Ләкин шагыйрьнең беренче «Шигырьләр» җыентыгы Х.Госман редакциясендә 1960 та гына дөнья күрә. Бүгенге көндә шагыйрьнең иң тулы «Шигырьләр һәм поэмалар» басмасы 1988 дә фәнни комментарийлар б-н М.Госманов редакциясендә нәшер ителә. 1999 да «Сәхипҗамал» поэмасы аерым китап булып чыга.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. К., 1922. 1 җилд; Иртуган К. Шагыйрь Г.Кандалыйның кыскача тәрҗемәи хәле һәм шәхси хәяты // Безнең юл. 1927. № 8; Бәхтиев И. Шагыйрь Г.Кандалый турында // Яңалиф. 1929. № 13; Госман Х. Г.Кандалыйның яңа табылган әсәрләре // Совет әдәбияты. 1960. №5; Курбатов Х.Р. Г.Кандалый шигырьләрендә метрика һәм строфика // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 кит.; Тазюков Х. Г.Кандалый турында кайбер мәгълүматлар // Совет мәктәбе. 1978. № 6; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том; Госманов М. Кандалый мирасын барлау юлында // Казан утлары. 1987. №7; Госманов М. Габделҗаббар Кандалый: яңага таба борылыш//Мирас.1997. №7.

*А.М.Ахунов.*

**КАРАНЫЙ** Саләх (псевд. Әбү Хәҗиб) (19 йөз), язучы. «Тәнбиһел-кәмал» («Талант уянуы») дини-дидактик шигырь, «Иказәтет-төҗҗар» («Сәүдәгәрләргә нәсыйхәт») хикәя җыентыгы авторы. Аларда 19 йөзнең 1 нче чирегe татар әдәбиятына хас булган традицион дини мәсьәләләр, мөселман руханилары б-н мөнәсәбәт проблемалары яктыртыла. К. диния нәзарәте б-н хезмәттәшлеккә каршы чыга, указлы муллаларны һәм абызлар хәрәкәте вәкилләрен тәнкыйтьли, мөселманнарга чәй б-н шикәрне тыярга чакыра. К. әсәрләре кульязмалары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты каршындагы Кульязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсендә һәм Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар бүлегендә саклана.

*М.В.Гайнетдинев.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# «ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ»НӘ 90 ЕЛ

**—90 яшь. Тарих өчен, бәлки, әлләни зур сан түгелдер. Ләкин иҗтимагый тормышяшәеш җәһәтеннән чыгып караганда, бу инде—үзе бер тарих, татар дөньясының ташка баскан тере елъязмасы. Сүзне газетаның «чишмә башы»ннан дигәндәй әләктереп китәсе килә...**



—«Чишмә башы»—1920 елның 22 гыйнвары, ягъни «Кызыл яшьләр»нең Iнче саны чыккан көн. 1938 елда газета «Яшь сталинчы»га әйләнә, ә 1957 елдан ул—«Татарстан яшьләре».

Шушы 90 ел эчендә газетаның баш мөхәррирләре булып менә кемнәр эшләгән—Гали Хуҗиев, Хәбиб Гобәйдуллин, Рафак Тимергалин, Барлас Камалов, Миншәех Зәбиров, Салих Гарипов, Харис Әшрафҗанов, Ислам Әхмәтҗанов, Хәлим Гайнуллин. Тарих өчен бер мизгел булса да, 90 ел—кеше өчен дә, газета өчен дә бик күп. Бу вакыт эчендә ил һәм аның белән бергә газета да, билгеле, төрле чорларны кичергән— «Т. Я.» битләрендә чын тормышның кайнар сулышын тоярга була.

**—«Т. Я.»—Татарстандагы милли басмалар арасында ел саен иң күп тираж җыя. Матбугатта озак еллар эшләгән кеше буларак, мин моның «серен» чамалыйм. Әмма әлеге серне баш редактор авызыннан ишетү урынлырак булыр...**

—Бөтен «сер» шунда, без «йөрәктән чыккан гына йөрәккә барып житә» дигән принцип буенча эшлибез. Ә инде укучыларыбыз күп икән, димәк, яраталар.

**—Статистика әйткәнчә, Татарстанда 2 млн., Россия Федерациясендә 5 млн. татар яши. Редакциянең, дөресрәге, газетаның читтәге татарларыбыз белән бәйләнеше ни дәрәҗәдә? Әйтик, Татарстаннан читтә сезнең тираж күпме?**

—Чит төбәкләргә «Татарстан яшьләре» 2 мең чамасы тарала.

**—Глобальләшү процессы, корыч танк сыман, татарның мәдәниятен, барыннан да бигрәк туган телебезне кысрыклый, таптамакчы була. 30-40 елдан соң туган телебез таза-сәламәт хәлендә сакланырмы? Совет чорындагыча, кухня теле булып кына калмасмы?**

—Сакланмас сыман, процесс бик кызу бара. Медицина теле белән әйткәндә, бу чир башта хроник формада иде, озакка сузылды, ә хәзер исә агрессив форма алды. Ул әле көннәрдән-беркөнне кухнядан да кысрыкланырга мөмкин. Ана телен белмәү, манкортлашу афәте көннән-көн көчәя барган шартларда, яшьләрне милли мәдәнияткә һәм әдәбиятка, хәтта, һичьюгы, ана телендәге газета-журналларга җәлеп итүнең ысулларын эзләргә һәм табарга кирәк.

**—Ничек уйлыйсың, халыкта популяр булган «Татарстан яшьләре» битләрендә туган телебезнең киләчәгенә, язмышына, аңа мәхәббәт тәрбияләү мәсьәләләренә бәйле махсус бер сәхифә ачарга вакыт түгел микән?**

—Газетаның һәр бите, ул биттәге һәр мәкалә, һәр рәсем асты татарның теле, киләчәк язмышы һ.б. белән турыдан-туры бәйле һәм «шушы тегермәнгә су коя».

**—Ни әйтсәк тә, туган телебез, гореф-гадәтләребезнең төп нигезе, яшәр урыны—авылда. Элегрәк бу бигрәк тә шулай иде. Әмма хәзер эшсезлек, эчкечелек, җан**

**кыюлар, хәтта наркоманлык кебек заман афәтләре авылларыбызга да үтеп керде. Рухи һәм әхлакый чишмәләребез саега. Кыскасы, авылның нигезе какшый башлады. Сезнең газета битләрендә авыл темасы ничегрәк, ни дәрәҗәдә чагылыш таба?**

—Безнен газета битләрендә авыл темасы ул ничек бар, шулай чагыла. Алга таба да шулай чагылыр. Син санап киткән чир-зәхмәтләр бөтен Русияне колачлап алган. Татар дөньясы да шушы киңлектә булганлыктан, бу чирләрнен безгә дә йокмый хәле юк, чөнки болар йогышлы чирләр. Битлек киеп кенә котылып була торган түгел. Ә инде авылның үлеп баруына килсәк—ә бу милләтнең бетеп баруы дигән сүз— үзе бер зур тема. Бу хакта аерым утырып сөйләшсән дә тиз генә ерып чыга торган түгел. Бүген авылда ин мөһим нәрсә, мөгаен, эшләгән кешенен уч тутырып акча ала алмавыдыр. Җәмгыятьнен күп зәхмәтләре хәерчелеккә барып тоташа.

**—Әйтә аласызмы, сезнең газетаны Президентыбыз һәм министрлар укый микән?**

—Министрлар турында өздереп әйтә алмыйм, әмма Президент укый дип беләм.

**—Яшерен-батырын түгел, бүгенге көндә «Татмедиа»ны сүгүчеләр дә бар. Сез әлеге Ачык акционерлык җәмгыяте «кочагына» кермәдегез, үзбашка—ягъни мөстәкыйль яшисез. Моның рәхәте һәм михнәте нәрсәдә?**

—«Татмедиа» кочагына кереп карамагач, монын рәхәте һәм михнәте турында нәрсә әйтим инде?

**—Мисалларга тукталып тормыйм, кызганычка күрә, бүгенге татар милли матбагасын кысрыклау, йөгәнләү, аларның мәсләген үзгәртергә тырышу, хәтта кайбер басмаларны ябарга омтылыш күзгә ташлана. Сез моның өчен борчыласызмы?**

—Милли басмаларга зыян салырга тырышу омтылышы бар икән, милләт баласы буларак бу мине борчымый кала алмый, билгеле. Бу—тәрәккыятькә каршы бара торган, бары тик тискәре караш кына уята торган ахмак гамәл. Әгәр Русиядә дөрес милли сәясәт алып барылса, бик күп четерекле мәсьәләләр гамәлдән төшеп калыр, яки булганнары хәл ителер иде. Каршылык—каршылыкны, явызлык—явызлыкны тудыра.

**—Сөйләшеп утыруларның берсендә аксакал әдип Әмирхан ага Еники: «Мин кайчак социализмны сагынып куям. Ләкин аңа кире кайтасы килми»,—дигән иде. Заманында без «Татарстан яшьләре»ндә күпмедер еллар бергә эшләгән идек. Син ул елларны сагынасыңмы, юкмы?**

—Әмирхан агадан да төгәлрәк итеп әйтеп булмас. Сагындыра, билгеле. Ләкин бу социализмны түгел, ә яшьлекне сагыну.

**—Редакциядә кайчандыр Барлас Камалов, Шамил Маннапов, Рафикъ Юныс, Рашат Низами, Харрас Әюп һ.б.ның эшләвен беләбез. Яшьләр газетасы битләрендә атнасына бер тапкыр «Әдәбият-сәнгать» дигән сәхифә даими рәвештә чыга килде. Шигырьләр сездә хәзер фоторәсем асларында гына «ялтырап» ала. Әдәбият-сәнгать сөючеләр өчен атап чыгарылган бу сәхифә ни өчен туктатылды икән?**

—Дөрес әйттен, һәр заманнын үз үзенчәлеге. «Татарстан яшьләре»ндә кырлардан шигъри репортажлар басылган заманнар да булган. Ләкин гомерләр үтү белән безнен кечкенә газетага шигырьләр сыймый башлады. Шул ук вакытта шигырьләрне кулдан тартып алучы дистәгә якын махсус әдәби-мәдәни басмалар пәйда булды. Һәрхәлдә, әдипләр, язучылар һәм аларның язмалары өчен ишегебез һәрвакыт ачык.

**—Яшьләрне, яшь буынны элек-электән сүгәргә яратканнар. Бүгенге көн яшьләре нинди? Сез шәхсән аларны якыннан аралашып беләсезме, әллә күбрәк редакциягә килгән кульязмалар аша гынамы?**

—Яна тарихкка кадәр үк, ягъни б.э.к. үк «аталар һәм балалар каршылыгы» дигән нәрсә булган. Һәр заманның үз яшьләре, үз картлары. Яшьләрне аңларга тырышам. Ләкин кульязмалар аша гына яшь буын турында фикер йөртеп булмый. «Гомумконтекст» аша фикер йөртергә тырышам. Бүгенге көн яшьләре, мөгаен, күп яктан бездән яхшырактыр. Баш мөхәррир урындыгыннан карап, мин бүгенге

татар яшьләренең иң зур кимчелеге—туган телне белмәүләре дип саныйм. Аларның әти-әниләре «чәчәк аткан» социализм чорында туып-үсеп формалашкан кешеләр, күбесендә милли үзаң бик сыек. Зур төзелешләр, шәһәрләшү барлы-юклы миллилекне дә йотып бетерә язды. Бүгенге яшьләрнең иң зур күпчелеге прагматиклар. Юк, бу начар сыйфат түгел, әмма алар милләттән тагы да ераграк, читләшкәнрәк, чөнки акча эшләү, карьера ясау, нигездә, урыс теле мохитендә алып барыла. Аларның балалары, бәлки, татарларның соңгы буыны булыр. Милли үзаң уянуда 90нчы еллардагы сыман тагын бер җилкенү, өермә булмаса, милли киләчәккә бик зур куркыныч яный.

**—Сезнең коллективта, бигрәк тә бүлекләрдә күбрәк хатын-кызлар эшли. Бизнес-фәләнне, төшемле урынны сайлап, ир-егетләр журналистика эшеннән читләшә башлады микән әллә?**

—Татар журналистикасында ни өчендер (моның, билгеле, үз сәбәпләре бардыр), хатын-кызлар күбрәк. Килер бер вакыт, ирләр дә күбәер. Шулай дип өметләник.

**—Хатын-кызлар димәктән, яшьләр газетасында иң озак еллар эшләгән кеше Рина ханым Зарипова булды түгелме?**

—Әйе, Рина Зарипова редакциядә утыз биш елга якын эшләде. Хатлар бүлеге мөхәррире булып. Ә хатлар бүлеге—редакциянең «кайнар ноктасы», төп кухнясы ул. Рина ханым шунда бөтен күңелен, җанын, йөрәген биреп эшләде. Ул газетада ачып җибәргән «Сердәш» сәхифәсе генә дә ни тора! Укучылардан хат күп килә иде. Рина ханым аларның берсен дә җавапсыз-игътибарсыз калдырмады.

**—Сезнең эштә иң кыены нәрсә?**

—Безнең эштә иң кыены кеше укырлык газета чыгару. Иң рәхәте дә шул.

**—Бер генә ата-ана да үзенең баласына тел-теш тидерергә тырышмас. Шулай да... Кимчелексез кеше булмаган шикелле, сезнең газетада да җитешсез яклар юк түгелдер. Әгәр үзтәнкыйть белән карасак...**

—«Татарстан яшьләре» тоташ житешсезлекләрдән генә тора. «Аһ, менә бүген, ниһаять, нинди шәп газета эшләдек!»—дисең. Икенче көнне укып карыйсың—чуп-чар җыелмасы! Мин үзем, мәсәлән, «Татарстан яшьләре»нең әле буяу исе дә кибеп бетмәгән яна санын кулыма алгач, йөз елга бер тапкыр гына канәгатьлек хисе кичерәм.

**—Исмәгыйль Сәлмәнович, баш редакторның буш вакыты бармы? Булса, ул аны ничегрәк үткәрә икән? Әдәбият укырга яратасызмы? Төгәлрәк әйтсәк, кайсы язучыларны...**

—«Буш вакыт» дигән нәрсәне белмим, чөнки редакция эше өйгә ияреп кайта. Әдәбият укырга яратам, ләкин вакыт тими, шуңа күрә күп кенә яна китапларны диагональ буенча гына карап өлгерәм. Хәзерге вакытта Мөхәммәт Мәһдиевнең яна чыккан 5 томлыгы әле ачылмаган килеш өстәлдә ята, Рабит Батулланың «Урыннары җәннәттә булсын!» дигән китабы укый башлаган килеш тора, Һади Такташ белән Габдулла Тукайның бөтен әсәрләрен тагын бер кат укып чыгарга вакыт җитте—белмим, кайчан керешермен, Виктор Шендеровичның сатира һәм юмор антологиясендә чыккан китабы белән Михаил Жванецкийның сайланма әсәрләрен кайбер көннәрдә караштырып алам һ.б., һ.б.

**—Ялгышмасам, Татарстан китап палатасы базасын нык кына «иләделәр» шикелле. Тарих өчен, киләчәк буыннар өчен «Т.Я.»ның барлык төпләнмәләре дә саклана микән, бу эш ничек тора?**

—Әйе, архивта саклана. Үзебездә газетабызның соңгы 15 елдагы тегелмәләре бар.

*Әңгәмәдәш*—**Рашат НИЗАМИ.**

# ХАЛЫКНЫҢ МОҢЛЫ УЛЫ

Җәүдәт Фәйзи... Татар халкының соңгы илле еллык музыкаль культурасын бу исемнән башка күз алдына китерүе дә кыен. Бөтен гомерен гүзәллеккә багышлаган зур музыкант, иҗади тормышның күп тармакларында үзен күрсәткән олы шәхес турында сөйләү—мактаулы һәм шул ук вакытта кыен эш. Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Заһит Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзиләр буыны—иң бәхетле буын, чөнки аларга татар профессиональ музыкасы мәйданындагы беренче буразналарны салырга туры килде. Ләкин Җәүдәт Фәйзинең бәхете өлкән яки беренче буын композиторы булуда гына түгел, әлбәттә. Табигать ана таланттан тыш үтә дә хезмәт сөючәнлек, тырышлык та бүләк иткән иде. Ул яшәгән өйгә кайчан гына барып кергәндә дә аның йә рояль артында, йә язу өстәле янында эшләп утырган чагына туры киләсен. Һәм, нәтиҗәдә: өч йөздән артык җыр, музыкаль комедияләр, опера, балалар өчен әсәрләр, фольклор көйләре, җәмәгать эшләре...



Республикабызда җыр язмаган, җыр өлкәсендә эшләмәгән композитор юктыр дисәк, ялгышмабыз. Җәүдәт Фәйзи шушы олы агымда югалып калмады, ә бәлки үзенә генә хас интонацияләрне таба алды. Аның җырларын халык яратып кабул итте. Аның җырлары көй эшләнеше, сюжет байлыгы һәм музыкаль уй-фикернең төгәллеге белән аерылып торалар. Лирик һәм эпик, шаян һәм уйчан, тантаналы һәм моңсу җырлар олы гражданлык хисе белән сугарылганнар. Язылганына 45 ел узуга карамастан, «Комсомолка Гөлсара» (Ә. Ерикәй шигыре) җыры әле һаман комсомол темасына язылган җырлар арасында лаеклы урынны алып тора. «Шауласын, гөрләсен безнең җыр» (Ә. Ерикәй шигыре) да үз заманында халыкны патриотик тәрбияләүдә гаять зур роль уйнады һәм әле дә шулай булып кала.

Теге яки бу композиторның иҗатын күз алдыннан үткәргәндә, аның башлангыч вакыты һәм чәчәк аткан чоры турында сөйлибез. Ә менә Җәүдәт Фәйзинең көйләре һәрвакыт җитлеккән, төгәлләнгән булулары белән характерлы. Аның иң беренче җыры «Урман кызы»н (Һ. Такташ шигыре) яки соңгы җырларын иске төшерсәк, аларның иҗади кыйммәте бер төрле: халыкчан, яна, тапталмаган интонацияләргә бай һәм, иң әһәмиятлесе—заманча яңгыраш.

Республикабызда җыр сәнгатенең Җәүдәт Фәйзи чоры булды, дияргә мөмкин. Үз заманында аның җырларын башкармаган бер генә җырчы да, аның әсәрләре кермәгән бер генә концерт программасы да юк иде. Төрле спектакльләргә язылган музыкалар композиторның иҗатында шулай ук зур урын алып тора. Ж. Фәйзи үз гомерендә 20дән артык спектакльгә музыка язды. Алар мөстәкыйль музыка әсәрләре булып та таралдылар. Тамашачыны, тыңлаучыны нык тетрәткән әсәрләрнең берсе М. Әмирнең «Тормыш җыры» спектакленә язган музыкасы булды. Андагы «Фатыйма арышлары»н яки Басыйрның «Җырга салып җибәргән хаты»н дулкынланмый

тынлап буламы?! Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар»ыннан Гайнавал җыры кайсыбызның колагында яңгырап тормый? Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ына язылган «Сәлви җыры» да зур сәнгать әсәренә хас эзләнү һәм зәвык белән эшләнгән. Бу иҗади уңыш композиторны тагын да яңа әсәрләр язарга рухландырды һәм татар музыкасында булачак «җиңел музыка» өлкәсенә нигез салган классик әсәр—«Башмагым»ның иҗат ителүенә китерде. Бу музыкаль комедиясе белән композитор татар музыкаль сәхнә әсәрен генә тудырып калмады, күп милләтле совет тамашачысының алтын хәзинәсенә дә яңа рухи байлык өстәде. Аны илебезнең байтак театрлары, төрле телләргә тәрҗемә итеп, үз сәхнәләрендә куйдылар. Ул украин, башкорт, тува, бурят телләрендә, Ташкентта—үзбәк телендә, Свердловскида—рус телендә барды, Казан сәхнәсендә исә 600 дән артык куелды. Шулай итеп, милли «башмак» чын мәгънәсендә интернациональ «башмак»ка әйләнде. Чөнки Җәүдәт Фәйзинең иҗаты бөек рус классигы Н. А. Римский-Корсаковның, «халык иҗаты авазларына һәм табигатенә колак салып, аларның көйләрен үз иҗатына нигез итеп алырга», дигән сүзләренә туры килә.

«Башмагым»нан соң композитор хәзерге заман темасына «Акчарлаклар» (Ә. Фәйзи либреттосы), «Алтын көз» (Г. Насрый) музыкаль комедияләрен язды. Күләмле әсәрләр язу аны «Тапшырылмаган хатлар» лирик операсына алып килде. Ж. Фәйзи аңа либреттоны да үзе язды. Гомумән, ул шагыйрь йөрәкле иде. Аның нәсерләре, шигырьләре, поэмасы, Татарстан китап нәшрияты тарафыннан чыгарылган «Музыкаль кичәләр» китабы, Мәскәү нәшриятында басылып чыккан симфоник оркестр турында балалар өчен язылган «Кунаклар» исемле хезмәте һәм башкалар бар.

Ж. Фәйзинең иң яраткан жанры—вокаль жанр. Чөнки җыр аның табигатенә хас иде. Ул, ару-талуны белмәстән, җырның рамкаларын киңәйтте, романслар, балладалар язды. Болар—Зоя Космодемьянская, Газинур Гафиятуллин, Мулланур Вахитов турындагы балладалар. «Газинур» балладасы яңгыраганда, тыңлаучының күз алдына йомшак күңелле, монсу, туган ягына гашыйк, дошманга карата кыю һәм аяусыз егет образы килеп баса. Вокаль әсәрләрнең күбесе туган як гүзәллеге турында. С. Хәким шигыренә язылган «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Казан арты» һәм башка бик күп әсәрләре әнә шундыйлар.

Сөекле композиторыбыз халыкка үз әсәрләрен тәкъдим итү белән генә чикләнмәде, ул халык җырларын эшкәртүгә дә зур көч куйды. Концертларда, радиотапшыруларда еш яңгырый торган «Кошлар кебек», «Матур булсын», «Рәйхан» һәм башка бик күп көйләр аның эшкәртүендә яңгырады. Алай гына да түгел, ул халык җырларын җыеп, классификацияләде, аннотацияләр язып, китап итеп бастырды. 235 җырдан тупланган «Халык җәүһәрләре»—әнә шуның мисалы. Болар—35 ел буенча бөртекләп җыелган хәзерге заман җырлары.

Җәүдәт ага эшчәнлегенең тагын бер ягы шул, ул унган җәмәгать эшлеклесе дә иде. Халык иҗаты йорты үткәрә торган үзешчән композиторлар семинарында даими рәвештә практик ярдәм күрсәтте. Татарстан радиосы аша музыкаль кичәләр оештырып, әңгәмәләр алып барды, авыл районнарында очрашулар үткәрде, халык көйләрен җентекләп җыйды...

Татарстан Композиторлар союзы оештырылган көннән башлап, шактый еллар шунда идарә члены һәм председатель урынбасары хезмәтен башкарды. Хөкүмәтебез Җәүдәт Фәйзинең хезмәтләренә зур бәя бирде. Аңа РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемнәр бирелде, ул ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Ж. Фәйзи безнең көннәрдә һаман да киң эрудицияле, зур мәгълүматлы, барлык вакыйгалардан хәбәрдар, халыкның ихтирамына лаек олы композиторыбыз булып сакланыр.

**Бату МУЛЮКОВ,**
*композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*
*1980 ел.*

Газинур
Морат

## ИКЕ ИКЕҢ БИШ БУЛА

### Нобель бүләге

Көтмәгәндә-уйламаганда Татарстан Язучылар берлегенә Стокһольмнан, Нобель премиясе комитетыннан телеграмма килеп төште.

«Хөрмәтле вә гыйззәтле татар язучылары!—дип язылган иде анда.—Без Сезнең бөек халкыгыз илә әдәбиятегез алдында баш иябез, һәм Сезгә тирән ихтирам йөзеннән, Нобель премиясе комитеты татар әдипләре өчен махсус квота булдырырга карар итте. Без Сездән иң лаеклы кандидатыгыз турында белешмә җибәрүегезне көтеп калабыз».



Телеграмманы укып чыккач, берлектәгеләр аһ итте. Итәрсен дә, бу инде сина елнын-елында Тукай премиясен бүлеп утыру ише генә мәрәкә түгел иде. Нәрсә ул Тукай бүләге?! Анын әҗере хәтта калтырча бер «иномарка» сатып алырга да җитми ләбаса. Ә монда сүз миллион доллар турында бара! Шуна күрә баштарак бу үтә дә четерекле мәсьәләне, зур гауга кубудан куркып, киң җәмәгатьчелеккә чыгармыйча, үзара гына хәл кылып, Ренат Харис кандидатурасын бертавыштан хупларга уйлаган иделәр дә, тик, уйлаша торгач, бу яшертен ниятгән кире кайтырга булдылар. Һәм дөрес эшләделәр. Чөнки әлеге кырын эшнең кырык минуттан соң ук Марсель Галиевкә мәгълүм булачагы һәм анын халыкара буза куптарачагы болай да билгеле иде. Шунлыктан Тукай клубында язучыларның гомуми җыелышын җыюдан башка чара калмады.

Бу юлы җыелышны алып бару вазифасын ни өчендер Зиннур Хөснияргa йөкләделәр. Киләсе сайлауда син рәислеккә барыбер үз кандидатураңны куячаксың. Әгәр рәис була калсаң, әйдә, язучыларның хуҗалык эшләре белән таныша тор, дигәннәрдер инде, күрәсең. Ә Зиннурга президиум түрендә хуҗа булып утыру чыннан да бик килешә иде.

Язучылар берлеге тарихында булмаган хәл: бу юлы җыелышка һәммәсе дә—йөри алганнары да, алмаганнары да, яза белгәннәре дә, белмәгәннәре дә килгән иде.

Менә җыелыш башланып та китте. Зиннур Хөснияр беренче хәлиткеч сүз әйтүне, әлбәттә инде, якын һәм ышанычлы дусты Ркаил Зәйдуллага

тапшырды. Ркаил дә, дуслыкның кадерен яхшы белүче инсан буларак, сүзен үгезнең мөгезеннән алып башлады:

—Мин үзем Нобель премиясенә үк дәгъва итмим,—диде ул, Зиннур Хөснияр тарафына карамаска тырышып. —Безнең әдәбияттә бу абруйлы бүләккә лаек егетләр болай да җитәрлек. Мәсәлән, Ләбиб Лерон.

Зал бер мәлгә өнсез калгандай булды. Хәтта президиум рәисенең дә йөзендә аптырау катыш үкенү галәмәте шәйләнә иде. Ләкин әле Ркаилнең сүзе бетмәгән булып чыкты.

—Әйе, мин үзем шәхсән Ләбиб Лерон кандидатурасына каршы түгел,—дип дәвам итте ул чыгышын.—Ни дисәң дә, Ләбибнең паспорты белән Нобель премиясен алу бермә-бер җинелрәк булачак. Хәзер бит паспортта милләт күрсәтү юк, ә Ләбибнең Актаныш мулласы кушкан исеме Лемон икәнен күпләрегез беләдер инде. Леронов Лемон Лиронович, ягъни мәсәлән. Ләбибнең әле үз бабасы кушкан исеме дә бар, анысы—Ленарис. Авылдашлары да, җәмәгате дә, Зөлфәтнең хатыны Фирая апа да аны нигездә Ленарис буларак белә. Ә дөньяга ул студент чагында мин кушкан исем белән танылды. Монысын, белеп торыгыз, дип кенә әйтүем. Кыскасы, бүген мин татар әдәбиятендә Лемон-Ленарис Лиронович Лероновтан да кулайрак кандидатура күрмим. Чөнки аны Нобель премиясе комитетында, һичшиксез, яһүд дип беләчәкләр. Ә яһүд ул, үзегез беләсез, теләсә кайсы халык телендә дә язарга мөмкин. Мандельштам да, әнә, 10 яшенә кадәр урысча бер авыз сүз белмәгән...

Ркаилнең чыгышы шактый дәлилле булса да, ул җыелыш халкын һич кенә дә куандырмады. Бигрәк тә Равил Фәйзуллин борчулы күренде. Гәрчә, паспортындагы исем шәрифләре әлләни зур өметләр уятмаса да, Русиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Тукай һәм Җәлил премияләре лауреаты, Татарстанның халык шагыйре, һәм, ниһаять, туган авылында үзе дә «җәбрәй» дигән нәсел кушаматы йөртүче кеше буларак, Равил Габдрахманович Нобель премиясен болай җинел генә кулдан ычкындырырга һич тә теләми иде. Шуңа күрә аңа, сүзне шаяруга борыбрак, залга бер реплика ыргытырга туры килде:

—Әгәр мең еллык татар әдәбиятенең дәрәҗәсе язучының паспорттагы исеме белән үлчәнә икән, Ркаил Рафаэлевич үзе дә Нобель премиясенә бик тә лаек,—диде ул, янәшәсендә утырган шәкерте Марсель Галиевкә нидер ишарәләп. Марсель Баяновичның үзен хуплап сүз әйтәсенә остаз бик тә ышана иде. Һәм шулай булып чыкты да. Остазының ни әйтергә теләгәнен Марсель Галиев шундук аңлап алды.

—Әйе, җәмәгать, Фәйзуллин дөрес әйтә,—диде ул, сәхнәдәге алагаем зур Тукай сурәтенә текәлеп.—Фәйзуллин чыннан да хак сөйли: әгәр бик тырышсак, без Нобель премиясен Ркаилнең үзенә дә рәхәтләнеп бирә алабыз. Аның исеме генә дә ни тора! Мондый исем хәтта Тель-Авивның үзендә дә юктыр. Ул исемнең ни аңлатканын без үзебез дә бик соңлап, Газинур Морат белән пирәшләп утырганда гына ачыкладык әле. Безнеңчә «Рабоче-крестьянская армия интернационалистов-ленинцев» була икән ул. Кыскартып әйтсәң, РКАИЛ килә дә чыга. Дөрес, заманында Сибгат Хәким аны, барыбызга да аңлаешлы телгә кучереп, Ркацетели дип кенә йөртә иде...

Марсель Галиевнең шундый зур җыелышта, могтәбәр язучылар алдында, Мөдәррис Әгъләм әйтмешли, ашау-эчү турында сүз кузгатуы Газинур Моратның күнеленә бигүк хуш килмәде, билгеле. Шулай да ул җыелышта торып сүз әйтергә форсат чыгуына сөенеп тә куйды.

—Нобель премиясе комитеты, һәрвакытгагыча, дөрес карар кабул иткән,—дип зурдан кубып башлады Газинур сүзен.—Халыклар төрмәсендә яшәргә һәм язарга хөкем ителгән һәр татар әдибе диссидент саналырга, Нобель премиясе лауреаты булырга лаек.—Газинурның, гадәттәгечә, акыллы

булып күренергә тырышуы яһүдләр кебек «р» авазын әйтергә иренүеннән дә аңлашылып тора иде.—Ләкин үзегез күреп торасыз: Нобель премиясен бүлеп утыручылар татар өчен бер генә урын тәгаенләгән. Димәк, без дә бердәнбер лаек кандидат өчен тавыш бирергә тиеш булабыз. Мин үзем, мәсәлән, хәзерге татар әдәбиятендә Марсель Баянович Галиевтән дә кулайрак кандидатура юк дип исәплим. Ул Нобель премиясе лауреаты булырга паспорт буенча мотлак туры килә. Марсель, диденме—шундук Марсель Пруст, Марсель Марсо хәтергә килә; Баян, диденме—Израильдәге бер күл һәм Алла Баянова күз алдына килеп баса; Гали, диденме—каршына Галилео Галилей белән Бутрос Гали житәкләшеп килгәндәй була.

Жыелыш әһелләренә Газинурның дәлилләре тагын да ышанычлырак булып тоелды, ахры—алар бертавыштан Марсель Галиев кандидатурасын яклап тавыш бирде.

Искитмәле манзара: татар язучылары арасында мондый ук бердәмлекнең Кол Гали заманыннан бирле булганы юк иде әле.

Бераздан Нобель премиясе комитетына татар галәменнән бер-бер артлы хатлар ява башлады. Стокһольмнан килеп ирешкән хәбәрләргә караганда, карт һәм яшь пенсионерлар исеменнән сырланган әлеге хатларда бары бер нәрсә—Марсель Галиевнең Азнакай төбәгендә туып-үскән чеп-чи татар икәнлеге хакында язылган булып чыкты.

Шуннан бирле Марсель Галиевнең «дело»сы Стокһольмга барып житә алмыйча, һаман кайдадыр адашып йөри...

## Яшәсен Максим Галкин!

Русия чираттагы сайлау алды мәрәкәсе белән матавыклана. Бу юлы безнең хөрмәтле электорат алдында яңа Президент галижәнабләрен сайлап кую бурычы тора. Үтә дә җаваплы һәм, әйтергә кирәк, тарихи миссия йөкләтелгән безгә, ханым-әфәнделәр. Президент сайлап кую—ул сиңа хатын алу гына түгел. Хатынны аны, күңелең ятмаса, анасына кире илтеп бирергә дә була, ә менә Президент сайлаганда ялгышсаң, шул бер хатаң аркасында гомер буе чиләнергә дә бик мөмкинсең. Кыскасы, сөйкемсез хатын белән тордың ни дә, сөйкемсез Президент белән яшәдең ни—икесе дә Ходай биргән каза инде аның.

Шуңа күрә киләсе сайлауда мин үзем дә, сәяси субъект буларак, актив рәвештә катнашырмын дип торам. Бу юлы инде, бер акыллысы әйтмешли, начар хакимиятләрне сайлауларда катнашмаган яхшы ватандашлар сайлый диярлек булмасын иде. Мин, Ходай насыйп итсә, тавышымны, ике дә уйлап тормастан... Максим Галкинга бирәчәкмен. Дөресен әйтим, бик тә ошый бу егет миңа. Әгәр үзен телевизордан бер генә көн күрми торсам да, бу кызыксыз дөньяда яшәүнең бер кызыгы да калмас кебек тоела башлый. Шөкер, ярый әле андый көннең булганы юк, юкса, телевидениенең барча каналлары аша берөзлексез күрсәтелә торган мәзәкчеләр мәжлесенә, мөһим дәүләт эшләреннән аерып, күпме депутат, министрны, экс-Президентны һәм, хәтта ки, Президентның үзен дә чакырып китерергә туры килер иде.

Нәрсә, нәрсә, Президентлыкка кандидатлар исемлегендә Максим Галкинның исеме юк, дисәкме? Әйе, дөрес әйтәсез, сезнең ише ЕР, КПРФ, ЛДПР, СПС әгъзалары өчен, бәлки, юктыр да ул, ә менә минем кебек фиркасезләр өчен Галкин исемлектә һәрчак булды һәм булачак та!

Максим Галкин!!! Күрәсезме, ничек горур яңгырый бу исем! Аңа хәтта Алла Пугачева үзе дә гыйшык тота. Ә Примадоннаны гашыйк итәр өчен, үзегез беләсез, кем дигәндә, Филипп Киркоров кебек баскетболист буйлы, ыспай, чибәр егет булырга кирәк. Ләкин хикмәт буйда гына түгел икән шул, җәмәгать. Әнә, Максим Галкинның буй-сыны безнең мәзәк остасы

Камил Кәримовныкыннан әлләни аерылып та тормый, ә үзе Примадонна янәшәсендә Филядән дә мәһабәтрәк булып күренә, чукынмыш. Хәер, әйтүләренә караганда, безнең Камил Кәримовка да Әлфия Афзалова башаягы белән гашыйк диләр ич.

Кыскасы, Президент булып сайланыр өчен Максим Галкинның бөтен параметрлары да мотлак туры килә. Өстәвенә, ул сайлау алды кампаниясен дә теләсә кайсы кандидатка караганда остарак һәм нәтиҗәлерәк алып бара. Телевизорда ничә канал бар—һәркайсыннан һәркөнне бертуктаусыз Максим Галкин сөйләп тора. Мондый бәхет хәтта гамәлдәге Президентка да елына бер генә мәртәбә—Русия халкын Яңа ел белән тәбрик иткәндә генә елмаеп ала.

Инде килеп, Максимның башка кандидатларга караганда тагын бер зур өстенлеге бар—ана табигать тарафыннан теләсә кем булып сөйли яки җырлый белү куәсе бирелгән. Тели икән—Ельцин рәвешенә керә, тели икән—Путинча сөйләргә керешә, тели икән—Жириновский булып кычкырынырга тотына, тели икән—Черномырдинга әйләнә, тели икән—Зыкинача җырлый башлый... Ул хәтта Задорнов, Хазанов, Петросян, Степаненко, Шифрин, Аншлаг булып та кыландыра белә әле.

Кыскасы, әйтәсе килгәнем шул: Максим Галкин югарыда исемнәре аталган һәм аталмаган затларның бөтенесен берүзе дә алыштыра ала. Русиядә гомер-гомергә иң кадерле байлык саналган кеше ресурсларына никадәр зур экономия булачак дигән сүз бит бу! Моңардан ил дә, халык та отачак кына, җәмәгать.

Әйтик, көннәрнең берендә Галкиныбыз, Черномырдин булып, Шамил Басаевка шалтыратты һәм аны: «Хәерле иртә, Шамил!»—дип сәламләде ди. Әйтте диярсез, Чечнядә шул көнне үк сугыш тукталачак, чечен гыйсъянчылары, автоматларын ташлап, шундук йөзем, хөрмә үстерергә тотыначак.

Әйтергә онытып торам икән: Галкин, Русиянен яна тарихында беренче мәртәбә буларак, Президент Путинча сөйләшергә җөрьәт иткән гаярь егет тә әле ул. Һәм менә шул тавыш, Уфага шалтыратып, татар теленен хәзерге торышы турында сораштыра башласа, иманым камил, Башкортстанда татар теленә мөнәсәбәт шундук 180 градуска үзгәрер иде. Телевизордан көне-төне мәзәкчеләр мәҗлесен тамаша кылып утыручыларның күргәне бардыр: Галкин Америка Президенты булып та бик оста маташтыра. Димәк, Максимга Гыйрактагы сугышны туктату да берни тормый. Моның өчен анын Пентагонга бер шалтыратуы да җитә.

Хәер, шалтырату дигәннән, Максим Галкинның шалтыратмый калган көннәре бик сирәк инде анын. Ул бит әле Русия халкын ничек итеп миллионер булырга да өйрәтеп маташа. Анда исә, телисенме-теләмисенме, каядыр шалтыратып, электоратны миллионер итәр өчен нык кына тырышырга да туры килә. Ә бездә, үзегез беләсез, эшләмичә генә миллионер булырга хыялланмаган электорат юк та юк инде ул. Шуңа күрә мин киләсе сайлауда үз тавышымны һич икеләнмичә Максим Галкинга бирәчәкмен, иптәшләр.

Яшәсен Максим Галкин!

## Үле тел

Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясенең 1552нче гадәттән тыш сессиясе гаять мөһим мәсьәләгә—латин телен кабат терелтү проблемасын тикшерүгә багышланган иде. Ник дисәгез, дөнья куа-куа бер-берсен тәмам анламас хәлгә килгән халыкларга һич кичекмәстән уртак бер аралашу, аңлашу теле кирәк иде. Дөрес, баштарак бу вазифаны инглиз теле башкарыр дип уйласалар да, әлеге нияттән бик тиз кире кайтырга

туры килде, чөнки, дөньяның ярты халкы болай да безнеңчә сөйләшә инде, дип кытай вәкилләре шундук протест белдерде. Шуна күрә БМОдагыларга һәр халыкны да канәгатьләндерә торган нейтраль тел уйлап табудан бүтән чара калмады. Тел өлкәсендә бөек ачышлар ясаган Нобель премиясе лауреатларының да уртак фикере иде бу.

Әмма һич көтмәгәндә БМО алдына тагын бер катлаулы мәсьәлә килеп басты. Телне терелтим дисәң, шул телдә сөйләшүчеләрнең булуы да кирәк ич әле! Йә, кем инде үз теленнән йөз чөереп, әллә ничә мең еллар элек җан тәслим кылган телдә сөйләшә башласын ди?! Америка индеецларының берәр кабиләсенә көчләп таксаң гына инде... Әмма монысы да гамәлгә ашарлык нәрсә түгел, чөнки әлерәк кенә майя кабиләсенең юлбашчысы Ала Бүрене Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль секретаре итеп сайлап куйдылар.

Бу юлы аларга Тартариянең БМОдагы вәкаләтле вәкиле үзе ярдәмгә килде.

—Сезнең дару өчен рецепт язарга гына яраклы телегезне дә безнең бөек татар халкы гына терелтергә сәләтле,—дип белдерде ул, югары мөнбәрдән чыгыш ясарга форсат чыгуына чиксез куанып.—Татар теле ЮНЕСКОның иң абруйлы исемлегенә кертелгән үндүрт телнең берсе булып та тора. Һәм, гомумән, төрле тәҗрибәләр үткәрер өчен дөньяда безнең халыктан да кулайрак халык юк. Без 1500 ел эчендә дүрт мәртәбә әлифба алыштырып та, исән калган кавем.

Сүзгә БМОның Генераль секретаре да кушылды.

—Тартария вәкиле дөрес әйтә,—диде Ала Бүре.—Безнең майя телендә дә татар кәлимәләре бик күп очрый...

Ләкин Генераль секретарьның әйткәннәре башкорт вәкиленә ошап җитмәде бугай, ул:

—«Татар» дигәнегез тарихи дөреслеккә туры килми, аны «башкорт»ка алыштырырга кирәк,—дип Ала Бүрене төзәтеп куярга мәҗбүр булды.—Цивилизациянең каян башланганлыгын онытмавыгызны үтенәм, иптәш Генераль секретарь! Иң башта сез миңа шуны аңлатып бирегез: татарлар латинга күчкәч, без дә шул телдә сөйләшә башларга тиеш булабызмы инде?

Генераль секретарь җавап бирергә дә өлгералмый, калды, залда Московия вәкиленең кисәтүле тавышы яңгырады:

—Татарларның латинча сөйләшүе Московиянең иминлегенә зур куркыныч тудыра, шуңа күрә без моңа категорически каршы,—диде ул, бәхәскә урын калдырмаслык итеп.

Чыннан да, Московия вәкиленең чыгышыннан соң бәхәс куертып торуның хаҗәте юк иде инде. Чөнки дәүләтләрнең иминлеген саклау—Берләшкән Милләтләр Оешмасының төп вазифасы санала иде.

Шулай итеп, көнүзәк мәсьәләне тавышка куйдылар.

Ни гаҗәп, аны уңай хәл кылыр өчен бу юлы да татарга нибары ике тавыш җитмичә калды...

## Указ

Тавык төшенә тары керә дигәндәй, Алмаз Хәмзин дә төшендә бер генә сәгать булса да Президент кәнәфиендә утырып торганын күргән бит, әй. Әле җитмәсә, шул төшен, мәзәк итеп, сәхнәдән дә сөйләп йөри башлады. Билгеле инде, Алмазның мәзәген тамашачылар күз яшьләренә буыла-буыла, иләндә тәгәри-тәгәри тыңлый иде.

—Да, малай,—дип тел шартлатты халык.—Бәгъзеләр ише генә

шамакайланмый бу егет, билдән түбән төшми, югары төшенчәләр белән эш итә!

Шуңадыр, күрәсең, Алмазның мәзәге дә югарыдагыларга көне-сәгате белән барып ирешә. Ә алар, гадәттәгечә, уйлаштылар-уйлаштылар да Хәмзиннең үзе белән сөйләшеп карарга булдылар.

—Алмаз Наилевич, сезгә бик мөһим бер сүзебез бар иде, вакыт табып, безнең тарафларга сугылып чыга алмассызмы?—диделәр.

Көтелмәгән хәбәрдән хәтта сәхнәләрдә аунап үскән Алмазның да тез буыннары йомшарып китте, тамагына төер утырды, шуңа күрә телефон төрепкәсенә дә бер кәлимә сүз кайтарып әйтә алмады. Секунд эчендә ми күзәнәкләре буйлап мең төрле уй йөгереп узды. Ләкин үзе бу галәмәтне ни-нәрсәгә юрарга да белмәде. Әллә булачак юбилеема бирәр сюрприз әзерлиләр микән, дип тә уйлап карады, әллә «Алмаз-холдинг» кебек төшемлерәк урынга аткарып, кеше көлдереп йөрүдән туктатырга чамалыйлармы икән, дип тә тәшвишләнде, әмма артык дулкынланудан башына бер генә дә адәм рәтле фикер килмәде.

Ләкин Алмазыбыз юкка гына борчылган булып чыкты. Аны югарыда кочак җәеп, кем әйтмешли, якты чырай, такта чәй белән каршы алдылар. Һәм, әлбәттә, әйтәсе сүзләрен дә, әйләндереп-тугландырып тормыйча, турыдан ярып әйттеләр.

—Алмаз Наилевич, сезнең «Төш» дигән мәзәгегез безгә дә бик ошады, шуңа күрә, әйдәгез, күңелегездә калмасын, өнегездә дә берәр сәгать Президент кәнәфиендә утырып карагыз,—диделәр.

Алмаз монысын ук көтмәгән иде, билгеле. Карале, дип уйлап куясы итте ул шунда, телевизордан гел җитди-акыллы сүзләр генә сөйләүче кешеләрдә дә юмор хисе була икән лабаса.

Шулай да Алмаз аларның тәкъдименә каршы килергә базмады. Болай да тәртәгә аз типмәде ич инде, ә ахыры гел күңелсез бетте: «Алмаз плюс» тапшыруы «Алмаз минус»ка әйләнде, «атказанган» дигән исемнең дә сәхнәләрдән кычкырып әйтелми торганын гына бирделәр...

Бу юлы инде һич кенә дә чыгымларга, тәртәгә тибәргә ярамый иде. Әгәр адәм баласына үз гомерендә бер генә тапкыр бирелә торган шушы форсатны да кулдан ычкындырса, Алмазны сәхнәдәш дуслары—Шамкай белән Шәрәфи дә мәңге гафу итәчәк түгел иде.

Шуңа күрә ул, теләсә дә, теләмәсә дә, Президент кәнәфиенә барып утырырга мәҗбүр булды. Һәм, ни гаҗәп, шул мәлдә үк Алмаз Наилевичне дә, нәрсә эшләргә, дигән мәңгелек сорау бимазалый башлады. Халык бәхетле булсын өчен нишләргә? Билгеле, мондый биниһая зур мәсьәләне ялгыз башың гына хәл итү мөмкин түгел иде. Шуңа күрә Алмаз Наилевичкә дә эш сәгатен үзенә акыллы киңәш бирердәй кешеләрне барлаудан башларга туры килде. Һәм ул шундук якташы, авылдашы Разил Вәлиевкә шалтыратып карарга булды. Чүтеки бергә уйнап үскән егет ич. Үзе язучы, үзе депутат. Өстәгеләр белән дә бөеренә таянып сөйләшә. Сүзенә дә һәрчак колак салалар.

Ләкин, ни кызганыч, Разил Исмәгыйлевич Казанда булып чыкмады. Аны ашыгыч рәвештә Американың Конгресс китапханәсенә тәҗрибә уртаклашыр өчен чакырып алганнар иде.

Әлеге хәбәрдән Алмаз Наилевичнең күз аллары караңгыланып китте. Инде нишләргә, дигән уй тәмам чарасыз итте. Әмма бу дөньяда аңа киңәш бирердәй акыллы кешеләр барыбер дә калган иде әле! Алмаз Наилевич сөенеченнән ашыга-кабалана якташы, күрше авыл егете Зөлфәт Хәкимнең номерын җыярга кереште. Ә нигә? Үзе җырчы, үзе композитор, үзе драматург, үзе Президентның ышанычлы заты. Кыскасы, югары даирәләрдә

да абруйлы, үз кеше.

Ходайның рәхмәтедер инде, телефон төрепкәсен Зөлфәт Хәким үзе алды.

Зөлфәтнең холык-фигылен яхшы ук белгәнгә күрә, Алмаз Наилевич энекәшенең хәл-әхвәлен сорашып тормаска булды, юкса гозеренне әйтеп өлгерә алмавың да бар.

Зөлфәтнең җавабы, гадәттәгечә, бик кыска булды:

—Күпме түлисең? Мин сезгә бушлай фикер чәчеп йөрергә Марсель Галиев түгел!

Юк, Алмаз Наилевичнең якташына аз гына да хәтере калмады. Бу мәсьәләдә Зөлфәт һичшиксез хаклы иде. Үз бәясен яхшы белә егет. Рафаэль Сәхабинең авылдашы икәнлеге әллә каян күренеп тора. Сәхаби дә артистлыкка укымаса, менә дигән юморист булып китәсе иде бит. Шуна күрә Алмаз Наилевич якташының акыллы кинәш бирәсенә аз гына да шикләнми иде.

Опера һәм балет театрының Һолландиядә гастрольдә йөрүе сәбәпле, Рафаэль Сәхаби дә өендә булып чыкты, рәхмәт төшкере. Алмаз Наилевич бар кыюлыгын җыеп, гасабиланып, аңа да шул ук гозерен кабатлады:

—Нәрсә эшләргә?

—Андый сорау бимазалый башласа, мин үзем дә Разилдән, йә Марсель Галиевтән чылтыратып белешәм,—диде Сәхаби, гадәттәгечә, көр, бәрхет тавыш белән.—Алар нәрсә эшләргә кирәген шундук әйтеп бирә...

Шулай итеп, Алмаз Наилевичкә, Сәхабинең кинәшен тотып, Марсель Галиевкә шалтыратудан башка чара калмады. Юкса эш сәгате тәмамланырга да санаулы гына минутлар калып бара иде. Шулвакыт, көтмәгәндә, Алмаз Наилевичнең үз кесә телефоны чылтырый башламасынмы! Аның «Әлү?» дию булды, теге очтан:

—Ү-зе-ме? —дигән бик тә таныш тавыш ишетелде.—Ү-зе-ме? Карале, нәдәнем, бу татар сәхнәдән кеше көлдерми торган мәзәк сөйләп, кеше көлдереп йөрүдән кайчан туктар икән? Әнә, бераз ябрәйләрдән өйрәнегез, йә минем мәзәкләрне күбрәк сөйләп йөрегез. Кеше көлдерәм дигәч тә, кендектән аста кармаланырга сколько можно?!

Бу, әлбәттә, Марсель Галиев үзе иде. Аның шулай, кәефе килгәндә, шалтыратып, дус-ишләренең хәл-әхвәлен белешү гадәте барлыгын Алмаз яхшы белә иде. Әмма Алмазның бер сәгатькә Алмаз Наилевичкә әйләнеп алуы турында Марсель хәбәрдар түгел иде бугай. Хәер, аның шулай булуы хәерлерәктер дә әле, чөнки, җае чыгып торганда, Марсельнең дә «Халык язучысы» исеме турында сүз кузгатуы бик мөмкин иде.

Шул секундта ук Алмаз Наилевич үз гомерендә беренче һәм соңгы Указын чыгарды. Кеше көлдерми торган мәзәк сөйләп, кеше көлдереп йөрүдән туктарга, диелгән иде анда.

Нәкъ шул мәлдә Алмаз Хәмзиннең Президентлык сәгате дә чыкты.

Указ «Яшел эшләпә» гәзитендә басылу белән үз көченә керде...

## Кремльчә сөйләшү

Мәскәү телевидениесенең кайсы гына каналын ачсаң да, аннан пелт итеп Жириновский үзе, йә аныңча мәтәштерә белә торган Максим Галкиннар килеп чыга. Русия сәясәтенең иң кәттә шоумены буларак, Владимир Вольфович, билгеле, бөтен җиргә дә үзе генә өлгерә алмый, шуңа күрә аны, державаның баткак юлларында йөреп пычранган кирза итеген Һинд океаны

суларында юып йөргән чакларында, юмористлар спецназы алыштырып торырга мәҗбүр. Шунсыз ярамый да, юкса, гомер бакый мәзәк тормышта яшәп, үзе дә мәзәкчегә әйләнеп беткән халыкта кабат житдирәк тамаша, мәсәлән, ГыКыЧыПычылар кебек, «Аккош күле» балетын карыйсы килү теләге дә туарга мөмкин бит. Әйттем исә кайттым, анысын вакытлы-вакытсыз берүк күрсәтә генә күрмәсеннәр инде. Ә менә Жириновский һәм аның юморист коллегалары алмаш-тилмәш телевизордан берөзлексез сөйләп торганда, халыкнын күнеле һәрчак көр, тамагы—тук, өсте—бөтен, күзе гел хикмәттә булачак. Чөнки, Жириновский авызы белән Кремль абзагыз үзе сөйләп тора, диләр ич. Күрәсен, белеп әйтәләрдер: югыйсә безнен тормышлар гел ул дигәнчә генә бармас иде.

Ләкин безгә барыбер дә үз Кремлебезнен сүзе—сүз. Мәскәү сүзен бик күп тыңладык инде. Тынлый-тынлый телсез, денсез кала яздык. Житеп торыр. Безнен үз Кремлебез бар, безгә кеше Кремле кирәкми.

Ә инде Кремлен бар икән, димәк, анынча сөйләп торучы депутатың да булырга тиеш. Юкса, аларны сайлап һәм сайлатып куюның бөтенләй дә хаҗәте калмас иде. Кызык, бездә Кремль булып сөйләү вазифасы кайсы депутатка йөкләтелгән икән?

Яшерен-батырын түгел, мин үзем, мәсәлән, бу мәсьәләдә өч депутатыбыздан аеруча нык шикләнәм. Чөнки алар, беренчедән, өчесе дә бик популяр. Икенчедән, халык үзләрен дә, сүзләрен дә һәрдаим күреп, ишетеп, укып тора. Өченчедән...

Шәт, сүзнең кемнәр турында барганын үзегез дә чамалагансыздыр инде. Әйе, нәкъ шулай: Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев һәм Роберт Миннуллин җәнабләре хакында бара сүз. Өчесе дә коеп куйган оратор, сүз эзләп, кесәгә керә торганнардан түгел. Өчесе дә югары мөнбәрдән ана телендә генә чыгыш ясый. Ә безнен Кремльгә нәкъ шул гына кирәк тә! Путин үзе татарча сөйләп торганда—бигрәк тә.

Дөрес, үзбәк әйтмешли, Кремльчә гәп оруда Роберт Миннуллиннын, язучы-депутат коллегаларыннан аермалы буларак, зур бер өстенлеге бар. Ул халыкка әледән-әле күрсәтмәләр бирергә ярата. Нәкъ Кремльчә инде менә! Мәсәлән, анын «Яратыгыз!», «Бәхетле булыгыз!» дигән җырларын җырлап кинәнмәгән татар сирәктер. Ә бит уйлап баксаң, халыкны бәхетле итү Кремльнен дә төп максаты булып тора. Менә шуннан сон, безнен Кремльчә кайсы депутат сөйли икән, дип баш ватасы калмый инде...

## Революционер

Без кемнән ким—безнен дә революционер буласы килә. Хәзер бит революция ясыйм, дисән, күн тужурка киеп, наган асып, банк-фәлән басып, байлар талап йөрисе юк. Муеныңа ниндидер төскә манылган шарф элеп, әлеге дә баягы мәйданга чыгып басасың да өстәгеләрне бурлыкта, ришвәтчелектә, коррупциядә—кыскасы, балда-майда йөзеп яшәүдә гаепли башлыйсын.

Без кемнән ким—безнен дә балда-майда йөзәсе килә.

Ләкин менә революцион шарфны нинди төскә манырга—төп мәсьәлә әнә шунда. Дөресен генә әйткәндә, бу дөньяда безгә төс булырдай бер генә төс тә калмаган бугай инде. Чөнки революционер элгәрләребез бар төсләрне дә национализацияләп, экспроприацияләп, приватизацияләп, монетизацияләп бетергән.

Кызыл төс—кызылларныкы, ак төс—акларныкы, кара төс—анархист һәм антихристларныкы, яшел төс—яшелләрнеке, зәнгәр төс—зәнгәрләрнеке. Хәтта кызгылт сары төсне дә украин кардәшләребез, без авыз ачып торган

арада, үзенеке итеп өлгерде. Юкса, ул төс безгә дә бик мач килеп торыр иде. Ә нәрсә? Алардагы мәйдан бездә дә бар, алардагы РУХ бездә дә житәрлек. Өстәвенә, хохол үзе дә татар сүзе. Безнеңчә тотам чәч дигәнне аңлата. Болары бер хәл, заманында шул «тотам чәч»ләрне кара болгар дип тә атап йөрткәннәр әле.

Ләкин, сары, сары, дия торгач, берүк сары йортка гына илтеп яба күрмәсеннәр. Классик әйтмешли, юлларыбыздан күренгәнчә, болай да дураклар илендә яшибез бугай ич инде...

## Татар космонавты

«Чыктым аркылы күпер» дигән китабы басылып чыгу уңаеннан «Нью-Йорк таймс», «Вашингтон пост», «Жэнминь жибао», «Мәдәни җомга», «Асахи» һәм «Морнинг стар» гәзитләре мөхбирләренә биргән интервьюсында Ләбиб Лерон дөньяны аяктан егарлык хәбәр ирештерде. Бактың исә, ул малай чагында һич кенә дә язучы булырга теләмәгән, ә галәмгә очарга хыялланган икән бит. «...Әнинең карынында чакта ук «космонавт» сүзен еш ишеткәнмендер, күрәсең... Шулай булмаса, тәпи атлап китүемә һәм телем ачылуга күп тә үтмәстән: «Мин үскәч космонавт булам!»—дип шәрран ярып кычкырмас идем»,—дип сөйли Ләбиб әлеге интервьюсында. Әле алай гынамы, ул үзенең космонавт булырга теләвен шигырьгә салып, «Яшь ленинчы» гәзитенә да юллаган һәм, ни гаҗәп, шигырь басылып та чыккан икән. «... Бу «шигыремә» үз битендә урын биреп, «Яшь ленинчы» шул вакытта, үзе дә сизмәстән, төзәтеп булмаслык зур хата ясады: шаулап чәчәк аткан совет иле Лемон Леронов дигән мәшһүр космонавтын югалтты»,—дип сыкрана язучы әлеге дә баягы интервьюсында.

Билгеле инде, әлеге хәбәр дөнья җәмәгатьчелегенең игътибарын шундук үзенә җәлеп итте. Бигрәк тә татар галәмен нык дулкынландырды ул. «Әгәр бу дөньяда «Яшь ленинчы» дигән гәзит чыкмаса, татар әллә кайчан космонавтка тиенәсе булган икән ләбаса»,—дип уфтанды берәүләр. «Их, нишләп шул чакта ук гәзитнең шеф-редакторы Роберт Миңнуллин булмады икән? Ул бит булдыклы егет, ничек тә малайны космонавт итү әмәлен табар иде әле. Юкса Ләбиб Лерон дигәнебез тәмам Роберт Миңнуллинның персональ пародистына әйләнеп бетте ич инде»,—дип көрсенде икенчеләр.

Ләкин әле татарның башкачарак уйлый белә торган гаярь егетләре дә юк түгел иде. Һәм аларның иң көттәсе, әлбәттә инде, Шәледән, Камил Кәримовның авылдашы Мәгъсүм Гәрәев җәнапләре иде. Кытайларның «Жэнминь жибао» гәзитеннән Ләбибнең интервьюсын укыгач, аның иңнәренә канатлар үсеп чыккандай булды. Татарны дөньяга танытуда армый-талмый хезмәт куючы әһле каләм һәм София Гобәйдуллина, Робертино Лоретти, Мстислав Ростропович, Иосиф Кобзон, Галина Вишневская, Евгений Евтушенко кебек мәшһүрләрнең иң якын дусты буларак, Мәгъсүм Гәрәев мондый тарихи форсатны кулдан ычкындырырга ярамавын шундук аңлап алды. «Чыктым аркылы күпер» дигән китап белән генә әллә ни кыра алмас егет,—дип уйлады ул.—Әйдә, ичмасам, космоска очып карасын. Хет галәмдә татар дигән халыкның барлыгын белерләр».

Тимерне һәрчак кызуында сугып калырга гадәтләнгән Мәгъсүм агабыз бу юлы да махы бирмәде, тотты да Америкага, академик дусты Роальд Сәгъдиевкә чылтыратты. Ни хикмәт, Казаннардан килеп ирешкән гозер Зиннур абзый малаеның күңеленә бик тә хуш килде. Ул Ләбиб Леронның балачак хыялын тормышка ашырыр өчен һәрчак әзер булуын белдерде.

Академик, үз чиратында, Мәскәүгә, кайчандыр үзе җитәкләгән Космик тикшеренүләр институтына чылтыратты. Телефонда институт директоры

академик Альберт Галиев иде.

Коллегалар буларак, космик телдә хәл-әхвәл сорашып алгач, алар шундук үзебезчә сөйләшүгә күчтеләр. Тынлый-нитә калса, Мәскәү анламасын, дигәннәрдер инде...

—Карале, якташ,—диде Роальд Сәгъдиев, бик зур дәүләт серен ачарга җыенгандай.—Карале, без бит синең белән ничә еллар үзебез космонавт очыртып утырдык. Тик менә алар арасында ник бер татар булсын! Безгә бу тарихи хатаны төзәтергә кирәктер, якташ. Әле җитмәсә, Казаннын үзеннән да шундый гозер белән мөрәҗәгать иттеләр. Кем мөрәҗәгать итте, дисеңме? Кем булсын, Мәгъсүм Гәрәев үзе инде... Казаннын меңьеллыгына бирәр дастуйный бүләк әзерләргә кирәк иде, дип чылтырата...

Билгеле, мондый зур һәм җаваплы эшкә керешер алдыннан, беренче чиратта, Мәскәүнең рөхсәте таләп ителә иде. Ләкин, ни кызганыч, бу юлы да аның ризалыгын алып булмады. Татарга ышаныч юк, татарлыгын бар галәмгә таратып, латин имласын тыйган өчен марсианнардан сәяси сыену урыны сорап, Рәсәйне бар галактикага рисвай итәр, дип уйлаганнардыр инде, күрәсең...

## Татар бугазы

Сез ничектер, җәмәгать, ә мин Мәскәү авызыннан «Татар бугазында кораб баткан» дигән хәвефле хәбәрне ишеткән саен сискәнеп куям, үземне гаепле сизә башлыйм. Ә андый хәбәрләр безгә, гөнаһ шомлыгына күрә, диимме, көн саен ук булмаса да, еш килеп ирешә тора. Менә шунда үзеңнең дә тамак төбенә төер утыра, тынычлыгың югала, йокың кача, аппетитың бозыла. Хәтта, ирексездән, бу якты дөньяларга ник татар булып туганына тагын бер кат үкенеп куярга да туры килә.

Без бит инде болай да Рәсәйнең үсешен бик нык тоткарлаган халык. «Татар-монгол игосы» белән, диюем. Ә хәзер менә Татар бугазында әледән-әле кораблары әйләнеп каплана. Көннәрнең берендә анысын да безгә сылтамаслар, дип йә кайсыгыз кистереп әйтә ала?

Шуна күрә безгә Татар бугазы мәсьәләсендә һич кичекмәстән ашыгыч чаралар күрә башларга вакыт җиткәндер, җәмәгать. Кабат ул-бу килеп чыкканчы, аның исемен үзгәртүдән дә хәерлесе булмастыр, мөгаен. Моның өчен дөньяда яшәүче барлык татарлар исеменнән Дәүләт Думасына мөрәҗәгать юлларга кирәктер. Һәм бу хат-мөрәҗәгать туп-туры Жириновский әфәнде исеменә җибәрелсә, тагын да дөресрәк булыр кебек. Ни дисән дә, ул бит милли мәсьәләләр буенча Рәсәйдә иң зур белгеч санала. Шунлыктан Думадагылар да, Кремльдәгеләр дә аның сүзеннән чыкмас, дип уйлыйк.

Ә инде Татар бугазын кем бугазы белән алыштырырга соң, дигәндә, анысын да бик җинел генә хәл итеп була, минемчә. Әйтик, безнең ут-күршеләребез арасында татарның соңгы ыштанын салдырып кияргә әзер торучы кемсәләр аз түгел ич. Тотсыннар да кушсыннар шуларның берәрсенең исемен. Аларның да күнеле булыр, безнең дә тамак төбенә төер утырмас. Үзебезне гаепле итеп тә сизмәбез. Йокыбыз да качмас. Дөньябыз да түгәрәкләнер.

## Кадерле вә кыйммәтле

Урыс телендә «дорогой» дигән бик тә хикмәтле кәлимә бар. Аны безнеңчә «кадерле» дисәң дә, «кыйммәтле» дисәң дә хата булмаячак. Ул сүзне аеруча югары эшелондагылар нык ярата. Алар, әдәп иярәре буларак, бер-берсенә һәрвакыт «Дорогой Фәлән Төгәневич» дип кенә эндәшә. Фәлән Төгәневичнең кәнәфие биегәйгән саен «дорогой» дигәнебез кадерлерәк кенә түгел, кыйммәтлерәк тә була бара. Бер эшләүче кешегә биш нәчәлник туры килгән илдә—бигрәк тә. Бездә алар хәтта пенсионерлардан да ишлерәк

бугай. Шуна күрә коррупция-фәләнгә каршы берүк митинг кына ясый күрмәсеннәр инде. Ул кадәр халык урамга чыкса, пенсионерлар ише генә кыланмас. Әгәр алар ришвәт алудан, казна малын хосусыйлаштырудан да баш тартса, нишләмәк кирәк? Дәүләт машинасы шундук салулый башлаячак, бөтен эш туктап калачак, халык кабат митингларга чыгарга мәҗбүр булачак бит. Бу юлы инде ана ришвәтчелекне якларга туры килмәгәе. Чөнки бездә нәчәлникнең култамгасыннан башка, Равил Шәрәфи әйтмешли, җил дә исми, яфрак та селкенми. Шунлыктан култамга белән сәүдә итү ин төшемле кәсеп санала да. Дөньяда оҗмах ишекләрен ачтырырлык култамгалар да була, диләр. Әнә, халык та үз министрларын юкка гына оҗмахта яшәтмидер инде. Әле өстәвенә, бер мәскәүски министрны бер ел асрар өчен 600 мен у.е. түләргә дә туры килә ана. Гафу итегез, бу—мин уйлап чыгарган сумма түгел. Мәскәү гәзитләре үзләре шулай яза. Дөрес, Туфан Миннуллин әйтмешли, кеше кесәсендәге акчаны санау яхшы да түгел-түгелен, әмма кызык бит. Бигрәк тә салым түләүче халык кесәсендәге акчаны. Үзебезнекен, ягъни мәсьәлән. Нишлисен, акча ул шундыйрак нәрсә инде—Марсель Галиев әйтмешли, һәрвакыт санаганны ярата.

Алайга китсә, без үзебез дә төшеп калганнардан түгел анысы. Безгә дә ара-тирә «дорогие россияне» дип мөрәҗәгать иткәләп торалар. Димәк ки,без дә «кадерле» вә «кыйммәтле» булып чыгабыз. Ни өчен кадерле икәнлегебез яхшы анлашыла, билгеле: чөнки без кая—нәчәлник тә шунда. Без юк икән—нәчәлник тә юк.

Ә менә очын-очка ялгап яшәгән халыкны ни өчен «кыйммәтле» дип тә зурлыйлар—бусын инде бер чөллисез һич кенә дә анлап бетерешле түгел. Юкса, без бронежилет кигән, чиный-чиный һәрвакыт ашыга торган лимузиннарда да җилдермибез, артыбыздан өере белән тән сакчылары да ияреп йөрми, култамгабызнын да пенсия, стипендия, эш хакы алганда гына ара-тирә хаҗәте чыккалап куя. Ә үзебез ни өчендер «кыйммәтле россияннәр» саналабыз. Әллә сон хезмәт хакын да, стипендияләрне дә, пенсияне дә үз авызыннан берьюлы өзеп биргәне өчен хөкүмәт күзенә шулай кыйммәтле булып күренәбез микән без? Уптым исәпләп карагач, бик зур акча килеп чыга бит, җәмәгать. Олигархлар зарплатасы кадәр.

Әллә бер министрны тоту өчен ел саен 600 мен у.е. түләп тора алган халык, чыннан да, Абрамович шикелле бик бай һәм Фаберже йомыркасы кебек кыйммәтле микән? Мөгаен, шулайдыр. Югыйсә, сөекле илебез чиновниклар саны буенча дөньяда—беренче, миллиардерлар саны буенча өченче урында тормас иде. Хезмәт хакы буенча да без кояшлы Африканын банан республикаларыннан бик азга калышабыз икән ләбаса. Боерган булса, киләчәктә, бәлки, аларны да куып җитеп, узып китәрбез әле. Бананнарын сатып алмасак, билгеле. Ничава, монарчы банан ашап яшәмәдек әле. Моннан сон да яшәрбез, иншалла.

Ә менә югары эшелондагыларны бананнан һич кенә дә аерырга ярамас. Чөнки ул башны яхшы эшләтә, диләр. Ә башлы җитәкче—һәр дәүләтнен ин югары пробалы алтын хәзинәсе инде ул. Андый кыйммәтле байлыкны хәтта Швейцария банкында сакласан да, һич артык булмастыр...

## Ркаил—горур яңгырый

Депутат булмаса да, Ркаилне белмәгән кеше сирәктер. Үзе шагыйрь, үзе язучы, үзе драматург, үзе журналист дигәндәй. Исеме дә бер ишетүдә истә кала торган, Гиннес китабына кертелергә лаек бердәнбер исем. Мондый исем хәтта Актанышта да очрамый. Өч сүз белән әйткәндә, Ркаил—горур янгырый.

Ә соңгы вакытта ул кәттә сценарист буларак та нык танылып килә. Хәзер мәшһүр язучыларнын юбилей кичәләре Ркаил язып биргән сценарийлар

буенча гына үткәрелә. Ул тотындымы—кичәнен уңышлы чыгасына беркем дә шикләнергә җөрьәт итми. Хәтта Роберт Миңнуллин да. Чөнки тиздән аның үз юбилееи дә үткәрәсе бар.

Соңгы арада Ркаилебез Акмулла юбилеен үткәрү мәрәкәсе белән йөрде. Бусы хәтта аның өчен дә үтә четерекле эш булып чыкты. Ни дисәң дә, Акмулла берьюлы өч халыкның уртак шагыйре исәпләнә ич. Мондый чакта, билгеле инде, беркемне дә рәнжетмәскә тырышасың, һәркайсына ярарга, һәркайсының күңелен күрергә туры килә. Бигрәк тә ут күршеләр алдында сүзеңне үлчәп әйтү кирәк, юкса алар Акмулланың асаба башкорт икәнен ник әйтмәдегез дип халыкара буза куптарырга да күп сорамас. Чөнки, башкорт галимнәре уйлап чыгарганча, Кол Гали дә Әйле ыруы башкорты икән ләбаса. Ә без моңарчы шуны да белми йөргәнбез...

Хәер, заманында Ркаил үзе дә чүттән генә өч халыкның уртак шагыйре булмыйча калган диләр ич.

Әйтүләренә караганда, Ркаил, бишек яшеннән чыгуга ук, фәһемле мишәр ябрәе буларак, телләр өйрәнә башлый. Пионер чагында инде ул чуаш, башкорт, урыс телләрен үз ана теледәй яхшы белә. Тора-бара шул телләрдә шигырьләр дә язарга керешә. Аның хәтта «Татар каны ага тамырда» дигән атаклы шигыре дә иң элек чуашча иҗат ителгән дигән хәбәрләр йөри. Үз чиратында ул, әлбәттә, урыс, башкорт телләренә дә аударыла. Әмма никадәр генә шәп шигырь тоелмасын, ни Өфедә, ни Шупашкарда, ни Мәскәүдә аны бастырып чыгарырдай гәзит-журнал табылмый. Хәзер инде ни өчен бастырмаулары аңлашыла кебек: «татар» дигән сүз генә харап иткән егетебезне. Әгәр «татар» урынына «башкорт», «урыс», «чуаш» дип сырларга онытмаган булса, бүген Ркаилебез дә, Акмулла кебек, өч халыкның уртак шагыйре саналып йөртеләсе иде бит. Хәер, Чуашстанның Комсомол районындагы Чичкан авылында яшәп яткан беркатлы малай ул чагында шигырьнең мондый ук нечкәлекләрен каян белеп бетерсен инде?

Ә менә «Татар каны ага тамырда» дигән шигырен Ркаил сәхнәләрдән әле дә булса сөйләп йөри диләр, чөнки ул аның яттан белгән бердәнбер шигыре икән...

## Туганнар

Без—туганнар. Беребез—өлкән, беребез—кече. Бердәм гаилә булып, бер үк табактан сосабыз, бер үк тустаганнан чөмерәбез.

Өлкәннәр, билгеле инде, кечеләрне гел өйрәтеп торырга ярата. Әгәр кәҗәләнә башласаң, арт шәрифләреңне каеш белән өтәләргә дә, кыеп берәр кыек сүз әйтә калсаң, ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә күп сорамый. Нишләмәк кирәк, туры әйткән туганына ярамый шул.

Ә безнең туганлык бик ерактан—хан заманнарыннан ук килә. Дөрес, ул чакта әле без чыбык очы туганнар гына булганбыз. Баҗайлар кебегрәк, ягъни мәсәлән. Аннары ата—улны, ана кызны белмәс заманнар килгән дә без бөтенләй үк туганлашып беткәнбез. Тукай әйтмешли, хәтта бер җепкә бергә теркәлеп туу хәленә барып җиткәнбез. Шул туганлашудан Татаринов, Татаркин, Татарчук, Татаренко, Татарскийлар нәселе башланып киткән. Әлеге татарскийлар үрчи-үрчи бик нык ишәеп, тора-бара өлкән туганга әйләнгән. Ә без исә һаман да Галиләр, Вәлиләр булып кала биргәнбез. Әле өстәвенә Гали дигәнебез—Галялар, Вәли дигәнебез Валялар белән чуала торгач, дөньясын да чуалтып бетерә язган. Әнә, дөньяны яуларга хыялланган Наполеон әзи дә, көймәсе комга терәлгәч, өлкән туганны кырып карасаң, аннан кече туган килеп чыга, дияргә мәҗбүр булган. Мондый якын туганнарның беркайчан да җиңелмәячәген бик соңлап аңлаган шул, бахыр.

Ләкин соңгы вакытта, без бердәм гаилә булып яши торган тулай торакның түбәсеннән су үтә башлагач, өлкәнлек-кечелек мәсьәләсендә күңелгә икеле-микеле уйлар да килгәли бит әле, җәмәгать. Безнең якларда, мәсәлән, өлкән агалар, башлы-күзле булуга, тизрәк башка чыгып китү җаен карый. Бабадан калган гадәт-йоласы шундый чөнки. Ә монда без нигәдер үзебез,башка чыгып, үзбаш яшәргә чамалап торабыз. Әмма шул хакта кыеп берәр кыек сүз әйтүебез була, шундук башыбызга оралар.

Әллә соң без үзебез өлкән туган микән? Юкса, башка суктыра-суктыра булса да, башка чыгарга болай ук атлыгып тормас идек бит...

## Юралмаган төш

Соңгы арада сәер төшләр кереп бимазалый башлады бит әле, җәмәгать. Әле кайчан гына төшемдә йә очып йөргәнемне, йә булмаса, хур кызларын кочып ятканымны гына күрә идем. Ә хәзер... Картаям бугай, күрәсең. Дөнья уе баш миенең һәрбер күзәнәгенә шлак булып утыра бара бугай. Хәерлегә булсын...

Әле бер көнне төштә Президент белән балык сөзеп йөрдек. Майка белән. Әлбәттә, мин моны үземчә яхшыга юрадым: димәк, Президентыбыз да, нәкъ минем шикелле, малай чагын сагынып яши икән, дидем.

Ә менә күптән түгел Ельцин белән бергә безнең авылда мунча кердек. Минемчә, бусы да начар фал түгел: димәк, Е.Б.Н. ил-халык алдында кылган гөнаһларын юарга тели...

Ләкин сез, бу адәмнең төшенә гел президентлар гына керә икән, дип уйлый күрмәгез тагы. Һич алай түгел. Мәсәлән, кичә күргән әкәмәт төшне сөйләсәм, күпләрегез ышанмассыз да әле. Дөресен әйткәндә, мин аңа үзем дә бигүк ышанып җитмим һәм ни-нәрсәгә юрарга да белми торам. Белмәссең дә шул, үз гомереңдә бер кәлимә сүз язып карамаган башың белән язучылар җыелышында утыр әле син. Җитмәсә, һәркайсы миңа таба борылып карап ала да, күршесе белән пышын-пышын сөйләшергә тотына. Бу кайсы саланың йолкыш даһие икән, дип уйлыйлардыр инде. Мин дә сиздермичә генә тирә-ягымны күзәтәм, әлбәттә, бер дивизия язучы арасыннан таныш чырайларны эзлим. Аларны бит телевизордан еш күрсәтеп торалар. Бигрәк тә депутат язучыларны. Депутат булмаганнары арасында да мин таныганнары юк түгел. Мәсәлән, Мөдәррис Әгъләм. Без аның белән бер мунчага йөрибез. Ара-тирә ләүкәдә очрашкалап та куябыз.

Мин баштарак, бу кадәр халыкны нигә җыясы иттеләр икән, дип тә уйлаган идем. Юкса язучыларның үзара бүлешер нәрсәләре дә юк бугай ич инде. Ләкин Марсель Галиев дигән язучы югары мөнбәргә менеп сүз каткач, барысы да аңлашылды.

—Ни өчен Төркиядә гел бер генә язучының китабы чыга дип уйлыйсыз?— диде ул, гасаби елмаюы артына сыенып.—Чөнки төрекләр татар әдәбиятын фәкать безнең Язучылар берлеге рәисе язганнар буенча гына күзаллыйлар һәм, боларның башлыклары да шулай язгач, калганнары бөтенләй җөмлә төзи белми торгандыр, дип уйлыйлардыр. Шуңа күрә безгә, бәлки, имиджны үзгәртергә, ягъни председательне алыштырырга кирәктер? Аннары, 10 ел буе мыжык язучылар көен көйләп йөреп, Ринат та арыгандыр инде. Ял итсен бераз. Менә минем кебек гади язучы булып та яшәп карасын...

Икенче булып мөнбәргә күтәрелгән Роберт Миңнуллинга, депутат һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, М.Галиев кебек әтәчләнү килешми иде, әлбәттә. Шуңа күрә ул Марсельгә дә комплимент әйтеп куюны кирәк тапты:

—Безнең Марсель кешедән көләргә ярата инде ул... Ә мин үзем Ринат Сафиевич турында алай дип әйтмәс идем. Дөрес, кайчандыр мин үзем дә «Татарстан яшьләре» гәзитендә болар хакында язып чыккан идем. Ул

чагында Ринат Сафиевич мина үпкәләп тә йөрде әле, җавап мәкаләсе дә язып бастырды. Ләкин без, соңыннан барыбер дуслар, фикердәшләр булып калдык. Хәзер дә бер комиссиядә эшлибез. Мине Тукай премияле итүдә дә Ринат Сафиевичның ярдәме зур булды. Рәхмәт аңа!

Ниһаять, мөнбәр артыннан минем иске танышымның да башы күренде.

—Тукай премиясенең монда ни катнашы бар?!—диде Мөдәррис, мунча ташыдай кызган тавыш белән.—Алайга китсә, ул премияне миңа да Мөхәммәди заманында бирделәр. Премияне алмыйлар, агай-эне, премияне бирәләр!.. Ни генә әйтсәгез дә, Мөхәммәдиегез булдыклы егет ул сезнең. Иманым камил: монда утырган күбегез адәм рәтле итеп кадак та кага белми торгандыр әле. Ә менә рәисегез, бармагына чүкеч белән бер мәртәбә дә сукмыйча, коттедж кадәр йорт җиткереп чыкты. Беләсегез килсә, мондый булдыклы егетләр өстәрәк, җаваплырак урыннарда эшләргә тиеш!

Зал Мөдәррисне озакка сузылган алкышларга күмеп озатып калды.

Шулвакыт җыелышны алып баручы Ренат Харис сәгатенә күз төшерде. Күрәсең, фикер алышуга билгеләнгән вакыт бетеп килә иде. «Димәк, сүзне «авыр артиллерия»гә бирергә вакыт җитте»,—дип уйлагандыр ул.

Менә мөнбәргә шәрәфле академик Гариф Ахунов күтәрелде.

—Мин Мөдәрриснең дә, Роберт Мөгаллимовичның да фикерләренә кушылам,—диде аксакал.—Ә менә Марсель Галиев белән килешеп бетмим. Марсель үзе бик талантлы язучы ул. Заманында без аның белән союзда да бергә эшләдек. Мин әле аның «Ерак урман авазы» дигән повесте турында гәзиттә мактап та чыккан идем. Шәйдә апагыз да бик ярата Марсельне. Ләкин Язучылар берлеге дә рәиссез яши алмый. Мин үзем дә ун ел буе председатель булып торган кеше. Шуңа күрә ул эшнең нинди авыр икәнен бик яхшы беләм. Андый авырлыкны Ринатыбыз кебек таза, озын гәүдәле егетләрнең генә иңнәре чыдата ала.

Шулчак зал тагын гөжләп куйды. Баксаң, әзмәвер гәүдәле Зиннур Хөснияр тирәсендә утыручылар кыбырсып алган икән.

Шул арада залдагы халык арасыннан: «ПЕН-үзәк президентына кайчан сүз бирергә уйлыйсыз?»—дигән дәһшәтле аваз ишетелде. Туфан Миңнуллин икән. Һәм ул сүз биргәннәрен дә көтмичә мөнбәргә юнәлде, чыгышын да, гадәтенчә, үгезнең мөгезеннән алып башлады.

—Нишләп без монда көне буе Ринат Мөхәммәдиев турында ләчтит сатып утырабыз соң әле?—диде ул.—Безгә союзның яңа рәисен сайларга кирәк ләбаса. Әллә өч йөз язучыгыз арасыннан бер кандидатура таба алмыйсызмы?

Зал тагын шаулаша башлады.

—Безгә Мөхәммәдиевтән башка беркем дә кирәкми,—диде бер зәгыйфь хатын-кыз тавышы. Аны хуплаучылар дәррәү кул чабарга тотынды.

Ситуациянең хәтәр борылыш алуын сизә башлаган Т.Миңнуллин:

—Ә сезнең арада язу таный белүчеләр бармы соң?—дип, сүзне шаяруга борасы итте.

Бу шаяру монарчы тын гына утырган Р.Мөхәммәдиевне дә чыгырыннан чыгара язды.

—Без, Туфан Абдуллович, союзга укый белүчеләрне түгел, яза белүчеләрне алабыз шул,—диде ул төксе генә.

—Сизелә...—диде Т.Миңнуллин, президиум гына ишетерлек итеп.—Юкса җыелыш алдыннан хет берәрегез булса да Язучылар берлегенең уставын укып карар идегез. Ә анда акка кара белән язып куелган: бер үк кеше рәис булып ике генә тапкыр сайлана ала, диелгән.

Ул көнне өч йөз язучы берлек рәисен сайлый алмыйча таралышты. Шулай да, сатулаша торгач, яңа рәис итеп Тукай бүләге дә, фатиры да, машинасы да, дача-бакчасы да булган һәм депутат итеп тә сайланмаган

кешене сайларга кирәк, дип килештеләр.

Ә Язучылар берлеге әгъзалары арасында бу таләпләрнең барысына да җавап бирердәй бер генә кандидат булуы ачыкланды. Ул, әлбәттә, Гөргөри җәнапләре иде...

### Бәби ни дә, бэби ни?

Элеккерәк елларда, бездә секс юк, дип сөйләнсәләр дә, халык бу сүзгә бигүк ышанып җитмәде. Вәләкин «секс» дигәннәренең череп, таркалып баручы Көнбатыштан кергән импортный кәлимә икәнлегенә тамчы да шикләнмәде. Ул чакта әле секс-шоуларны да телевизордан ук күрсәтмиләр иде шул. Татар теленең халыкара абруе да хәзергечә югары түгел иде. Әйтик, мәсәлән, коммунистлар заманында, секс—татар сүзе, дисәләр, мона Батулладан башка тагын кем генә ышаныр иде икән? Ә хәзер—ышаналар. Татар теле дөньядагы иң кәттә ундүрт тел арасына юкка гына кертелмәгән ләбаса.

Секс ул, бик беләсегез килсә, гап-гади сигез (8) саныннан яралып, тора-бара бар кыйтгаларны туганлаштырган кодрәтле сүзгә әйләнгән. Ә «8» үзе, ике божрадан хасил булып, берсе—ир-ат, икенчесе хатын-кыз женесен белдерә. Шуңа күрә ЗАГСларга да, туй машиналарына да ике божра беркетеп куялар. Никахлашучыларның бер-берсенә балдак кидерешүе дә шул «8»ле галәмәте. Ике божра бергә кушылдымы—аннан секс-шоуга, ягъни шау-шулы кети-метиләргә дә ерак калмый инде. Нәтиҗәдә дөньяга бер-бер артлы бәбиләр аваз сала башлый. Дөрес, үзләрен бик культуралы санаган халыклар аны, бераз кыландырыбрак, бэби, дип әйтергә ярата. Әйдә, кыландыра бирсеннәр—бәби ни дә, бэби ни—барыбер түгелмени?!

Ләкин шунысы гаҗәп, татар теле яралганчы, ул культуралы халыклар сексcыз да, шоусыз да, бэбисез дә ничек яшәде икән соң? Әле бит, өстәвенә, аларның «мама»сы да татар бәбиләре ими сораганда әйтә торган «мәми»дән килеп чыккан, дигән хәбәрләр йөри.

Юк, җәмәгать, безнең телебезнең авыл капкасыннан чыккач та кирәге бар әле. Ул тел безне Римгә дә, Парижга да, Истанбулга да, Лондонга да, Шанхайга да илтеп куячак. «Секс» дигән иң мәшһүр, иң аңлаешлы сүзне бөтен дөньяга тараткан халыкның теле ич ул сина!..

❋

# КҮҢЕЛЕНӘ ДӨНЬЯ СЫЙГАН

Күченеп йөрү, төрле җирләрдә яшәү анын язмышында язылган булгандыр күрәсең. 1950 елның 1 гыйнварында Башкортстанның Благовар районы Кучәрбай авылында туган Нурия Измайлованың үсмер еллары да Татарстанның һәм Башкортстанның берничә авылында үтә. Ә аннан Уфа-Казан юллары—белем эстәү, Фирганә өлкәсе, Мәскәү каласы, океан аръягы тормышы... Иҗат кешесе кайда гына яшәсә дә дөньяны үзенчә күрә, « Американы үзенчә ача», яшәгән җиренә бәһане дә үзенчә бирә. Үз илендә, үз телендә, үзенчә яшәп, үзенчә иҗат иткән нечкә күңелле җан иясе чит җирдә Үзе булып калалырмы? Үз итәрләрме аны биредә?



*... Үзен югалткан кешегә*
*Сагыну да—сөенеч.*

Сагынудан—сөенеч, газапланудан рәхәтлек табуга да рухы бай, үзәге нык булганнар гына ирешә алуны күрәбез без анын шигырьләрендә.

Хатын-кыз иҗатчыларыбызның көй-моннарын тыңлаганнан, шигырь-хикәяләрен укыганнан соң, кайчакта күңелне шатлыклы бер хис били: әле ярый Ходай Тәгалә хатын-кызларны ир-атларга караганда хисләрәк, моңлырак, самимирәк, нәфисрәк итеп яраткан. Бары тик хатын-кыз күңеле генә тоя, ул гына күрә-ишетә алган төсмерләре бихисап бит галәмнең. Әлеге төсмерләр тирән акыл, фикер киңлеге аша уздырылып күңел түрендә урын ала алырлык әсәрләргә әвереләләр... Сүз-көй беләнме, буяу-төсләр ашамы... Ә остасы—хатын-кыз. Рәссам, җырчы, шагыйрә... Мәхәббәттә мең кат адашса да ул янә дә адашудан курыкмый, мәхәббәтне каһәрләми, бәгыре катыланмый...

*Китмәм, ахры, шушы язмышымнан*
*Мин бит бәхетем белән адашкан!*
*Моңлы урманымны—буш ялангa,*
*Буранымны җилгә алмашмам.*

Гомеренең инде уртасына җитеп килгәндә Америкага китеп баруы да, анын әнә шул бәхете белән адашасы килүдән булгандыр, бәлки. Югыйсә шагыйрә тиккә генәме чит-ят кыйтгаларда иҗат ителгән шигырьләре белән тулыландырылып чыгарылган яңа китабын «Адашкан» дип атар идеме?

Н. Измайлованың иҗатында күпчелек шагыйрәләргә хас булган иң төп темаларның берсе—Ана һәм Бала мөнәсәбәтләрен сурәтләгән шигырьләрендә яшь буынның киләчәге—милләт язмышы да икәне яктыртыла. Әлеге китапка язган кереш

сүзендә тәнкыйтьче, шагыйрь Равил Рахмани «Солтанга мирас» шигырен күздә тотып: «Автор бирелә илебез, милләтебез, үзе белән чордаш булган тулы бер буын вәкилләре яшәешенә социаль диагноз куя. Милләтнең киләчәктә Дөнья базарына алып чыгасы төп байлыгы турында фикер йөртә. Ярым житди, ярым шаяртып, әмма эчтән әрнеп-сызлап, Милләт вәкиле буларак, Ана һәм Бала буларак, Шагыйрә буларак ерак Американы—димәк, үзебезне, яшь буынга алга карап бару өчен кирәк булган тормыш хакыйкатен ача. Хыялланырга, уйланырга, гыйбрәт алырга яраткан татар кешесе игътибарына шактый зур мәгънә салынган бу шигырьдә»,—дип язган. Бер шигырьгә генә дә нинди олы бәһа! Андый бәһагә лаек шигырьләр шагыйрә иҗатында шактый.

Әйе, кулында корал-каләме, күнелендә милләте өчен шатлану-борчылу булган һәркем бурычлы бу турыда уйланырга.

*Кош сыя кош оясына,*
*Ә күңелгә—дөнья сыя:*
*Сыйган анда халыкларым;*
*Халыкларның шатлыклары,*
*Кайгылары сыйган тагы.*
*Төшемдә дә өмет күрәм,*
*Шомнар күрәм, уйлар күрәм.*
*Өнем тулган уйлар белән,*
*Күңел тулган уйлар белән...*

Мәктәптә укыганда ук «Кызыл таң» газетасында, «Яшь көстәр» (Уфа), «Кызлар жыры» (Казан) күмәк җыентыкларда дөнья күргән шигырьләре көннән-көн арта барып, шагыйрәнең иҗаты тагын да ачыла төшеп «Яратам» (1981), «Алтын тарак» (1984), «Минем җәй» (1988), «Җирдә» (1993), «Алашкан» (2000), рус телендә «Ива на ветру» (1986), балалар өчен «Ак малай минем энем» (1995) китаплары чыга. Бай күнелле, тирән кичерешле шагыйрәнең әйтер сүзләре, күргән-кичергәннәре шигырь юлларына гына сыеп бетәрме? 1989 елда «Иң серле әкиятем» исемле хикәяләр җыентыгы, 2001 елда исә мөһаҗирлектәге тормышын, бүгенге Американы сурәтләгән «Язылмаган хатлар» исемле китабы дөнья күрә.

Әлеге китапта без Американы сәяси яктан чыгып түгел, аның галәти көнкүрешен яктырткан, гореф-гадәтләрен, яшәеш-табигатен сурәтләгән язмалары белән танышабыз. Автор әлеге илне күпмедер дәрәҗәдә күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

«Чын күнелен тышка чыгарып, кычкырып, нәфрәтләнеп сөйләшүчене күрсәләр, ул тирәдән корт чаккандай качалар, һәм «Эмоушенел» (эмоциональ) дигән сыйфатлама бер дә мактау сүзе түгел. Шулай итеп, ихласлык, эмоциональлек, ачыклык каралар өлеше булып, акларга, аристократларга икейөзлелек кала».

Билгеле, мондый шартларда язучыга үзенең хисләрен, сагыну-сагышларын ак кәгазьгә төшерергә туры килә.

«Сәер генә рәвешләрдә чагыла ул илне сагыну. Мин, мәсәлән, арыш ипие пешерәм. Көрпәле арыш оныннан. Үзебезнекеләрдән кем дә булса килеп керсә, гел иң зур сый итеп, кап-кара шул ипи куела. Еракка киткән саен якыная бара дигән сүз шулдыр инде». Туган яклардан еракта, чит-ят кавемнәр арасында халкыбызның милли рухына тугры калып, аның нечкә күнелле шагыйрәсе булып яши ул.

«... Тик гомер йомгагы гына туктауны белмәс, чит ил дип тормас, тәгәрәр дә тәгәрәр...»

Гомер йомгагының тәгәрәр юлы озын булсын иде!

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

## Әсгать Салахка 75 яшь



Язучы Әсгать Салахның балачак һәм үсмер еллары сугыш чоры баласы буларак, шактый авыр шартларда уза. Шуна күрә дә язмаларында да тормышның кырыслыгы, язмышның аяусызлыгы чагыла.

Ул 1935 елның 5 гыйнварында Татарстанның Әлмәт районы Елховой авылында крестьян гаиләсендә туа. Ватан сугышының мәрхәмәтсез җиле алар гаиләсенә дә үтеп керә, әтисе сугышта хәбәрсез югала, әнисе ялгыз башы дүрт баланы тәрбияләп үстерә. Әсгать кечкенәдән үк белемнең дә, һөнәрнең дә ир-атка бер дәрәҗәдә кирәклеген аңлый, урта мәктәпне тәмамлагач та туган авылында хисапчы булып эшли башлый, бераздан илдә нефть чыгару башлангач Әлмәттә бораулаучылар мәктәбен тәмамлап, шул хезмәтне дә үзләштерә. Армия хезмәтеннән соң ул югары белем алырга ниятләп, 1960 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә читтән торып укырга керә, 1965 елда исә матбугат эшенә күчә. Әлмәттә чыга торган «Знамя труда» газетасы редакциясендә башта бүлек мөдире, соңрак мөхәррир урынбасары вазифаларын башкара. Матбугат эшенә ул күп көч куя. Илдәге үзгәртеп корулар, милли басмаларга ихтыяҗ арту, милли үзаң уянуга да сәбәпче була—1990 елда Әлмәт төбәгендә милли рухлы мөстәкыйль татар газетасы «Әлмәт таңнары»н (элек ул дубляж рәвешендә чыгарылган) оештыра, 1999 елга кадәр аның мөхәррире була. Матбугат өлкәсендә озак еллар хезмәт итү аның язучылык эшенең дә нигезе булып тора. 1994 елда «Мирас» китап нәшриятында Ә. Салахның публицистик язмаларын, хикәяләрен туплаган «Аккан сулар» исемле беренче китабы дөнья күрә. 1999 елда «Балыкчы малайлар», «Бараж токымы» (2003)—тарихи-публицистик очерклар, «Каеннар юлы» (2006)—повестьлар җыентыгы чыга, 2001 елда Татарстан Язучылар берлегенә алына.

Ул—Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.

## Диләрә Зөбәерованың тууына 80 ел

Аның белән бергә эшләгән хезмәттәшләре, замандашлары язучы һәм журналист Диләрә Зөбәерова турында сүз чыкканда: «Язмасының азагына исем-фамилиясен куймаса да, темаларның дөрес сайланышыннан, йөгерек-матур тел белән язылышыннан ук аныкы икәнен белеп була иде»,—диләр. 1930 елның 9 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Кутәмәле авылында туып-үскән, Алабуга укытучылар әзерләү училищесын, Казан педагогия институтын кызыл дипломга тәмамлаган кыз журналистикага 60 елларда килеп керә. Күпчелек каләм тибрәтүчеләргә хас булганча, аның әдәби эшчәнлеге шигырьләр язудан башлана, алар төрле газеталарда дөнья күрәләр.

Берара Д. Зөбәерова Казаннан китеп, республиканың төрле районнарында мәктәптә укытучы, мәгариф инспекторы булып эшли. 1960-62 елларда «Ватаным Татарстан» газетасының Зәй районындагы махсус хәбәрчесе була.

1962 елда Д. Зөбәерова янәдән Казанга әйләнеп кайта. 1985 елга кадәр—лаеклы ялга киткәнче «Азат хатын» («Сөембикә») журналында бүлек мөдире вазифасын башкара. Гел юлда, кешеләр белән якыннан аралашу, язмаларының тормышчан булуы, тынгысыз каләм иясенә журналист буларак танылу алып киләләр. Тормышның авыр да, катлаулы да, сөенечле дә, гыйбрәтле дә яклары ана тагын да зуррак күләмле әсәрләр—әдәби әсәрләр язарга этәргеч бирә. 1969 елда «Казан утлары» журналының алтынчы санында «Дустым авазы» исемле беренче повесте басылып чыга. Ул әсәрләр әдәби тәнкыйтьчеләр һәм укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Тагын бер елдан «Куш өянке шаһит», «Кыр чәчәге» повестьлары дөнья күрә. Бернича дистә хикәясен, нәсер, повестьларын туплаган «Кичер, сөеклем» (1971), «Кызлар, кызлар» (1977), «Яшьләр күңеле» (1980) китаплары, «Халкым хаклы» (1990) публицистик язмалар җыентыгы чыга.

Ул 1971 елда СССР Язучылар берлегенә алына. 1980 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була.

2000 елның 15 декабрендә Казанда вафат булды.

Илдус
Хуҗин

# ЯҢА РОБИНЗОННАР

ХИКӘЯТ

## Яңа дуслар

Педагогия көллиятенең 411 төркемендә беренче карауда гадәти бер вакыйга булды: кышкы каникуллар үтеп, укулар башлангач, яңа егет барлыгы беленде. «Фәрит»!—диде ул һәм арткы рәттәге буш урынга барып утырды.

Дәрес башланды, әмма барысының да күзе артка төбәлгән иде. Уртачадан озынрак буйлы, атлет гәүдәле, коңгырт кара чәчле иде ул. Берничә көн үтүгә, кызлар инде барысы да аңа гашыйк иделәр. Бу хәл егетләргә ошамады, ләкин Фәрит аларны тиз тынычландырды: ул бер кызга да ныклап әһәмият бирми иде.

Озакламый Фәрит тирәсендә аның иң якын дуслары булып киткән егетләрдән торган түгәрәк оешты: ул үзе, Идрис һәм Расих. Соңгы икесе моны сизмәсәләр дә, Фәрит аларны үзе сайлап алган иде.

Менә инде уку елы тәмамланды. Фәрит барлык фәннәрдән дә яхшы билгеләр генә алды, ә үзе укытучының нинди билге куюына әһәмият бирми иде дә кебек.

Идрис белән Расихны аның күп нәрсә белүе үзенә тартты. Нинди генә темага аңгәмә бармасын, ул үзен судагы балык кебек хис итә иде. Җитмәсә, үзе оста көрәшче дә икән. Ә инде иң зур сәләте—кешене үз артыннан ияртә белү.

Июньнең соңгы көннәренең берсе иде. Өч дус Фәритнең бүлмәсендә утыралар. Нәрсә генә юк монда: зур глобус дисеңме, диңгез секстанты, иске астролябия, корабль компасы, тагын әллә нинди приборлар. Ә китаплары ниндиләр: төрле таблицалар, карталар, океаннар атласы, төрле телләрдәге сүзлекләр һәм башка шундый бүлмә хуҗасына карата ихтирам уятырлык әйберләр.

Идрис бер яктарак гаилә альбомын карарга тотынды. Менә ул альбом битләре арасына салып куелган төсле фоторәсемне кулына алды. «Матур кыз»,—дип уйлап куйды ул һәм фотоның арткы ягын әйләндереп карады. «Дустым Фәриткә Алсудан. 2003 ел»,—дип язылган иде анда. Идрис Фәритнең үзенә таба борылганын күреп, гаепле кеше сыман, рәсемне тиз генә альбом эченә тыкмакчы булды, ләкин ялгыш төшереп җибәрде.

Фәрит килеп идәндәге фотоны алды да бераз кыенрак хәлдә калган Идриска карап:

—Бу Алсу,—диде.—Без аның белән элек бер шәһәрдә яши идек. Бер мәктәптә дә укыдык. Дискотекаларга да йөреп алырга өлгердек. Мин белгән бер кыз да аның белән тиңләшә алмый иде.

—О-о-о!—дип куйды Расих.—Ничә мәртәбә үбештегез?

—Дөресен әйткәндә,анысына җитешә алмадык. Без бит гашыйклар исәбендә йөрмәдек,дуслар гына идек. Бу турыда безнең барлык иптәшләр дә белә иде. Ә шулай да Алсу белән аерылу—минем өчен иң зур югалту булды.

—Язышасызмы соң?—дип сорады Идрис.

—Юк...—диде Фәрит бик сагышлы тавыш белән.

—Ничек инде юк?

—Ни булды?

—Алсу югалды.

—Кайда югалды? Ничек?

—Тыңлагыз,алай булгач. Былтыр җәй көне Алсу иптәшләре белән теплоходта круизга китте. Бу сәяхәттә алар Азия илләреннән Малайзия, Сингапур,Вьетнам портларына керергә тиешләр иде. Сингапурда теплоход дүрт көн торган. Өченче көнне Алсу юлдаш кызлары белән шәһәргә чыккан булган. Ләкин ул әйләнеп кайтмаган: кайдадыр югалып калган. Әлбәттә, аны эзләп караганнар. Ләкин шундый гигант калада кеше тиз генә табыламы соң? Җитмәсә, капитан көтә алмавын әйтеп, тиешле вакытында кузгалып киткән. Соңыннан Алсуны илчелек аша да,төрле оешмалар аркылы да эзләтеп карадылар,ләкин файдасы тимәде.

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Нәрсә әйтергә ярый мондый вакытта? Дәшми утыруың ин яхшысы түгелме соң?

—Егетләр!—диде бераздан Фәрит.—Мин Алсуны эзләмәкче булам...

— Ничек?! Кайчан? Барып чыгармы соң бу эш? Син акылыңдамы соң?...—дип, чиктән тыш гаҗәпкә калган дуслары Фәритне төрле сораулар белән күмделәр.

—Ә сез,дуслар!?—дип сорады ул алардан.—Миңа юлдаш һәм ярдәмче була алыр идегезме?

— Син шаяртасыңдыр!—диде Идрис.—Анда барыр өчен ничә мең чакрым юл үтәргә,ничә ил аша чыгарга кирәк! Үзең беләсең бит,тиз генә чит илгә чыгып китү безнең халык өчен гадәти нәрсә түгел. Аның юл хакы гына да күпме тора. Гади кеше ел буена да эшләп ала алмый бездә андый акчаны.

—Дуслар! Алсуның әтисе бу проектны матди яктан тәэмин итәргә булды,—диде Фәрит.—Без анда туристлар төркемендә барачакбыз. Бу бит ул кадәр үк хәтәр сәяхәт түгел. Меңнәрчә россиялеләр ел саен бөтен дөнья буйлап сәфәр чыгалар.

Бүлмәдә тынлык урнашты. Килачәк сәяхәт турында сүз куертып утыру—бер хәл,ә инде үзең шул юлга чыгып китү—бөтенләй башка нәрсә.

## Алсуны эзләп

Лайнер кузгалып китү белән үк егетләр иллюминаторларга капландылар. Беренче мәртәбә һавага күтәрелү бәхетенә ирешкән дусларның күзләре яна, ә йөрәкләре читлегеннән чыгардай булып тибә. Булачак сәяхәт аларны дулкынландыра да,куркыта да иде.

Юл әлләни кызык булмады: лайнер болытлардан югары очканга,аста салкын кышны хәтерләткән күренешләр генә кала баралар иде. Ә менә Азиянең таулы урыннарына җиткәч, хәл үзгәрде: Алтай, Тянь-Шань һәм Тибетның пычак йөзе кебек үткен кырлары болытларны кисеп чыгып,күз күреме җиргә тезелгәннәр иде. Алардан соң инде чалт аяз һава һәм диңгез күренешләре дә ачылды.

Ә лайнер эчендә яшь кенә стюардесса ханымның ягымлы тавышы агыла иде:

—Сингапур—шул исемдәге утраудагы республика. Бездән сул якта күренгән Малакка ярымутравына,ягъни «Зур җиргә» ясалма дамба аша йөрилəр. Монда яшәгән ике миллион ярымнан артык халыкның сиксән процентын кытайлар тәшкил итә. Калганнары—берничә дистә милләт кешеләре. Шуларның якынча

ярты миллионы—малайялылар. Дәүләт теле—шулай ук малайя теле. Ә төп административ тел булып инглиз теле хезмәт итә. Сингапур—халыкара туризм үзәге, сез моны чит ил кешеләренең күплегеннән аңларсыз...

Сингапурда сәяхәтчеләребез бик уңайлы отельгә урнаштылар. Алар Алсуны ничек итеп эзләү турында баш вата башладылар.

—Фәрит!—диде Расих.—Башта син безгә аның ничек югалуы турында бөтен белгәнеңне ачып сал. Шуннан соң уйлашырбыз.

—Егетләр! Мин сезгә теге вакытта бар белгәннәремне сөйләдем инде.

—Аның үзе белән акчасы булганмы соң?—дип сорады Идрис.

—Ансы да билгесез.

—Хәер,—дип дәвам итте Идрис,—акчасын алу өчен кешене юк итү хаҗәт түгел; Алсуның югалу сәбәбе башкада кебек...

—Мәсәлән!...

—Мәсәлән, заложник итәр өчен.

— Алсуның туганнарыннан акча кысу өчен, әйеме?—дип сорады Фәрит.—Ләкин әле берсе дә мондый таләп белдергәне юк. Синең версияң, Расих?

—Минемчә, аны коллыкка сатар өчен урлаганнар. Яки...

—Яки нәрсә?

—Алсуның чибәрлеген исәпкә алсаң...

—Әйтеп бетер, сузма!..

— Тел әйләнми!—диде Расих.—Син мине гафу ит, Фәрит! Аны фәхишә итеп тотар өчен урлаганнардыр.

Авыр тынлыкны берсе дә бозарга батырчылык итмәде.

Икенче көнне иртә белән туристлар төркеме тиешле мәшәкатьләренә керешә, ә өч дус Алсуны эзләү чарасына тотындылар. Башта биредәге полиция бүлегенә мөрәҗәгать иттеләр. Анда исә, озак кына аларның документларын тикшергәннән соң, Алсу турында бер яңалык та юк, дип белдерделәр.

—Ничек уйлыйсыз?—дип сорады бүлек башлыгыннан инглизчә яхшы гына сукалаган Фәрит.—Без аны эзләүне нәрсәдән башларга тиешбез?

—Сезме? Бернәрсәдән дә! Бу сезнең эш түгел. Ул гына да түгел, сезгә туристлар төркеменнән башка йөрү катгый рәвештә тыела. Сезне хәзер үзегезнекеләр янына илтеп куячаклар, ә төркем башлыгы сезнең өчен җаваплы булуы турында искәртеләчәк.

Егетләргә төркемнән аерылып йөрү кыенлашты, шуңа күрә Алсу турында башкаларга да сөйләп бирергә туры килде.

Полиция ярдәменнән башка кызны эзләве, дөресен әйткәндә, мөмкин дә түгел иде. Егетләр өч көн буе порт тирәсендә, якындагы базарда, урамнарда көн үткәрделәр, инглизчә белгәннәрдән сораштылар, ләкин бу файдасыз булды. Кич белән арып-талып, Алсуны табудан өметләрен өзеп кайтып егылалар иде.

Берничә көн үтте. Өч дус максатларына ирешүдә бер адым да алга китә алмадылар. Менә алар шәһәрнең үзәгенә якынрак урамны да «өйрәнергә» булдылар. Шулвакыт Идрис Фәритнең күлмәгеннән тартты:

—Тыңла әле, Фәрит!

—Кайда, нәрсәне?—Т-с-с-с!

Кайсыдыр йортның ишегеннәнме, әллә тәрәзәсеннәнме музыка тавышы ишетелә иде, ләкин гади музыка түгел, чып-чын татар көе иде бу. Аларның аяклары ихтыярсыз шул якка атладылар. Шушы урамдагы коттеджлардан әлләни аерылып тормаган, тышкы күренеше буенча урта хәлле кешеләр торган йорт иде бу.

Дуслар өйнең тәбәнәк баскычы янына килеп туктагач ук өй эчендә музыка тынды һәм ишектән җитмеш-җитмеш биш яшьләр тирәсендәге бер карт чыкты. Ялтыратып кырылган башына кара түбәтәй кигән, чал сакал-мыегы пөхтә итеп кыскартылган ягымлы йөзле бу бабай өс киеме, килеш-килбәте белән шәһәр кешеләреннән аерылмый иде.

Карт, чыгып, егетләргә бераз карап торды да, кытайчамы, әллә малайя телендәме—сорау бирде. Егетләр башларын селкегәч, инглиз теленә күчте:

—Хәерле көн, әфәнделәр! Өйгә рәхим итегез! Бусаганы үткәч, Идрис мөселманча сәлам бирде:—Әссәламегаләйкем!

Бабай аптыравыннан бер мәлгә сүзсез калды. Башындагы түбәтәе нилектәндер идәнгә шуып төште. Шуны алып кигәч кенә ул кунакларга җавабын бирде:

—Вәгаләйкемәссәлам!

Шунда ук урындыкка утырып дога кылды. Өч дус та иреннәрен кыймылдатып бит сыйпадылар.

Бабай татар кешесе булып чыкты, татарчага күчте. Аның исеме Таһир, Сингапурда кырык ике ел тора икән.

—Мин монда Кытайдан күчеп килдем,—дип сөйләп китте ул,—кытайлылар белән бергә. Ә туган җиремнән,Ырынбур ягыннан,мине бала чагымда ук алып киткәннәр. Бу хәл егерме тугызынчы елда булган. Минем әтием татар зыялысы, әнием дә заманының алдынгы карашлы кешесе баласы булган. Халык дошманы, дип яла яга башлагач, эзәрлекләүләрдән качып, чит илгә китә алганнар. Бер дә онытырлык түгел, гомер буе туган туфракка кайту, шунда җирләнү турында хыялландылар.

Без өч бала булганбыз, ләкин мин генә исән калганмын. Туган илемне хәтерләмим,Кытайда үстем. Шунда мөселман җәмгыятенең бер бик мөхтәрәм кешесенең кызын үземә хәләл җефет иттем. Илдә дә матур тордык, Аллага мең шөкер,балаларыбыз булды,әле дә исәннәр...

Зур сугыштан соңгы Кытайдагы болганулар безне тагын күчеп китәргә мәҗбүр итте. Ниһаять, монда тукталып калдык. Ул вакытта мин яшь идем, дәртле чак, шуңа авырлыклар безне куркытмады. Мин монда каучук агачы плантацияләрендә эшләдем,азрак хәлләнгәч,йорт сатып алдым. Тормышыбыз,Ходайга мең шөкер, түгәрәкләнде. Инде оныкларым да бар. Алар минем яныма килеп йөриләр. Карчыгым күптән түгел генә вафат булды, урынын оҗмахтан әйләсен... Туган якларга кайтасым килә,ләкин куркам. Әле ярый атам безне алып китеп коткарып калган. Әгәр дә шулай булмаса,нәселебез тамырдан корый иде бит...

Соңгы елларда Рәсәйдә иркенлек сизелгән кебек булса да, икенче яктан, сөенергә дә нигез юк кебек,миңа калса,бу алдавычрак хөррият. Әле гәҗитләр укыштырам, Аллага шөкер, күзем ярыйсы гына күрә... Менә бу экраннан дөньяда нәрсәләр булганны күзәтәм,радиоалгычтан Казанны тотам... Ләкин Казан ни өчендер көчлерәк станция куймый, бик начар ишетелә. Әле ярый «Азатлык» татарча сөйли. Видеокассеталарым да күп...

Минем аңлавымча, Россиядә хәлләр мөшкелрәк, хөкүмәт идарәне кулдан ычкындыра бара шикелле. Бездә эш хакын түли алмаган хуҗа бөлә, бөтен нәрсәсеннән буш кала. Сездә алай түгел: күптән банкрот булган хуҗалар дилбегәне кулларыннан ычкындырасылары килми. Рәсәйдә һәрдаим шулай булды: түрәләр халык алдында һичкайчан җавап тотмадылар, ә киресенчә, көч белән гавам өстендә торып, аның исәбенә симерделәр...

Таһир бабай,сөйләнә торгач,егетләрнең артык игътибар белән тыңламауларын сизде.

—Ә-й-е-е! Сез әле яшьсез. Бу вакыйгалар сезгә турыдан-туры кагылмаганнар. Ә сезнең ата-аналарыгыз инде эшнең кая таба барганын сизгәннәрдер. Сезнең өчен кызык булмаса да, ватандашларымны күргәч, күңелемдә җыелганнарны сөйләми булдыра алмадым. Кичерегез, балалар!

Әмма Таһир бабай, түзми, сүзне тагын сәясәткә борды:

—Шунысы аяныч, Рәсәй хөкүмәте халык турында кайгыртуны бөтенләй үз җилкәсеннән төшереп бара. Аның бер генә уе—ничек итеп халыктан күбрәк салым җыю. Ә салым җыелмый. Ни өчен? Монда бер генә җавап булырга мөмкин: карга күзен карга чукымый. Ягъни эре салым түләүчеләр күптән инде түрәләрне сатып алганнар. Ә алар түләргә тиешлесен гади халыктан арттырып-арттырып алачаклар. Җыелган акча хакимиятне,армияне һәм полицияне туйдырырга гына җитәчәк. Бөтенләй урта гасырлардагы кебек... Шулай булгач, уйлагыз: элекке ханнар-патшалар белән хәзерге түрәләр арасында нинди аерма бар соң? Шундый сорау туа: Рәсәй халкы моңа күпме түзеп торыр икән? Кимсетелүнең нинди дәрәҗәсенә җиткәч, гавам баш күтәрер икән? Яңа Разиннар, Салаватлар һәм Пугачёвлар килеп чыкмас микән?...

—Шунысы кызганыч!—дип дәвам итте тәмам кызып киткән карт.—Бу

хәлләрне китереп чыгарган кешеләр барыбер оттырмаслар, аларның инде чит ил банкларында күп миллионнары җыелгандыр. Ә илдән кача башласалар, чит мәмләкәтләрдә менә дигән сарайлары әзер торадыр...

Картның сүзләренә баштарак битараф булган кунаклар хәзер аны кызыксыныбрак тыңлый башлаганнар иде. Фәрит хәтта бәхәскә керә язды.

— Сез артык куертасыз шикелле, Таһир бабай, —диде ул. —Мин шәхсән айнык акыл җиңәчәгенә ышанам.

— Бирсен Хода! Бирсен Ходай! Шулай гына булсын. Яшьләр киләчәккә һәрвакыт зур ышаныч белән карый. Өметегез корымасын! Йә, ярый! Мин сезне алҗыттым бугай. Менә чәй дә җитеште. Үзебезчә чәй эчү—минем өчен бәйрәм ул!

Чәйдән соң бабай кунакларына карап әйтеп салды:

—Оланнар, күреп торам, йөзегезгә олы мәшәкать билгесе чыккан. Зур эш белән йөрисез шикелле. Әйдә, сөйләп бирегез...

Фәрит ун минут эчендә бабайга бөтен серне ачып бирде: үзләренең кем икәнен, ни эшләп йөргәннәрен һәм Таһир бабайдан нинди ярдәм көткәннәрен.

Акыллы карт бик озак уйга чумып утырды. Ниһаять, ул башын күтәрде дә:

—Ай, авыр булачак ул баланы табуы-ы-ы! Әгәр дә инде Аллаһы Тәгалә ярдәме белән исән-имин булса, —диде. —Ә шулай да башыгызны түбән имәгез, иншалла, табылыр, Ходай ярдәм итәр...

—Менә нәрсә, балалар, —дип, аннары эшлекле тонга күчте, —иртәгә иртә белән монда килеп җитегез. Мин оныгымны чакырачакмын, Хәсәнне. Булышса, ул булышыр.

## Хәсән

Иртәгесен сәгать тугызлар тирәсендә өч дус Хәсән белән сөйләшеп утыралар иде инде. Үзләреннән ике-өч яшькә генә олырак бу егетне җирле малайя кешесеннән аерып та булмас иде. Шул ук вакытта, татарча сөйләшә башласа, ул үзгәреп китә, күзләрендә шатлыклы чаткылар уйный башлый, үз-үзен тотышы да үзебезнең милләт кешесенә хас тыйнакка әверелә.

Хәсән башта егетләргә бераз гына үзе турында сөйләп алды:

—Көллияттә адвокатлыкка укыймын, әле ике курс тәмамладым. Дүрт тел беләм: туган телемне, малайя, кытай һәм инглиз телләрен. Соңгылары монда өчесе дә бер хокукта йөри. Хәзер инде без иптәшләребез белән тагын Ауропаның бер-ике теленә ябышырга уйлыйбыз...

Кунак егетләр, сиздермичә генә бер-беренә карашып куйдылар: телләр үзләштерү җәхәтеннән алар Хәсәнгә җитә алмыйлар иде.

—Әлегә ял итәбез, —дип дәвам итте Хәсән. —Дусларым белән күңелле яшибез, төрле илләрдән килгән яшьләр белән очрашабыз. Яхтабыз бар. Әле тагын су асты көймәсе эшләдек, күрсәгез исегез китәр. Диңгезгә чыгабыз... Татар иптәшләрем генә юк. Бәлки сезнең белән дуслашып китәрбез...

Таһир бабай Хәсәнне туктатып, кунакларга сүз бирде. Фәрит тагын баштан ахырга кадәр Алсуның тарихын сөйләп бирде.

Хәсән шундук әйтеп салды:

—Фантастика! Афәрин, егетләр! Мактыйм! Бары тик шулай гына яшәргә кирәк. Шуннан дөньяда нигә яшәгәнеңә дә үкенмәскә мөмкин. Мин сезгә, әлбәттә, ярдәм итәчәкмен. Бүген үк иң якын дусларым белән сөйләшәм. Курыкмагыз, алар сатлык җан түгелләр. Сездә Алсуның фоторәсеме бардыр бит? Бирегез миңа. Хәзергә сау булыгыз, мин йөгердем. Иртәнгә кадәр!

Егетләр отельгә гаять канатланып кайттылар. Сүрелә башлаган өмет чаткылары аларның күңелендә яңадан кабынып, дөрләп яна башлаганнар иде. Ләкин алар бер-берсен артык сөенмәскә, төрле хәлләргә әзер тора белергә чакырдылар.

Икенче көнне Хәсән сүзен болай дип башлап китте:

—Сез инде Алсу өчен берсе дә акча таләп итмәде, дип әйткән идегез. Шуңа күрә, ул вариантны алып ташлыйбыз.

—Дөрес фикер, —диде Расих.

—Без иптәшләребез белән ике вариант бар, дип исәплибез: Алсуны йә берәр утрауга коллыкка алып киткәннәр, йә...

—Әйтеп бетер!

—Йә берәр шәһәргә фәхишә итеп тотар өчен урлаганнар. Әгәр шулай була калса, безнең алда чишә алмаслык мәсьәлә торган булыр иде. Ләкин без беренче вариантны яклыйбыз, чөнки моның өчен кечкенә генә булса да нигез дә бар. Эш шунда ки: утрауларда, ә бу тирәдә алар берничә йөз, төрле халык дөнья күрә. Шулар арасында җинаятьчел элементлар да бар. Менә шулар еш кына кешеләрне, бигрәк тә яшьләрне, урлап алып китеп, үзләренә эшләтәләр.

Үткән җәйне, нәкъ Алсу югалган вакытларда аңа охшаган кызны күрүче булган. Порт тирәсендә яшәүче бер кечкенә сукбай аны фоторәсем буенча таныды. Аның сүзе буенча, ике яшь кенә кеше кызны көчләп катерга утырткannар. Теге мескен ярдәм сорап кычкырып та караган... Ләкин катер бик зур тизлектә ачык диңгезгә чыгып киткән.

Катерның төсе карасу-яшел, аскы өлеше кара. Исеме яки номеры юк. Әлбәттә инде, андый суднолар күптер, эзләргә кирәк, безнең бүтән чара юк. Шунысы да билгеле, юлбасарларның берсе аксый төшә икән.

Инде уйлыйк. Мондый катерда бик ук еракка китеп булмый, шторм вакытында алар бөтенләй диңгезгә чыкмый. Ә шулай да тугыз-ун сәгатьлек юлга чыгарга хәлләреннән килә, ә бу инде өч йөз-өч йөз илле миль дигән сүз. Ә андый ераклыкта йөзләгән утрау бар: Сингапур тирәсендә, Линга архипелагында һәм Анамбас утраулар төркемендә.

—Сингапур тирәсендәгеләрен исәпкә алмасак та була: аларны полиция тикшеребрәк тора, —дип дәвам итте Хәсән. —Линга архипелагы Индонезия биләмәләренә керә, шуңа күрә без анда тиз генә барып кысыла алмыйбыз. Ә менә Анамбас утрауларына мин игътибар итәр идем, чөнки алар бәхәсле җирләр, һәм аларны берсе дә карамый. Өстәвенә, ул тирәләрдә энҗе-марҗан күп табыла. Урлап алып киткән кешеләрне тирән су төбенә чумып, энҗе алып чыгарга мәҗбүр итәләр. Ул эшне башкарырга өйрәтелгән кешеләр биш-алты елдан артыкка чыдамыйча күпләп кырылалар икән.

— Менә сезгә Анамбас утраулары картасы, —диде ахырда Хәсән. —Ә кич белән мин сезгә бернәрсә күрсәтәм, исегез китәр.

Хәсәннең сюрпризы—кечкенә генә су асты көймәсе булып чыкты. Бу болай булды: Хәсән кулындагы пультны диңгезгә таба каратып, күпсанлы кнопкаларның берсенә басты. Берничә секундтан соң ниндидер хайванның аркасы күренде, һәм ул яр буена килеп туктады. Өсте үтә күренмәле калфаксыман капкач белән ябылган, акула формасындарак итеп ясалган бу көймә чыннан да тере хайванны хәтерләтә иде.

— Без моны иптәшләрем белән ике елда төзеп бетердек, —диде горур тавыш белән Хәсән. —Тизлеге бик зур—кырык биш узел. Моторы фотоэлементлар ярдәмендә кояш энергиясендә эшли. Хәтта су астында да. Карагыз, корпусның өске өлеше тулысынча фотоэлементлардан тора. Караңгы вакытта электромотор аккумулятордан әйләнә. Ә аны шул ук фотоэлементлар тулыландырып тора. Бик зур тизлектә китәргә кирәк булса, өстәмә бензин моторы тора. Дөрес, бензин күп алып булмый, ләкин аның кирәге дә чыкмас, дип уйлыйм.

Иртәнге сәгать җиделәр тирәсендә өч дус Хәсән янына ашыктылар. Көймәне әзерләгән, азык-төлек һәм башка кирәк-ярак хәстәрләгән хуҗа аларны көтә иде инде.

— Бу көймә түгел, бу—хыял, —диде Идрис үз урынына төшеп утыргач. —Аңа шундый исем бирәсе калган.

—«Виктория» дә бик әйбәт, —дип каршы төште Расих. —Безгә нәкъ шул җиңү кирәк тә инде.

—Сез әле аның «уңганлыгын» алда күрерсез. Хәер, көймә әле зур сынау үтмәгән... Ләкин мин аңа ышанам, —дип, Хәсән рульне диңгезгә таба борды.

Шулай итеп, сәяхәтнең хәлиткеч өлеше башланды.

Башта алар Сингапур тирәсендәге эре һәм вак утраулардагы катерларны карап чыктылар. Моның өчен бер көн вакыт китте. Икенче көнне ачык диңгезгә чыгып, Анамбас утрауларына таба юл алдылар.

—Болай итәбез,—диде дилбегәне үз кулына алырга өлгергән Хәсән,—картада бөтен утраулар да төшерелгән. Без аларның һәрберсен карап чыгыйк һәм тикшерелгәннәрен билгеләп барыйк. Катерны кайда очратсак,шунда тукталырбыз да уйлашырбыз.

Анамбас утравына безнең эзтабарлар кичкә генә килеп җиттеләр. Төнне көймәдә уткәрделәр.

Иң беренче очраган утрау Гаобао исемле иде. Утрауда кеше күп яши иде ахрысы: өйләр, мал-туар күренә. Яр буйлары төрле зурлыктагы көймәләр, джонкалар,катерлар һәм яхталар белән капланган. Ләкин ватерлиниядән түбән ягы кара булган яшел катер күренми.

Ул көнне экипаж ундүрт утрауны тикшереп чыкты,ә уңыш икенче көнне генә килде: Минданао утравына килеп туктауга,яр буеннан кара аслы яшел катер кузгалып китте. Хәсән аның артыннан борылырга теләгән иде,Расихның: «Карагыз әле!»—дигән тавышы ишетелде: яр буенда тагын шундый ук бер катер дулкыннар өстендә чайкала иде.

—Нишлибез,егетләр?—дип сорады аптырый төшкән Хәсән.

—Болай итик!—диде Фәрит.—Мондагысы качмас, картада урынын гына билгеләп куябыз. Ә инде үзебез тегесенең артыннан куыйк.

—Дөрес!—дип җөпләде Хәсән һәм көймәне кирегә борды.

Күп тә үтмәде, катер белән көймә арасы якыная башлады. «Виктория»нең өстен ябып,корпусны бераз суга батырдылар. Су өстенә үтә күренмәле калфак кына чыгып тора иде. Болай итмәгәндә,тегеләрнең куа килүчеләрне вакытыннан алда күреп алулары мөмкин.

Бер сәгатьләп баргач, алдагы катер зур гына утрауга килеп туктады. Бу—Китурам утравы иде. Катер яр буена тукталуга,аннан бер ир белән хатын төштеләр дә шәһәргә юнәлделәр. Безнең сәяхәтчеләр,нишләргә белмичә,көймәдә утырып калдылар. Хафалануларының тагын бер мәгънәсе бар: әлеге катер артыннан килгән чакта,күрше утрауда тагын да шундый ук бер судно күренде. Ул яр буена бәйләп куелган иде.

— Ничек сөйләшкән булсак,шулай дәвам итәбез,—диде Хәсән,—барысының да урыннарын билгелибез,һәм һәрберсен тикшерәбез. Бүтән чара юк.

Китурам тирәсендә кирәкле төстәге биш катер табылды. Аларның хуҗаларын ачыклау болай барды: икесе ярга чыгып (аның берсе,әлбәттә,Хәсән),әлеге катер тирәсендәрәк йөрештерәләр иде. Шунда очраган берәр кешедән катерның хуҗасы турында сораштыралар.Янәсе, алар аны сатып алырга тели, һәм нәкъ шундый судно аларга кирәк тә инде.

Дүрт катерның хуҗалары шикле кеше булып чыкмадылар. Алар тирә-юньдә билгеле,эшлекле кешеләр икән. Ә менә бишенче катерның хуҗасы хакында. Шул тирәдә ауларын төзәтеп маташкан бер кытай кешесе болай диде: «Катерын сатуын-сатмавын белмим. Сатса,бик яхшы булыр иде,чөнки көне-төне мотор шаулатып, балыкны качырып бетерә. Механизмнарын карамый,мае агып,бертуктаусыз яр буен пычрата. Әнә никадәрле май таплары йөзеп йөри,барысы да аныкы. Эшем кешесе түгел,бер җилкуар малай. Кайда яшәгәнен белмим,шунда,шәһәрдә инде...»

Эзтабарлар, бераз киңәшкәч, көймәнең хуҗасын яр буенда гына көтәргә булдылар. Кирәкле кеше,дөресрәге кешеләр,икенче көнне генә күренделәр. Ярга таба ике егет атлый,кулларында авыр чемоданнар. Аларның берсе азиат йөзле икәне күренеп тора,ә икенчесе европалыга охшаган. Хәсән кинәт Фәритнең кабыргасына төртте: азиат дигәне уң аягына аксый иде.

—Димәк!... Шулар булып чыга!—дип пышылдады Фәрит, дулкынланудан калтыраган тавыш белән.

—Т-с-с-с!

Ул арада тегеләр тыныч кына катер янына килеп әйберләрен урнаштырдылар да,ашыкмый гына моторны кабызып,диңгезгә чыктылар һәм көнчыгышка таба юнәлделәр. Катер ерагайгач,«Виктория» аның артыннан кузгалды.

—Болар кая барыр икән?—дип,Фәрит карта өстенә иелде.

—Ялгышмасам,—диде Расих,—Анамбас утрауларының иң ерактагы төркеменә баралар. Карагыз әле,анда унлап утрау бар. Кайберләрендә бөтенләй кеше дә яшәми,һәрхәлдә,картада бу турыда бер мәгълүмат та юк.

«Виктория» белән катерның арасы якыная барды.

—Хәсән!—диде Фәрит,—аларга бик якынайма.

—Ни өчен!—дип аптырады Идрис.—Безгә хәзер аларны «алырга» кирәк.

—Барып чыкмас,—диде Хәсән.—Сез аларның коралларына игътибар иттегезме? Икесенең дә пистолетлары бар, хәтта эре калибрлы. Аннан соң, аларны алу әле Алсуны коткару дигән сүз түгел.

—Соң син нәрсә тәкъдим итәсең?

— Әлегә күзәтик кенә. Түземле булыйк. Сабыр төбе сары алтын,ди бит минем бабам. Күренмәс өчен,көймәне төпкәрәк батырырга кирәк безгә.

Ике сәгатьтән күбрәк баргач,алда утрау күренде.

— Егетләр,бу утрауның исеме дә юк бит картада!—дип кычкырып җибәрде Расих.

—Бу чагыштырмача яңа утрау. Вулканнан калган. Күрәсезме,үсемлеккә дә бик фәкыйрь. Нинди дә булса хуҗалык алып бару өчен яраксыз икәне күренеп тора.

Теге катер текә яр кырына килеп җитте дә кинәт күздән югалды. Фәрит Хәсәнгә биноклен тоттырды да:

— Катер юкка чыкты!—дип белдерде.

— Ничек инде юкка чыкты?—дип сорады Идрис.

— Шайтан белсен!

—Туктый төшик!—диде Хәсән.—Юкса,аучылардан ауланучыларга әйләнүебез бар. Хәтта,тирәнгәрәк тә төшәргә кирәк әле.

Ярга чаклы әле байтак булса да, «Виктория» перископ тирәнлегенә төште һәм әкрен генә хәрәкәтен дәвам итте. Биек ярга бер кабельтов чамасы калгач, перископтан карап барган Фәрит:

—Егетләр! Нәрсәдер күрәм,—диде.—Минемчә, кыяның ерыгы бар, өстән карасаң,тарлавык булыр иде. Катер шунда кереп югалды бугай. Ә болай көймәфәлән туктарлык урын бөтенләй юк,кыя,стена сыман,суга кадәр төшкән. Инде аңлашылды: бу—тарлавык. Нишлибез?

—Керәбез тарлавыкка!—дип беравыздан кычкырдылар Идрис белән Расих.

— Юк,дуслар!—дип, Хәсән тагын иптәшләрен салкын кан белән эш итәргә өндәде.—Мин ерактан гына күзәтергә тәкъдим итәм хәзергә.

«Виктория» кире диңгезгәрәк чыкты да,уңайлырак позиция сайлап,якорь төшерде. Шушы урында иртәнгә кадәр көтәргә туры килде аларга. Диңгезнең тынычлыгы дусларны бик сөендерде,ә бүтән кыенлыкларга алар инде күнеккән иде.

Иртән кояш туып кына килгән вакытта кизүдә утыручы Идрис иптәшләрен уятты:

—Карагыз әле!

Иптәшләре перископтан утрауга таба күз салдылар: өч катер, тарлавыктан чыгып, төньяк юнәлешенә борылалар иде. Иң мөһиме—суднoларның берсе егетләргә таныш: карасу-яшел төстәге номерсыз катер иде бу. Өч катерда барысы унбишләп кеше урнашкан,аларның кайберсе кораллы иде.

Катерлар зур гына тизлектә төньякка омтылдылар. Бераз көткәч, эзәрлекләүчеләр дә алар артыннан кузгалдылар,араны бинокль аша күрерлек кенә итеп тоттылар.

— Фәрит!—диде рульне иптәшенә биргән Хәсән.—Якынрак килсәк тә була. Без бит калфак астында. Ә ул дулкыннар арасыннан бөтенләй күренми диярлек.

Дүрт сәгатьләп диңгез телгәннән соң кәрван,кинәт кенә курсны үзгәртеп,җитмеш градуска төньяк-көнбатышка борылды да шул ук тизлектә хәрәкәтне дәвам итте. Хәсән шундук картага карап: «Сиам култыгына борылдык. Бик кызык!»—дип куйды.

Яңа курс белән озак кына баргач, катерлар капыл гына туктадылар да нәрсәдер көтә башладылар. Аларга кадәр ике кабельтов калгач,«Виктория» дә тукталды һәм бинокль эшкә җигелде. Көтмәгәндә Фәритнең күзләре уңгарак төштеләр,һәм ул кычкырып ук җибәрде: катерларга таба көнчыгыш ягыннан ниндидер бер зур лайнер килә иде.

—Дизель—электроход «Меконг» бу!—диде Хәсән.—Тайбейдан Рангунга кадәр йөри. Үзе Вьетнамныкы. Туктагыз, нәрсә бу?! Катердан лайнерга флажоклар белән ниндидер сигналлар бирә башладылар. Егетләр, кайсыгыз аңлый диңгезчеләр әлифбасын? Фәрит, синме? Тот бинокльне!

Фәрит тиз генә бинокльне алды да, сигналларның мәгънәсен иптәшләренә җиткерә башлады:

—Бер генә фразаны кабатлыйлар: «Хәзер үк туктарга! Юкса, батырачакбыз».

Тизлеген аз гына акрынайта төшкән лайнер катерлар яныннан уза башлагач, бер катердан ракета очып чыкты да судноның антеннасын сындырып узып, диңгездә шартлады. Бу инде, әлбәттә, шаяру гына түгел иде.

—Нишлиләр бу вәхшиләр!—дип тешен кысты Хәсән.—Анда бит гади пассажирлар, туристлар.

Лайнерга туктарга туры килде. Пассажирлар башта кызыксынып палубага чыксалар да, кораллы кешеләрне күргәч, кире каюталарына таралып беттеләр. Зур катердан, инглизчәләтеп, мегафон тавышы ишетелде:

— Әй, «Меконг»тагылар! Бөтенләй туктагыз! Бу—халыкара полиция. Трап төшерегез! Ишеттегезме?

Катерлар тукталып калган лайнер янына килеп җиттеләр, өстән трап төшүгә унлап кеше, кыска автоматларын өскә каратып, палубага менделәр. Палубада ыгы-зыгы купты, халык җыела башлады. Аларны юлбасарлар каюталардан куып чыгарып, бер урынга җыялар иде бугай.

Ун-унбиш минутлар узгач, ачыкланды: корабны басып алучылар палубадан аска—үзләренең катерларына төрле пакетлар, чемоданнар, капчыклар төшерә башладылар.

—Кешеләрне баштук тентеп чыгарганнардыр инде,—дип куйды Расих.

Байтак әйбер төшерелгәч, пиратлар үзләре дә төштеләр, һәм тиз генә төньякка таба юнәлделәр. Лайнер күздән югалгач, катерлар өчесе өч тарафка таралды. «Виктория» электән таныш судно артыннан китте. Бераздан һавада гөрелдәгән тавыш ишетелде: өстә вертолет йөри иде. Ул ары-бире ике-өч тапкыр узды да югалды. Ә таныш катер юнәлешне берничә мәртәбә үзгәртеп, эз яшереп йөргәч, куа килүчеләрне тагын шул ук утрау янына алып килде һәм үзе тарлавыкка кереп югалды.

Эзтабарларга бары да аңлашылды: бу утрау диңгездә талау белән маташкан чып-чын пиратларның качып яткан һәм талаган әйберләрен саклый торган урыны иде.

Хәзер инде нишләргә? Утрауга ничек үтеп керергә? Шул турыда киңәшләшеп утырганда, Расих кулы белән яр буена таба күрсәтте:

—Карагыз әле, иптәшләр!

Катерлар кереп югала торган кыя өстендә нидер ялтырап-ялтырап китә иде.

— Бу бинокль объективы,—диде Хәсән.—Кояш түбәнәйгәч, аның нурлары линзаларда чагылалар. Димәк, анда күзәтчеләр бар. Сак булыйк, егетләр, көймәне яшерә төшик.

Кич булу сәбәпле, монда торуның инде мәгънәсе юк иде. Караңгыга кадәр утрауны тулысынча әйләнеп чыгу уе белән, сәяхәтчеләр яр буйлап киттеләр. Утрауның һәр ягы да текә кыя булып чыкты, һичбер тукталыр җир юк иде.

—Сайлый белгәннәр урынны!—дип куйды Идрис.

Ул киңлекләрдә караңгы бик кинәт төшә, шуңа күрә алар утрауны әйләнеп чыгу белән үк якорь төшереп, төн үткәрергә булдылар. Диңгез тыныч булса да, көймәне шактый тирбәтә, гүя диңгез егетләрне йоклатырга тели. Ләкин дүрт дусның күзләренә йокы керми. Бу кадәр киеренке хәлләр, көтелмәгән вакыйгалар арытса да, якын киләчәкнең тагын да мәшәкатьлерәк булуын сизү аларны ярсыта, йөрәкләрен кыса, дулкынландыра иде.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# ӘЙТЕРГӘ МИКӘН?

Ак җилкән-җилкәнкәй!

Серемне бөтен дөньяга тарат әле! Серемне белерләр, ләкин минеке икәнен белмәсләр. Чөнки мин хат азагында исемемне генә куям, ә минем исемдәге кызлар хәзер дөнья тулы. Безнең класста гына да бишәү без.

Серем шул: мин гашыйк булдым. Кемгә икәнен әйтмим. Белми торыгыз әле менә. Моны әле беркем дә сизми. Ул үзе дә. Әни генә, нигә син гел җырлап йөри башладың әле, ди. Моны мин үзем дә сизмәгәнмен, җырлыйм икән шул. Җырласаң җинелрәк була икән. Җинел дип, болай да авыр түгел инде түгеллеккә. Ләкин серне эчтә йөртү читен. Өйгә дә, мунчага да су кергән үзе, ә мин, чистарак бит дигән булып, алар турындагы чишмәгә йөрим. 4—5 тапкыр барып кайтам. Әни суны кая куярга белми. Шундый рәхәт инде, чабып кына диярлек барам, тиз-тиз атлап кайтам. Бер тапкыр очрады тәки. Капка төбендә утын ярып тора иде. Мине күргәч, ул да дәртләнебрәк яра башлады. Әллә мина гына шулай тоелды инде. Майкачан гына, беләкләрендә мускуллары уйнап тора. Үзе күрмәмешкә салышкан була... Нигә алай икән инде ул?.. Чишмә буенда бер бозау арканлап куелган иде. Беләм, аларның бозавы ул. Түзмәдем, шул бозаудан М. мине яратамы, яратса, мөгрә әле, дидем. Мөгрәде бит. Миңа шул да җитә калды, бөтен тирә-якны яңгыратып көлдем. Аннары:

*Әйтергә микән, әйтмәскә микән,*
*Сине яратам, сине яратам!»*

дип җырлап җибәрдем. Чыннан да ничек кирәк икән соң? Болай бик авыр бит. Авыр дип, авыр да түгел инде, рәхәт тә кебек үзе. Тик җайсыз яклары бар шул. Бер тапкыр топ-тозлы аш пешердем, әллә ничә кашык тоз салганмын. «Өчлеләр» ала башладым. Дәреслекне ачам, укып кына булмый бит. Күз алдында аның уң яккарак таралган саргылт чәче, почык борыны һәм... Юк, күзләренең төсен белмим, чөнки күзенә туры карый алганым юк әле.

Әй, ходаем, моны «Ак җилкән»нән укыса, үзен таныячак бит инде ул. Шуннан ни булыр, әйбәт булырмы, начар булырмы? Белмим генә бит, әй. Җибәрергәме соң бу хатны, юкмы?.. Ә без аны болай итәбез. Акча чөябез. Иләк төшсә, җибәрмим, күн төшсә—җибәрәм... Күн төште бит, әй! Шулай да, һаман икеләндерә әле. Утын яргандагы кебек, моны да күрмәмешкә салышырга мөмкин бит ул... Бер тәҗрибәм дә юк бит минем, бу хакта китаплардан укып, кинолардан карап кына беләм бит мин. Кинәшер кеше дә юк, киңәшсәм, арттан көлеп йөриячәкләр, серемне бөтен авылга таратачаклар бит... Нишләргә икән соң, ә?

**ЛӘЙСӘН.**

*Арча районы.*

## БЕЗНЕҢ ДУСЛАР МӘКТӘПТӘ!

«Казан утлары» редакциясенең иҗат бригадасы җөмһүриятебезнең берничә районында мәктәп укучылары белән очрашып кайтты әле. Бригада дигәнем ике мөхәррир—мин, ягъни Алмаз Хәмзин белән Камил Кәримов һәм җаваплы сәркәтибебез Алмаз Гыймади. Кайчагында матур гына бер җырчы кыз да алып барабыз.

Балаларның игътибарын озак җәлеп итеп тору бик авыр бит ул. Укытучылары да шулай ди. Тәртип саклау өчен үзләре дә кереп утыралар. Камил белән шук балаларның җаен табарга хәйран оста булып чыктык әле. Башта үзем, җырым тәрбияви эчтәлектә булса да, шуны күңелле итеп башкарып, балаларның хушын алам: яннарына төшеп, кул биреп исәнләшеп чыгам. Аннан Камил туган телебезнең матурлыгын, аның дөнья халыкларының телендә кулланышын, бөеклеген раслап, әллә нинди кызык дәлилләр белән укучыларны шаккатырып бетерә. Баксаң, инглизләрнең «бэби» сүзе дә татар сүзе икән бит, «бәби» бит инде ул! Балалары татар булгач, әти-әниләре дә татар була түгелме соң, дип тә өстәп куя әле Камил. Үзем дә аны тыңлап әллә ничаклы татар сүзенең дөньяда кулланышта йөргәненә сөенеп, телебез өчен горурланып утырам.

Балаларның күзе гел бездә. Шаяру, кылануларын бөтенләй онталар. Шуны ычкындырмас өчен җыр кирәк, җыр! Сәхнәдә җырның эчтәлегенә карап ничек театр куярга кирәклеген өйрәтәм, «Кем көлдерә», «Гөлйөзем» дигән җырларымны башкарам. Зал гөрли, зал гөжли, бал кортлары, әйе, бал кортлары диярсең! Бал җыялар, үзләренә әдәбият-сәнгать дәресендә белем эстиләр. Менә бит ул ничек булырга тиеш тәрбия, әхлак дәресләре! Укытучылары да очрашуыбыз тәмамлангач бу турыда искәртеп куялар.

Концерт-дәресебезнең иң кайнаган чагы дип мин Алмаз Гыймадиның үз әсәре—Татар малаеның япон малаена хатны укуын һәм табышмаклар әйтүен атар идем. Менә шунда көлә-көлә эчләр ката инде. Үзебез дә балаларга ияреп бала-чагаланып бетәбез. Менә кайда ул язучы өчен язу чималы! Кызыгын язып кына аңлатып булмый, аны күрергә кирәк. Табышмаклар әйтүгә күчәм. Гыймадиның иң беренче табышмагы мондый: «Үзе яшел, үзе пеләш, үзе сикерә» Нәрсә ул? Камил Кәримов шундук, Алмаз Хәмзин түгел, дип кисәтеп куя. Балалар очынып-очынып җавап бирә башлыйлар. Кайсы гына очрашуда бирмә бу табышмакны, аның беренче кычкыручысы «бака» ди. Икенчесе—чикерткә, өченчесе—туп дип кычкыра. Аның дөрес җавабы бака да, чикерткә дә,туп та түгел. Ләкин «бака» дигәне, нигәдер, кызыграк. Шул кызыграк җавапка бер бүләк—«Көлдергечләр» китабы бирәбез. (Чын җавабын бу юлы да әйтми торам, кызыгы бетә, журнал укучыларга да уйлый тотырга бер сәбәп булыр). Икенче табышмакка күчәбез. Гыймадиның ул табышмагы мондый: «Үзе кечкенә, үзе филгә охшаган». Теге табышмакның «бака» дигәненә бүләк биргәч, әлеге дә баягы бала тагын «бака!» дип кычкырды. Өченче табышмактан соң да «бака» дип кычкырды әле ул

җавапны. Югыйсә табышмак мондый иде: «Бер мөгез, бер күз».

Ул малайның гел «бака» дип кычкыруының сәбәбен соңыннан гына аңладык. Аларның өе күл буенда икән.

Кызык хәлләр, мәзәкләр шул юл йөргәндә, очрашуларда туа бит инде. Тагын нинди табышмаклар бар соң әле дип баш ватып йөргәндә Камил Кәримов чалбарының ике буш кесәсен чыгарып салды. «Бу нәрсә?» Уйга калдык. Шәп табышмак ич бу! Әйдә, балаларга күрсәтәбез! Үзебезчә җавапны «язучыларның бүгенге хәле» дип уйлап куйган идек. Очрашуларның берсендә Камил шул кесәле табышмакны чыгарып күрсәтте бит! Балалар уйга калдылар. Тынлык. Зал баш вата. Берзаман арткы рәттәге өлкән сыйныф укучыларының берсе «Кризис!» дип кычкырып җибәрмәсенме! Барыбыз да гөжләп кул чабарга тотындык. Моннан да төгәл җавап табу







мөмкин түгел иде. Афәрин! Әлбәттә, бүләкнең иң яхшысы бирелде. Ул «Казан утлары»ның әле яңа гына чыккан саны иде.

Гыймади һәм Камилдән соң табышмаклар әйтүне мин дәвам итәм. Минекеләр—музыкаль. Кем икәннәрен әйтмичә Илһам Шакиров һәм Ренат Ибраһимов булып җырлап күрсәтәм. Илһамны җырлап бетереп, «Кем бу?» дип соравым булды, алгы рәттә утырган өч кечкенә кыз сикереп тордылар да, бармаклары белән миңа төртеп «Үзең!» диделәр. Тәгәрәпләр китә яздым. Камил көлә, Гыймади көлә!.. Тынычланып, икенче пародияне күрсәтәм. Җырлап бетерүем булды, тагын теге өч кыз сикереп торып: «Тагын үзең!» димәсеннәрме? Менә, ичмасам, җавап! Әлбәттә, аларга да бүләкләрнең саллысын—журналларыбызны тараттык.

Җырчы кызыбыз Рәфинәнең үзенә, матур көлмәкләренә, сихри тавышына сокланып утырганнан соң укучылар, «очрашуыбыз тәмам» дигәнне дә көтмичә, сәхнәгә ыргылалар. Аларның бүгенге очрашуга килгән язучы абыйларыннан автографлар аласы бар. Фотога да төшеп каласы иде.

Ә нигә төшмәскә, автограф биреп, изге теләкләр теләп калмаска ди! Бәлки, үзләре Зур Кешеләр булгач, бу фотолардан безне күрсәтеп: «Менә бу—язучы Камил абый, артист Алмаз абый, менә икенче Алмаз—Гыймадиев, монысы җырчы Рәфинә апа»,—дип үзләренең балаларына, дусларына күрсәтерләр!

**Алмаз ХӘМЗИН**



## Мәхәббәтнең ике утында

Мин башканы сөям... Ләкин синең
Күзләреңә карап алдалыйм...
Шул газаплы мәхәббәттә янам,
Шаштым инде гүя, аңламыйм...

Иңнәреңә синең кагылганда
Тик ул гына минем уемда...
Аны уйлыйм йолдыз тулы төндә
Җылынганда синең куенда.

Яратам мин аны, тик алдалыйм
Югалтасым килми сине дә.
Онтыр идем. Онта алмыймын шул,
Тик ул гына минем күңелдә...

Еллар артта кала барган саен
Күңелдән ди барсы онтыла...
Оныта алмыйм, янам инде хәзер
Мәхәббәтнең ике утында...

## Азан моңы

Кичләр җиткәч, тирә-якка
Агыла азан моңы.
Моңлы тыңласаң, кабына
Йөрәкнең серле чыңы.

Азан моңы тирә-якка
Сафлык булып түгелә.
Ниләр ята азан әйткән
Бабайларның күңелендә?

Искә төшәдер аларга
Кыйбласыз, нурсыз еллар.
Чукындырганда бирешми
Сызлаган аяк-куллар.

Йөрәк түрендә ятадыр
Сугыштагы окоплар.
Мәчет манарасын кискән
Тәреле, җансыз поплар...

Барысы да артта калган,
Шөкер, бар бит кыйблабыз.
Иркен сулап саф һаваны,
Бергә дога кылабыз...

**Алсу НУРГАТИНА**
*Аксубай районы, Иске Ибрай авылы.*

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*

## Илдус Диндаров



Илдус Гали улы Диндаров 1949 елның 15 мартында Татарстанның Октябрь (хәзер Нурлат) районы Биккол авылында туа. Нурлат урта мәктәбен тәмамлагач, комсомол юлламасы белән Түбән Кама шәһәренә китә, химия гиганты төзелешендә бетончы, монтажчы булып эшли. Армия сафларында хезмәт итә. 1972 елдан—вакытлы матбугатта. Нурлат, Минзәлә районнары газетасы редакцияләрен житәкли, «Шәһри Казан» газетасының, 1991 елдан «Ватаным Татарстан» газетасының үз корреспонденты вазифаларын башкара.

Илдус Диндаров—Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы. Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә керткән зур өлеше, күпьеллык намуслы хезмәте өчен ана «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелгән.

Ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, Ленинград Югары партия мәктәбендә (бүген политология институты) укый. Берара Октябрь райкомында эшләп ала.

Илдус Диндаров әдәби ижат эше белән житди шөгыльләнә. Беренче шигырь-хикәяләре мәктәп елларында ук Октябрь (Нурлат) районының «Дуслык», жөмһүриятебезнең «Татарстан яшьләре» газеталарында, «Ялкын» журналында күренә башлый. Ижат жимешләре бүген республиканың «Ватаным Татарстан», «Мәдәни жомга», «Шәһри Казан», «Сабантуй», «Салават күпере» газеталарында, «Казан утлары», «Чаян», «Идел» журналларында басылып килә. Бөтенсоюз комсомол төзелешендә эшләгән чорда Түбән Каманың Рахмай Хисмәтуллин житәкләгән әдәби берләшмә эшчәнлегендә актив катнаша, яшь язучыларның республика фестивапенә чакырыла.

Илдус Диндаровның бүгенгәчә берничә китабы дөнья күрде. «Нурлат йолдызлыгы» дигән кумәк жыентыктан тыш, 2007 елда «Гомер фасыллары» исемле үз (мөстәкыйль) китабы басылып чыга. 2009 елда нәшер ителгән шигырьләр жыентыгы «Күнел яктысы»дип атала. Тиздән аның тагын бер яна китабы чыгачак.

Үз көчен төрле жанрларда сынап карый. Лирик парчаларына, юмористик хикәяләренә, мәсәлләренә кызыклы детальләрне «тотып ала» белү, тормышчанлык хас. Шигырьләре исә гади кешеләрнең күнел кичерешләре,туган жир, туган тел, туган табигать турында уйланулары рәвешен алган. Кайберләре музыкага салынган.

Татарстан Язучыларының 2009 елның 21 декабрендә үткән Идарә утырышында, Берлекнең Кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Илдус Гали улы Диндаров Татарстан Язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—Айдар Хәлим, Факил Сафин, Альберт Хәсәнов) кабул ителде.



«Казан утлары» журналында «Почет ордены» тапшырылган көн истәлеге. 1982 ел.

Язучы һәм журналист
Диләрә Зөбәерова. Үткән
гасырның 60нчы еллары.





Редакциядә очрашу. Сулдан уңга—Нури Арсланов, Роза Хафизова, Ләбибә Ихсанова, Венера Ихсанова, Роберт Бикмөхәммәтов. 1964 ел.



*Замандашлар. Уңнан сулга—Гадел Кутуй, Салих Сәйдәшев, Исмәгыйль Усманов. 1928 ел.*



*Язучы, СССР Югары Советы депутаты, Татарстан Язучылар союзы рәисе Ибраһим Гази үзенең сайлаучылары—Әлмәт нефтьчеләре белән. Әдипнең соңгы рәсемнәреннән берсе. 1971 ел. Әлмәт.*



*СССРның халык артисты Фуат Халитов һәм язучы Әхәт Гаффар.*

# ТУКАЙНЫҢ МЕМОРИАЛЬ ҮЗӘГЕН БУЛДЫРЫЙК!

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУКАЙ ПРЕМИЯСЕНӘ ЛАЕК БУЛГАН ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ МӨРӘҖӘГАТЕ

### Татарстан Президенты Минтимер ШӘЙМИЕВКӘ

Хөрмәтле Минтимер Шәрип улы!

2008 елның сентябрендә Тукаебызның соңгы истәлеге булган «Болгар» номерларын югалттык. Бу гамәл халкыбыз тарихында көтелмәгән үкенечле вакыйга булды.

Бу эштә барыбыз да зур гөнаһлы—без, татар зыялылары, әле бина бар чакта, бергәләп киңәшеп, килешеп, Габдулла Тукайның ошбу реликвиясен саклау, аны үстерү, файдалану концепциясен тәкъдим итә алмадык. Инде бүген, гаепләләрне эзләп вакыт уздырмыйча, бу хатабызны төзәтү уе белән Сезгә үзебезнең фикер-теләгебезне җиткерәбез.

Бина сүтелгәнче, Габдулла Тукай яшәгән 40нчы бүлмәне саклау, мәңгеләштерү турында хыялланган, бүген инде яңа архитектура проекты белән төзелгән ниндидер комплекста ясалма Тукай бүлмәсе оештыру аны хурлау гына булыр иде. Тукаебызның рухи бөеклеге истәлегенә туры килердәй бер генә мөмкин эш, ул—иске эскизлар буенча торгызылган «Болгар» номерларының бер өлешендә (якынча 35-40 бүлмәдә) «Тукай мемориал үзәге»н—«Тукаевский мемориальный центр» оештыру. Бу очракта Габдулла Тукай үзе тирәсендә бер гасыр элек шул нигездә аралашкан, "Болгар" номерларында яшәп яткан бөек замандашларын яңадан янына җыяр, киләчәк буыннарга таныштырыр иде.

Бу үзәктә татар халкының бөек тарихи затлары (якынча 50-60 шәхес): шагыйрьләр, язучылар, дин әһелләре, галимнәр, бөек сәнгатькярләр—композиторлар, артист-башкаручылар, күренекле дәүләт эшлеклеләре, халыкара күләмдәге сәясәтчеләр, хәрби, башка өлкәләрдәге хезмәткәрләр урын алачак. Башка музейлардан аермалы буларак, аның өстенлеге—татарның бөтен тарихи шәхесләре турындагы мәгълүматның бер урында булуы, анда аларның кыскача тормыш тарихлары, кылган гамәлләре, калдырган хезмәтләре, әсәрләре турында тулы белешмәләр тупланыу. Мемориал киләчәк яшь буынны тәрбияләү эшендә дә киң файдаланылыр иде.

Үзәктә оештырылган китапханә аларның хезмәтләрен, әсәрләрен туплау, электрон, аудио форматларда булдыру, боларны халкыбызга кайтару белән шөгыльләнергә тиеш. Мультимедиа төркеме компьютерлы мәгълүмат системалары, стендлар булдыру, бөек әдәби, музыкаль, сәхнә әсәрләренең аудио—видео язмаларын җыйнау, аларны буклетлар белән урыс, инглиз, төрки телләрдә яздыру, тарату бурычын үтәргә тиеш.

Чыгымнарына килгәндә, бинаны торгызу эшен аны җимергән оешмаларга йөкләргә кирәк. Үзәкне оештыру, аны яшәтүдә «Халыкара Тукай фонды», икътисади потенциалы булган бай оешмалар, гомумән, бөтен халыкның хәйрия гамәлләре күздә тотыла.

Бу олы бурычны үтәүдә Сезнең теләктәшлегегезгә, ярдәмегезгә ышанып калучы замандашларыгыз—Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары:

**Равил Фәйзуллин, Рабит Батулла, Марсель Галиев, Туфан Миңнуллин, Әхсән Баян, Разил Вәлиев, Рафаэль Мостафин, Шәукәт Галиев, Марсель Зарипов, Фәнис Яруллин, Роберт Миңнуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Салават Фәтхетдинов, Наилә Гәрәева, Илдус Әхмәтҗанов, Наил Дунаев, Рамил Төхфәтуллин, Фәрит Бикчәнтәев, Зөлфәт Хәким, Сергей Скоморохов, Әзһәр Шакиров, Равил Шәрәфиев, Шәукәт Биктимеров, Ринат Таҗетдинов, Нәҗибә Ихсанова, Айрат Арсланов, Әхсән Фәтхетдинов, Зөфәр Гыймаев, Абрек Абзгильдин, Харис Якупов, Рәшит Кәлимуллин, Резидә Әхиярова.**

## КОМПОЗИТОРЛАР ҖЫЕНЫ

***

Татарстан Композиторлар берлеге быел үзенең 70 еллыгын билгеләп үтте. Юбилей чаралары ноябрь ахырында ук концертлар циклы белән ачылып китте. «Җырларым» дип аталган беренче концерт 21 ноябрьдә С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында Татарстан дәүләт камера хоры (җитәкчесе М. Тәминдарова) һәм Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле (җитәкчесе А. Хәмитов) катнашында узды. 28 ноябрьдә исә шул ук залда Ф. Мансуров җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры чыгыш ясады. 1 декабрьдә тамашачы «Музыкальное приношение» дип аталган камера концертын тыңлады. Әлеге концертларда республикабыз композиторларының әсәрләре яңгырады.

Берлекнең юбилеена багышлап ике күргәзмә дә ачылды. Аларның берсе—«Татарстан композиторлары» дип исемләнгәне С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында оештырылган иде. «Дөнья халыкларының музыка уен кораллары» дип аталган икенче экспозиция үткән атнада Кремльдәге «Эрмитаж» галереясендә ачылды. Күргәзмәне Татарстан музыкантларының шәхси коллекциясендә сакланган уен кораллары тәшкил итә.

***

4 декабрьдә Композиторлар берлегенең XI съезды әлеге иҗат оешмасының юбилей чараларына йомгак ясау рәвешендә булды. Съезд Мәдәният министрлыгы бинасында үтте. Композиторлар ике съезд арасында җыелган проблемаларын уртага салып сөйләштеләр.

Татарстан Композиторлар берлегендә бүген 60 композитор әгъза булып тора. Корылтайга шуларның 41е килгән иде. Татарстан Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева съездны Татарстан Президенты М. Шәймиевнең котлавын уку белән ачып җибәрде. Аннары Россия Композиторлар берлеге рәисе В. Казенин чыгыш ясады.

Соңрак съезд эшен Композиторлар берлеге рәисе Рәшит Кәлимуллин дәвам итте. Ул соңгы 5 ел эчендә башкарылган һәм башкарылып җитмәгән эшләр хакында хисап тотты. «Профессиональ музыка сәнгате—милли байлык һәм ул саклануга, яшәтелергә, үсәргә тиеш. Бүген милләтебезне саклаучы төп көчләрнең берсе мәдәният булып калганда, бу аеруча мөһим»,—дип ассызыклады ул.

Съезд ахырында Композиторлар берлегенең яңа идарә составы сайланды. Берлекнең рәисе булып янәдән Рәшит Кәлимуллин калды.

***

Татарстан Композиторлар берлегенең XI съезды кичен С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында бәйрәм концерты белән тәмамланды. «Татарстан музыкасы шедеврлары» дип аталган симфоник концертта Н. Җиһанов, Ф. Яруллин, М. Мозаффаров, Ж. Фәйзи, Л. Батыркаева, Ш. Тимербулатов, Р. Кәлимуллин һ. б. композиторларның әсәрләрен Татарстан дәүләт симфоник оркестры һәм җырчылар З.Сөнгатуллина, Р. Галимова, А. Исламов, Р. Асаев, В. Васильев, Ф. Каһиров башкарды. Концертны Татарстан Президенты М. Шәймиев тә тамаша кылды.

## ЭШЕҢ БУЛСА—ӨМЕТ СҮНМӘС

11-12 декабрь көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының 2009 ел йомгакларына багышланган киңәйтелгән утырышы булды. Билгеле булганча, Конгресс каршында төрле комиссияләр эшләп килә. Мәдәният комиссиясе, гадәттә, Мәдәният министрлыгында Комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева җитәкчелегендә алып барылды.

З. Вәлиева комиссиянең еллык эшчәнлегенә бәя биреп, Россия һәм БДБ илләрендә яшәүче татарларыбыз арасында зур резонанс тудырган «Татар моңы» татар фольклоры фестиваленә киң тукталды. «Татар моңы» милләттәшләребезне, кайда, ничек яшәүләренә карамастан, бер мәдәни мохиткә туплаучы чара буларак үзен һичшиксез аклады»,—диде ул.

Соңгы елларда Сабан туеның бик күп төбәкләрдә тиешле дәрәҗәдә үтүе, өлкә, край, республика җитәкчелегенең Сабан туен читләтмәүләре, үз бәйрәмнәре кебек кабул итүләре артында төбәкләребездә яшәүче татарларыбызның абруйлы булулары турында ассызыкланды. Балалар Сабан туйларының, киңәеп, бер үзен-

чәлекле күренешкә әйләнүе һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан анын һичшиксез яклау табачагына әһәмият бирелде.

Зилә Вәлиева чыгышында Бөтенроссия татар фольклоры фестивале «Түгәрәк уен» да игътибар үзәгендә булды.

Утырышта Дәрдемәнд һәм С. Сәйдәшев шәхесләре, Бөек Жинүнең 65 еллыгы, Г. Тукайның тууына 125 ел h. б. юбилей даталары турында сүз күп булды. Комиссия утырышында катнашучылар татар халкынын этник мәдәниятенә мөнәсәбәте булган, ел әйләнәсендә төрле төбәкләрдә даими үткәрелеп килүче чараларнын аерым планын һәм татар халкы мәдәнияте, тарихы, сәнгате белән бәйле күренекле даталар исәпкә алынган махсус календарь булдыруны тәкъдим иттеләр.

Эшлекле тәкъдимнәр арасында Россия Федерациясе субъектларындагы төзекләндерү көтеп ятучы татар тарихына бәйле архитектура һәйкәлләренен дә аерым бер реестрын булдырып, аларны федераль программа кысаларында төзекләндерү юлларын бергәләп эзләү кебекләре дә булды. Гомумән, Мәдәният комиссиясе утырышында конструктив фикерләр һәм эшлекле тәкъдимнәр күп булды. Төбәкләрдән килгән милләттәшләребез утырыш тәмамлангач та, Республикабызнын төрле оешма житәкчеләре белән эшлекле сөйләшүләрен, үзара килешүләрен дәвам иттеләр. Димәк, киләчәктә эшчәнлек тагын да кинәячәк.

## ДӘРДЕМӘНДНЕ ОЛЫЛАУ ТАНТАНАЛАРЫ

***

Декабрь аенда бөек татар шагыйре, химаяче Дәрдемәнднең тууына 150 ел тулу кин жәмәгатьчелек тарафыннан зурлап билгеләп үтелде.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «Исә жилләр, кучә комнар...» дип исемләнгән тантаналы кичә үткәрелде. Анда Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең Дәрдемәнд юбилее тантанасында катнашучыларга сәламләү мөрәжәгатен укып ирештерде. Анда шагыйрьнең халык гаме белән өртелгән зур талантка ия булуы, шулай ук анын XX гасыр башындагы милли-мәдәни күтәрелештә химаяче буларак зур өлеш кертүе ассызыклап әйтелгән иде. Дәрдемәнднең мәнә шушы мөкатдәс миссиясе Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов һәм ТФА академигы Миркасыйм Госманов чыгышларында үзәккә алынды.

Тантаналы кичәдә Дәрдемәнднең тәржемәи хәленә бәйле театральләштерелгән эпизодлар күрсәтелде, сәхнә осталары башкаруында шагыйрьнең тезмә һәм чәчмә әсәрләре янгырады, жыр һәм биюләр тәкъдим ителде.

Дәрдемәнд бәйрәмендә Мәскәү, Санкт- Петербург, Уфа һәм башка шәһәрләрдән килгән вәкилләр дә бар иде.

***

Юбилей кысаларында Татарстан Мәдәният министрлыгы бинасында «Дәрдемәнд мирасы һәм хәзерге заман» дип исемләнгән фәнни конференция үткәрелде. Анда танылган галимнәр һәм язучылар чыгыш ясады.

***

Казанның Г. Тукай музеенда «Вакыт бизмәне» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Анда галимнәр М. Госманов, Н. Хисамов, И. Гыйлажев, музей хезмәткәрләре, күренекле артистлар катнашты.

***

Дәрдемәндкә багышланган тагын бер конференция Башкортстан Дәүләт музееның актлар залында да уздырылды. Анда Казаннан галимнәр К. Миннуллин, Н. Хисамов һәм язучы Л. Хәмидуллин докладлары тыңланды.

***

Башкорт дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында бөек татар шагыйре Дәрдемәнднең 150 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичә булды. Анда Татарстаннан Дәүләт Советынын мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Р. Вәлиев, Татарстанның халык язучысы Т. Миннуллин сәламләү сүзе белән чыкты.

***

Бөек шагыйрьнең туган авылы Жиргәндә (Башкортстан, Мәләвез районы) анын исемен мәнгеләштерү ниятеннән мемориаль такта урнаштырылды. Анда Дәрдемәнднең горур кыяфәттәге барельефы сурәтләнгән, өч телдә—башкорт, рус, татар телләрендә шагыйрьнең шушы авылда туганлыгын хәбәр иткән язма уелган. Тактанын бизәлеш авторы—татар рәссамы һәм скульпторы Фарис Фәтхи. Мәрмәр һәм металлдан эшләнгән бу тактаны Жиргән авылына Татарстан мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры, «Жыен» татар телен, мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды бүләк итте. Истәлек тактасы Жиргән авылы мәдәният сарае диварына беркетелде.

Жиргәндәге тантаналарда Татарстаннан әдәбият һәм сәнгать вәкилләреннән торган делегация катнашты. Татарстанның халык язучысы Т. Миннуллин, республикабызнын Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге

ияләре, шагыйрьләр Р. Вәлиев һәм Г. Рәхим, җырчы З. Сәхәбиева, «Җыен» фонды директоры Ф. Рафиков һ. б. катнашты.

## ДИМ БУЕНЫҢ БӨЕК УЛЫ

2009 ел татар әдәбиятында Фатих Кәрим елы булды. Февраль аенда аның тууына—100, батырларча һәлак булуына 64 ел тулды. Шул уңайдан күп кенә истәлекле бәйрәм чаралары үтте. Алар шагыйрьнең туган ягы—Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында да, һәлак булган җире—Калининград өлкәсенең Багратионовск каласында да узды. Шулай ук Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында шагыйрь иҗатына багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрелде.

19 ноябрьдә Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында патриот шагыйрь Фатих Кәримнең туына 100 ел тулуга багышланган «Кыңгыраулы яшел гармун» дип исемләнгән тантаналы кичә булды.

Кичәдә шагыйрьнең Уфа һәм Мәскәүдән килгән туганнары, иҗатын яраткан укучылары, үзе туып-үскән Башкортстан якларыннан килгән кунаклар, җәмәгать эшлеклеләре, Татарстан Дәүләт Советы депутатлары, әдипләр һәм Ф. Кәримнең кызы Ләйлә ханым катнашты.

Әдәби кичәне ачып, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов болай диде:

—Фатих Кәрим совет төрмәсендә һәм фронтта, иҗат итәр өчен коточкыч шартларда 200дән артык шигырь, 8 поэма, 2 повесть һәм драма әсәрләре язган икән, ул инде лаеклы рәвештә шул чорның елъязмачысы, шаһите, алай гына да түгел, хөкемдары да булган диган сүз. Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Фатих Кәрим... Бу олпат затларыбызның тормыш юллары, язмышлары төрле-төрле булса да, аларда никадәр охшашлык!

Тантаналы кичәдә Татарстан мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина катнашты һәм чыгыш ясады. «Шагыйрьнең туган иленә, сөйгән халкына мәхәббәте шул тиклем дә көчле булган ки, сугышка китүен ул бәхетсезлек итеп түгел, ә бәлки намус эше дип санаган һәм илгә тугрылыгын иҗаты, батырлыгы белән исбатлаган. Ул—бүген дә иң яраткан шагыйрьләребезнең берсе».

Тантаналы кичәдә чыгыш ясап, Фатих Кәримнең кызы Ләйлә ханым әтисе турында истәлек-хатирәләрен яңартты.

Кичәдә шулай ук Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, Ф. Кәримнең якташлары—«Тамаша» журналының баш мөхәррире Наил Гаетбаев, Бишбүләк районы мәдәният йорты методисты Дәрия Исламова; Бишбүләк районы Ает авыл советы җирлеге башлыгы Расил Гыймазетдинов, Ает авылының Фатих Кәрим исемендәге мәктәп директоры Илмир Садыйков, Ает авылындагы Фатих Кәрим музее (шагыйрьнең берданбер музее) җитәкчесе Рәйсә Хафизова чыгыш ясады.

Тантаналы кичә Татарстан сәнгать осталарының чыгышлары белән үрелеп барды.

## ЭЛЕМТӘЛӘРНЕ НЫГЫТЫРГА КИРӘК

Мәскәүдә III Бөтендөнья ватандашлар конгрессы булып узды. Форумга 90 илдән 1000гә якын кеше килгән иде. Конгресста ТР Президенты Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Союзлар Йортының колонналы залында конгрессны ачу тантанасында М. Шәймиев: «Татарстан Конституциясендә ватандашларга, аларның кайда яшәүләренә дә карамастан, һәрьяклап ярдәм күрсәтү аерым маддә белән ныгытылган. Республикада якын араларда әлеге юнәлеш буенча махсус закон да кабул ителәчәк. Әлеге үрнәккә РФнең башка өлкәләре дә иярер дип уйлыйм»,—диде. Ул шулай ук соңгы елларда дөньяның күп кенә илләрендә уздырыла башлаган Сабан туе бәйрәменең дә кешеләрне берләштерүен ассызыклап үтте. Аның фикеренчә, халыкны берләштерүче тагын бер көч ул—спорт. Татарстанда аны үстерү буенча күп эш башкарыла. Татарстан Президенты үзенең чыгышында форумда катнашучыларны Казанга чакырды һәм IV Бөтендөнья ватандашлар конгрессын Татарстан башкаласында үткәрергә тәкъдим итте.

## КАЗАН—РОССИЯНЕҢ СПОРТ БАШКАЛАСЫ

«Советский Спорт» басмасы уздырган тавыш бирү шуны күрсәткән. Бу исемгә Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи, Пенза, Ханты-Мансийск шәһәрләре дә дәгъва кылган булган. Казан «Россия—спорт державасы» форумын уздырачак. 2013 елгы Универсиаданы каршы алучы кала буларак, ул көндәшләрен бик нык артта калдырган. Күпләр хәбәрдар: безнең спорт командалары да даими рәвештә зур җиңүләр яулый. Казан өчен тавыш бирүчеләр моны да исәпкә алмый калмагандыр. Шушы уңайдан Мәскәүдә «Россиянең алтын командасы» премиясе лауреатларын тәбрикләү тантанасы үтте.

## МИРАС САКЛАУГА МОХТАҖ

Тарихи-мәдәни ядкәрләрне саклау һәм файдалану мәсьәләсе даими игътибар сорый. «Эрмитаж-Казан» үзәгендә ачылган халыкара «Мәдәни мирас объектларын бәяләү һәм иминиятләштерү» дигән конференциядә катнашучылар әлеге проблеманың иң мөһим аспектларыннан берсен тикшерде. Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева форумны

ачканда: «Бу конференциянең темасы безнең өчен аеруча кызыклы, чөнки ул тарихи мирасны саклау эшендә яңа мөмкинлекләр ача»,—дип билгеләп үтте.

Конференцияне ачканда шулай ук Росохранкультураның тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне дәүләт саклавы идарәсе башлыгы урынбасары А. Никифиров, Росохранкультураның Идел буе федераль округы буенча идарәсе житәкчесе Д. Мусин да чыгыш ясады. Дәүләт Думасы депутатлары, РФ Мәдәният һәм Икътисади үсеш министрлыклары белгечләренең катнашуы жыенны тагын да абруйлырак итте. Форумда катнашучылар фикеренчә, иң мөһиме—бүген тарихи-мәдәни мирасны саклау белән шөгыльләнүчеләрнең, милекчеләр дә, дәүләт структуралары да тарихи ядкәрләргә зыян китермәячәк, дигән ышанычы нык булырга тиеш.

Конференциядә шулай ук тарихи-мәдәни мирасның аеруча әһәмиятле объектларын мәжбүри иминиятләштерү механизмының федераль закон белән ныгытылу мөмкинлеге, тарихи күчемсез мөлкәтне икътисади бәяләүгә караган гамәли мәсьәләләр тикшерелде.

## ҮЗЕШЧӘННӘРНЕҢ ҺӨНӘРИ БӘЙГЕСЕ

Г. Камал театры бинасында халык театрлары бәйгесен йомгаклау кичәсе үтте.

Республикабызда 1900ләп үзешчән театр яши һәм иҗат итә. Аларның 10ысы халык театры исемен йөртә. Зона ярышларында жиңеп, Казан сәхнәсендә чыгыш ясауга ирешкән 13 театр арасында Гран-прине Кукмара халык театры яулады. Алар куйган «Гөргөри кияүләре»н (Т. Миңнуллин) тамашачы бик жылы кабул итте. II дәрәжәле лауреат дипломына актанышлылар ия булды. Алар күрсәткән «Су юлы» спектаклендә уйнаган Таһир Фатыйхов «Иң яхшы ир-ат роле» бүләгенә дә лаек булды. Рәзилә Галиева исә «Дебют» номинациясендә бүләк алды. III дәрәжәле лауреат дипломы Сарман артистларына бирелде. Алар тамашачыларга «Зәңгәр шәл»не тәкъдим итте. Сарман кызы Гөлназ Сафина «Яшь талант» номинациясендә бүләкләнде. Сәетгалиев исемендәге мәдәният йорты һәвәскәре (Казан) Гөлчәчәк Мулләхмәтова «Иң яхшы хатын-кыз роле» өчен бүләк алды. Халык театрлары бәйгесен оештыруда башлап йөрүче Камил Саттаров та онытылмады бу кичәдә. Ул «Театр сәнгатенең тере легендасы» номинациясендә бүләкләнде. Кичә беренче татар артистлары тормышына багышланган «Гөлҗиһан» спектаклен тамаша кылу белән тәмамланды.

## ЯШЬЛӘРГӘ—ЯШЕЛ ЮЛ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Һөнәр» дип аталган яшь татар режиссурасы фестивале булып узды. Бер атна буе кече сәхнәдә яшь режиссерлар тарафыннан төрле театрларда куелган спектакльләр уйналды. Иң беренче булып Илгиз Зәйниев пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Балакаем» спектакле тәкъдим ителде. Аны Әлмәт Татар дәүләт драма театрында шул театрның актрисасы Нәфисә Исмәгыйлева сәхнәләштергән. Яшь режиссер наркомания фажигасен сәхнәдә ачып күрсәтү кебек авыр эшкә алынган.

Булат Бәдриев Чаллы театрында куйган «Саран» комедиясен (Ж.-Б. Мольер) тамашачы хөкеменә чыгарды.

Минзәлә театрының баш режиссеры Дамир Сәмирханов Т. Миңнуллинның «Мулла» әсәрен алып килгән. Тамашачы да, тәнкыйтьчеләр дә спектакльне яхшы кабул итте.

Альберт Гафаров фестивальдә берьюлы ике спектакль белән катнашты. Туймазы театрында ул И. Зәйниевнең «Люстра»сын сәхнәләштергән. Икенче әсәр—Камал театры сәхнәсендә куелган «Акылдан язган кеше язмалары» (Н. Гоголь). Моноспектакльнең текстын Йолдыз Миңнуллина тәржемә иткән.

Фестиваль кысаларында «Дуслар жыелган жирдә» (Т. Миңнуллин) спектакле тагын бер кат уйналды. Лилия Вәлиева диплом эше итеп куйган бу тамаша үткән сезонда Камал театрының кече сәхнәсендә уйналып килде.

«Һөнәр» фестивален Камал театры артисты Эмиль Талипов куйган «Зөбәйдә—адәм баласы» драмасы (Ш.Хөсәенов) йомгаклады.

Фестивальнең соңгы көнендә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева «Һөнәр»дә катнашкан һәр яшь режиссерга тантаналы рәвештә дипломнар тапшырды, уңышлар теләде. Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев: «Россиядә бүген 12 татар театры эшләп тора. Без аларны профессиональ режиссерлар белән тәэмин итәргә тиешбез. Шуңа күрә яшь татар режиссурасы фестивален даими үткәрергә уйлыйбыз»,—диде.

## «БӘРМӘНЧЕК» ЮЛГА ЧЫГА

Казанда тагын бер дәүләт ансамбле пәйда булды. Ул—керәшеннәрнең «Бәрмәнчек» дәүләт фольклор ансамбле. Шул уңайдан Татар дәүләт филармониясенең концерт залында аны тәкъдим итү кичәсе узды. Ансамбльнең «Бәрмәнчек» дип аталуы очраклы түгел. Ул яз көне шытып чыккан тал песие дигәнне аңлата. Концертны Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев ачып жибәрде. Коллектив тамашачыга төрле төбәкләрдә яшәүче керәшен жырларын, биюләрен һәм туй йолаларын тәкъдим итте.

Коллективны тәбрикләргә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З.Вәлиева килде. Ул иң элек Президент

М. Шәймиевнең сүзләрен искә төшерде. «Телдә, музыкада, гамәли сәнгатьтә ата-бабаларыбызның борынгы традицияләрен саклап калуда без керәшеннәргә бурычлы»,—дигән иде Президент. Республикабызда профессиональ дәрәҗәдә эшли торган сәнгать коллективлары күп. Алар арасында «Бәрмәнчек»—иң төпчеге»,—диде З. Вәлиева. Ул аларга Премьер-министр Р. Миннехановның кул куйган 150 мең сумлык сертификат тапшырды. «Бәрмәнчек»не төрле төбәкләрдән килгән ансамбльләр котлады. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле барысына да сәнгатьнең профессиональ үрнәген күрсәтте.

## ТАТАР ШАГЫЙРЕНӘ—ЧУАШ ПРЕМИЯСЕ

Татарстанның халык шагыйре Ренат Хариска Чуашстанның танылган шагыйре Михаил Сеспель исемендәге халыкара премиясе тапшырылды. Ренат Харис әлеге бүләккә чуаш язучыларының күпсанлы әсәрләрен татар теленә тәрҗемә иткәне өчен лаек булган. Сеспель исемендәге премияне шулай ук шагыйрь, тәрҗемәче Аристарх Дмитриевка да биргәннәр. Яна бүләк ияләре бәйрәм кичәсендә дә катнашты.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Әле генә үтеп киткән 2009 ел ахырында шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республиканың Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Зиннур Мансуровның иҗатына багышланган төрле чаралар булып узды.

25 ноябрьдә шагыйрьнең туган авылы—Мамадыш районы Түбән Ушмы мәдәният йортында язучылар һәм район үзешчәннәре катнашында зур әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары В. Нуриев җитәкчелегендә бертөркем каләм әһелләре, атап әйткәндә, Казаннан—Р. Батулла, Р. Гаташ, И. Иксанова, Р. Зәйдулла, Л. Лерон, Чаллыдан—В. Имамов, Р. Бәшәр, Мамадыштан—Р. Газизов, В. Галиев, В. Гали һ.б.лар катнашты. Иҗат кичәсендә шулай ук җирле үзидарә һәм төрле оешмалар җитәкчеләре, шагыйрьнең сабакташлары һәм туганнары чыгыш ясады. Район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Т. Галимханов бәйрәмдәрга Мамадыш муниципаль районы башлыгы, район Советы рәисе Р. Кәлимуллинның тәбрикләвен ирештерде.

Мамадыш районына сәфәр кылган язучылар Югары Сон, Урта Кирмән авылларында да әдәбият сөючеләр белән очрашты, мәктәпләрдә булып, китапханәләр, туган як музейлары эше белән танышты. Кичәләрдә прозаик һәм шагыйрьләрнең чыгышы район үзешчәннәренең җыр-биюләре белән үрелеп барды.

Мамадышта язучылар делегациясен район башкарма комитеты җитәкчесе А. Иванов каршылады. Аннары әдәбият бәйрәмендә катнашучылар Мамадыш сәнгать мәктәбендә укучылар һәм «Агымсу» әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзалары белән очрашты, шушы ук бинада урнашкан аталы-уллы композиторлар Заһидулла, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннарның музее ядкәрләрен карады. Кунаклар шулай ук никахлашу сараенда һәм мәдрәсәдә дә булды.

***

7 декабрьдә С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында шагыйрь Зиннур Мансуров иҗатына багышланган «Язмышларга өстәп язылганнар» исемле әдәби-музыкаль кичә булды. Анда шагыйрьнең аерым темаларга багышланган шигъри шәлкемнәре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады, шулай ук «Ике еглау» драматик поэмасыннан өзек тәкъдим ителде. Шигъри әсәрләрне тамашачыларга Инсаф Абдулла һәм аның Казан театр училищесындагы шәкертләре,театр артистлары бик тәэсирле итеп ирештерде. Ә җырларны, «Мирас» инструменталь квинтетына кушылып, Р. Сәхабиев һәм аның оныгы Нариман, Р. Галимова, Г. Ибушев, А. Габдинов, Р. Сәйфи, Г. Талипова, А. Нургаянов һ.б.лар башкарды. Биюләрне Татарстан җыр һәм бию ансамбленең хореографик төркеме тәкъдим итте. Ә шагыйрь Зиннур Мансуров, халык хозурына ике тапкыр чыгып, үзенең шигырьләрен укыды.

Иҗат кичәсе барышында бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрыннан Татарстанның халык артистлары Ә. Шакиров белән А. Хафиз, Мамадыш районы мәдәният бүлеге башлыгы И. Хафизов һ.б.лар котлады. Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Айдар Гайнетдинов шагыйрь Зиннур Мансуровка Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиеваның тәбрикләвен тапшырды.

Кичәне Л. Шакирҗан һәм Ф. Җиһанша алып барды.

***

15 декабрьдә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында шагыйрь Зиннур Мансуров иҗатына багышланган очрашу булды. Анда авторның үзе укуында, шулай ук студентлар башкаруында күп кенә шигырьләр яңгырады. Университет үзешчәннәре җырлар да тәкъдим итте. Очрашу вакытында Зиннур Мансуров яшьләргә әдәбият, гыйлем-мәгърифәт һәм мәдәниятнең кеше тормышындагы әһәмияте турында сөйләде, студентларның күпсанлы сорауларына җавап бирде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары В. Нуриев,

кичәдә катнашучыларны сәламләп, татар филологиясе факультетына әдипләребезнең яңа китапларын бүләк итте.

Очрашуны университетның татар әдәбияты кафедрасы мөдире, профессор Ф. Галимуллин алып барды.

### ОЛУГ ҖЫРЧЫНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

9 декабрьдә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында Россия һәм Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, танылган җырчы Зилә Сөнгатуллинаның 60 яшьлек юбилеена багышланган кичә булып узды. «Тормыш, язмыш, мәхәббәт...» дип аталган концертта тамашачы җырчының 36 еллык иҗат юлына сәяхәт кылды, аның башкаруында иң танылган арияләрне, классик композиторларның әсәрләрен тыңлады.

Җырчыны Премьер-министр урынбасары —мәдәният министры Зилә Вәлиева котлады. Ул үзенең котлавыннан соң З. Сөнгатуллинаны «Халыклар дуслыгы» ордены белән бүләкләү турындагы Россия Президенты Д. Медведев Указын укыды.

Юбилярны Санкт-Петербург, Прага, Вильнюс шәһәрләреннән килгән җырчылар тәбрикләде. Кичәдә үзе белән бергә Зилә ханымның шәкертләре дә чыгыш ясады.

«Зилә Сөнгатуллина—безнең иң яраткан, күренекле җырчыларыбызның берсе. Ул бу сәхнәдән дөньякүләм арияләрне генә түгел, атаклы татар композиторларның да классик әсәрләрен югары профессионал дәрәҗәдә башкарды»,—диде мәдәният министры.

### УНБЕР ИЛДӘН ҖЫЕЛДЫЛАР

Төрки халыкларның яшәешенә игътибар елдан-ел арта.

Күптән түгел генә Төркия тел җәмгыяте, «Төрексой» халыкара оешмасы һәм Афйон Кожатепе университеты «Иске төрки тел: Ерак Азиядән Якын Азиягә кадәр» дип исемләнгән I Халыкара фәнни конференция уздырды. Анда 11 ил галимнәре фикер алышты.

Бу олы җыенда Татар төркология мәркәзе башлыгы, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты профессоры Фәрит Хәкимҗанов та катнашты. Россиядән берденбер вәкил булып килгән галим Идел буе төбәге белән бәйле фәнни нотык сөйләде. Ул рун язулы борынгы төрки язмаларны беренчеләрдән булып уку бәхетенә ирешкән Дания галиме В. Томсенга багышланган махсус секциягә җитәкчелек тә итте.

Конференция эше уртак тикшеренүләр алып бару турында килешүләр төзү белән тәгәлләнде.

### ӘФАРИН, НАРИМАН!

Башкалабызның Вахитов районы Кече сәнгать академиясе укучысы Нариман Сәхабиев Мәскәүдә узган «Ретро: XX век голосами детей XXI века» дигән икенче Бөтенроссия балалар җыр фестивалендә Гран-при яулап кайтты. «Академик вокал» номинациясендә чыгыш ясаган җырчыны жюри рәисе—СССРның халык артисты Иосиф Кобзон югары бәяләде. Шулай ук Нариманның укытучысы Венера Федотованың тырыш хезмәте дә искә алынды. Быелгы фестиваль күренекле җырчы Мөслим Могамаев һәм Әниләр көненә багышланган иде.

### «ТАТАР ЕГЕТЕ—2009»

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында батыр, зирәк, тапкыр, кыю егетләрнең «иң-иң»нәре бергә җыелды. 9-11 нче сыйныф укучылары арасында үз районнарында беренчелекне яулаган егетләр шәһәр күләмендәге «Татар егете—2009» бәйгесендә көч сынашты. Егетләр җыр һәм биюгә осталыкларын күрсәтте, тарих, әдәбиятка кагылышлы сорауларга җавап бирде, татар халкының гореф-гадәтләре белән таныштырды. Кыскасы, бәйгене тамаша кылучылар «егет кешегә—житмеш төрле һөнәр дә аз» икәнлегенә тагын бер кат инандылар. Ә «Татар егете—2009» исемен Совет районының 125нче мәктәп укучысы Илфат Бикмәтов яулады.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Кышкы манзара.

*Дүртенче биттә:* язучы-публицист **Илшат Вәлиулла**.

# Яңа китаплар




**Рафаэль Мостафин.** Репрессияләнгән татар әдипләре.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2009.—175 бит. Тиражы—2000 данә.

Хәзерге хәбәрдарлык чорында шәхес культы корбаннары турында тарихи дөреслекне торгызу, нахакка гаепләнгән язучыларны халыкка кайтару, аларның исемнәренә кайчандыр ягылган кара тапларны юып төшерү—җәмгыятебез алдындагы зур бурычларның берсе. Тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Рафаэль Мостафинның әлеге китабы бу юнәлештә бер адым булып тора.




**Фоат Садриев.** Авылдан хатлар (Яшәешебезгә тәнкыйди бер караш). Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2009.—192 бит. Тиражы—2000 данә.

Бу хатлар 2009 елда алты ай буе «Ватаным Татарстан» газетасының җомга сәхифәләрендә дөнья күрде. Бүген авылда бара торган тискәре процессларга ничек чик куярга? Ф. Садриев әнә шул проблеманы чишү юнәлешендә фикер йөртә, чарасызлыктан өзгәләнә, дөреслеккә, гаделлеккә чакыра.

Китапка кереш сүзне Т. Миңнуллин язган.



Илшат Вәлиулла

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)